Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

А.М. Гайнетдинов

Әтнә районы эпиграфик истәлекләре

Казан – 2017

УДК 930.27:94(470.41)
ББК 63.2(2Рос.Тат)+63.3(2Рос.Тат)
Г 17

«Татарстан Республикасы торак пунктларының тарихы» сериясе

Фәнни мөхәррире:
тарих фәннәре докторы, ТР ФА академигы *Р.Р. Салихов*

Рецензентлары:
филология фәннәре докторы, профессор *М.И. Әхмәтҗанов*
тарих фәннәре кандидаты *И.Ж. Фәйзрахманов*

Гайнетдинов А.М. **Әтнә районы эпиграфик истәлекләре.** – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. – 556 б. + 12 б. төсле ябышт.

Китапта Татарстан Республикасы Әтнә районы территориясендә хәзерге көнгә хәтле сакланып калган гарәп язулы татар эпиграфик истәлекләренең текстлары, аларның хәзерге телгә күчермәләре китерелде. Урта гасырлардан алып 1939 елга хәтле куелган гарәп язулы 1567 кабер ташы исәпкә алынды. Шулай ук кайбер кабер ияләре хакында кыскача мәгълүмат бирелде һәм фәнгә билгеле булган шәҗәрәләре күрсәтелде.

Хезмәт татар төбәк тарихын, тарихи-мәдәни мирасыбызны өйрәнүче галимнәргә, мөгаллимнәргә, аспирантларга, гомумән, татар халкы тарихы белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-275-4

© Гайнетдинов А.М., 2017
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017

КЕРЕШ

Халкыбыздан безгә мирас буларак гаять күп сандагы тарихи-мәдәни истәлекләр сакланып калган, шул исәптән гарәп графикасында язылган борынгы кабер ташлары да бихисап күп. Алар халкыбыз тарихын, мәдәниятен, телен өйрәнүдә, һичшиксез, әһәмиятле роль уйный.

Каберләргә таш кую традициясе безгә борынгы төркиләрдән үк килә. 731, 734 елларда ук Күлтәгин, Билге каган кебек Төрки каганат җитәкчеләре истәлегенә рун хәрефләре белән язылган ташбилгеләр куелуы мәгълүм. Шулай ук төрки халыкларда каберләр өстенә балбаллар (кеше рәвешендә ясалган таш сын) кую гадәте таралган булган, алар да, үзенә күрә, кабер ташы функциясен үтәгән, җиңелгән дошманнарны рухсыз итү символы буларак кулланылган[1]. Төркиләр ислам динен кабул иткәннән соң, руник язулы ташлар һәм балбаллар гарәп телендәге дини гыйбарәләр, Коръән аятьләре, хәдисләр язылган ташбилгеләргә алыштырылган. Гарәп графикасындагы беренче ташъязма истәлекләр 1161–1162 елларда ук төрки кабиләләр төзегән Караханилар дәүләтендә куела башлаган[2].

Тарихтан билгеле булганча, Болгар шәһәре Алтын Урда тарафыннан яулап алынганчы, болгарларда, ягъни безнең җирлектә, бөтенләй каберләр өстенә язулы ташлар кую гадәте булмаган. Татар галимнәре М.И. Әхмәтҗанов, Р.Ф. Фәхретдинов исбатлап язганча, бу традиция аларга Алтын Урда цивилизациясе аша кергән[3]. Шул чордан башлап безнең җирлектә кабер ташларына язулар төшерү гадәте киң таралып, бүгенге көнгә хәтле дәвам итә. Ортодоксаль ислам дине кабер өстенә нинди дә булса таш куюга, корылма коруга тискәре караса да[4], безнең халык VIII гасырдан ук килгән гореф-гадәтләрен югалтмаган, саклаган, буыннан-буынга тапшырып килгән.

Соңгы елларда тарихи-мәдәни истәлекләргә игътибар көчәеп китте һәм аларны өйрәнү дә бик актуаль юнәлешкә әверелде. Шуңа күрә татарлар яшәгән һәр төбәк җентекләп өйрәнелергә тиеш, әби-бабаларыбыздан сакланып калган бер генә эпиграфик ядкәрне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый, аларның һәрберсен түкми-чәчми халыкка кайтаруда җиң сызганып эшләү таләп ителә. Бу вазыйфаны һәр фидакарь эпиграфист кулыннан килгәнчә үтәргә тырышкан һәм эстафетаны бер-берсенә тапшырып килгәннәр.

Әтнә районы борынгы эпитафияләренең берникадәр өлешен кайбер галимнәр инде өйрәнергә өлгергәннәр һәм алар, нигездә, XIII–XVIII гасыр ташъязмаларына гына зур игътибар биреп, күбесен фәнни әйләнешкә кертеп җибәргәннәр. Бу эштә хәтта башка милләт вәкилләре дә читтә калмаган, кулларыннан килгәнчә өйрәнергә тырышканнар.

Бөек татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) хәзерге Әтнә районы авыллары белән бәйле кайбер борынгы кабер ташларын ачыклаган һәм үзенең мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтендә аларның тулы текстларын теркәп калдырган[5].

1927–1928 елларда күренекле галим Гали Рәхим (1892–1943) Әтнә районының кайбер авылларындагы борынгы кабер ташларын өйрәнгән. Нигездә, аны XVI–XVII гасырларга караган ташлар гына кызыксындырган. Ул Казан университеты каршындагы Татарстанны өйрәнү җәмгыятендә һәм Тарих, этнография, археология җәмгыятендә фәнни эш алып барган, берничә эпиграфик экспедициядә катнашып, шактый күп

---

[1] Әхмәтҗанов М.И. Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казань, 2011. – Б. 5.

[2] Джумагулов Ч. Эпиграфика Киргизии. Выпуск 3 / Ч. Джумагулов. – Фрунзе: Изд-во «Илим», 1987. – С. 60.

[3] Кара: Әхмәтҗанов М.И. XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казань, 2011. – Б. 9; Фахрутдинов Р. Золотоордынский Булгар / Р. Фахрутдинов // Татарская археология. – 2006. – №1–2. – С. 71.

[4] Поляков С.П., Черемных А.И. Погребальные сооружения населения долины Заревшана / С.П. Поляков, А.И. Черемных // Домусульманские верования и обряды Средней Азии. – М.: Наука, 1977. – С. 277; Мухаметшин Д.Г. Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия «Археология евразийских степей» / Д.Г. Мухаметшин. – Выпуск 6. – Казань: Институт истории АН РТ, 2008. – С. 18.

[5] Кара: Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 416.

ташъязма истәлекләрне өйрәнгән. Г. Рәхим Иске Мәңгәр авылында 15, Югары Сәрдәдә – 10, Иске Өҗемдә – 9, Кече Әтнәдә – 6 борынгы ташбилге тапкан һәм аларны, җентекләп анализлап, фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән[6]. Моннан тыш Арча һәм Биектау районнарына кергән авылларда да йөреп, барлыгы алтмышка якын ташъязма истәлек ачыклаган[7]. Инде ул заманнарда ук ташларның сакланышы куандырырлык булмаган, текстларының шактый өлеше күренмәгән. Г. Рәхимнең эпиграфик эшчәнлеге шунысы белән игътибарга лаеклы: ул Ш. Мәржани тәкъдим иткән кайбер таш текстларында хаталар табып, аларның дөрес укылышын тәкъдим иткән, әмма шул ук вакытта үзе дә кайбер ялгышлыклар җибәргән.

XX гасыр урталарында төрле галимнәр Казан арты төбәгендә археологик истәлекләр эзләгән һәм шул исәптән борынгы кабер ташларына да игътибар иткәннәр. Табылган материаллар нигезендә археологик карталар, альбомнар төзелгән.

Әтнә районында иң борынгы ташбилгеләр XV–XVI гасырларга караган. Атаклы галим Һ. Йосыпов (1914–1968) Түбән Бәрәскә авылында XV йөзгә кагылышлы борынгы кабер ташын тапкан[8], XVI гасырга карый торганнарын шул ук Түбән Бәрәскә, Иске Өҗем, Иске Мәңгәр, Кече Әтнә, Олы Бәрәзә, Югары Сәрдә салаларында, XVII йөз белән билгеләнгәннәрен шул ук Иске Өҗем, Олы Мәңгәр (Иске Мәңгәр) зиратларында ачыклаган[9]. Ул өйрәнгән Түбән Бәрәскә, Югары Бәрәскә, Олы Мәңгәр, Иске Өҗем зиратларындагы 6 эпиграфик истәлекләрнең текстлары «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику» китабында, шулай ук Югары Сәрдә, Олы Мәңгәр, Кече Әтнә, Югары Бәрәскә, Түбән Бәрәскә, Олы Бәрәзә авылларындагы 16 иң борынгы ташбилгеләрнең укылышы «Татарская археология» журналында басылып чыкты[10].

Һ. Йосыпов тапкан кабер ташларын мәшһүр татар галиме Марсель Әхмәтҗанов та күпсанлы эпиграфик һәм археографик экспедицияләр вакытында җентекләп өйрәнгән[11]. Гомумән, ул Әтнә районы эпиграфикасын өйрәнүгә зур өлеш керткән: 2000 елда басылып чыккан «Олы Мәңгәр авылы тарихы» китабында ул үзе тарафыннан табылган ташъязма истәлекләрнең укылышын биргән, анализлаган һәм кызыклы күзәтүләр ясаган[12]. Шулай ук галимнең «XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре» исемле кыйммәтле хезмәтендә дә Әтнә төбәге белән бәйле булган берничә борынгы ташъязма истәлек китерелгән[13].

Районның иң борынгы ташбилгеләрен сәнгати бизәлеше ягыннан галим Фоад Вәлиев өйрәнгәнлеген дә билгеләп үтәргә мөмкин. Әтнә төбәгендәге эпиграфик истәлекләрне ачыклап, фәнни яктан тикшеренүләр алып баручылар югарыда санап киткән шәхесләр белән генә чикләнми, әлбәттә, ләкин башкалар бу дәрәҗәдә үк зур өлеш кертмәгәннәр.

Әтнә районының борынгы кабер ташлары әле һаман фәнни-практик яктан тулысынча өйрәнелмәгәнгә, андагы татар авылларының зиратларында һәм аерым каберлекләрендә хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен 2016 елның яз һәм көз айларында без берничә фәнни экспедициягә чыктык. Бу авыр эштә Ш. Мәржани исемендәге Тарих институтының фәнни хезмәткәре Сайрус Хәмидуллин бик нык ярдәм итте. Шул рәвешле, 1939 елга хәтле вафат булган кешеләргә куелган гарәп язулы кабер ташларын эзләп табып, фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Эшебезнең нәтиҗәсе игътибарыгызга тәкъдим ителә торган әлеге китапта тулаем чагылды. Барлыгы 48 авыл (юкка чыкканнарын да кертеп) зиратында 1567 борынгы кабер ташы табылды. Бу бер район өчен гаять зур сан, чөнки Татарстанның башка районнарында күпкә кимрәк ташбилге табылган. Мәсәлән, Әлмәт районында гарәп

---

[6] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / Төз. Р. Мәрданов, И. Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 214–274.

[7] Шунда ук. – Б. 214–274.

[8] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / Г.В. Юсупов. – М.-Л.: Изд-во Академии наук СССР, 1960. – С. 23.

[9] Шунда ук. – С. 25–27.

[10] Юсупов Г.В. Эпиграфические памятники Атнинского района / Автор введения и примеч. М. Ахметзянова. – Татарская археология. – 2005. – №1–2 (14–15). – С. 74–83.

[11] Шунда ук. – С. 85–91.

[12] Әхмәтҗанов. Олы Мәңгәр авылы тарихы / М. Әхмәтҗанов – Казан: «Идел-Пресс», 2000. – Б. 26–28.

[13] Әхмәтҗанов М.И. XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казань, 2011. – Б. 52, 65–66, 81–83.

язулы 53[14], Әгерҗе районында – 230[15], Кукмара районында – 305[16], Мамадыш районында – 342[17], Арча районында – 1288[18].

Әтнә районының Җилгелде һәм кайбер юкка чыккан авылларда бөтенләй бер борынгы кабер ташы да табылмады, ә кайбер салаларда исә аларның саны йөздән артып китте. Әгәр дә кайсыдыр таш безнең игътибардан читтә калган икән, димәк, ул таш инде юкка чыккан яки таба алмаслык җирдә яткан булырга мөмкин. Без инде, көчебездән килгәнчә, бөтенесен дә эзләп табарга, берсен дә калдырмаска тырыштык. Эпиграфик истәлекләрне ачыклау һәм өйрәнү эшенең никадәр авыр һәм читен икәнлеген моны фәкать үз җилкәсендә татыган эпиграфистлар гына белә. Һәр эпиграфист галим диярлек кабер ташларын өйрәнү күп көч, тырышлык, чыдамлык сорый торган эш икәнлеген язып калдырганнар. Шуңа күрә бүгенге көндә зиратларда йөреп, татар эпиграфикасын ныклап өйрәнүчеләрне санап чыгарга бер кулдагы бармаклар да җитәдер.

Иң күп ташъязма истәлек ачыкланган авыл Олы Әтнә булды (ике зиратында барлыгы 200 таш). Икенче урында Олы Мәңгәр саласы: 85 ташбилге табылды. Иске Өҗем авылында 82 (шул исәптән икесе авыл басуында) эпиграфик истәлек сакланып калганлыгын ачыкладык, димәк, әлеге сала ташлар саны буенча өченче урында саналырга хаклы. Югары Бәрәскә авылы хәзерге вакытта Түбән Бәрәскә составына кереп, атамасын югалткан, шул сәбәпле, әгәр дә аларны бергә кушып санасак (Югары Бәрәскәдә – 47, Түбән Бәрәскәнең ике зиратында – 47 таш), барлыгы 94 борынгы кабер ташы сакланган булып чыга. Яңа Өҗем, Кышлау, Мамыш, Олы Бәрәзә, Күлле-Киме, Күңгәр, Күәм, Иске Йогып авылларында да шактый күп эпиграфик истәлек табылды. Нигездә, аларның күплеге теге яки бу торак пункт халкының матди һәм рухи яктан нык үсеш алганлыгын күрсәтә. Гадәттә, ташбилгеләрне бай югары катлау вәкилләре куйган, чөнки аларны эшләтү бик кыйммәткә төшкән. Элекке заманнарда бер таш яздыру бер ат, югары зәвык белән ясалганы берничә ат бәясенә тиң булган[19]. Шуңа күрә гади халыкның фәкать тамгасы төшерелгән кечкенә агач багана яки эшкәртелмәгән примитив бер таш кына куярга хәле җиткән.

Без ачыклый алган иң борынгы кабер ташы Казан ханлыгы чорына туры килә, төгәлрәк әйткәндә, 1476–1477 елларга карый. Бу эпиграфик истәлек Югары Сәрдә авылының борынгы зиратында табылды. Иске Мәңгәр саласында исә 1495 елга караган эпиграфик истәлек сакланган. Шул ук Югары Сәрдә зиратында 1499–1500 елларга караган кабер ташын табып өйрәнү дә безнең өчен зур ачыш булды. Ябынчы саласы янында 1503 елда бакыйлыкка күчкән Солтан улы Ябынчы ташбилгесе ачыкланды. Иске Мәңгәрдә 1504 елда вафат

[14] Әхмәтҗанов М.И. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казань, 2000. – Б. 13–66, 143.

[15] Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре / Р.Ф. Мәрданов, И.Г. Һадиев. – Казан: «Тамга» нәшр., 2008. – Б. 5.

[16] Һадиев И.Г., Мәрданов Р.Ф. Кукмара төбәгенең ташъязма истәлекләре / И.Г. Һадиев, Р.Ф. Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2014. – Б. 5. Кукмара районына оештырылган эпиграфик экспедицияләребезнең нәтиҗәләре хакында мәкаләбез түбәндәге газета-журналларда басылып чыкты: Гайнетдинов А.М. Кукмара төбәге эпиграфик истәлекләре / А.М. Гайнетдинов // Түгәрәк уен. – 2016. – №4. – Б. 62–64; Гайнетдинов А.М. Кукмара төбәгенең кыйммәтле эпиграфик истәлекләре / А. Гайнетдинов // Хезмәт даны. – 2017. – 18 октябрь (№77). – Б. 3.

[17] Һадиев И.Г., Мәрданов Р.Ф. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре / И.Г. Һадиев, Р.Ф. Мәрданов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – Б. 5. Мамадыш районына оештырылган археографик экспедицияләребезнең нәтиҗәләре хакында без төрле конференцияләрдә чыгыш ясап, алар түбәндәге фәнни җыентыкларда һәм журналларда басылып чыкты: Гайнетдинов А.М. Түбән Ушмы авылы эпиграфик язмалары / А.М. Гайнетдинов // Традиционная культура народов Поволжья: материалы Всероссийской научно-практической конференции (11–13 февраля 2014 г.). – Казань: Ихлас, 2014. – Б. 45–51; Гайнетдинов А.М. Түбән Ушма эпиграфикасы / А.М. Гайнетдинов // Татарская фольклористика. Исследования молодых. Вып. 5. – Казань: Ихлас, 2014. – Б. 8–15; Гайнетдинов А.М. Мамадыш районы борынгы эпитафияләре / А.М. Гайнетдинов // Татарская фольклористика. Исследования молодых. Вып. 5. – Казань: Ихлас, 2014. – Б. 105–119; Гайнетдинов А.М. Ташка язу осталары бертуган Солтанбәковлар / А.М. Гайнетдинов // Эхо веков – Гасырлар авазы. – 2015. – №3–4. – Б. 254–258; Гайнетдинов А.М. Мамадыш районының борынгы ташъязмалары / А.М. Гайнетдинов // Түгәрәк уен. – 2016. – №1. – Б. 54–57.

[18] Гайнетдинов А.М. Арча районы эпиграфик истәлекләре / А.М. Гайнетдинов. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2016. – Б. 4.

[19] Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр / В.М. Усманов. – Уфа: ДизайнПолиграфСервис, 2005. – Б. 56.

булган Шәех-Хәсән хатынына куелган кабер ташы да бик борынгы, аны заманында эпиграфист галим Г. Рәхим ачыклаган булган инде[20], шулай да үз күзләребез белән аны күреп, текстын укып, сакланыш дәрәҗәсен тикшереп кайту безнең өчен кызыклы һәм файдалы булды. Кече Әтнәнең борынгы зиратында табылган таш та безнең тарафтан укылып, Шәех Булад Сәйед Гали Мәүля улына куелганлыгы һәм һиҗри 945 елга (безнең ел исәбе белән 1507–1508 еллар) нисбәт ителүе мәгълүм булды. Иске Өҗем зиратында 1513 елга нисбәтле эпиграфик истәлек сакланган. Чирүче шәех Нәҗем улына куелган бу ташбилгене беренчеләрдән булып Г. Рәхим ачыклаган иде[21], шулай да, аннан аермалы буларак, без ташның датасын төгәлрәк ачыклый алдык. Болардан тыш, тагын Иске Мәңгәр саласында 1516 елга нисбәтле таш сакланган. Гомумән, XV–XVIII гасырга караган җиде дистәгә якын эпиграфик истәлек яки аларның фрагментлары бүгенге көнгә хәтле сакланып калган. Бәхеткә каршы, кайберләренең текстлары әле табигатьнең кырыс шартларына бирешмәгәннәр, даталарын һәм исемнәрен, авырлык белән булса да, ачыкларга мөмкин иде.

Әйткәнебезчә, без 1939 елга хәтле вафат булган кешеләргә куелган гарәп язулы кабер ташларын исәпкә алып, барысын да диярлек әлеге хезмәтебезгә керттек. 1940 елдан соң куелганнарын инде өйрәнмәдек, чөнки, беренчедән, таш чагыштырмача яңарак булган саен аның тарихи әһәмияте кими, икенчедән, барысын да бу китапка кертү мөмкин эш түгел. Әтнә районында гарәп графикасында язылган ташлар хәтта XX йөзнең 60 нчы елларында да очрый, хәзерге көндә дә гарәпчә язылган кабер ташы кую очраклары юк түгел.

Халык әйтүе буенча, Әтнә районындагы күп авыл зиратларында уеп эшләнгән бертөрле типтагы XIX–XX гасыр ташбилгеләре, нигездә, хәзерге Мари Эл Республикасының Бәрәңге төбәгендә урнашкан бер таш карьерыннан алынганнар. Аларның эшкәртү осталыгын Бәрәңге ягына Ташкичү авылыннан күчеп килгән Насретдин һәм Борһанетдин нәселләре алып килгәннәр[22]. Шулай ук кабер ташларын ясау өчен материал хәзерге Мари Эл Республикасының Яңа Торъял авылындагы таш чыгару карьерыннан китерелгәнлеген ачыкладык. Олырак яшьтәге кешеләр сөйләвенчә, кайбер ташбилгеләрне махсус заказ белән Оренбург якларыннан, Урта Азиядән алып кайтып, каберләр өстенә урнаштырганнар.

Ташка язу, бизәк төшерү процессы гаять катлаулы булган, остадан күп көч, тырышлык, сабырлык, сәләт сораган. Материал, гадәттә, җир астыннан чыгарылгач та, дымлы көенчә булганда җиңел эшкәртелгәнгә күрә, аңа язу өчен яңа чыккан ташларны сайлаганнар. Ә инде кибеп каткач, анда язу төшерү, әлбәттә, авыррак булган. Аларны «еш очракта ике метр озынлыктагы зур пычкы белән дүрткел формада кискәннәр, балта белән эшкәртканнәр, каләм белән язганнар һәм махсус өтергеләр ярдәмендә уеп бизәк төшергәннәр. Әгәр дә эш барышында таш кибеп катыланып китсә, язарга уңайсыз була башласа, аны берникадәр вакыт су эченә салып тоткаллар яисә өстенә су сибеп торганнар һәм шундый рәвештә ташны йомшартып әүвәлге хәленә кайтарганнар»[23].

Эш барышында без 19 ташка язу остасының исемнәрен ачыкладык: Колмөхәммәд Килмөхәммәд улы, мулла Сәлахеддин Казаклари, мөәзин Лотфулла (Казак Үртәме авылыннан), мөәзин Фәтхелкадыйр (Мүлмә авылыннан), Фәтхелкадыйр Кәлмитев Казани, Фәләхеддин Шәмседдин улы Кенәбаши, Габделбари Ашыти, Әхмәд Бәрәңгеви, Сибгатулла Гобәйдулла улы, Әхмәдхәсән, Фәтхулла Галиәкбәр улы, мөәзин Миңлебай, мулла Касыйм Рәхмәти, мулла Габделмәннаф, Амай Мөхәммәдгариф улы, Габдулла Габделҗаббар улы, Габделҗаббар, Гариф, Мөхәммәднәҗиб Камаледдин улы. Аларның кайберләре ташбилгеләрне бик зәвыклы, матур, купшы, бай орнаментлы итеп эшләгән һәм каллиграфик стиль белән язган, кайберләре гади, примитив рәвештә язган, тик шулай да һәрберсенең эшләре игътибарга лаек.

[20] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / Төз. Р. Мәрданов, И. Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 262–263.

[21] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / Төз. Р. Мәрданов, И. Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 267.

[22] Әхмәтҗанов М.И. Мари Эл Республикасы, Бәрәңге төбәге татар ташбилгеләре / М.И. Әхмәтҗанов // Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения: Материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.). – Казань, 2011. – Б. 145.

[23] Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр / В.М. Усманов. – Уфа: ДизайнПолиграфСервис, 2005. – Б. 55–56.

Шулай ук тышкы сыйфатлары һәм текстлары белән кайсыдыр ташка язу остасы эшләре икәненә ишарә итеп торучы ташъязма истәлекләр дә бар, тик аларда язучы-оста үзенең исемен теркәп калдырмаганга, текстын нәкъ менә шул кеше язган, дип төгәл әйтеп булмый. Бер үк калып һәм стиль белән эшләүче һәм бер дәвердә яшәүче каллиграфлар да юк түгел. Казан арты төбәгендә байтак ташка язу осталары яшәп, үзләреннән соң бик күп югары дәрәҗәдә эшләнгән «шедеврлар» калдырган. Кызганычка каршы, күпләре үзләренең эшләрендә исемнәрен теркәп куюны кирәк дип санамаган. Беренчедән, татар халкы электән үк тыйнак булган һәм эшләре белән мактануны сөймәгән, икенчедән, кабер ташына вафат булучы белән берәттән, үз исемеңне дә язу, төрле ышанулар, хорафатлар белән бәйле булып, ничектер, үз үлемеңне дә чакыру кебек тоелгандыр, күрәсең.

Эпитафик текстларны бирүгә килгәндә, шуны әйтәсе килә, ни өчендер галимнәр арасында гарәп җөмләләрендәге саф гарәп сүзләрен татарча әйтелешкә якынайтып уку таралаган. Мәсәлән, «ү» хәрефе урынына «ө» куялар, ләкин гарәп телендә «ө» авазы бөтенләй юк бит. Болай язу татар телендәге җөмләләр эчендә булган алынма гарәп сүзләренә генә кагылырга мөмкин. Без башка принцип белән эш итеп, ташлардагы гарәп җөмләләрен тәҗвид кагыйдәләренә туры китерелгән формада язарга булдык. Бу бары тик сузык хәрефләрне (мәдләрне) биргәндә генә шулай эшләнде. Мәсәлән, «зәәъикатүн» сүзендә «зәл» хәрефеннән соң «әлиф» тора, шуны белдерер өчен ике «ә» куелды. Әгәр дә шуны белдерер өчен «з» хәрефеннән соң «а» хәрефе куйсак, дөрес булмый, чөнки «з» хәрефе бу очракта нечкә аваз (гарәп телендә «з»ның калын әйтелә торганы да бар) һәм нечкә әйтелергә тиеш. Шулай ук гарәпчә «дөнья» сүзен «дүнйәә» дип бирдек, чөнки «йә» хәрефе гарәпләрдә нечкә әйтелә, ә ике «ә» хәрефен кую «й»дан соң «әлиф» килгәнен белдертә. Шуның кебек үк тартык хәрефләрдән соң гарәп алфавитындагы «йә» хәрефе торса, ике «и» (калын әйтелгәндә «ый») хәрефе, «уау» хәрефе килсә ике «ү» («у») куйдык. Гарәп теле фонетикасын бозмас өчен болай эшләү дөресрәк һәм отышлырак, дип уйлыйбыз, чөнки ташлардагы язмаларның күбесе гарәп телендә язылган: Коръән аятьләре, хәдисләр, шигырьләр, гыйбарәләр, мәкальәйтемнәр һ.б. Коръәнгә килгәндә, ул, ислам дине буенча, бары тик тәҗвид кагыйдәләре буенча гына укылырга тиеш, шуңа күрә аятьләрне тулысынча шуңа нигезләнеп яздык. Коръәннән кала башка гарәп җөмләләрендә, әйткәнебезчә, «мәд» һәм шулай ук «васыл» (сүзләрнең үзара тоташуы, кушылуы, мәсәлән, «каблә әлмәүүт» урынына «кабләл-мәүүт» һ.б.) кагыйдәләрен кулландык.

Китабыбызда китерелгән ташбилгеләрнең татар телендәге текстларын да хәзерге заман кешесенә аңлавы кыен, чөнки бик күп гарәп-фарсы алынмалары, борынгы төрки сүзләр, архаизмнар һ.б. белән чуарланган. Шуңа күрә халык укысын, аңласын өчен һәр таш текстының хәзерге татар теленә күчермәсе дә бирелде, шактый күп очраган гарәп-фарсы телендәге җөмләләр һәм сүзләр тәрҗемә ителде. Шунысын искәртәбез: борынгы эпитафик текстны хәзерге татар теленә күчергәндә күп очракта юллардагы сүзләр урыннары белән алмашына, шуңа күрә алар тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Мәсәлән, гарәп телендәге җөмләдә фигыль башка сүз төркемнәреннән алда, ә татар телендә ул һәрвакыт артка куела, шул сәбәпле, юлдан юлга тәрҗемә итеп булмый. Иске татар телендә, гарәп теленнән калькалаштыру аркасында, фигыльне җөмлә башына кую очраклары еш күзәтелә, андый очракларда да (тик шигъри юлларга бу кагылмый, чөнки рифмага зыян килүе бар) фигыльне җөмлә ахырына куеп, хәзерге татар теленә күчердек.

Кайбер кабер ияләренең фәнгә билгеле булган шәҗәрәләре бирелде, атаклы шәхесләр хакында кыскача мәгълүмат язылды, һиҗри (мөселман) календаренә нигезләнеп бирелгән даталар милади (европача) ел исәбенә күчерелде. Шунысы да бар: ташка язу остасы параллель рәвештә һиҗри һәм милади даталарын язса да, һәрвакыт монда төгәллек булмаган, шуңа күрә бу ике календарь арасында берничә елга, айга яисә көнгә аерма күзәтелергә мөмкин.

Кызганычка каршы, Әтнә районында табылган һәрбер эпиграфик истәлекнең фотосурәтен китабыбызда бирү мөмкинлеге юк иде. Бу инде хезмәтебезнең артык күләмле һәм финанс мөмкинлекләребезнең чикләнгән булуы белән аңлатыла. Шуңа күрә бик борынгы ташбилгеләрнең һәм кайбер мәртәбәле шәхесләргә куелган ташларның фоторәсемнәре генә китап ахырында китерелде.

Ташъязма истәлекләрнең үлчәмнәре фәндә эпиграфика белгечләре тарафыннан төрлечә бирелә: кайберәүләр башта буен, аннары киңлеген, соңыннан калынлыгын, ә кемнәрдер исә, киресенчә, башта калынлыгын, аннары киңлеген, соңыннан буен күрсәтеп язалар. Без үлчәмнәрне беренче вариантагы тәртиптә бирергә булдык. Мәсәлән, 100х40х10 саннары язылган булса, ташның буе – 100 см, киңлеге – 40 см, калынлыгы – 10 см дигәнне аңлата. Шулай ук кайбер ташбилгеләр махсус нигез өстенә утыртылган, андый очракта гомуми буе җәяләр эчендә күрсәтелде.

Эш барышында без ташъязмалар аша бик күп атаклы шәхесләр, изгеләр, дин әһелләре, мөгаллимнәр, иганәчеләр, байлык һәм кодрәт ияләре каберләрен табуга иреште к һәм әлеге хезмәтебездә, фәндә беренче мәртәбә буларак, текстларының тулы укылышын биреп, фәнни әйләнешкә керттек. Шушы китапны укыганнан соң байтак кеше үзләренең әби-бабаларының каберләрен табарлар, аларны зиярәт кылып, барысы өчен догалар кылырлар, ташларын төзәтеп, зиратларны җыештырып кайтырлар, дип ышанабыз. Тик шунысын онытмаска кирәк: кабер ияләрен изгеләштереп, алардан нәрсәдер сорау, ялвару, бәрәкәт эзләү, каберләре янында корбаннар чалу, табыну урыны ясау – гөнаһлы гамәлләр. Бу турыда кисәткән иң олуг дин галимнәребезнең берсе Ризаэддин Фәхреддиннең түбәндәге сүзләрен китерергә мөмкин: «Зиярәт кылган вакытта мәет һәм мәетләр өчен дога кылу да тиешле эш. Рәсүлүллаһ һәм сәхабәләре каберлекләрдә мәетләр өчен догалар кылалар иде. Әмма үлекләрдән ярдәм сорау, аларга сыену, алардан хәҗәт сорау өчен каберлекләргә бару дөрес түгел, бәлки, ислам шәригатендә тыелган бер эштер»[24]. Шулай ук безнең бөек дин галимебез Галимҗан Барудиның сүзләрен дә китерү артык булмас: «Нәтиҗә: зиярәттән беренче максат – үлемне искә төшерү, моның белән үзеңне төзәтеп, ахирәткә әзерләнү. Үлемне бервакытта да истән чыгару дөрес булмаса да, дөнья шөгыльләре сәбәпле, күбесенчә үлемгә игътибар ителми. Каберләргә зиярәт исә бу ваемсызлыкның бетүенә, үлем искә төшүгә сәбәп була. Сөннәт булган зиярәт – бу рәвештәге зиярәт. Башка рәвештәге зиярәт, мәсәлән, «әүлия каберләре» дип билгеле булган каберләргә сәдакалар бирү (Шәһри Болгар, Хуҗалар тавы ише зиратларына барып, корбаннар чалу кебек), корбаннар чалу, алардан ярдәм сорау, хаҗәтләр сорау – мондый зиярәтләр сөннәткә каршы, бәлки кабәхәт бидгать һәм бер төр мәҗүсилек»[25].

Эпиграфик истәлекләрне ачыклау, өйрәнү эшен башкарып чыгуда безгә ярдәмнәре тигән кешеләр шактый күп булды. Беренче чиратта, Әтнә муниципаль районы башлыгы Г.Г. Хәкимовка, район Советы Аппараты җитәкчесе Г.Р. Галәветдиновага, авыл җирлекләренең башлыкларына олы рәхмәтебезне белдерәбез. Шулай ук рәхмәт сүзләре белән Әтнә районында яшәүче Наил хәзрәт Сәгъдиев, Алмаз Батталов, Җәүдәт Мәгъсүмов һәм Фәрит Закировларны аерым билгеләп үтәсе килә, чөнки алар, әлеге эшебезнең милләтебез өчен кыйммәтен аңлап, кулларыннан килгәнчә булышырга тырыштылар. Бу китапны әзерләүдә ярдәм иткәннәре өчен мәшһүр галим Р.Р. Салихов, гарәп теле белгече Р.Б. Бикбаев, тарихчылар С.Р. Хәмидуллин һәм Х.З. Баһаветдиноваларга рәхмәтебезне җиткерәбез.

Ахырдан әйтәсе килгән сүзебез шул: ташъязма истәлекләребезне кулдан килгәнчә саклап калырга тырышыйк, ягъни үлгәннәрнең каберен белик, борынгы кабер ташларының кадерен белик!

[24] Фәхреддин Р. Җәвамигыль-кәлим шәрехе / Р. Фәхреддин. – Оренбург, 1916. – Б. 224.

[25] Баруди Г. Хәдис: Гыйлемсез галим, төш мәсьәләсе, зиярәте кобур хәдисе. Хатыннарның кабергә зиярәтләре. Әдәбе зиярәт / Г. Баруди // Дин вә әдәб. – 1913. – №24. – Б. 742–743.

Ары авылы зираты

1. Мифтахеддин Сәйфеддин улына куелган кабер ташы, 1922 ел[1].

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) саахибү һәзә-
3) -л-кабри мәрхүм
4) Мифтахеддин
5) Сәйфеддин
6) углы 52 йәшендә
7) 1922 нче йылда ма-
8) -йның беренче йәүмендә
9) дарел-фәнадин дар-
10) -ел-бәкайә рихләт әйләде
11) рахимәһүллаһү рахмәһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Каалүү иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун йәә Аллаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабер
3) иясе мәрхүм
4) Мифтахеддин
5) Сәйфеддин
6) улы 52 яшендә
7) 1922 ел ма-
8) -еның беренче көнендә
9) фани дөньядан мәңгелек
10) дөньяга күчте.
11) Аллаһ үз рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әйттеләр [изге бәндәләр]: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 85х34х11.

2. Бибигафия Гайсә кызына куелган кабер ташы, 1928 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) әл-хәмдү лилләәһи
3) галәә күлли хиинин
4) вә зәмәән вә ләә
5) түхъриҗнәә минәд-дү-
6) -нйәә илләә би-шәһәәдәтиһи
7) вәл-иимәән
8) саахибәтүл-кабри Биби-
9) -гафийә Гайсә кызы
10) мәдфүн
11) 1928 сәнәи милади-
12) -ййәдә 27 ну-
13) -йәбрдә 77 йәшдә
14) Аллаһ рәхмәт
15) әйләсен».

Уң ягы (уеп язылган): «Фәҗгальһәә таагат»[2].

Сул ягы (уеп язылган): «Әд-дүнйәә сәәгаһ»[3].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Һәр вакыт һәм
3) заман өчен Аллаһка
4) мактау булсын. Безне
5) шәһадәт кәлимәсе һәм
6) иман белән генә
7) дөньядан чыгарт[, йә, Аллаһ].
8) Кабер иясе Биби-
9) -гафия Гайсә кызы
10) милади
11) 1928 елның
12) 27 ноябрендә
13) 77 яшьтә җирләнде.
14) Аллаһ рәхим
15) кылсын».

Уң ягы (уеп язылган): «Аны итагать белән үткәр».

Сул ягы (уеп язылган): «Дөнья – бер сәгатьлек».

Таш үлчәмнәре: 104х34х13.

3. Фәхрениса Габделлатыйф кызына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибе
3) мәрхүмә Фәхр-
4) -енниса Габде-

[1] Биредә үлгән елы күрсәтелеп барды.

[2] Башы сул ягында.

[3] Дәвамы уң ягында.

5) -ллатыйф кызы 50 йә-
6) -шдә 1899
7) нчы йылда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
2) ләә иләәһә илләәллаah
3) Мүхәммәдүр-расүү-
4) -лүллаah 23 ү-
5) -ктәбрдә мәдфүн
6) Аллаh рәхмәт
7) кылсын амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүмә Фәхр-
4) -ениса Габде-
5) -ллатыйф кызы 50 я-
6) -шьтә 1899
7) елда [җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Шәфкатьле, Рәхимле Аллаh исеме белән.
2) Аллаһтан башка табынырлык зат юк,
3) Мөхәммәд – Аллаһның
4) илчесе. 23 о-
5) -ктябрьдә җирләнде.
6) Аллаh рәхим
7) кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 71(85)х31х9.

4. Габдрахман Габделгаффар улына куелган кабер ташы, 1934 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбратүн ләнәә
2) фәгътәбәруу
3) йәә үүләәл-әлбәәб
4) саахибүл-кабри
5) мәрхүм Габдерра-
6) -хман Габделгаффар
7) углы 1934 нче
8) сәнәи миладиййәдә
9) 4 нче дикәбрдә
10) 70 йәшдә дарел-бәкайә
11) күчде Аллаh рәхмәт».

Уң ягындагы язулары бөтенләй уалып беткән.

Сул ягы (уеп язылган): «Һәр дайым без догада».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем безнең өчен гыйбрәт,
2) аңа игътибар итегез,
3) әй, акыл ияләре.
4) Кабер иясе
5) мәрхүм Габдра-
6) -хман Габделгаффар
7) улы милади
8) 1934 елның
9) 4 декабрендә
10) 70 яшьтә мәңгелек дөньяга
11) күчте. Аллаh рәхим [кылсын]».

Уң ягындагы язулары бөтенләй уалып беткән.

Сул ягы: «Һәрдаим без догада».

Таш үлчәмнәре: 85х37х11.

5. Хәкимҗан Әхмәҗан улына куелган кабер ташы, 1931 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) мөтәвәффа мәрхүм
3) Хәкимҗан Әхмәд-
4) -җан углы
5) 1931 нче сәнәи
6) миладиййәдә
7) 20 нче ийүлдә
8) 74 йәшдә».

Уң ягы (уеп язылган): «Истәгыйддү лилмәүүт».

Сул ягы (уеп язылган): «Каблә нүзүүлилмәүүт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Мәрхүм
3) Хәкимҗан Әхмәд-
4) -җан улы
5) милади 1931
6) елнгың
7) 20 июлендә
8) 74 яшьтә вафат».

Уң ягы: «Үлемгә әзерләнегез»[4].

[4] Башы сул ягында.

Сул ягы: «Үлем килгәнче үк»[5].

Таш үлчәмнәре: 77х32х10.

6. Бибигайшә Бәйрәмгали кызына куелган кабер ташы, 1934 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) мәрхүмә
3) Бибигайшә
4) Бәйрәмгали
5) кызы 1934
6) йылда 30 нчы
7) синтәбрдә 65
8) йәшдә
9) вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән фии кабрии».

Сул ягы (уеп язылган): «Мүтәфәккиран фии әмрии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Мәрхүмә
3) Бибигайшә
4) Бәйрәмгали
5) кызы 1934
6) елның 30
7) сентябрендә 65
8) яшьтә
9) вафат».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы».

Сул ягы: «Минем эшем хакында фикерләүче».

Таш үлчәмнәре: 64х28х11.

7. Хәбибҗамал Шәмседдин кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әсгадүкәллааһү
2) Тәгаалә фиид-дәә-
3) -райн
4) бу каберә мәд-
5) -фүн
6) мәрхүмә Хәбиб-
7) -җамал Шәмс-
8) -еддин кызы
9) 1910 нчы йылда
10) 20 үктәбрдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә сине
2) ике дөньяда да бәхетле
3) итсен.
4) Бу кабергә
5) мәрхүмә
6) Хәбиб-
7) -җамал Шәмс-
8) -еддин кызы
9) 1910 елның
10) 20 октябрендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 90х36х11.

8. Галиәхмәд Габдессаттар улына куелган кабер ташы, 1928 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[6]:
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибүл-кабри мәрхүм
3) Галиәхмәд бине Габдессаттар
4) мәдфүн
5) 1928 нче сәнәи милади-
6) -ййәдә 5 гыйнварда
7) Аллаһ мәкәнене раузаи
8) җәннәт әйләсен».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Кабер иясе мәрхүм
3) Галиәхмәд бине Габдессаттар
4) милади
5) 1928 елның
6) 5 гыйнварында җирләнде.
7) Аллаһ урынын җәннәт
8) бакчасы итсен».

Таш үлчәмнәре: 72(93)х33х10.

9. Нигъмәтулла Идрис улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү

[5] Дәвамы уң ягында.

[6] Өске өлешендә ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.

2) лилләәһ
3) һәзәә саа-
4) -хибүл-кабри
5) мәрхүм Нигъмә-
6) -тулла Идрис
7) углы 1918
8) нче йылда үктә-
9) -брнең 25 нче
10) йәүмендә 35
11) йәшендә даре
12) фәнадин даре
13) бәкайә рихләт
14) әйләде Аллаһның
15) рәхмәтендә булсын».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Каалүү иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун йәә Аллаах».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем
2) Аллаһта.
3) Бу ка-
4) -бер иясе
5) мәрхүм Нигъмә-
6) -тулла Идрис
7) улы 1918
8) ел октя-
9) -бренең 25 нче
10) көнендә 35
11) яшендә фани
12) дөньядан мәңгелек
13) дөньяга
14) күчте. Аллаһның
15) рәхмәтендә булсын».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Әйттеләр [изге бәндәләр]: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Таш үлчәмнәре: 115(127)х35х14.

10. Гайнеддин Галиәкбәр улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри
3) мәрхүм Гайнеддин
4) Галиәкбәр углы
5) 1913 нче сәнә миладиййә
6) аугыст 29 нда 52 йәшендә
7) вафат рахимәллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән бикабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[7].

Сул ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[8].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Гайнеддин
4) Галиәкбәр улы
5) милади 1913 елның
6) 29 августында 52 яшендә
7) вафат. Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Сул ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 104(117)х31х13.

11. Хәсәнҗан Гомәр улына куелган кабер ташы, 1939 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бисмилләәһ-
2) -ир-рахиим
3) бу кабер
4) ийәсе
5) Хәсәнҗан
6) Гомәр углы
7) 1859 йылдда
8) туган
9) вафат булда
10) 1939 йылда
11) Аллаһ рәхмәт
12) кыйлсын амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Рәхимле Аллаһ
2) исеме белән.
3) Бу кабер
4) иясе

[7] Дәвамы сул ягында.
[8] Башы уң ягында.

5) Хәсәнҗан
6) Гомәр улы
7) 1859 едда
8) туган,
9) 1939 елда
10) вафат булды.
11) Аллаһ рәхим
12) кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 92х26х10.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Хәсәнҗан бине Гомәр бине Исхак бине Исмәгыйль бине Иркәрәм бине Әбкәләм[9].

12. Галиәскәр Габделхәйдәр улына куелган кабер ташы, 1939 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[10]:
1) «Галиәскәр
2) Габделхәйдәр
3) углы
4) вафат 1939 йыл
5) април 30 нда
6) 55 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Галиәскәр
2) Габделхәйдәр
3) улы
4) 1939 елның
5) 30 апрелендә
6) 55 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 85х32х9.

13. Әүхәди Гомәр улына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назил
3) мәрхүм
4) Әүхәди
5) Гомәр углы».

Арткы ягы (уеп язылган)[11]:
1) «Вафат
2) 1927 сәнәдә
3) 30 үктәбрдә
4) 70 йәшдә
5) Аллаһ рәхмәт
6) әйләсен».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче –
3) мәрхүм
4) Әүхәди
5) Гомәр улы».

Арткы ягы:
1) «1927 елның
2) 30 октябрендә
3) 70 яшьтә
4) вафат.
5) Аллаһ рәхим
6) кылсын».

Таш үлчәмнәре: 91х35х15.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Әүхәди бине Гомәр бине Исхак бине Исмәгыйль бине Иркәрәм бине Әбкәләм[12].

14. Әхмәҗҗан Гыйззәтулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хәмдү лилләәһил-ләзии
2) галәә күлли хиинин вә зәмәән
3) вә ләә түхъриҗнәә минәд-дүнйәә
4) илләә би-шәһәәдәтикә
5) вәл-иимәән
6) саахибү һәзәл-кабри
7) мәрхүм Әхмәҗҗан
8) Гыйззәтулла углы
9) мәдфүн
10) 1920 сәнәдә 23 нуйәбрдә».

Арткы ягы (уеп язылган)[13]:
1) «Ләә иләәһә илләәллаah
2) Мүхәммәдүр-расүүлүллаah».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр вакыт һәм заман
2) өчен Аллаһка мактау булсын.
3) Безне шәһадәт кәлимәсе һәм
4) иман белән генә дөньядан
5) чыгарт[, йә, Аллаһ].
6) Бу кабер иясе

[9] Әтнә районы музее материаллары.
[10] Өске өлешендә ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.
[11] Өске өлешендә ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.
[12] Әтнә районы музее материаллары.
[13] Айлы-йолдызлы манара рәсеме төшерелгән.

7) мәрхүм Әхмәҗан
8) Гыйззәтулла улы
9) 1920
10) елның 23 ноябрендә җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,
2) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе

Таш үлчәмнәре: 96х35х14.

15. Нәфисә Мөхәммәдгали кызына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) саахиб-
3) -үл-кабри мәр-
4) -хүмә
5) Нәфисә
6) Мөхәммәдгали
7) кызы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Кабер
3) иясе мәр-
4) -хүмә
5) Нәфисә
6) Мөхәммәдгали
7) кызы».

Таш үлчәмнәре: 85(99)х34х15.

16. Хәерниса Хәлилулла кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим
2) бисмилләәһир-рахмәнир-рахиим
3) ләә иләәһә илләәллааһ мүхәммәд-
4) -үр-расүүлүллааһ күллү мән галәйһәә
5) фәән бер мең сигез йөз дә ту-
6) -ксан тугызынчы йылда
7) майның 15 ндә Ары
8) авылының Гомәр җәмәгате
9) Хәйренниса бинте Хәлилулла».

Уң ягы (уеп язылган): «Буны йаздым йәдкәр улмак өчүн».

Сул ягы (уеп язылган): «Каалүү иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун йәә Аллааһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһил-галиййил-кәбиир
2) 1313 нче йылда җөмади-
3) -әл-әүвәлнең 10 нчы көнендә
4) Гомәр җәмәгате Хәйерниса
5) Хәлилулла кызы 70
6) йәшендә дарел-фәна-
7) -дин дарел-бәкайә
8) рихләт әйләде Аллаһ
9) Тәгаләнең рәхмәтенә гарикъ улсын».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шайтаннан Аллаһка сыенам.
2) Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ исеме белән.
3) Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд –
4) Аллаһның илчесе. Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә
5) фани. Бер мең сигез йөз дә ту-
6) -ксан тугызынчы елның
7) 15 маенда Ары
8) авылыннан Гомәр җәмәгате
9) Хәерниса бинте Хәлилулла».

Уң ягы: «Моны ядкәр булу өчен яздым».

Сул ягы: «Әйттеләр [изге бәндәләр]: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Арткы ягы:
1) «Хөкем Олуг, Бөек Аллаһта.
2) 1313 ел җөмади-
3) -әл-әүвәленең 10 нчы көнендә
4) Гомәр җәмәгате – Хәерниса
5) Хәлилулла кызы – 70
6) яшендә фани дөнья-
7) -дан мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ
9) Тәгаләнең рәхмәтенә күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 80(91)х32х11.

17. Габделлатыйф Габделгалим улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Габделлатыйф
3) Габделгалим углы
4) 80 йәшендә вафат

5) миладиййә 1910 нчы йылда
6) 10 нчы ийүндә
7) гарикы рәхмәт улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Габделлатыйф
3) Габделгалим улы
4) 80 яшендә
5) милади 1910 елның
6) 10 июнендә вафат.
7) Рәхмәткә күмелсен».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 84(96)x34x11.

18. Гомәр Исхак улына куелган кабер ташы, 1876 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражиим Аллаһ
2) бисмилләәһир-рахмәнир-рахиим ләә иләәһә илләәллааһ мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
3) күллү мән галәйһәә фәән 76
4) 18[14] нчы йылда април-
5) -нең 15 ндә Гомәр Исхак
6) углы 70 йәшендә
7) дарел-фәнадин дарел-бәкайә
8) рихләт әйләде гарикы
9) рәхмәт әйләсүн Аллаһ
10) Тәгалә амин каалүү иннәә лилләәһи
11) вә иннәә иләйһи рааҗигуун
12) әй мөэминләр дога».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шайтаннан Аллаһка сыенам. Аллаһ.
2) Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ исеме белән. Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
3) Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
4) 1876 елның 15
5) апрелендә Гомәр Исхак
6) улы 70 яшендә
7) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ
9) Тәгалә рәхмәткә
10) күмсен, амин. Әйттеләр [изге бәндәләр]: «Чынлыкта, без Аллаһныкы
11) һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».
12) Әй, мөэминнәр, дога [кылыгыз]».

Таш үлчәмнәре: 111x35x13.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Гомәр бине Исхак бине Исмәгыйль бине Иркәрәм бине Әбкәләм[15].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 1 б. №1.

19. Сәмигулла Латыйф улына куелган кабер ташы, 1939 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[16]:
1) «Сәмигулла
2) Латыйф углы
3) вафат 1939 йыл
4) ийүн ... нда
5) ... айында».

Таш үлчәмнәре: 86x31x10.

20. Бибигайшә Гайсә кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Биби-
3) -гайшә Гайсә
4) кызы Сәйфеддин
5) зәүҗәсе 62
6) йәшендә 1905 нче
7) йылда синтәбрнең
8) 25 нче йәүмендә
9) дарел-фәнадин да-
10) -рел-бәкайә рихләт
11) әйләде Аллаһ Тәгалә-
12) -нең рәхмәтенә гарикы
13) улсун».

[14] 1876 ел датасы шул рәвешле икегә бүленеп язылган.

[15] Әтнә районы музее материаллары.

[16] Өске өлешендә ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.

Уң ягы (уеп язылган): «Каалүү иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Биби-
3) -гайшә Гайсә
4) кызы – Сәйфеддин
5) хатыны – 62
6) яшендә 1905
7) ел сентябренең
8) 25 нче көнендә
9) фани дөньядан
10) мәңгелек дөньяга
11) күчте. Аллаһ Тәгалә-
12) -нең рәхмәтенә
13) күмелсен».

Уң ягы: «Әйттеләр [изге бәндәләр]: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 109x34x13.

21. Сәйфеддин Миңлебай улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) саахибү һәзә-
3) л-кабри мәрхүм
4) Сәйфеддин
5) Миңлебай углы
6) 75 йәшендә
7) 1916 нчы йылда
8) мартның 22
9) сендә дарел-фәна-
10) -дин дарел-бәка-
11) -йә рихләт
12) әйләде рахимәһ-
13) -үллаһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Каалүү иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабер
3) иясе мәрхүм
4) Сәйфеддин
5) Миңлебай улы
6) 75 яшендә
7) 1916 елның
8) 22 мартында
9) фани дөнья-
10) -дан мәңгелек дөнья-
11) -га күчте.
12) Аллаһ киң рәхмәте белән
13) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әйттеләр [изге бәндәләр]: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 99(113)x33x13.

Әйшияз авылы зираты

1. Хәбибҗамал Гайсә кызына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Хәбибҗамал Гайсә кызы
4) Мөхәммәдшаһ зәүҗәсе
5) вафат 1923 нче җыл
6) ... нче април 1341 һиҗри-
7) -ййә камәриййә рамазан
8) 72 йәшдә рахимәһәә-
9) -ллаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлунгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Хәбибҗамал Гайсә кызы –
4) Мөхәммәдша хатыны –

5) 1923 елның
6) ... апрелендә, һиҗри (ай исәбе белән)
7) 1341 [елның] рамазанында
8) 72 яшьтә вафат. Аллаһ аны
9) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 86х28х9.

2. Мөхәммәдша Япи улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Мөхәммәдшаһ Йәпи
4) углы 1921 нче җыл
5) фиврал 18 ндә
6) 85 йәшендә
7) вафат рахимәһүллааһү
8) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[17].

Сул ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[18].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Мөхәммәдша Япи
4) улы 1921 елның
5) 18 февралендә
6) 85 яшендә
7) вафат. Аллаһ аны киң рәхмәте
8) белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Сул ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Таш үлчәмнәре: 85х27х9.

3. Бәйрәмгали Габделҗаббар улына куелган кабер ташы, 1928 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) Бәйрәмгали
3) Габделҗаббар
4) углы 1928 сәнә
5) 18 нче априлдә
6) 1346 сәнә 26 нчы
7) шәүвәлдә 72
8) йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллааһү Тәгаалләә».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт итсен».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бәйрәмгали
3) Габделҗаббар
4) улы 1928 елның
5) 18 апрелендә,
6) [һиҗри] 1346 елның 26
7) шәүвәлендә 72
8) яшендә вафат».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын».

Сул ягы: «Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 93х31х10.

4. Корбангали Габделҗаббар улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Корбангали Габд-
4) -елҗаббар углы
5) 1926 нче җылда
6) 8 нче гыйнвар 72
7) йәшдә вафат
8) рахимәһүллааһ»[19].

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

[17] Башы сул ягында.
[18] Дәвамы уң ягында.
[19] Дәвамы сул ягында.

Сул ягы (уеп язылган): «Рахмәтән вәәсигаһ»[20].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Корбангали Габд-
4) -елҗаббар улы
5) 1926 елның
6) 8 гыйнварында 72
7) яшьтә вафат.
8) Аллаһ аны рәхим кылсын».

Уң ягы (уеп язылган): «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы (уеп язылган): «[Аллаһ аны] киң рәхмәте белән [рәхим кылсын]».

Таш үлчәмнәре: 86x29x9.

5. Габделһади Габдессадыйк улына һәм Мәфтуха Габдессадыйк кызына куелган кабер ташы, 1921 һәм 1922 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Габделһади Габдессадыйк
4) углы 1921 нче милади
5) 1 нче фиврал һиҗри 1339
6) шәгъбан 20 ндә 72 йәшдә
7) вафат рахимәһүллааһү Тәгааләә
8) рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Гакыйбәт бер көн китәрсең ул гокбага».

Сул ягы (уеп язылган): «Әй гафил алданма бу дөнйага».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу каберә назилә мәрхүмә
2) Мәфтуха Габдессадыйк кызы
3) Габделһади зәүҗәсе
4) 1922 җыл дикәбр
5) 27 һиҗри 1340
6) җөмадиәл-ахир 15 ндә
7) 7... йәшендә вафат
8) Аллаһ рәхмәт
9) әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделһади Габдессадыйк
4) улы милади 1921 [елның]
5) 1 февралендә, һиҗри 1339 [елның]
6) 20 шәгъбанында 72 яшьтә
7) вафат. Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте
8) белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Ахырдан беркөн китәрсең ул ахирәткә».

Сул ягы: «Әй, ваемсыз, алданма бу дөньяга».

Арткы ягы:
1) «Бу кабергә иңүче мәрхүмә
2) Мәфтуха Габдессадыйк кызы –
3) Габделһади хатыны –
4) 1922 елның 27
5) декабрендә, һиҗри 1340 [елның]
6) 15 җөмадиәл-ахирендә
7) 7... яшендә вафат.
8) Аллаһ рәхим
9) кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 90x29x10.

6.Бибимәлихә Галиәкбәр кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ
2) Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
3) һиҗрииййә илә 1322 нче
4) сәнәд миладиййә илә 1904
5) нче сәнәд маһе шәрифнең 6 сында
6) бөрҗе үктәбрнең 31 ндә Бибимәлихә
7) Галиәкбәр кызы 64 йәшендә йәкшәнбә көн
8) сәйран даре ахирәт әйләде Аллаһ
9) Тәгалә гарикы рәхмәт әйләгәй иде
10) амин».

Сул ягы (уеп язылган): «Таййибәллааһү сәрааһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ»[21].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,

[20] Башы алгы ягында.

[21] Ир-атка карата кулланыла торган кушымчалар белән язылган.

2) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
3) Һиҗри белән 1322
4) елның 6 рамазан шәрифнендә,
5) милади белән 1904 елның
6) 31 октябрендә Бибимәлихә
7) Галиәкбәр кызы 64 яшендә якшәмбе көн
8) ахирәткә күчте. Аллаһ
9) Тәгалә рәхмәткә күмсә иде,
10) амин».

Сул ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Таш үлчәмнәре: 83х30х13.

7. Галимҗан Мөхәммәдъяр улына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәәл-кабри мәрхүм
3) Галимҗан Мөхәммәдъяр
4) углы 1919 нчы йылда
5) 8 дикәбр мәүлүд айында
6) 58 йәшендә вафат
7) рахимәһүллаахү рахмәтән
8) вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Галимҗан Мөхәммәдъяр
4) улы 1919 елның
5) 8 декабрендә, мәүлед аенда
6) 58 яшендә вафат.
7) Аллаһ аны киң рәхмәте белән
8) рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 85х31х8.

8. Мөхәммәдсадыйк Рәхмәтулла улына куелган кабер ташы, 1875 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Мөхәммәдсадыйк
4) Рәхмәтулла углы
5) 1875 нче җылда
6) 1 нче фивралда 53»[22].

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллааһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәшендә вафат»[23].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Мөхәммәдсадыйк
4) Рәхмәтулла улы
5) 1875 елның
6) 1 февралендә 53 [яшендә вафат]».

Уң ягы: «Аллаһ аны рәхим кылсын».

Сул ягы: «[53] яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 68х32х9.

9. Бәдриҗамал Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун
2) мәрхүмә Бәдри-
3) -җамал Фәтхулла кызы
4) 70 йәшендә 10
5) нчы мартда 1895
6) нче йылда мәдфүн
7) Хак Тәгаләнең
8) рәхмәтендә улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Мәрхүмә Бәдри-
3) -җамал Фәтхулла кызы
4) 70 яшендә 1895
5) елның 10
6) мартында җирләнде.
7) Хак Тәгаләнең
8) рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 79х34х13.

10. Бибимәфтуха Насыйбулла кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә

[22] Дәвамы сул ягында.

[23] Башы алгы ягында.

3) Бибиәфтуха Насыйбулла кызы
4) Габделгалләм Галиәкбәр углы-
5) -ның әһлийәсе 1907 нче сәнә
6) 28 май 70 йәшдә вафат
7) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Гакыйбәт бер көн әҗәл әйләр галил»[24].

Сул ягы (уеп язылган): «Нә дәклү улса да гомерең тавил»[25].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Бибиәфтуха Насыйбулла кызы –
4) Габделгалләм Галиәкбәр улы-
5) -ның хатыны – 1907 елның
6) 28 маенда 70 яшьтә вафат.
7) Аллаһ рәхим кылсын».

Уң ягы: «Ахырдан беркөн әҗәл хәлсез итәр».

Сул ягы: «Ни тиклем гомерең озын булса да».

Таш үлчәмнәре: 68х31х9.

11. Галиәкбәр Габдерәфыйк улына куелган кабер ташы, 1862 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу кабер ийәсе
3) Галиәкбәр Габдерәфыйк
4) углы 1862 нче йылда
5) аугус 21 ндә 63
6) йәшендә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) Галиәкбәр Габдерәфыйк
4) улы 1862 елның
5) 21 августында 63
6) яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 54х31х8.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 1 б. №2.

[24] Башы сул ягында.
[25] Дәвамы уң ягында.

12. Габделгалләм Галиәкбәр улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәәл-кабри мәрхүм
3) Габделгалләм Галиәкбәр углы
4) 1912 нче йыл 1 нче үктәбр
5) 80 йәшендә вафат
6) рахимәһүллааһү рахмәтән вәәсигаһ
7) әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[26].

Сул ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[27].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделгалләм Галиәкбәр улы
4) 1912 елның 1 октябрендә
5) 80 яшендә вафат.
6) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын,
7) амин».

Уң ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Сул ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Таш үлчәмнәре: 72х31х9.

Әйшияз авылы янындагы хан зираты

Әлеге Хан зиратында элегрәк XVI–XVII гасырларга караган язуларсыз 3 борынгы кабер ташы сакланган булган[28]. Хәзерге көндә анда 2 ташбилге генә сакланган (берсе ни сәбәпледер югалган), тик аларның язулары уалып юкка чыккан, ә, бәлки, булмагандыр да. Ташларның үлчәмнәре: 98х53/72х21, 90х32/55х24.

Хан зиратыннан ерак түгел бер җирдә «Изгеләр каберлеге» дигән зират урнашкан. Җирле халык ышануына караганда, анда Ирәлгали (Ирәмәли) балалары: Сөләйман хаҗи, мул-

[26] Башы сул ягында.
[27] Дәвамы уң ягында.
[28] Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С.101.

ла Таҗеддин, Гайшәбикә һәм Хәнифәбикә абыстайлар, шулай ук 5 сабый кыз бала җирләнгән, имеш.

Бахтачы авылы зираты

1. Мәдинә Гарифулла кызына куелган кабер ташы, 1939 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[29]:
1) «Гарифулла
2) кызы
3) Мәдинә
4) 1931 – 1939
5) вафат
6) Алла рәхмәт
7) кыйлсын».

Таш үлчәмнәре: 86(97)х29х9.

2. Бәдреддин Габделкамал улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Бәдреддин Габделкамал
4) углы 1922 нче йыл
5) март 15 һиҗриййә 1340
6) шәгъбан 4 ндә 53
7) йәшдә вафат Аллаһ
8) рәхмәт әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Бәдреддин Габделкамал
4) улы 1922 елның
5) 15 мартында, һиҗри 1340 [елның]
6) 4 шәгъбанында 53
7) яшьтә вафат. Аллаһ
8) рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 97х28х8.

3. Габделвәли Вәлид улына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер сахибе Габделвәли
3) Вәлид углы 1903 нче сәнә май
4) 15 нче йәүмендә 71 йәшендә бу фәна-
5) -дин бәкайә рихләт кыйлды
6) рахимәллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәңа икән йарын сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылучыны Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе Габделвәли
3) Вәлид улы 1903 ел маеның
4) 15 нче көнендә 71 яшендә бу фанилык-
5) -тан бакыйлыкка күчте.
6) Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 80х30х13.

4. Бибимәликҗамал Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу кабергә дахилә мәрхүмә Бибимәлик-
3) -елҗамал Гобәйдулла кызы Габделвәли Вәлид
4) углыйның әһлийәсе румиййә илән
5) 1900 нче сәнә 70 йәшендә 11 нче мартда
6) җомга көн дарел-фәнадин дарел-бәкайә рихләт
7) кыйлды нәүвәраллааһү мәркадәһәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылучыны Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә керүче мәрхүмә Бибимәлик-

[29] Өске өлешендә ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.

3) -җамал Гобәйдулла кызы – Габделвәли Вәлид
4) улының хатыны – милади белән
5) 1900 елның 11 мартында 70 яшендә
6) җомга көн фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 95х35х9.

5. Баһаеддин Фәхреддин улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибе
3) мәрхүм Баһаэддин
4) Фәхреддин углы
5) вафат булды
6) 1904 нче йылда
7) 14 нче мартда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «53 нче
2) йәшендә Аллаһ-
3) -ның рәхмәтендә
4) булсын амин
5) мөэмин кардәш-
6) -ләр догадан та-
7) -шламагыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Баһаеддин
4) Фәхреддин улы
5) 1904 елның
6) 14 мартында
7) вафат булды».

Арткы ягы:
1) «53 нче
2) яшендә [вафат]. Аллаһ-
3) -ның рәхмәтендә
4) булсын, амин.
5) Мөэмин кардәш-
6) -ләр, догадан та-
7) -шламагыз».

Таш үлчәмнәре: 60(70)х28х6.

6. Шакиржан Фәттах улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Шакиржан Фәттах углы
4) 1912 нче сәнәи милади 12 нче
5) агусда 48 йәшдә
6) дарел-бәкага рихләт
7) кыйлды Аллаһ рәхмәт
8) әйләсүн амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәнгә икән йарун сәнгәдер».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Шакиржан Фәттах улы
4) милади 1912 елның 12
5) августында 48 яшьтә
6) мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ рәхим
8) кылсын, амин».

Уң ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 72х26х8.

7. Хөсәен Габделмөнгыйм улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Хөсәйен Габделмөнгыйм
4) углы 1923 нче йыл
5) 25 нче гыйнварда
6) 65 йәшдә вафат
7) итде рахимәһүллааһү
8) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[30].

[30] Дәвамы сул ягында.

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[31].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Хөсәен Габделмөнгыйм
4) улы 1923 елның
5) 25 гыйнварында
6) 65 яшьтә вафат
7) булды. Аллаһ киң рәхмәте
8) белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Сул ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Таш үлчәмнәре: 92x28x9.

8. Хәерниса Миңлебай кызына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) бу кабер ийәсе мөтәвәффийә
3) мәрхүмә Хәйренниса
4) мәшһүр Миңлебай
5) кызы 50 йәшендә 1900 нч
6) йыл 12 нче нуйәбрдә кабере
7) нурлы булсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[32].

Сул ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[33].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүмә Хәерниса
4) мәшһүр Миңлебай
5) кызы 50 яшендә 1900
6) елның 12 ноябрендә вафат. Кабере
7) нурлы булсын, амин».

Уң ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Сул ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Таш үлчәмнәре: 103x32x12.

9. Габделмөнгыйм Габделхәким улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгааләә
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Габделмөнгыйм Габделхәким углы
4) румиййә илә 1907 нче йылда
5) априлнең 10 нчы көнендә 82
6) йәшендә дарел-бәкайә рихләт
7) кыйлды Аллаһ рәхмәт кыйлсун
8) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблəл-әҗəл».

Сул ягы (уеп язылган)[34]:
1) «Ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл
2) кәтәбәһәә мөәзине
3) Үртәм Лотф-
4) -улла».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделмөнгыйм Габделхәким улы
4) милади белән 1907 ел
5) апреленең 10 нчы көнендә 82
6) яшендә мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ рәхим кылсын,
8) амин».

Уң ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Сул ягы:
1) «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми.
2) Моны язды: Үртәм
3) мөәзине Лотф-
4) -улла».

Таш үлчәмнәре: 111x31x14.

[31] Башы уң ягында.
[32] Башы сул ягында.
[33] Дәвамы уң ягында.

[34] Беренче юлы вертикаль рәвештә, калганнары диагональ буенча язылган.

10. Габделхәким Габдулла улына һәм Мәргубә Габделмән кызына куелган кабер ташы, 1837 һәм 1895 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) бу кабер ийәсе мөтәвәффа
3) мәрхүм Габделхәким
4) Габдулла углы
5) 45 йәшендә 1837 нч
6) йыл 12 нче дикәбрдә
7) кабере нурлы булсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Күреб каберүм хәлеңне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган)[35]:
1) «Дога берлә кылынгыз рухымы шад
2) йазгуч
3) Сәлах мулла
4) Казаклари».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу кабердә мөтәвәффийә мәрхүмә
3) Мәргубә Габделмән
4) кызы 87 йәшендә
5) 1895 нче йыл 10 нчы
6) ийүлдә кабере
7) нурлы булсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Габделхәким
4) Габдулла улы
5) 45 яшендә 1837
6) елның 12 декабрендә вафат.
7) Кабере нурлы булсын.

Уң ягы: «Каберемне күреп, хәлеңне искә ал».

Сул ягы:
1) «Дога белән рухымны шатландырыгыз.
2) Язучы:
3) Сәлах мулла
4) Казаклари».

Арткы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабердә мәрхүмә
3) Мәргубә Габделмән
4) кызы, 87 яшендә
5) 1895 елның 10
6) июлендә вафат. Кабере
7) нурлы булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 97x27x12.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 1 б. №3.

11. Мөхәммәдшакир Мөхәммәдшәриф улына куелган кабер ташы, 1924 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Мөхәммәдшакир
4) Мөхәммәдшәриф углы
5) 1924 нче җыл 2 нче
6) гыйнвар 1342 сәнә һиҗриййә
7) җөмадиәл-әүвәл 5 ндә 72
8) йәшендә вафат Аллаһ
9) рәхмәт әйләсүн
10) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[36].

Сул ягы (уеп язылган): «Таки насыйб идә Аллаһ оҗмахы»[37].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Мөхәммәдшакир
4) Мөхәммәдшәриф улы
5) 1924 елның 2
6) гыйнварында, һиҗри 1342 елның
7) 5 җөмадиәл-әүвәлендә 72
8) яшендә вафат. Аллаһ
9) рәхим кылсын,
10) амин».

Уң ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Сул ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Таш үлчәмнәре: 90x28x9.

[35] Беренче юлы вертикаль рәвештә, калганнары диагональ буенча язылган.

[36] Башы сул ягында.

[37] Дәвамы уң ягында.

12. Маһиҗиһан Мөхәммәдрәхим кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу каберә мәдфүнә
2) Маһиҗиһан Мөхәммәдрәхим
3) кызы Мөхәммәдшакир
4) җәмәгате 1920 нче җыл
5) нуйәбр 19 нда 66
6) йәшендә вафат итде
7) рахимәһәәллааһү рахмәтән
8) вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи раажигуун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабергә җирләнүче
2) Маһиҗиһан Мөхәммәдрәхим
3) кызы – Мөхәммәдшакир
4) җәмәгате – 1920 елның
5) 19 ноябрендә 66
6) яшендә вафат булды.
7) Аллаһ киң рәхмәте белән
8) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Таш үлчәмнәре: 76х28х7.

Бәхтияр авылы зираты

1. Хәбибҗамал Мөфти кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лаа иләәһә иллаәллааһ Мүхәммәдүр-
расүүлүллааһ салләәллааһү галәйһи вә сәлләм
2) румиййә илә 1912 нче
3) йылда 13 нче ийүлдә
4) 75 йәшендә Хәбибҗамал
5) Мөфти кызы даре фәнадан
6) рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә рухымы идеңез шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) ««Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен).
2) Милади белән 1912
3) елның 13 июлендә
4) 75 яшендә Хәбибҗамал
5) Мөфти кызы фани дөньядан
6) күчте».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Сул ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 92х31х11.

2. Сәйдә мулла Исмәгыйль кызына куелган кабер ташы, 1928 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лаа иләәһә иллаәллааһ Мүхәммәдүр-
расүүлүллааһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Сәйдә мулла Исмәгыйль
4) кызы Бәхтийәр карйәсендә
5) мулла Габделвәли тәхтә
6) никяхында 1928 сәнәи мила-
7) -диййә 1346 сәнә һиҗриййә
8) үктәбр... [рихләт]»[38].

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи раажигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «әйләде рахимәһәәллааһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин»[39].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Сәйдә мулла Исмәгыйль
4) кызы (Бәхтияр авылындагы
5) мулла Габделвәли
6) никяхында иде) милади 1928-
7) елның октябрендә, һиҗри 1346
8) елда [вафат]».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

[38] Дәвамы сул ягында.
[39] Башы алгы ягында.

Сул ягы: «Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 85х34х11.

3. Бибифакиһә Әсәдулла Әхмәд улының кызына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) Әсәдулла Әхмәд
3) углының кызы Биби-
4) -факиһә Габделбакый
5) Габдулла углының
6) әһлийәсе 1911 нче
7) йылда 25 нче май-
8) -да вафат улды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1329 нчы
2) йылда мәүлүд а-
3) -йның 12 нче
4) көнендә мәдфүн
5) улды Аллаһ
6) Тәгалә рәхмәт
7) кылсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән..
2) Әсәдулла Әхмәд
3) улының кызы Биби-
4) -факиһә – Габделбакый
5) Габдулла улының
6) хатыны – 1911
7) елның 25 маен-
8) -да вафат булды».

Арткы ягы:
1) «1329
2) ел мәүлед ае-
3) -ның 12 нче
4) көнендә
5) җирләнде. Аллаһ
6) Тәгалә рәхим
7) кылсын».

Таш үлчәмнәре: 104(112)х32х12.

4. Мөхәммәдкәрим Галим улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) румиййә илә 1913 нче
3) йылда 2 нче ийүлдә
4) 33 йәшендә Мөхәммәдкәр-
5) -им Галим углы даре
6) фәнадан рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән бикабрии мүтәфәккиран ли-әмрии»[40].

Сул ягы (уеп язылган): «Күнтү бил-әмси мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[41].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Милади белән 1913
3) елның 2 июлендә
4) 33 яшендә Мөхәммәдкәр-
5) -им Галим улы фани
6) дөньядан күчте».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Сул ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 87х30х10.

5. Бибихөбәйбә Габделфәез кызына куелган кабер ташы, 1877 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәүвәраллааһү мәркадәһәә
2) мәрхүмә
3) Бибихөбәйбә
4) Габделфәйез
5) кызы
6) Гобәйдулла
7) мәрхүм
8) җәмәгате
9) 82 йәшендә
10) 1877 йылда
11) 11 нҗе ийүндә».

Уң ягы (калкытып язылган): «Бакый калмаз бу җиһанда гәр шәкыйдур гәр сәгыйдь».

Сул һәм арткы якларында матур бизәкләр төшерелгән.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ аның каберен нурландырсын.

[40] Дәвамы сул ягында.
[41] Башы уң ягында.

2) Мәрхүмә
3) Бибихөбәйбә
4) Габделфәез
5) кызы –
6) Гобәйдулла
7) мәрхүм
8) җәмәгате –
9) 82 яшендә
10) 1877 елның
11) 11 июнендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Мәңге калмас бу җиһанда бәхетсез булсаң да, бәхетле булсаң да».

Таш үлчәмнәре: 134x34x14.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 1 б. №4.

6. Фәхрениса Әхмәҗән кызына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбрah
2) Фәхренниса Әхмәд-
3) -җан кызы Мостафа
4) Мөхәммәҗән углы-
5) -ның хәлиләсе
6) миладиййә илә
7) 1927 нче сәнә
8) 12 нче априлдә
9) 70 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Әл-кабру мәнзилүн мин мәнәәзилил-әәхыйрah».

Сул ягы (уеп язылган): «Һиҗриййә 1345 нче йыл 10 нчы шәүвәлдә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Фәхрениса Әхмәд-
3) -җан кызы – Мостафа
4) Мөхәммәҗән улы-
5) -ның сөеклесе –
6) милади белән
7) 1927 елның
8) 12 апрелендә
9) 70 яшендә вафат».

Уң ягы: «Кабер – ахирәт йортларыннан бер йорт».
Сул ягы: «Һиҗри 1345 елның 10 шәүвәлендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 96x31x12.

7. Мостафа Мөхәммәҗән улына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәhи вә иннәә иләйhи рааҗигуун
2) Мостафа Мөхәммәд-
3) -җан углы
4) тарих миладиййә
5) илә 1925 нче
6) йылда 19 нчы
7) ийүндә 75
8) йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Зүүрууль-кубүүра фә-иннәhәә түзәккиракүмүл-әәхыйрah».

Сул ягы (уеп язылган): «Һиҗриййә илә 1344 нче йыл 28 нче зөлкагдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Мостафа Мөхәммәд-
3) -җан улы
4) милади
5) белән 1925
6) елның 19
7) июнендә 75
8) яшендә вафат».

Уң ягы: «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар сезгә ахирәтне искә төшерә».

Сул ягы: «Һиҗри белән 1344 елның 28 зөлкагдәсендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 88x34x10.

8. Хәдичә Гыйрфан кызына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әд-дүнйәә мәзрагатүл-әәхыйрah
2) Хәдиҗә Гыйрфан
3) кызы Мөхәммәд-
4) -шәриф Әүхәди
5) углыйның хәлилә-
6) -се миладиййә илә
7) 1927 нче сәнә
8) 13 нче фивралда
9) 68 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Җәгаләллаһү кабраһәә раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Һиҗриййә илә 1345 нче йыл 10 нчы шәгъбанда вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Дөнья – ахирәт басуы.
2) Хәдичә Гыйрфан
3) кызы – Мөхәммәд-
4) -шәриф Әүхәди
5) улының сөекле-
6) -се милади белән
7) 1927 елның
8) 13 февралендә
9) 68 яшендә вафат».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Сул ягы: «Һиҗри белән 1345 елның 10 шәгъбанында вафат».

Таш үлчәмнәре: 99(114)х31х12.

9. Нигъмәтулла Гатаулла улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) Нигъмәтулла Гата-
3) -улла углы һиҗриййә
4) илә 1340 нчы йыл
5) 10 нчы мөхәррәмдә миладиййә
6) илә 1922 нче йыл
7) 23 нче аугустда
8) 60 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллаһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Нигъмәтулла Гата-
3) -улла улы һиҗри
4) белән 1340 елның
5) 10 мөхәррәмендә, милади
6) белән 1922 елның
7) 23 августында
8) 60 яшендә вафат».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 77х32х9.

10. Һәдия Әхмәдулла кызына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Һәдийә Әхмәдулла
3) кызы 26 йәшендә
4) Хөрмәтулла
5) зәүҗәсе
6) 1927 сәнәи миладиййә
7) 3 нче гыйнварда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада иде-
3) -ңез йад тәсадды-
4) -клә кыйлуңыз
5) рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Һәдия Әхмәдулла
3) кызы –
4) Хөрмәтулла хатыны –
5) милади 1927 елның
6) 3 гыйнварында
7) 26 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) Юмартлык кылып,
2) догада искә
3) алыгыз. Сәдака бирү
4) белән рухымны
5) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 88х31х10.

Дусым авылы зираты

1. Мөхәммәдйосыф Әхмәдсадыйк улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәһ
2) Мөхәммәдйосыф
3) Әхмәдсадыйк
4) углы 41 йәшендә
5) 1330 сәнәи һиҗриййә

6) 1912 сәнәи миладиййә
7) 10 нчы фибралда
8) дарел-бәкайә рихләт
9) әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта гына.
2) Мөхәммәдйосыф
3) Әхмәдсадыйк
4) улы 41 яшендә
5) һиҗри 1330 елда,
6) милади 1912 елның
7) 10 февралендә
8) мәңгелек дөньяга
9) күчте».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 98х31х11.

2. Бибишәмсия Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун
2) мәрхүмә Бибишәмсийә
3) Фәтхулла кызы
4) 62 йәшендә 5 нч
5) мартда 1893
6) нче йылда мәдфүнә
7) Аллаһ Тәгаләнең
8) рәхмәтендә улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Мәрхүмә Бибишәмсия
3) Фәтхулла кызы
4) 62 яшендә 1893
5) елның 5
6) мартында җирләнде.
7) Аллаһ Тәгаләнең
8) рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 93х30х12.

3. Габделхәким Сәйфеддин улына куелган кабер ташы, 1886 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун
2) мәрхүм Габделхәким Сәйфеддин
3) углы 59 йәшендә
4) 2 нче ийүлдә
5) 1886 нче йылда мәдфүн
6) Аллаһ Тәгаләнең
7) рәхмәтендә улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Мәрхүм Габделхәким Сәйфеддин
3) углы 59 яшендә
4) 1886 елның
5) 2 июлендә җирләнде.
6) Аллаһ Тәгаләнең
7) рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 93х30х12.

4. Мәгъсүд Габделкәрим улына һәм Сәхибкамал Мөхсин кызына куелган кабер ташы, 1851 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәл-хәййүл-ләзии ләә йәмүүт
2) Дусым авылының
3) имамел-җамигъ мулла
4) Мәгъсүд Габделкәр-
5) -им углы дарел-фәнад-
6) -ин дарел-бәкайә
7) рихләт әйләде 56
8) йәшдә 1851 йылда
9) әл-мәүтү кәфәә вәәгыйзаа».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-мәрхүүмәтүл-мүкәррамәтү
2) мулла Мәгъсүд хәләә-
3) -ле Мөхсин кызы Сәхиб-
4) -камал дарел-фәна-
5) -дин дарел-бәкайә
6) рихләт әйләде 75
7) йәшдә 1851 йылда
8) әл-мәүтү кәфәә вәәгыйзаа».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Тере, Үлми.
2) Дусым авылының
3) мәчет имамы мулла
4) Мәгъсүд Габделкәр-
5) -им улы 56
6) яшьтә 1851 елда
7) фани дөньяд-
8) -ан мәңгелек дөньяга күчте.
9) Үлем вәгазьче буларак җиткән».

Арткы ягы:
1) «Хөрмәтле мәрхүмә
2) мулла Мәгъсүд хәлә-
3) -ле – Мөхсин кызы Сәхиб-
4) -камал – 75
5) яшьтә 1851 елда
6) фани дөньяд-
7) -ан мәңгелек дөньяга күчте.
8) Үлем вәгазьче буларак җиткән».

Таш үлчәмнәре: 176x30x12.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 1 б. №5.

5. Бинеямин Фазлулла улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт
3) Бинейәмин Фазлулла
4) углы 45 йәшендә
5) 1923 сәнә миладиййә
6) майның 16 нчы көнендә
7) дарел-фәнадин дар-
8) -ел-бәкайә рихләт итде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак.
3) Бинеямин Фазлулла
4) улы 45 яшендә
5) милади 1923 ел
6) маеның 16 нчы көнендә
7) фани дөньядан мәңгелек
8) дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 65x30x11.

6. Габденнәфыйк Рәхмәтулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Габд-
2) -еннәфыйк
3) Рәхмәтулла
4) углы май 5 нче
5) 1920 нче йыл
6) 75 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ
2) Тәбарәкә
3) вә Тәгалә
4) рәхмәтенә ва-
5) -сыйл улса
6) иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Габд-
2) -еннәфыйк
3) Рәхмәтулла
4) улы 1920 елның
5) 5 маенда
6) 75 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ
2) Тәбарәкә
3) вә Тәгалә
4) рәхмәтенә
5) ирешсә
6) иде».

Таш үлчәмнәре: 85(97)x27x7.

7. Габделфатих Габденнәфигъ улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә
2) иләйһи рааҗигуун
3) Габделфатих
4) Габденнәфигъ
5) углы вафат
6) 1913 нче йыл
7) 25 нче гыйнвар».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «45 йәшендә дәфен кылынды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Йукары Шашы
2) карйәсинең
3) Әхмәдхан
4) Әхмәдгали
5) углының
6) йәрдәме илә
7) йазылды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.
3) Габделфатих
4) Габденнәфигъ
5) улы
6) 1913 елның
7) 25 гыйнварында вафат».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Сул ягы: «45 яшендә җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Югары Шашы
2) авылыннан
3) Әхмәдхан
4) Әхмәдгали
5) улының
6) ярдәме белән
7) язылды».

Таш үлчәмнәре: 82(96)x31x9.

8. Сәгъдеддин Зөбәер улына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе Сәгъдеддин
3) Зөбәйер углы румиййә илән
4) 1903 нче сәнә 65 йәшендә
5) ийүл 26 нчы көн мәдфүн
6) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе Сәгъдеддин
3) Зөбәер улы милади белән
4) 1903 ел июленең 26 нчы
5) көнендә 65 яшендә җирләнде.
6) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 95x30x11.

9. Хәдичә Әюб кызына куелган кабер ташы, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Дусым авылыйның Габделфатих
3) Габденнәфигъ углыйның
4) хәләле Хәдиҗә Әйүб кызы
5) 28 йәшендә вафат итде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Дусым авылыннан Габделфатих
3) Габденнәфигъ улының
4) хәләле – Хәдичә Әюб кызы –
5) 28 яшендә вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 76(91)x32x12.

10. Сәгъдеддин Рәхмәтулла улына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Сәгъдеддин
3) Рәхмәтулла углы
4) 1319 сәнәи һиҗриййә
5) 1901 сәнәи миладиййә
6) 14 нче агусда
7) 55 йәшендә
8) гарикы рәхмәт улсун».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада идеңез
3) йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Сәгъдеддин
3) Рәхмәтулла улы
4) һиҗри 1319 елда,
5) милади 1901 елның
6) 14 августында
7) 55 яшендә [вафат яки җирләнде].
8) Рәхмәткә күмелсен».

Арткы ягы[42]:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә
3) алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 79(91)х31х11.

11. Гали кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Биби...
2) Гали кызы
3) 45 йәшендә
4) 1910 нчы йылда
5) рамазан шәриф
6) 15 ндә мәдфүн рахимәллаahү
7) рахмәтән вәәсигаh
8) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Биби[камәр]
2) Гали кызы
3) 45 яшендә
4) 1910 елның
5) 15 рамазан
6) шәрифендә җирләнде. Аллаh киң рәхмәте
7) белән рәхим кылсын,
8) амин».

Таш үлчәмнәре: 93(113)х34х14.

12. Бәхрелхәят Сәгъдеддин мулла хатынына куелган кабер ташы, 1879 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаahү ли-мән зәәрании
2) ошбу каберә назилә
3) Бәхрелхәйәт зәүҗәте
4) мулла Сәгъдеддин хәзрәт
5) 1296 hиҗриййә
6) зилхиҗҗәнең 19 нда
7) 77 йәшендә мәрхүмә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаh рәхим кылсын.
2) Бу кабергә иңүче
3) Бәхрелхәйәт мулла
4) Сәгъдеддин хәзрәт хатыны
5) hиҗри 1296 [елның]
6) 19 зөлхиҗҗәсендә
7) 77 яшендә мәрхүмә [булды]».

Таш үлчәмнәре: 113х31х17.

13. Дамелла Насреддин дамелла Сәгъдеддин улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаahү ли-мән зәәрании
2) карйәи Дусым имам
3) дамулла Насреддин
4) ибне әл-хаҗҗе дамулла
5) Сәгъдеддин 40 йыл имамәт
6) идүб 69 йәшендә 1905 сәнәи
7) мәсихиййә 6 нчы април 1323 сәнәи hиҗриййә
8) 14 нче сәфәрел-хәйердә мәнзиле ахирәтә
9) назил рахимәhүллаahү Тәгаалә рахмәтән вәәсигаh».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[43].

Сул ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[44].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәтәбәhәә мулла Сәлахеддин
2) Казаклари».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаh рәхим кылсын.
2) Дусым авылы имамы
3) дамелла Насреддин
4) ибне хаҗи дамелла
5) Сәгъдеддин, 40 ел имамлык
6) итеп, 69 яшендә милади 1905
7) елның 6 апрелендә, hиҗри 1323 елның
8) 14 сәфәрендә ахирәт йортына
9) иңде. Аллаh Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Сул ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

[42] Вертикаль рәвештә язылган.

[43] Дәвамы сул ягында.

[44] Башы уң ягында.

Арткы ягы:
1) «Моны язды: мулла Сәлахеддин
2) Казаклари».

Таш үлчәмнәре: 124(143)х33х17.

Әлеге кабер иясе 1864 елның 1 сентябрендә указ (номеры: №6901) алып, авылга мулла итеп билгеләнгән.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 1 б. №6.

14. Мөхәммәдсиддыйк Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Мөхәммәдсиддыйк
3) Хәбибулла
4) углы 4 нче ийүндә
5) 1335 сәнәи һиҗриййә
6) 1916 сәнәи миладиййә
7) 79 йәшендә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мөхәммәдсиддыйк
3) Хәбибулла
4) улы һиҗри
5) 1335 елда, милади
6) 1916 елның 4 июнендә
7) 79 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 87х35х11.

15. Хисмәтулла Зәйнулла улына куелган кабер ташы, 1932 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә
2) иләйһи рааҗигуун
3) Хисмәтулла Зәйнулла
4) углы вафат булды
5) 1 нче априлдә 76 нч
6) йәшендә рәхим илә тале
7) Тәгалә Аллаһ 1932 нче йыл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.
3) Хисмәтулла Зәйнулла
4) улы 1 апрельдә
5) 76 нчы яшендә
6) вафат булды. Аллаһ Тәгалә
7) рәхим кылсын. 1932 ел».

Таш үлчәмнәре: 71х33х8.

16. Габденнасыйр мулла Габдешшакир улына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бисмилләәһир-рахмәән-
2) -ир-рахиим...
3) ...
4) Габденнасыйр мулла
5) Габдешшакир улы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ-
2) исеме белән...
3) ...
4) Габденнасыйр мулла
5) Габдешшакир улы».

Таш үлчәмнәре: 80х33х8.

17. Мөхәммәдхәнәфи Мөхәммәдһади улына куелган кабер ташы, 1939 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Мөхәммәдхәнәфи
2) Мөхәммәдһади
3) углы
4) туган йылы 1864
5) вафаты 15/XII 1939
6) Аллаһ рәхмәт кыйлсун
7) әткәбезгә кызың Мә...дән
8) соңгы бүләк».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мөхәммәдхәнәфи
2) Мөхәммәдһади
3) углы.
4) туган елы: 1864,
5) вафаты: 15/XII 1939.
6) Аллаһ рәхим кылсын.
7) Әткәбезгә кызың Мә...дән
8) соңгы бүләк».

Таш үлчәмнәре: 70х37х17.

18. Галиулла Мортаза улына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбрah
2) Галийулла Мортаза
3) углы 63 йәшдә
4) 1908 сәнә ийүлдә
5) вафат Аллah
6) рәхмәт кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәраллаahү зүнүүбәh».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаahү мәркадәh».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Галиулла Мортаза
3) улы 63 яшьтә
4) 1908 елның июлендә
5) вафат. Аллah
6) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллah аның гөнаһларын кичерсен».

Сул ягы: «Аллah аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 64х30х11.

19. Мөхәммәдзакир Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1886 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәhи вә иннәә иләйhи раажигуун
2) мәрхүм Мөхәммәдзакир
3) Гобәйдулла углы
4) 51 йәшендә 3
5) нче ийүндә 1886
6) нчы йылда вафат
7) Аллаhның рәхмәтендә улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаhныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Мәрхүм Мөхәммәдзакир
3) Гобәйдулла улы
4) 51 яшендә 1886
5) елның 3
6) июнендә вафат.
7) Аллаhның рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 71х27х14.

Иске Йогып авылы зираты

1. Мулла Мәһди Габдрахман улына һәм Сафагәрәй мулла Мәһди улына куелган кабер ташы, 1840 һәм 1850 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәhи Тәгаалә
2) бу каберә назил мәрхүм
3) мулла Мәһди Габдеррахман
4) углы тарих румиййә илә
5) 1840 нчы йылда 60
6) йәшендә дарел-бәкайә рихләт
7) кыйлды Аллаh рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Дога берлә кыйлыңгыз рухымы шад
2) кәтәбәһәә мөәзине
3) Үртәм Лотфулла».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әс-сәләәмү
2) галәйкүм йәә әһләл-кубүүр
3) саахибү һәзәәл-кабри мәрхүм
4) Сафагәрәй мулла Мәһди
5) углы тарих румиййә илә
6) 1850 нче йылда
7) 40 йәшендә вафат
8) Аллаh рәхмәт әйләсүн
9) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) мулла Мәһди Габдрахман
4) улы милади белән
5) 1840 елда 60
6) яшендә мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаh рәхим кылсын».

Уң ягы:
1) «Дога белән рухымны шатландырыгыз.
2) Моны язды: Үртәм
3) мөәзине Лотфулла».
4)

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Арткы ягы:
1) «Сезгә
2) сәлам булсын, әй, каберләр ияләре.
3) Бу кабер иясе мәрхүм
4) Сафагәрәй мулла Мәһди
5) улы милади белән
6) 1850 елда
7) 40 яшендә вафат.
8) Аллаһ рәхим кылсын,
9) амин».

Таш үлчәмнәре: 90х31х13.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 1 б. №7.

2. Мөхәммәдгали Мөхәммәдсадыйк улына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) милади 1897 сәнә
3) ийүн 16 нда Мөхәммәдгали
4) Мөхәммәдсадыйк углы
5) 48 йәшендә мәдфүн».

Арткы ягы (уеп һәм калкытып язылган[45]):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) саахибүл-мәркади
3) Мөхәммәдгали Мөхәммәдсадыйк
4) углы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) милади 1897 елның
3) 16 июнендә Мөхәммәдгали
4) Мөхәммәдсадыйк улы
5) 48 яшендә җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Кабер иясе:
3) Мөхәммәдгали Мөхәммәдсадыйк
4) улы».

Таш үлчәмнәре: 92х35х13.

3. Мөхәммәдсадыйк Сабит улына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) Җогуб авылының Мөхәммәдсадыйк
3) Сабит углы даре фәнадан
4) даре бәкайә рихләт әйләде Аллаһ
5) Тәбарәкә вә Тәгалә рәхмәте гарикъ әйләб
6) җәннәтел-маэва илә мөшәррәф әйләйә
7) 85 йәшендә 1901 нче йылда
8) 15 нче гыйнварда мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Йогып авылыннан Мөхәммәдсадыйк
3) Сабит улы фани дөньядан
4) мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ
5) Тәбарәкә вә Тәгалә рәхмәткә күмеп,
6) Маэва җәннәте белән хөрмәтләсен.
7) 85 яшендә 1901 елның
8) 15 гыйнварында җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 79(86)х35х14.

4. Бибихәмидә Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер сахибәсе
3) Бибихәмидә Фәтхулла
4) кызы Әхмәдулла
5) Габидулла углы-
6) -ның зәүҗәсе
7) 1897 нче сәнәдә
8) 20 нче ийүндә
9) 70 йәшендә вафат
10) Аллаһ рәхмәтендә улсун
11) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер иясе
3) Бибихәмидә Фәтхулла
4) кызы – Әхмәдулла
5) Габидулла улы-
6) -ның хатыны –
7) 1897 елның
8) 20 июнендә
9) 70 яшендә вафат.
10) Аллаһ рәхмәтендә булсын,
11) амин».

Таш үлчәмнәре: 80х29х12.

[45] Ахыргы юлы гына калкытып, калганнары уеп язылган.

5. Гаҗибелкамал Нәҗмеддин кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) 1905 нче 21 нче дикәбрдә
3) Гаҗибелкамал Нәҗмеддин кызы
4) Мөхәммәдсадыйк Сабит углының
5) зәүҗәсе 66 йәшендә даре фәнадан даре
6) бәкайә рихләт әйләде
7) рахмәтүллаәһи рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1905 [елның] 21 декабрендә
3) Гаҗибелкамал Нәҗмеддин кызы –
4) Мөхәммәдсадыйк Сабит улының
5) хатыны – 66 яшендә фани дөньядан мәңгелек
6) дөньяга күчте.
7) Аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 89(104)х35х14.

6. Гаҗибкамал Сәгыйдь кызына куелган кабер ташы, 1867 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) милади 1867 сәнә
3) ийүл 29 нда
4) Гаҗибелкамал Сәгыйдь
5) кызы Мөхәммәдсадыйк Сабит
6) углының әһлийәсе
7) 38 йәшендә мәдфүнә».

Уң ягы (уеп язылган): «Би-хәккый гаршин әгъзамин нуури куръәән»[46].

Сул ягы (уеп язылган): «Илаһи мәгъфирәт кыйл Раббы Гофран»[47].

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Бу төрбәи шәриф
2) Гаҗибелкамал Сәгыйдь
3) кызының мәркадидүр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1867 елның
3) 29 июлендә
4) Гаҗибкамал Сәгыйдь
5) кызы – Мөхәммәдсадыйк Сабит
6) улының хатыны –
7) 38 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Бөек гареш, Коръән нурының хакы белән».

Сул ягы: «Илаһым, гафу ит, Кичерүче Раббым».

Арткы ягы:
1) «Бу төрбә шәриф
2) Гаҗибкамал Сәгыйдь
3) кызының кабередер».

Таш үлчәмнәре: 95х32х13.

7. Әхмәдулла Габидулла улына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Әхмәдулла Габидулла
4) углы 1893
5) нче сәнәдә
6) 19 нчы дикәбрдә
7) 76 йәшендә
8) вафат улды
9) Аллаһ рәхмәтендә
10) улсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер иясе
3) Әхмәдулла Габидулла
4) улы 1893
5) елның
6) 19 декабрендә
7) 76 яшендә
8) вафат булды.
9) Аллаһ рәхмәтендә
10) булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 90х29х11.

8. Ибраһим Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1879 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу кабер иясе Түбән

[46] Башы сул ягында.
[47] Дәвамы уң ягында.

3) Көйүк илинең мөтәвәффа
4) мәрхүм Ибраһим
5) Исмәгыйль углы 67
6) йәшендә 1879 нчы йыл 1 нче
7) үктәбрдә кабере нурлы булсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад
2) йазгучы
3) Сәлах мулла
4) Казаклари».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабер иясе Түбән
3) Көек иленнән
4) мәрхүм Ибраһим
5) Исмәгыйль улы 67
6) яшендә 1879 елның 1
7) октябрендә вафат. Кабере нурлы булсын».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Сул ягы:
1) «Дога белән рухымны шатландырыгыз.
2) Язучы:
3) Сәлах мулла
4) Казаклари».

Таш үлчәмнәре: 98х34х17.

9. Бибисабира Хәлилулла кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) милади 1898 сәнә
3) ийүн 14 ндә Бибисабира
4) Хәлилулла кызы
5) Мөхәммәҗан бине Сафагәрәй
6) әһлийәсе 46 йәшендә
7) мәдфүнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1898 елның
3) 14 июнендә Бибисабира
4) Хәлилулла кызы –
5) Мөхәммәҗан бине Сафагәрәй
6) хатыны – 46 яшендә
7) җирләндe».

Таш үлчәмнәре: 86х30х10.

10. Бибилатыйфа Мөхәммәдсадыйк кызына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибилатыйфа Мөхәммәдсадыйк
4) кызы Әхмәдгәрәй Сафагәрәй
5) углыйның әһлийәсе вафат
6) 1893 сәнәи миладиййә 15 нч
7) ийүлдә 43 йәшендә
8) рахимәһәәллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Нә дәклү улса да гомерең тавил гакыйбәт бер көн әҗәл әйләр галил».

Сул ягы (уеп язылган): «Йиде башлу аждаһадыр бу җиһан бу әҗәл һич кемсәйә вирмәс әман».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Бибилатыйфа Мөхәммәдсадыйк
4) кызы – Әхмәдгәрәй Сафагәрәй
5) улының хатыны –
6) милади 1893 елның 15
7) июлендә 43 яшендә вафат.
8) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Ни тиклем гомерең озын булса да, ахырдан беркөн әҗәл хәлсез итәр».

Сул ягы: «Җиде башлы аждаһадыр бу җиһан, бу әҗәл һичкемгә бирмәс иминлек».

Таш үлчәмнәре: 123х35х15.

11. Шаһгәрәй мулла Мәһди улына һәм Бәдигылҗамал Нигъмәтулла кызына куелган кабер ташы, 1884 һәм 1888 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер мәрхүм Шаһгәрәй
3) мулла Мәһди углы
4) 1884 нче сәнә март

5) 24 ндә 75 йәшендә
6) вафат Аллаһ рәхмәт
7) әйләсүн амин».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтү һәзәәл-кабри мәрхүмә
2) Бәдигылҗамал Нигъмәтулла кызы
3) Сафагәрәй әһлийәсе
4) 1888 нче миладиййә
5) 14 мартда 70 йәшендә
6) мәдфүнә нәүвәраллаһү кабраһәә
7) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер мәрхүм Шаһгәрәй
3) мулла Мәһди улыныкы,
4) 1884 елның 24
5) мартында 75 яшендә
6) вафат. Аллаһ рәхим
7) кылсын, амин».

Сул ягы:
1) «Бу кабер иясе мәрхүмә
2) Бәдигылҗамал Нигъмәтулла кызы –
3) Сафагәрәй хатыны
4) милади 1888 елның
5) 14 мартында 70 яшендә
6) җирләнде. Аллаһ аның каберен нурландырсын,
7) амин».

Таш үлчәмнәре: 94х31х13.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 1 б. №8.

12. Гыйләҗеддин Халид улына куелган кабер ташы, 1883 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһил-галиййил-кәбиир
2) руми 1883 сәнә
3) април 12 ндә һиҗри 1301
4) сәнә җөмадиәл-ахир 15 ндә
5) Җогуб авылында Гыйләҗ-
6) -еддин Халид углы сиһшәнбә
7) көн даре бәкайә»[48].

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары һәшишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (калкытып язылган)[49]:
1) «Рихләт кыйлды
2) рахимәллааһү Тәгаалә
3) рахмәтән вәәсигаһ
4) әәмиин»[50].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Олуг, Бөек Аллаһта.
2) Милади 1883 елның
3) 12 апрелендә, һиҗри 1301
4) елның 15 җөмадиәл-ахирендә
5) Йогып авылында Гыйләҗ-
6) -еддин Халид улы сишәмбе
7) көн мәңгелек дөньяга [күчте]».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы:
1) «Күчте.
2) Аллаһ Тәгалә аны киң
3) рәхмәте белән рәхим кылсын,
4) амин».

Таш үлчәмнәре: 103(123)х36х20.

13. Бибимәфтуха Габделлатыйф кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә күллү
2) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт румиййә
3) илә 1897 сәнә гыйнвар 17
4) нче көнендә һиҗриййә илә
5) 1315 нче сәнә маһе шәгъбан
6) 27 ндә Җогуб авылының
7) Гыйлажеддин Халид
8) углының зәүҗәсе Бибимәфтуха»[51].

Сул ягы (уеп язылган): «Габделлатыйф кызы 59 йәшендә җомга көн кич дарел-бәкайә рихләт кыйлды»[52].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Вә кыйфтү галәәл-әхиббәти хиинә саффәт
2) кубүүруһүм кә-әфраасир-риһәән
3) фәләммәә ән бәкиитү вә фәәда дәмгыый
4) раәт гайнәәйә бәйнәһүм мәкәәнии».

[48] Дәвамы сул ягында.

[49] Диагональ буенча язылган.
[50] Башы алгы ягында.
[51] Дәвамы сул ягында.
[52] Башы алгы ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр
2) җан иясе үлемне татыячак». Милади
3) белән 1897 ел гыйнварының 17
4) нче көнендә, һиҗри белән
5) 1315 елның 27
6) шәгъбанында Йогып авылыннан
7) Гыйлаҗеддин Халид
8) улының хатыны Бибиәфтуха».

Сул ягы: «Габделлатыйф кызы 59 яшендә җомга көн кич мәңгелек дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Дусларым янына, аларны рәт белән урнаштырганда, килеп бастым;
2) аларның каберләре чабыш атлары сыман.
3) Шул чакта еладым һәм күз яшьләрем ташып чыкты,
4) күзләрем алар арасында үземнең урынымны күрде».

Таш үлчәмнәре: 112(124)x37x14.

14. Гайшә Габделлатыйф кызына һәм Фазлулла Мөхәммәдгали улына куелган кабер ташы, 1901 һәм 1911 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу кабер ийәсе мәрхүмә
3) Гайшә Габделлатыйф
4) кызы Фазлулла
5) җәмәгате 1901 нче йыл
6) аугуст 5 ндә 71
7) йәшдә вафат Аллаһ
8) рәхмәт әйләсүн амин».

Сул ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
2) мәрхүм Фазлулла
3) Мөхәммәдгали углы 1911 нч
4) йыл синтәбр 1 ндә 88
5) йәшендә вафат
6) рахимәһүллааһү рахмәтән
7) вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Гайшә Габделлатыйф
4) кызы – Фазлулла
5) җәмәгате 1901 елның
6) 5 августында 71
7) яшьтә вафат. Аллаһ
8) рәхим кылсын, амин».

Сул ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Арткы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Мәрхүм Фазлулла
3) Мөхәммәдгали улы 1911
4) елның 1 сентябрендә 88
5) яшендә вафат.
6) Аллаһ аны киң рәхмәте белән
7) рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 83x31x9.

15. Хөсәен Сабит улына куелган кабер ташы, 1886 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) мәрхүм Хөсәйен
3) Сабит углы
4) 48 йәшендә 10
5) нчы дикәбрдә 1886
6) нчы сәнәдә вафат
7) Хак Тәгаләнең
8) рәхмәтендә улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Ахирәтдә рәхмәт нурың насыйб кыйл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йа Илаһым бу колыңны гафу кыйл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Мәрхүм Хөсәен
3) Сабит улы
4) 48 яшендә 1886
5) елның 10
6) декабрендә вафат.
7) Хак Тәгаләнең
8) рәхмәтендә булсын».

Уң ягы: «Ахирәттә рәхмәт нурыңны насыйп ит».

Сул ягы: «Йа, Илаһым, бу колыңны гафу ит».

Таш үлчәмнәре: 74(88)х26х14.

16. Әхмәдвәли Сәйфулла улына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт бу каберә Олуг
3) Җогыб илинең Әхмәдвәли Сәйфулла
4) углы 29 йәшендә
5) 1900 нче сәнәи миладиййә 29 нчы
6) ийүндә 1318 нче сәнәи һиҗриййә
7) рабигыль-әүвәл 15 нче йәүмендә
8) чәһаршәнбә көн даре фәнадин
9) даре бәкайә рихләт әйләде».

Уң ягы (калкытып язылган): «Уйан бу йан бакуб дога көтәрмез хәйер ихсан дәхи өмид итәрмез».

Сул ягы (уеп язылган): «Безем Коръән укуга телемез йук тәсаддык һәм кыйлуга пылымыз йук».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак». Бу кабергә [иңүче] Олы
3) Йогып иленнән Әхмәдвәли Сәйфулла
4) улы 29 яшендә
5) милади 1900 елның 29
6) июнендә, һиҗри 1318 ел
7) рабигыль-әүвәленең 15 нче көнендә
8) чәршәмбе көн фани дөньядан
9) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Ул якка, бу якка карап, дога көтәрбез; хәер-изгелек тагын өмет итәрбез».

Сул ягы: «Безнең Коръән укуга телебез юк, сәдака бирүгә дә көчебез юк».

Таш үлчәмнәре: 96(102)х31х13.

17. Хәкимулла Сабит улына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер Хәкимулла
3) Сабит углы-
4) -ныңдур 1898
5) нче йылда 25 нче
6) майда 65 нче
7) йәшендә вафат
8) булды рахмәтүллааһи
9) Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ
10) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер Хәкимулла
3) Сабит улы-
4) -ныкыдыр, 1898
5) елның 25
6) маенда 65 нче
7) яшендә вафат
8) булды. Аңа Аллаһ Тәгаләнең
9) киң рәхмәте булсын,
10) амин».

Таш үлчәмнәре: 85х29х10.

18. Шакиржан Нигъмәтҗан улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Шакиржан Нигъмәтҗан
4) углы 1911 нче йыл
5) үктәбрдә 53 йә-
6) -шдә вафат Аллаһ
7) рәхмәтендә булсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Шакиржан Нигъмәтҗан
4) улы 1911 елның
5) октябрендә 53 я-
6) -шьтә вафат. Аллаһ
7) рәхмәтендә булсын».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Таш үлчәмнәре: 73х31х9.

19. Сәйфулла Нигъмәтулла улына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән руми 1901
3) сәнә май 20 ндә Йогубның
4) Сәйфулла Нигъмәтулла углы
5) йәкшәнбә көн даре
6) бәкайә рихләт кыйлды».

Сул ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы
2) һәркем, һәрнәрсә фани». Милади 1901
3) елның 20 маенда Йогыптан
4) Сәйфулла Нигъмәтулла улы
5) якшәмбе көн мәңгелек
6) дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 100(118)х30х15.

20. Бибишәмсия Сәйфулла кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибишәмсийә Сәйфулла
4) кызы Сәйфулла Нигъмәтулла
5) углыйның әһлийәсе
6) 1920 нче җыл 10 нчы
7) ийүл 85 йәшдә
8) вафат Аллаһ рәхмәтендә булсун
9) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Бибишәмсия Сәйфулла
4) кызы – Сәйфулла Нигъмәтулла
5) улының хатыны –
6) 1920 елның 10
7) июлендә 85 яшьтә
8) вафат. Аллаһ рәхмәтендә булсын,
9) амин».

Таш үлчәмнәре: 95х31х10.

21. Бибифатиха Галиәкбәр кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

3) 30 нчы көнендә 33 яшендә
4) Мәгърифә Бикмөхәммәд кызы
5) җан тәслим кылды.
6) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 88х31х8

51. Фәрхезадә Габидулла кызына куелган кабер ташы, 1847 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Бу кабернең сахибе Фәрхезадә
2) исемилә йад идеңез догада
3) вабадин һәм баладин рихләт итде
4) мең ике йөз дә алтмыш өчдә китде
5) әткәсенең исеме Габидулла
6) дәхи зәүҗенең исеме ...улла
7) 1263 гарәбиййә 1847 русиййә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабернең иясе Фәрхезадә
2) Исеме белән искә алыгыз догада.
3) Вабадан һәм баладан күчте [ваба авыруыннан һәм бала табу аркасында],
4) Мең ике йөз дә алтмыш өчтә китте [һиҗри 1263 елда вафат].
5) Әткәсенең исеме Габидулла,
6) Иренең исеме ...улла.
7) Һиҗри 1263, милади 1847 [ел]».

Таш үлчәмнәре: 75х42х12

52. Мулла Фазлулла Нигъмәтулла улына куелган кабер ташы, 1852 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) әл-мәрхүүмүл-мәгъфүүру мулла Фазлулла
3) Нигъмәтулла углы 52 йыл имам
4) улуб сәнә 1852 нче йылда вә гарәбиййә
5) сәнә 1269 нчы йылда 80 йәшендә
6) даре фәнадан даре бәкайә
7) рихләт әйләде гафәраллаһү зүнүүбәһүмәә
8) кәәнә имәәмән гаалимән вә мүршидән кәәмиләә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Рәхим кылынган, гафу ителгән мулла Фазлулла
3) Нигъмәтулла улы, 52 ел имам
4) булып, 1852 елда, һиҗри
5) 1269 елда 80 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ аларның икесенең дә гөнаһларын кичерсен.
8) Гыйлемле имам һәм камил туры юл күрсәтүче иде».

Таш үлчәмнәре: 80х38х14.

Әлеге кабер иясенең фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Фазлулла бине Нигъмәтулла бине Бәшир бине Габдерәхим бине Уразмөхәммәд[105]. Ул авылда бик озак еллар имам-хатыйб вазыйфасын башкарган.

53. Әхмәтҗан Йосыф улына куелган кабер ташы[106], 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллаһ
2) Мүхәммәдүр-расүүлүллаһ
3) Әхмәтҗан
4) Йосыф углы
5) 1870 – туа
6) 1927 – нуйәбрдә
7) вафат
8) Алла рәхмәт

[105] Мәржани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 241.

[106] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә игътибарга лаек.

9) кылсун
10) кузларының
11) соңгу
12) бүләгү».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк,
2) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
3) Әхмәтҗан
4) Йосыф улы
5) 1870 [елда] туа,
6) 1927 [елның] ноябрендә
7) вафат.
8) Алла рәхим
9) кылсын.
10) Кызларының
11) соңгы
12) бүләге».

Таш үлчәмнәре: 99x28x8.

54. Бәйрәмгали Галим улына һәм Сәхибҗамал Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бәйрәмгали
2) Галим углы 1927
3) нче йылда април 10 нда
4) 70 йәшендә җан
5) тәслим әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Сәхибҗамал
2) Хәбибулла кызы
3) 1927 нче сәнә нуйәбр
4) 22 ндә 59 йәшендә
5) җан тәслим әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бәйрәмгали
2) Галим улы 1927
3) елның 10 апрелендә
4) 70 яшендә җан
5) тәслим кылды».

Арткы ягы:
1) «Сәхибҗамал
2) Хәбибулла кызы
3) 1927 елның 22
4) ноябрендә 59 яшендә
5) җан тәслим кылды».

Таш үлчәмнәре: 51x26x10.

55. Хисамеддин Сәйфеддин улына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Хисамеддин
2) бине Сәйфеддин
3) 1900 сәнә гыйнвар
4) 15 ндә 70 нче
5) йәшендә Хакга
6) васыйл улды
7) Аллаһ рахимәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хисамеддин
2) бине Сәйфеддин
3) 1900 елның 15
4) гыйнварында 70 нче
5) яшендә Хакка [Аллаһка]
6) иреште.
7) Аллаһ аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 99x33x10.

56. Ибраһим Хисамеддин улына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ибраһим
2) Хисамеддин улы
3) 1900 нче йылда синтәбр
4) 15 ндә 47 йәшендә
5) җан тәслим әйләде
6) Аллаһ рәхмәт әйләйә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ибраһим
2) Хисамеддин улы
3) 1900 елның 15
4) сентябрендә 47 яшендә
5) җан тәслим кылды.
6) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 71(81)x29x8.

57. Сәхибкамал Габделгафур кызына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Сәхибелкамал
2) Габделгафур кызы

3) Хисамеддин җәмәгате
4) 1919 нчы сәнә май 12 сендә 62 йәшенд
5) даре фәнадан даре бәкайә
6) рихләт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Сәхибкамал
2) Габделгафур кызы –
3) Хисамеддин җәмәгате –
4) 1919 елның 12 маенда 62 яшенд[ә]
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте».

Таш үлчәмнәре: 84(94)x30x9.

58. Хәмдениса Гыймадеддин кызына куелган кабер ташы, 1935 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әхмәдгәрәй хәләле
2) Хәмденниса Гыймадеддин
3) кызы 1935 нче сәнә
4) нуйәбр 20 нче көне 58 йәшендә
5) җан тәслим әйләде
6) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Әхмәдгәрәй хәләле –
2) Хәмдениса Гыймадеддин
3) кызы – 1935 ел
4) ноябренең 20 нче көнендә 58 яшендә
5) җан тәслим кылды.
6) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 66(78)x31x9.

59. Фатыйма Мөхәммәдъяр кызына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Фатыйма Мөхәммәдъяр
2) кызы Ибраһим җәмәгате
3) 1926 нчы сәнә август
4) 12 нче көне 60 йәшендә
5) җан тәслим әйләде
6) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Фатыйма Мөхәммәдъяр
2) кызы – Ибраһим җәмәгате –
3) 1926 ел августының
4) 12 нче көнендә 60 яшендә
5) җан тәслим кылды.
6) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 72(87)x29x8.

60. Үлмәс Мәрдхуҗа оныгына куелган кабер ташы, 1611 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә вә мәә тәдрии
2) нәфсүм-би-әййи әрдыйң тәмүүт вә каалә Сүбхәәнәһү
3) вә Тәгааләә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
4) тарих миң йыл узуб
5) йегермедә мөбарәк мөхәррәм
6) айында ирде Мәрд хуҗа йүчү-
7) -не Үлмәскә Аллаһ Тәгалә
8) рәхмәт кыйлсун».

Уң ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-карааарии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һичбер кеше
2) кайсы җирдә үләчәген белмәс» һәм [Аллаһ] Сүбхәнәһү
3) вә Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
4) Мең ел узып,
5) егерменче [елның] мөбарәк мөхәррәм
6) аенда иде, Мәрдхуҗа оны-
7) -гы Үлмәсне Аллаһ Тәгалә
8) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 124x51x20.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 2 б. №17.

61. Билгесез кабер ташы, XVI гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «...
2) каалә...
3) әд-дүнйәә...
...».

Уң һәм сул якларындагы язулары бөтенләй диярлек сөртелеп беткән.

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Бу ләүхне валидәсе
2) Татлы би бина кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «...
2) [Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын)] әйтте:
...
3) «Дөнья – ...
...».

Арткы ягы:
1) «Бу ташны анасы
2) Татлы би куйды».

Таш үлчәмнәре: 115х50х15.

62. Билгесез кабер ташы, XVI гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы һәм сул якларындагы язулары бөтенләй диярлек сөртелеп беткән.

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән [бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии]».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, [бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары]».

Таш үлчәмнәре: 109х51х20.

63. Чирүче шәех Нәҗем улына куелган кабер ташы, 1513 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәллаahүл-хәйүл-ләзии ләә йәмүүтү вә күллү хәййин сә-йәмүүт
2) кааләллаahү Сүбхәәнәһү вә Тәгааләә вә мәә тәдрии нәфсүм-
3) би-әййи әрдыйң тәмүүт вән-нәбии галәйһис-сәләәм
4) әд-дүнйәә сәәгатүн фәҗгальһәә таагah
5) каалән-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә мәзрагат-
6) -үл-әәхыйрah тарих тукуз йөз ун
7) ту[куз]да шәгъбан айында шәйех Нәҗем углы
8) Чирүҗе даре фәнадан даре бәкага рихләт кыйлды».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Сул ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул Аллah – Тере, Үлмәүче һәм һәр җан иясе үләчәк.
2) Аллah Сөбханәһү вә Тәгалә әйтте: «Һичбер кеше кайсы
3) җирдә үләчәген белмәс». Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) [әйтте]:
4) «Дөнья бер сәгатьлек, аны [Аллahка] итагать белән үткәр».
5) Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья – ахирәт
6) басуы». Тугыз йөз ун
7) ту[кузынчы елның] шәгъбан аенда шәех Нәҗем улы
8) Чирүче фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 109х53х20.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 2 б. №18.

64. Билгесез[107] кабер ташы, 1528 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли в-
4) -әл-икраам тарих тукуз йөз у-
5) -туз түрт дә шәгъбан айында
6) ...».

[107] Г. Рәхим әлеге ташның соңгы юлында Әхмәд исемен укыган (Кара: Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / Төз. Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 272). Хәзерге көндә ташның аскы өлеше ватылса да, кабер иясе атасының исеме Әхмәд булган, дип фаразларга мөмкин.

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Сул ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның
3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә
4) калачак. Тугыз йөз у-
5) -тыз дүртенче [елның] шәгъбан аенда
6) ...».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 100x50x15.

65. Сүдәкбай Нәҗимбай улына куелган кабер ташы, 1548–1549 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә вә мәә тәдрии
2) нәфсүм-би-әййи әрдыйң тәмүүт вә каалә Сүбхәәнәһү
3) вә Тәгааләә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
4) һәзәә мәкъбәратүн мөнәүвәратүн солтанел-гали
5) тарих тукуз йөз иллик бишдә
6) ир дикем Нәҗим бай углы Сүд-
7) -әк бай әүфад булды дар-
8) -ел-фәнадан дарел-бәкага рихләт кыйлды Хак Тәгалә
9) рәхмәт кыйлсун».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Сул ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Бу ләүхне хәләле
2) Дәүләт солтан кыйлды бина».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һичбер кеше
2) кайсы җирдә үләчәген белмәс» һәм [Аллаһ] Сөбханәһү
3) вә Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
4) Бу нурлы кабер бөек солтанныкы,
5) тугыз йөз илле бишенче [елда]
6) Нәҗимбай улы Сүд-
7) -әк вафат булды, фани
8) дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Хак Тәгалә
9) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Арткы ягы:
1) «Бу ташны хәләле
2) Дәүләтсолтан куйды».

Таш үлчәмнәре: 187x53x26.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 3 б. №19.

66. Хасай Шүдәк улына куелган кабер ташы, 1610 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә вә мәә тәдрии
2) нәфсүм-би-әййи әрдыйң тәмүүт вә каалә Сүбхәәнәһү
3) вә Тәгааләә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
4) кааләи-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә мәзрагатүл-әәхыйраһ
5) тарих миң йыл узуб ун
6) сигездә мөбарәк зилхиҗҗә айында
7) Шүдәк углы Хасайга Аллаһ
8) рәхмәт кыйлсун амин раббәл-гааләмиин».

Уң ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Арткы ягы (калкытып язылган): «Бу ләүхне инеси Чин Булат бина кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һичбер кеше
2) кайсы җирдә үләчәген белмәс» һәм [Аллаһ] Сөбханәһү
3) вә Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
4) Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья – ахирәт басуы».
5) Мең ел узып, ун
6) сигезенче [елның] мөбарәк зөлхиҗҗә аенда
7) Шүдәк улы Хасайны Аллаһ
8) рәхим кылсын, амин, [йә], Галәмнәрнең Раббысы».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Арткы ягы: «Бу ташны энесе Чинбулат куйды».

Таш үлчәмнәре: 87х65х23.

67. Мөхәммәдгали Хәсән улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Иске Өҗем авылыйның Мөхәммәд-
3) -гали Хәсән углы 1918 нче сәнә
4) үктәбр 1 нче көне 66 йәшендә
5) даре фәнадан даре бәкайә
6) рихләт әйләде Аллаһ
7) рәхмәт әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Иске Өҗем авылыннан Мөхәммәд-
3) -гали Хәсән улы 1918 ел
4) октябренең 1 нче көнендә 66 яшендә
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһ
7) рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 98х31х12.

68. Сибгатулла Фазлулла улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаләә
2) 1905 нче сәнә нуйәбр 2 нче көне
3) даре фәнадан даре бәкайә
4) рихләт әйләде Сибгатулла
5) Фазлулла углы
6) 62 йәшендә Хода рәхмәте
7) гарикъ әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1905 ел ноябренең 2 нче көнендә
3) 62 яшендә Сибгатулла
4) Фазлулла улы
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Хода рәхмәткә
7) күмсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 86х32х13

69. Бибизөһрә Әмир кызына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1901 сәнә
3) ийүл 4 Иске Өҗемнең
4) Фазлулла хәләле Бибизөһрә
5) Әмир кызы 85 йәшендә
6) даре бәкайә рихләт кыйлды».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1901 елның
3) 4 июлендә Иске Өҗемнән
4) Фазлулла хәләле – Бибизөһрә
5) Әмир кызы – 85 яшендә
6) мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 93х35х17.

70. Фәхрениса Шаһиәхмәд Бикмөхәммәд улының кызына куелган кабер ташы, 1907ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Иске Өҗем авылыйның
3) Сибгатулла Фазлулла
4) углының хәләле Фәхренниса

5) Шаһиәхмәд кызы 63 йәшенд
6) даре фәнадан даре бәкайә
7) рихләт итде Аллаһ рәхмәт әйләйә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Атасы Шаһиәхмәд бине Бикмөхәммәд әл-Мәмсәви
2) Фәхренниса
3) һижриййә иләи 1325 нче сәнә
4) маһе рамазанның 7 нче көнендә
5) румиййә иләи 1907 нче йылда
6) синтәбрнең 29 нчы көнендә
7) мәдфүн Хода рәхмәтенә гарикъ
8) әйләб җәннәт илә мөшәррәф әйләйә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Иске Өҗем авылыннан
3) Сибгатулла Фазлулла
4) улының хәләле – Фәхрениса
5) Шаһиәхмәд кызы – 63 яшенд[ә]
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Фәхрениса
2) (атасы Шаһиәхмәд бине Бикмөхәммәд Мәмсәви)
3) һижри белән 1325 ел
4) рамазан аеның 7 нче көнендә,
5) милади белән 1907 ел
6) сентябренең 29 нчы көнендә
7) җирләнде. Хода, рәхмәтенә
8) күмеп, җәннәт белән хөрмәтләсә иде».

Таш үлчәмнәре: 98x31x13.

71. Зәкәрия Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Йә Аллаһ Тәгалә мәдфүн
2) тарих румиййә 4 ндә агуст
3) 1917 сәнә дүшәнбә көн
4) дарел-фәнадан
5) дарел-бәкайә рихләт
6) кыйлды Зәкәрийә
7) Хәбибулла углы
8) 7 йәшендә
9) Хода рәхмәт
10) әйләйә амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ
2) Аллаһ Мүхәммәдүр-расүүл[108]
3) атасы Хәбибулла
4) бина кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Йә, Аллаһ Тәгалә.
2) Милади 1917 елның
3) 4 августында дүшәмбе көн
4) Зәкәрия
5) Хәбибулла улы
6) 7 яшендә
7) фани дөньядан
8) мәңгелек дөньяга күчте.
9) Хода рәхим
10) кылсын, амин».

Арткы ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк,
2) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
3) Атасы Хәбибулла
4) куйды».

Таш үлчәмнәре: 95(105)x24x10.

72. Зөләйһа Монасыйб кызына куелган кабер ташы, 1873 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) бу каберә назил Иске Өҗем авылыйның
3) Мөхәммәд зәүҗәсе Зөләйһа Монасыйб кызы
4) 1873 нче йылда 11 нче үктәбрдә
5) 75 йәшендә даре фәнадан даре
6) бәкайә рихләт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Бу кабергә иңүче Иске Өҗем авылыннан
3) Мөхәммәд хатыны – Зөләйһа Монасыйб кызы –
4) 1873 елның 11 октябрендә
5) 75 яшендә фани дөньядан мәңгелек
6) дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 105(128)x36x11.

[108] Бу җөмләдә кайбер сүзләрнең урыннары ялгыш алмашынган.

73. Шәһребану Габди кызына куелган кабер ташы, 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) руми 1882 сәнә май 26 да
3) һиҗри 1299 сәнә рәҗәб 28
4) ндә Иске Өҗемнең Шәһре-
5) -бану Габди кызы Фәтхулла
6) Вәлид углының зәүҗәсе
7) 85 йәшдә даре бәкайә
8) рихләт кылды таййибәллаһү сәраһәә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу ләүх кызы Фәрхе-
2) -нур бина кылдурды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади 1882 елның 26 маенда,
3) һиҗри 1299 елның 28 рәҗәбен-
4) -дә Иске Өҗемнән Шәһре-
5) -бану Габди кызы – Фәтхулла
6) Вәлид улының хатыны –
7) 85 яшьтә мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Арткы ягы:
1) «Бу ташны кызы Фәрхе-
2) -нур куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 116(130)x36x13.

74. Фәтхулла Вәлид улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән руми 1899 сәнә
3) май 28 дә һиҗри 1317 сәнә
4) сәфәр 3 дә Иске Өҗемнең
5) Фәтхулла Вәлид углы 86
6) йәшдә даре бәкайә рихләт
7) кылды таййибәллаһү сәрааһ әәмиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу ләүх кызы Фәрхе-
2) -нур бина кылдурды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә]
2) булучы һәркем, һәрнәрсә фани. Милади 1899 елның
3) 28 маенда, һиҗри 1317 елның
4) 3 сәфәрендә Иске Өҗемнән
5) Фәтхулла Вәлид улы 86
6) яшьтә мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын, амин».

Арткы ягы:
1) «Бу ташны кызы Фәрхе-
2) -нур куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 110(130)x36x14.

75. Бибиҗәмилә Габделгани кызына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер сахибәсе
3) Бибиҗәмилә Габделгани
4) кызы Фәтхулла Вәлид
5) углының зәүҗәсе
6) 1911 нче йылда синтәбр
7) 19 нда дарел-фәнадин
8) дарел-бәкайә рихләт
9) әйләде Аллаһ рәхмәтендә
10) улсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер иясе
3) Бибиҗәмилә Габделгани
4) кызы – Фәтхулла Вәлид
5) улының хатыны –
6) 1911 елның 19
7) сентябрендә фани дөньядан
8) мәңгелек дөньяга
9) күчте. Аллаһ рәхмәтендә
10) булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 87x32x10.

76. Гайнелхәят Габдерәхим кызына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ
2) Иске Коллар авылының
3) Габдеррәхим кызы
4) Гайнелхәйәт 1923 нче сәнә
5) 22 нче нуйәбр чәршәнбә
6) көн 80 йәшендә
7) даре бәкайә рихләт әйләде».

Сул ягы (уеп язылган): «Дәфен кылынды йәшендә[109]».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Гайнелхәйәт Баһаэддин
3) зәүҗәсе 27 нче
4) рабигыль-ахир җан тәслим
5) әйләде тугры кеше
6) иде Аллаһ рәхмәт әйләйә
7) Җамаледдин Хөснеддин
8) углы бина әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ.
2) Иске Коллар авылыннан
3) Габдерәхим кызы
4) Гайнелхәят 1923 елның
5) 22 ноябрендә чәршәмбе
6) көн 80 яшендә
7) мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «[80] яшендә җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Гайнелхәят Баһаеддин
3) хатыны 27
4) рабигыль-ахирдә җан тәслим
5) кылды. Тугры кеше
6) иде. Аллаһ рәхим кылсын.
7) Җамаледдин Хөснеддин
8) улы куйды».

Таш үлчәмнәре: 98x34x12.

77. Бикмөхәммәд Фәйзулла улына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Иске Өҗем авылыйның
3) Бикмөхәммәд Фәйзулла углы
4) 1889 нчы йылда дикәбр
5) 4 нче көне 85 йәшендә
6) даре фәнадан даре бәкайә
7) рихләт әйләде
8) Хода рәхмәт әйләсүн».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Углы Гомәр Морадшин
2) бина кылдырды».

[109] Бу якта, яше язылмыйча, буш урын калдырылган.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Иске Өҗем авылыннан
3) Бикмөхәммәд Фәйзулла улы
4) 1889 ел декабренең
5) 4 нче көнендә 85 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте.
8) Хода рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Улы Гомәр Морадшин
2) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 101(122)x31x12.

78. Бибиәшрәф Сиражи кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә руух
2) Күнгәр Сира-
3) -җи кызы Иске
4) Өҗем Әүхәди
5) Бикмөхәммәд
6) углының зәү-
7) -җәсе Бибиәшрәф
8) 56 йәшендә
9) рихләт әйләде
10) 1909 = 20 нуйәбр».

Уң ягы (уеп язылган): «Ахирәтдә бар хәйер... улсун».

Сул ягы (уеп язылган): «Хәкимулла кийәве бина кыйлды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) 1909 нчы нуйәбр 20
3) Әүхәди зәүҗә
4) Бибиәшрәф 56 йәшендә
5) дарел-бәкайә рихләт
6) әйләде
7) иләәһии әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Күңгәрдән Сира-
3) -җи кызы – Иске
4) Өҗемнән Әүхәди
5) Бикмөхәммәд
6) улының хаты-
7) -ны Бибиәшрәф

8) 56 яшендә
9) 1909 [елның] 20 ноябрендә
10) күчте».

Уң ягы: «Ахирәттә бар хәерлек... булсын».

Сул ягы: «Кияве Хәкимулла куйды».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1909 [елның] 20 ноябрендә
3) Әүхәди хатыны
4) Бибиәшрәф 56 яшендә
5) мәңгелек дөньяга
6) күчте.
7) Илаһым, амин».

Таш үлчәмнәре: 93(107)x34x12.

79. Бәдигылҗамал Зиннур кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1920 нче йыл
2) үктәбр 3 нче көн
3) Бәдигылҗамал Зиннур
4) кызы 75 йәшендә җан
5) тәслим әйләде
6) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1920 ел
2) октябренең 3 нче көнендә
3) Бәдигылҗамал Зиннур
4) кызы 75 яшендә җан
5) тәслим кылды.
6) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 68x29x8.

80. Мәхфүзә Сәйфеддин хатынына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1925 нче йыл
2) 15 нче ийүлдә
3) 83 йәшендә
4) Мәхфүзә
5) ...аледдин кызы
6) Сәйфеддин
7) хәләле вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1925 елның
2) 15 июлендә
3) 83 яшендә
4) Мәхфүзә
5) ...аледдин кызы –
6) Сәйфеддин
7) хәләле – вафат».

Таш үлчәмнәре: 84(98)x28x9.

Иске Өҗем авылы басуындагы аерым каберлек

1. Четеш Нәҗимбай улына куелган кабер ташы, 1542[110] ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам
4) тарих тукуз йөз кырык сигездә
5) зил-кагдә айында Нәҗим бай углы
6) Четеш узга барганда даре фәнадин даре бәкага
7) рихләт кыйлды Хак Тәгалә рәхмәт кыйлсун амин».

Уң һәм сул якларындагы язулары бөтенләй диярлек сөртелеп беткән.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның
3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак.
4) Тугыз йөз кырык сигезенче [елның]
5) зөл-кагдә аенда Нәҗимбай улы
6) Четеш узып барганда фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Хак Тәгалә рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 155x54x20.
Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 3 б. №20.

[110] Һиҗри 948 елның зөлкагдә ае 1542 елның март аена туры килсә дә, Г. Рәхим бу датаны 1541 елның ноябре дип билгеләгән (Кара: Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / Төз. Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 272).

2. Ядегәрә Садир улына куелган кабер ташы, 1540–1541 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә вә мәә тәдрии
2) нәфсүм-би-әййи әрдыйң тәмүүт вә каалә Сүбхәәнәһү
3) вә Тәгааләә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
4) һәзәә мәкъбәратүн мөнәүвәратүн солтанел-гали
5) тарих тукуз йөз кырык йидедә ир
6) дикем Садир углы Йәдигәрә
7) кяфер кулындин шәһид булды».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Сул ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һичбер кеше
2) кайсы җирдә үләчәген белмәс» һәм [Аллаһ] Сөбханәһү
3) вә Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
4) Бу нурлы кабер бөек солтанныкы,
5) тугыз йөз кырык җиденче [елда]
6) Садир улы Ядегәрә
7) кяфер кулыннан шәһит булды».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 120x46x18.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 3 б. №21.

Иске Шимбер авылы зираты

1. Бәдреддин (?) Габделвәли улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) мәрхүм [Бәдреддин]ддин (?)[111]
4) Габделвәли углы
5) 1926 җыл гыйнвар
6) 10 вафат 72 йә-
7) -шендә рахим-
8) -әллаһү рахмәтән вәә-
9) -сигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Лаа иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм [Бәдреддин]ддин (?)
4) Габделвәли улы
5) 1926 елның 10
6) гыйнварында 72 я-
7) -шендә вафат. Аллаһ
8) киң рәхмәте белән рәхим
9) кылсын».

Уң ягы: «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Сул ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Таш үлчәмнәре: 84x26x9.

2. Хөснеддин Сиражеддин улына куелган кабер ташы, 1934 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) Хөснеддин
3) Сиражеддин
4) углы
5) 76 йәшендә
6) 1934 йылда
7) мартда вафат
8) Аллаһ рәхмәт
9) кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллааһү зүнүүбәһ».

[111] Язулары өстеннән кара буяу белән йөртелеп чыкканга күрә, исеме язылган урыны начар күренә.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Хөснеддин
3) Сиражеддин
4) улы
5) 76 яшендә
6) 1934 елның
7) мартында вафат.
8) Аллаһ рәхим
9) кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 95х32х14.

3. Гайнекамал Вәли кызына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) Гайнелкамал
3) Вәли кызы
4) Хөснеддин
5) җәмәгате 60 йәшендә
6) 1913 йылда
7) ийүл 25 ндә
8) вафат
9) Аллаһ рәхмәт кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаһү мәркадәһәә».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллаһү зүнүүбәһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Гайнекамал
3) Вәли кызы –
4) Хөснеддин
5) җәмәгате – 60 яшендә
6) 1913 елның
7) 25 июлендә
8) вафат.
9) Аллаһ рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 88х33х13.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 3 б. №22.

4. Тажеддин Вәли улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Тажеддин Вәли
4) углы 1915 нче йылда
5) үктәбрдә 75 йәшдә
6) дарел-бәкайә рихләт
7) кыйлды рахимәһүллаһү
8) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлынгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Тажеддин Вәли
4) улы 1915 елның
5) октябрендә 75 яшьтә
6) мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ киң рәхмәте
8) белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 94х30х10.

Кабакса авылы зираты

1. Хәбибулла Сәгыйдь улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) мәрхүм Хәбибулла

3) Сәгыйдь углы
4) вафат 1909 нҗы йылда
5) үктәбр 13 ндә 60 нҗы
6) йәшендә тәрке
7) дөнйа итде гафәр-
8) -аллаһү зүнүүбәһ аамиин».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Гакыйбәт
2) бер көн
3) әҗәл әйләр
4) галил»[112].

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Нә дәклү
2) булса да
3) гомерең
4) тавил»[113].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Мәрхүм Хәбибулла
3) Сәгыйдь улы
4) вафат, 1909 елның
5) 13 октябрендә 60 нчы
6) яшендә дөньяны
7) калдырды. Аллаһ
8) аның гөнаһларын гафу итсен, амин».

Уң ягы:
1) «Ахырдан
2) беркөн
3) әҗәл хәлсез
4) итәр».

Сул ягы:
1) «Ни тиклем
2) гомерең
3) озын
4) булса да».

Таш үлчәмнәре: 90х32х21.

2. Сәгыйдь Габдессәлам улына куелган кабер ташы, 1876 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибүл-мәркади
2) мәрхүм Сәгыйдь Габд-
3) -ессәлам углы тарих
4) румиййә 1876 нҗы сәнәдә
5) нуйәбр 10 нында 80 йәшендә
6) тәрке дөнйаны дүн итде
7) рахимәһүллаһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Гомеренңез үтәрен сагышлайасыз».

Сул ягы (уеп язылган): «Безә Коръән укыйб багышлайасыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер иясе
2) мәрхүм Сәгыйдь Габд-
3) -ессәлам улы
4) милади 1876 елның
5) 10 ноябрендә 80 яшендә
6) дөньяны калдырды.
7) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Гомерегез үтүенә сагышланыгыз».

Сул ягы: «Безгә Коръән укып багышлагыз».

Таш үлчәмнәре: 77х35х17.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 3 б. №23.

3. Билгесез кабер ташы, XVI гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «[Кааләллаһү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә] фәән
...».

Уң ягындагы язулары уалып беткән.

Сул ягы (калкытып язылган): «Кааләһ[н-нә-бии галәйһис-сәләәм]...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «[Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә] фани.
...».

Сул ягы: «[Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын)] әйтте...».

Таш үлчәмнәре: 60х42х23.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 3 б. №24.

[112] Башы сул ягында.
[113] Дәвамы уң ягында.

4. Насыйбулла Миңлебай улына һәм Латыйфа Гыйсмәтулла кызына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибүл-мәркади
2) мәрхүм Насыйбулла
3) Миңлебай углы тар-
4) -их румииһә 1895 нҗе сәнә
5) април 28 ндә 50 йәшендә
6) тәрке дөнйаны дүн итде
7) рахимәһүллаahү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаh».

Уң ягы (уеп язылган): «Гомеренңез үтмәген сагышлайасыз».

Сул ягы (уеп язылган): «Безә Коръән укыб багышлайасыз».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтүл-мәркади
2) мәрхүмә Латыйфа
3) Гыйсмәтулла кызы
4) тарих румииһә берлә 1895 сәнә
5) ииһүн 7 нче көнендә
6) 55. йәшендә сарайе
7) ахирәтә иртихаль әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер иясе
2) мәрхүм Насыйбулла
3) Миңлебай улы
4) милади 1895 елның
5) 28 апрелендә 50 яшендә
6) дөньяны калдырды.
7) Аллаh аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Гомерегез үтүенә сагышланыгыз».

Сул ягы: «Безгә Коръән укып багышлагыз».

Арткы ягы:
1) «Кабер иясе
2) мәрхүмә Латыйфа
3) Гыйсмәтулла кызы
4) милади белән 1895 ел
5) июненең 7 нче көнендә
6) 55 яшендә ахирәт
7) сараена күчте».

Таш үлчәмнәре: 89(99)x36x15.

5. Сәмигулла Вәлиулла улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәh
2) Сәмигулла
3) Вәлийулла
4) углы
5) 65 йәшендә
6) 1923 сәнәдә
7) фиврал 11 ндә
8) вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Сәмигулла
3) Вәлиулла
4) улы
5) 65 яшендә
6) 1923 елның
7) 11 февралендә
8) вафат».

Таш үлчәмнәре: 72(83)x17/29x16.

6. Сафиулла Гайнулла улына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәh
2) Сафиулла Гайнулла
3) углы 1337 сәнәи һиҗриййәдә
4) 14 рәҗәбдә дар-
5) -ел-бәкайә рихләт
6) әйләде Аллаh Тәгалә
7) рәхмәт әйләсен».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Сафиулла Гайнулла
3) улы һиҗри 1337 елның
4) 14 рәҗәбендә мәңгелек
5) дөньяга
6) күчте. Аллаh Тәгалә
7) рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 72x29x13.

7. Корбангали кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) ...ри Корбангали
3) кызы 1334 сәнәи һиҗриййә-
4) -дә 13 мөхәррәмдә дар-
5) -ел-бәкайә рихләт әйләде
6) Аллаһ Тәгалә рәхмәт әйләсен».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) ...ри Корбангали
3) кызы һиҗри 1334 ел-
4) -ның 13 мөхәррәмендә мәңгелек
5) дөньяга күчте.
6) Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 100х41х10.

8. Мөхәммәдсадыйк Миңлебай улына һәм Бибизөһрә Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1882 һәм 1901 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) Мөхәммәдсадыйк
3) Миңлебай у-
4) -глы 45 йәшендә
5) 1882 сәнәи миладиййә
6) 15 нче гыйнварда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бибизөһрә
2) Хәбибулла
3) кызы Мөхәммәдса-
4) -дыйк зәүҗәсе
5) 54 йәшендә
6) 1901 сәнәи миладиййә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Мөхәммәдсадыйк
3) Миңлебай у-
4) -лы 45 яшендә
5) милади 1882 елның
6) 15 гыйнварында»[вафат яки җирләнде].

Арткы ягы:
1) «Бибизөһрә
2) Хәбибулла
3) кызы – Мөхәммәдса-
4) -дыйк хатыны –
5) 54 яшендә
6) милади 1901 елда [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 79(100)х31х9.

9. Җәләй Вәлиевкә куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Вәлийеф
3) Җәләй
4) 58 йәшендә
5) 1922 йылда май
6) 9 нда вафат
7) Аллаһ рәхмәт
8) кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллааһү зүнүбәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Вәлиеф
2) Җәләй
3) туды 1864,
4) вафат 1922,
5) 9 V».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Вәлиев
3) Җәләй
4) 58 яшендә
5) 1922 елның 9
6) маенда вафат.
7) Аллаһ рәхим
8) кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».

Арткы ягы:
1) «Вәлиев
2) Җәләй
3) 1864 [елда] туды,

4) 1922 [елның]
5) 9 маенда вафат

Таш үлчәмнәре: 71х30х12.

10. Җамали Җәләевкә куелган кабер ташы, 1936 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Җәләйеф
2) Җамали
3) 44 йәшендә
4) 1936 йылда
5) агуст 8 ндә
6) вафат Аллаһ рәхмәт
7) кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаһү мәркадәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллаһү зүнүүбәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Җәләйеф
2) Җамали
3) туды 1893,
4) 1936, 8/VIII
5) вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Җәләев
2) Җамали
3) 44 яшендә
4) 1936 елның
5) 8 августында
6) вафат. Аллаһ рәхим
7) кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».

Арткы ягы:
1) «Җәләев
2) Җамали
3) 1893 [елда] туды,
4) 1936 [елның] 8 августында
5) вафат».

Таш үлчәмнәре: 70х30х12.

11. Гөлҗамал Габделхәер кызына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) мәрхүмә Гөл-
3) -җамал Габделхәйр
4) кызы вафат 1913 нҗе йылда април
5) 24 ндә 90 йәшендә
6) гафәраллаһү зүнүүбәһәә».

Уң ягы (уеп язылган): «Гомеренңез үтмәген сагышлайасыз».

Сул ягы (уеп язылган): «Безә Коръән укыб багышлайасыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Мәрхүмә Гөл-
3) -җамал Габделхәер
4) кызы 1913 елның 24 апрелендә
5) 90 яшендә вафат.
6) Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Уң ягы: «Гомерегез үтүенә сагышланыгыз».

Сул ягы: «Безгә Коръән укып багышлагыз».

Таш үлчәмнәре: 106х46х23.

Каенсар авылы зираты

1. Гыйбадеддин Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1881 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәүвәраллаһү мәркадәһ
2) Гыйбадеддин
3) Ибраһим
4) углы
5) 63 йәшендә»[114].

Уң ягы (калкытып язылган): «1881 йылда»[115].

Сул ягы (калкытып язылган): «Априлдә»[116].

[114] Дәвамы уң ягында.
[115] Башы алгы ягында, дәвамы сул ягында.

Арткы ягы (калкытып язылган)[117]:
1) «Йәә әхыый күн нәәдимән каблəл-әҗəл
2) ән-нәдәәмәтү ләә йүфиидү бәгъдəл-әҗəл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ аның каберен нурландырсын.
2) Гыйбадеддин
3) Ибраһим
4) улы
5) 63 яшендә».

Уң ягы: «1881 елның».

Сул ягы: «Апрелендә [вафат]».

Арткы ягы:
1) «Әй, кардәшем, әҗəл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит.
2) Әҗəл килгәч, тәүбә файда бирми».

Таш үлчәмнәре: 102x39x13.

2. Гали Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1890 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Əл-хүкмү лилләəһ
2) бу кабернең сахибе мәгъфүр
3) вə мәрхүм Гали Исмәгыйль
4) углы тарих миладиййə илə
5) 1890 нчы йылда ийүннең
6) 12 нче йəүмендə вə тарих һиҗриййə
7) 1307 сәнәдə 97 йəшендə дар-
8) -ел-фәнадан дарел-бəкайə рихлəт əйләде».

Уң ягы (калкытып язылган): «Бу кабер хəлләрин сагышлайасыз безə Коръəн укуб багышлайасыз».

Сул ягы (калкытып язылган): «Атаңызны догада идеңез йад тәсаддыклə рухымы кыйлыңыз шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабернең ияе гафу ителгән,
3) һəм рəхим кылынган Гали Исмәгыйль
4) улы милади белəн
5) 1890 ел июненең
6) 12 нче көнендə һəм һиҗри
7) 1307 елда 97 яшендə фани
8) дөньядан мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Бу кабер хəлләренə сагышланыгыз, безгə Коръəн укып багышлагыз».

Сул ягы: «Атагызны догада искə алыгыз, сəдака бирү белəн рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчəмнəре: 106x41x22.

3. Мəхфүзə Габделмəннаф кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвəл-халләəкуль-бəəкыый
2) саахибəтү һəзəəл-кабри мəрхүмə
3) Мəхфүзə Габделмəннаф кызы Гали
4) Исмәгыйль углының əһлийəсе
5) румиййə илə 1905 нче йылда
6) ийүн 9 нчы көнендə 75
7) йəшендə мəдфүнə нəүвəраллааһү
8) кабраһəə əəмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) Бу кабер иясе мәрхүмə
3) Мəхфүзə Габделмəннаф кызы – Гали
4) Исмәгыйль улының хатыны –
5) милади белəн 1905 ел
6) июненең 9 нчы көнендə 75
7) яшендə җирләнде. Аллаһ аның каберен
8) нурландырсын, амин».

Таш үлчəмнəре: 86x36x11.

4.Əхмəдша Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Əл-хүкмү лилләəһ
2) бу кабер сахибе
3) мəрхүм Əхмəдшаһ
4) Исмәгыйль углы
5) вафат 1921 нче җыл
6) 23 үктəбр 82
7) йəшендə рахимəһүллааһү
8) рахмəтəн вəəсигаһ əəмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Ən-нəдəəмəтү ләə түфиидү бəгъдəл-əҗəл».

[116] Башы алгы һəм уң якларында.
[117] Вертикаль рəвештə язылган.

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблəл-әҗəл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Әхмәдша
4) Исмәгыйль улы
5) 1921 елның
6) 23 октябрендә 82
7) яшендә вафат. Аллаһ аны киң рәхмәте
8) белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Әҗəл килгəч, тəүбə файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗəл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 87х32х10.

5. Сәхибҗамал Габделгафур кызына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу каберə назилə
2) мәрхүмə Сәхибҗамал
3) Габделгафур кызы
4) Әхмәдшаһ җәмәгате
5) 1917 нче җыл нуйəбр
6) 3 җомга көн 78
7) йəшендə вафат Аллаһ
8) рəхмəт əйлəсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннə лилləəһи вə иннə илəйһи рааҗигуун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабергə иңүче
2) мәрхүмə Сәхибҗамал
3) Габделгафур кызы –
4) Әхмәдша җәмәгате –
5) 1917 елның 3
6) ноябрендә җомга көн 78
7) яшендә вафат. Аллаһ
8) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Таш үлчәмнәре: 79х34х10.

6. Вәлиулла Төхфәтулла улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Əл-хүкмү лилləəһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Вәлийулла
4) Төхфәтулла углы
5) 1923 нче йылның
6) аугысында 70
7) йəшендə вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннə лилləəһи вə иннə илəйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәтендә булсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Вәлиулла
4) Төхфәтулла улы
5) 1923 елның
6) августында 70
7) яшендә вафат».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаһ рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 67х31х7.

7. Мәгърифә Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу каберə назилə
2) мәрхүмə Мәгърифә
3) Гобәйдулла кызы
4) Вәлийулла җәмәгате
5) 1917 нче йылның
6) синтəбрендə 50
7) йəшендə вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Күллү мән галəйһəə фəəн».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт əйлəсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабергә иңүче
2) мәрхүмә Мәгърифә
3) Гобәйдулла кызы –
4) Вәлийулла җәмәгате –
5) 1917 елның
6) сентябрендә 50
7) яшендә вафат».

Уң ягы: «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани».

Сул ягы: «Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 66x30x8.

8. Мөхәммәдкасыйм Гыймадеддин улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәәл-кабри мәрхүм
3) Мөхәммәдкасыйм Гыймадеддин
4) углы 1894 нче йылда
5) 20 нче мартда 35
6) йәшдә вафат итде
7) рахимәһүллааһү рахмәтән вәәсигаһ
8) әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[118].

Сул ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[119].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Мөхәммәдкасыйм Гыймадеддин
4) улы 1894 елның
5) 20 мартында 35
6) яшьтә вафат булды.
7) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын,
8) амин».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Сул ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 94x31x11.

9. Галиәкбәр Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) тарих 1902 нче сәнә үктәбр
3) 7 ндә вафат Галиәкбәр
4) Гобәйдулла углы 76
5) йәшдә Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1902 елның 7
3) октябрендә Галиәкбәр
4) Гобәйдулла улы 76
5) яшьтә вафат. Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 85x31x13.

10. Маһиҗамал Габделмән кызына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) тарих 1900 нче сәнә
3) гыйнвар 16 нда Маһиҗамал
4) Габделмән кызы Галиәкбәр
5) җәмәгате 80 йәшендә вафат».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт кылгай иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) 1900 елның
3) 16 гыйнварында Маһиҗамал
4) Габделмән кызы – Галиәкбәр
5) җәмәгате – 80 яшендә вафат».

Сул ягы: «Аллаһ рәхим кылса иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 60x32x11.

11. Бибинәфисә Хуҗаәхмәд кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) саахибәтү һәзәәл-кабри мәрхүмә
3) Бибинәфисә Хуҗаәхмәд кызы

[118] Дәвамы сул ягында.
[119] Башы уң ягында.

4) Шәйхелислам Гыймадеддин
5) углыйның әһлийәсе 1905 нче
6) йылда 1 нче нуйәбрдә 29
7) йәшендә мәдфүнә кабере
8) мөнәүвәрә улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл ән-нәдәәмәтү лә түфиидү бәгъдә-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Бибинәфисә Хуҗаәхмәд кызы –
4) Шәйхелислам Гыймадеддин
5) улының хатыны – 1905
6) елның 1 ноябрендә 29
7) яшендә җирләнде. Кабере
8) нурлы булсын, амин».

Уң ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит. Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 98х30х11.

12. Гыймадеддин Баязидеддин улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Гыймадеддин Байаз-
4) -идеддин углы
5) 1909 сәнәи миладиййә1 нче
6) аугыст 90 йәшендә
7) вафат Аллаһ рәхмәт
8) кыйлгай иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Гыймадеддин Баяз-
4) -идеддин улы
5) милади 1909 елның 1
6) августында 90 яшендә
7) вафат. Аллаһ рәхим
8) кылса иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 96х30х10.

13. Гайнеддин Габделхәким улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Гайнеддин Габделхәким
4) углы 1899 нчы йылда
5) синтәбр 28 ндә 32
6) йәшендә вафат Аллаһ рәхмәт
7) кыйлгай иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Гайнеддин Габделхәким
4) улы 1899 елның
5) 28 сентябрендә 32
6) яшендә вафат. Аллаһ рәхим
7) кылса иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 79х32х8.

14. Бибиәсма Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибиәсма Гобәйдулла
4) кызы Гыймадеддин
5) Байазид углыйның
6) әһлийәсе 1910 нчы сәнәдә
7) 12 нче майда вафат
8) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[120].

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[121].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә

[120] Дәвамы сул ягында.
[121] Башы уң ягында.

3) Бибиәсма Гобәйдулла
4) кызы – Гыймадеддин
5) Байазид улының
6) хатыны – 1910 елның
7) 12 маенда вафат.
8) Аллаһ рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Сул ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Таш үлчәмнәре: 101х31х13.

15. Бибифатыйма Муса кызына куелган кабер ташы, 1888 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабергә назилә мәрхүмә
3) Бибифатыйма Муса
4) кызы Галәәддин
5) җәмәгате 1888 нче
6) җылда вафат 44
7) йәшендә Аллаһ
8) рәхмәтендә булсун
9) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Бибифатыйма Муса
4) кызы – Галәведдин
5) җәмәгате – 1888
6) елда 44
7) яшендә вафат. Аллаһ
8) рәхмәтендә булсын,
9) амин».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Таш үлчәмнәре: 101х32х11.

16. Галәведдин Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Галәәддин Ибраһим
4) углы 1918 нче
5) җылда мартда вафат
6) 88 йәшендә».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Галәведдин Ибраһим
4) улы 1918
5) елның мартында
6) 88 яшендә вафат».

Сул ягы: «Аллаһ рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 70х29х6.

17. Хөсәен Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) саахибү һәзәәл-кабри мәрхүм
3) Хөсәйен Гобәйдулла углы
4) румииййә илә 1904 нче йылда
5) ийүлнең 24 нче көнендә
6) 77 йәшендә дар-
7) -ел-фәнадин дарел-бәкайә
8) рихләт кылды Аллаһ рәхмәтендә
9) улсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Хөсәен Гобәйдулла улы
4) милади белән 1904 ел
5) июленең 24 нче көнендә
6) 77 яшендә фани
7) дөньядан мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ рәхмәтендә
9) булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 89х36х13.

18. Бибимотыйга Зөбәйер кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибимотыйга Зөбәйер кызы
4) Хөсәйен Гобәйдулла углы
5) әһлийәсе 1910 нчы йылда
6) 7 нче мартда 81 йәшдә
7) мәдфүнә нәүвәраллаahү кабраһәә әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Бибимотыйга Зөбәер кызы –
4) Хөсәен Гобәйдулла улы
5) хатыны – 1910 елның
6) 7 мартында 81 яшьтә
7) җирләнде. Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Уң ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 83х31х10.

19. Хәерниса Габделвәли кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаahү ли-мән зәәрании
2) бу каберә назилә мөтәвәффиййә мәрхүмә
3) Хәйренниса Габделвәли
4) кызы Габделгазиз Гыймад-
5) -еддин углыйның әһлийәсе
6) 24 йәшендә 1906 нчы сәнәдә
7) 29 нчы майда нәүвәр-
8) -аллаahү мәркадәһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Ганимәт кыйл кә форсаты һәвәс кыйлма бу дөнйайә».

Сул ягы (уеп язылган): «Вакытында гыйбадәт кыйл мәйетләргә дога да кыйл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Зөләйха Зөбәер кызы, Габделхаликъ
3) җәмәгате 1903 елның 23
4) апрелендә чәршәмбе көн җитмеш
5) яшендә мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ
6) каберен җәннәт бакчасы итсен, амин».

Уң ягы: «Ганимәт ит ки форсатны, күңел куйма бу дөньяга».

Сул ягы: «Вакытында гыйбадәт кыл, мәетләргә дога да кыл».

Таш үлчәмнәре: 96(120)х29х14.

3. Гайникамал Хуҗаәхмәд кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) саахибәтү һәзәәл-кабрии мәрхүүмәтү Гайни-
3) -камал Хуҗаәхмәд кызы
4) ...гал Тимергазиз углыйның
5) әһлийәсе 1906 нчы йылда
6) 8 нче дикәбрдә 22
7) йәшендә мәдфүнә нәүвәраллааһү
8) кабраһәә әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадыйм бер догадыр бу көн бәңа икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылучыны Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә Гайни-
3) -камал Хуҗаәхмәд кызы,
4) ...гал Тимергазиз улының
5) хатыны 1906 елның
6) 8 декабрендә 22
7) яшендә җирләнде. Аллаһ аның каберен
8) нурландырсын, амин».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 90(106)x31x9.

4. Мәлихә Фәхреддин кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибә-
3) -се Мәлихә
4) Фәхреддин кызы
5) вафат булды
6) 1912 нче йылда
7) 18 нче ийүлд
8) Аллаһның рәхмәтенд
9) улсун амин».

Сул ягы (уеп язылган): «Хәлилулла җәмәгате 64 йәшендә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер ия-
3) -се Мәлихә
4) Фәхреддин кызы
5) 1912 елның
6) 18 июлендә
7) вафат булды.
8) Аллаһның рәхмәтендә
9) булсын, амин».

Сул ягы: «Хәлилулла җәмәгате 64 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 88x30x11.

5. Шәрәфеддин Габделҗәлил улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Шәрәфеддин
3) Габделҗәлил углы
4) 6 нчы синтәбрдә
5) 1324 сәнәи һиҗриййә
6) 1906 сәнәи миладиййә
7) Мөхәммәдлатыйф»[188].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «70 йәшендә
2) йаздырды
3) ихване
4) мөслиминд-
5) -ән дога
6) рәҗа йидәмез»[189].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Шәрәфеддин
3) Габделҗәлил улы
4) һиҗри 1324 елның,
5) милади 1906 елның
6) 6 сентябрендә [вафат яки җирләнде].
7) Мөхәммәдлатыйф [яздырды]».

Арткы ягы:
1) «70 яшендә [вафат яки җирләнде]
2) [Мөхәммәдлатыйф] яздырды.
3) Мөселман
4) кардәшләрд-
5) -ән дога
6) өмет итәбез».

Таш үлчәмнәре: 93x30x10.

6. Фәхрениса Хәйрулла кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Фәхренниса
3) Хәйрулла кызы
4) Шәрәфеддин җәмәгате
5) 1332 сәнәи һиҗриййә
6) 1914 сәнәи миладиййә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «61 йәшендә
2) 4 нче априлдә
3) ихване
4) мөслиминдән ү
5) дога рәҗа йидәмез
6) Мөхәммәдлатыйф йаз-
7) -дырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.

[188] Дәвамы арткы ягында.
[189] Башы алгы ягында.

2) Фәхрениса
3) Хәйрулла кызы,
4) Шәрәфеддин җәмәгате
5) һиҗри 1332 елда
6) милади 1914 елда».

Арткы ягы:
1) «61 яшендә
2) 4 апрельдә [вафат].
3) Мөселман
4) кардәшләрдән
5) дога өмет итәбез.
6) Мөхәммәдлатыйф яз-
7) -дырды».

Таш үлчәмнәре: 110x31x15.

7. Әхмәд Габделмән улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәүвәраллаahү
2) мәркадәh
3) Әхмәд
4) Габделмән
5) углы
6) 65 йәшендә».

Уң ягы (калкытып язылган): «Йаздырды углы Рәхмәтулла».

Сул ягы (калкытып язылган): «1894 йылда 29 нчы агусда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh аның каберен
2) нурландырсын.
3) Әхмәд
4) Габделмән
5) улы
6) 65 яшендә».

Уң ягы: «Улы Рәхмәтулла яздырды».

Сул ягы: «1894 елның 29 августында [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 72(89)x35x13.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 5 б. №39.

8. Шәмсениса Хәсбиулла кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-ҳүкмилләәһи Тәгаалә
2) рух Йаңга Өҗем карйә-
3) -синең Шәмсениса Хәсбийулла
4) кызы Күәм карйәсинең
5) Исмәгыйль җәмәгате 1902 нче
6) сәнәдә рамазан шәрифнең
7) әүвәлге көнендә дарел-фәнадан
8) дарел-бәкайә рихләт кылды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Лаә иләәһә илләәллаah
2) Мүхәммәдүр-расүүлүллаah
3) күллү мән галәйһәә фәән
4) 72 йәшендә даре-
5) -л-бәкайә күчде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә хөкеме белән.
2) Рух – Яңа Өҗем авылын-
3) -нан Шәмсениса Хәсбиулла
4) кызы, Күәм авылыннан
5) Исмәгыйль җәмәгате 1902
6) ел рамазан шәрифенең
7) әүвәлге көнендә фани дөньядан
8) мәңгелек дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,
2) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
3) Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
4) 72 яшендә мәңгелек
5) дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 48(85)x33x14.

9. Билгесез кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «... 190... сәнәдә
2) нуйәбр 5 ндә дәфен иделде
3) рәхимәһүллаahү Тәгаалә
4) рахмәтән вәәсигаh әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «[Җәгалә]ллаahү кабраһү раудатән мин [рийәәдыйль-җәннәh]».

Сул ягы (уеп язылган): «[Галәмәтдән] морадым ихлас бер фатиха...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «... 190... елның
2) 5 ноябрендә җирләнде.
3) Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте
4) белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Сул ягы: «[Галәмәттән] морадым «Ихлас», бер «Фатиха» [сүрәләре уксыннар өчен]...».

Таш үлчәмнәре: 90х30х13.

10. Шәрәфеддин Хисамеддин улына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) бу кабергә назилә Шәрәфеддин
3) Хисамеддин углы
4) 63 йәшендә милади 1897 йылда
5) август 20 сендә дүшәнбә көн
6) кабере җәннәт бакчасы
7) улгай амин йаздыруб
8) куйучы Низамеддин Шәрәфеддин углы».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәңа икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Бу кабергә Шәрәфеддин
3) Хисамеддин улы
4) 63 яшендә милади 1897 елның
5) 20 августында дүшәмбе көн иңде.
6) Кабере җәннәт бакчасы
7) булсын, амин. Яздырып
8) куючы: Низамеддин Шәрәфеддин улы».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 90х30х11.

11. Бибимәфтуха Хисамеддин кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибимәфтуха Хисамеддин
4) кызы Фазлулла Гали
5) углының әһлийәсе 1903 сәнә
6) 1 нче априлдә 52 йәшендә
7) рахимәһүллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлыңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә мәрхүмә
3) Бибимәфтуха Хисамеддин
4) кызы, Фазлулла Гали
5) улының хатыны 1903 елның
6) 1 апрелендә 52 яшендә иңде.
7) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 70х29х9.

12. Хөснижамал Мозаффар кызына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә
2) иләйһи рааҗигуун
3) даре фәнадан даре
4) бәкайә рихләт
5) әйләде
6) Хөснижамал
7) Мозаффар кызы».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә
2) илә 1919 нчы
3) 3 нче үктәбрдә
4) 65 йәшендә
5) дәфен кылынды

6) Аллаһ рәхмәтенә гарикъ
7) улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.
3) Фани дөньядан мәңгелек
4) дөньяга
5) Хөснижамал
6) Мозаффар кызы
7) күчте».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) белән 1919 [елның]
3) 3 октябрендә
4) 65 яшендә
5) җирләнде.
6) Аллаһ рәхмәтенә
7) күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 86x31x13.

13. Мәрьямбану Галиәсгар кызына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назилә Мәрйәмбану
3) Галиәсгар кызы
4) һиҗрииййә 1326 нче йылда
5) румииййә 1908 нче йылда
6) 11 дикәбрдә».

Арткы ягы (уеп язылган): «31 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә Мәрьямбану
3) Галиәсгар кызы
4) һиҗри 1326 елда,
5) милади 1908 елның
6) 11 декабрендә иңде».

Арткы ягы: «31 йәшендә».

Таш үлчәмнәре: 83x30x8.

14. Мәфтуха Әюб кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Мәфтуха Әйүб
3) ... Әхмәҗан
4) зәүҗәсе 43
5) йәшендә 1910 сәнәи
6) румииййә фиврал
7) 5 ндә вафат
8) Аллаһ рәхмәт
9) кылсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһәә».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллааһү зүнүүбәһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Мәфтуха Әйүб
3) [кызы], Әхмәҗан
4) хатыны 43
5) яшендә милади 1910
6) елның 5
7) февралендә вафат.
8) Аллаһ рәхим
9) кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 95x33x14.

Күәм авылының икенче (көнчыгыштагы) зираты

1. Латыйфа Мөхәммәдгали кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) Латыйфа Мөхәммәдгали
3) кызы Бәйрәмгали
4) зәүҗәсе 42 йәшендә
5) 1912 нче йылда фиврал
6) 10 нда вафат Аллаһ
7) рәхмәт кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Җәгаләллаahү кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәh».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаh] – Мәңге.
2) Латыйфа Мөхәммәдгали
3) кызы, Бәйрәмгали
4) хатыны 42 яшендә
5) 1912 елның 10
6) февралендә вафат. Аллаh
7) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаh аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 82х32х13.

2. Бибифатыйма Габделвахид кызына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) мәрхүмә Бибифатыйма Габде-
3) -лвахид кызы 62
4) йәшендә синтәбр 15
5) ндә Хәсән зәүҗәсе
6) миладиййә 1901 нче йылда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта.
2) мәрхүмә Бибифатыйма Габде-
3) -лвахид кызы Хәсән
4) хатыны 62 яшендә
5) милади 1901 елның
6) 15 сентябрендә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 70х30х8.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 5 б. №40.

3. Гыйсмәтулла Насыйбулла улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Гыйсмәтулла Насыйбулла
4) углы 1911 нче сәнә април
5) 13 ндә 75 йәшендә вафат
6) Аллаh рәхмәт әйләсүн амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Гыйсмәтулла Насыйбулла
4) улы 1911 елның 13
5) апрелендә 75 яшендә вафат.
6) Аллаh рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 83х31х10.

4. Нәҗмеддин Хисамеддин улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Нәҗмеддин Хисамеддин
4) углы 1904 сәнә гыйнвар
5) 17 ндә 70 йәшендә вафат Аллаh
6) рәхмәтендә улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаh оҗмахы»[190].

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[191].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Нәҗмеддин Хисамеддин
4) улы 1904 елның 17
5) гыйнварында 70 яшендә вафат. Аллаh
6) рәхмәтендә булсын, амин».

Уң ягы: «Аллаh оҗмах бирсен өчен».

Сул ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Таш үлчәмнәре: 77х31х14.

[190] Дәвамы сул ягында.
[191] Башы уң ягында.

5. Габделкадыйр Габделхаликъ улына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибү һәзәәл-кабри мәрхүм
3) Габделкадыйр Габделхаликъ
4) углы 1902 сәнәдә
5) 1 үктәбрдә 51
6) йәшендә вафат Аллаһ
7) рәхмәт әйләсүн амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү лӛә түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблӛл-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделкадыйр Габделхаликъ
4) улы 1902 елның
5) 1 октябрендә 51
6) яшендә вафат. Аллаһ
7) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 112х32х12.

6. Шәрәфниса мулла Насреддин кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Шәрәфенниса мулла Насреддин
4) кызы дамелла Мөхәммәдшакир
5) әһлийәсе 1914 сәнәи миладиййә
6) фиврал 7 ндә 1332 сәнәи һижриййә
7) рабигыль-әүвәл 25 ндә мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Бәне күр дә гүр йарагың кыйла күр».

Сул ягы (уеп язылган): «Үтде дәүран кичде сәйран бәне күр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «75 йәшендә
2) рахимәллааһү рахмәтән
3) вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Шәрәфниса мулла Насреддин
4) кызы, дамелла Мөхәммәдшакир
5) хатыны милади 1914 елның
6) 7 февралендә, һижри 1332 елның
7) 25 рабигыль-әүвәлендә җирләнде».

Уң ягы: «Мине күр дә гүр кирәк-ярагыңны кыла күр».

Сул ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачып йөрү, мине күр».

Арткы ягы:
1) «75 йәшендә [вафат].
2) Аллаһ киң рәхмәте белән
3) рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 96х30х12.

7. Сәфәргали Тимергали улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лӛә иләәһә иллӛәллаах Мүхәммәдүр-расүүлүллаах
2) мәрхүм Сәфәргали
3) Тимергали углы
4) 1921 нче йылда
5) 17 март 65 йә-
6) -шендә вафат
7) рахимәһүллааһү рахмәтән
8) вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү кабраһү вә гафәра зүнүүбәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) мәрхүм Сәфәргали
3) Тимергали улы
4) 1921 елның
5) 17 мартында 65 я-

6) -шендә вафат.
7) Аллаһ аны киң рәхмәте белән
8) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын һәм гөнаһларын гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 104х31х10.

Күәм авылының өченче (Әмәш) зираты

1. Бибимәхфуза Хисамеддин кызына куелган кабер ташы, 1880 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Хисамедд-
2) -ин кызы Һибатулла
3) хәләле Бибимәхфу-
4) -за вафат 58 йәшендә
5) 1880 нче йылда
6) 22 нче февралда
7) бу мәкамә дафин улынды».

Уң һәм сул якларында үсемлек орнаменты уелып ясалган.

Арткы ягы (уеп язылган[192]):
1) «Килеб каберүн зийәрәт идән ихван
2) кыйлсалар рухыйна фатихаи ихсан».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хисамедд-
2) -ин кызы, Һибатулла
3) хәләле Бибимәхфу-
4) -за 58 яшендә вафат,
5) 1880 елның
6) 22 февралендә
7) бу урынга җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Килеп, каберен зиярәт иткән кардәш,
2) кылсалар [иде] рухына дога-изгелек».

Таш үлчәмнәре: 103х27х21.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 5 б. №41.

2. Габделвәли Әхмәдулла улына куелган кабер ташы, 1880 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң-зәәъикатүл-мәүүт
2) тарих румиййә иләи 1880 нче сәнәдә
3) 24 нче үктәбрдә Габделвәли
4) Әхмәдулла углы 56 йәшендә
5) дарел-фәнадин дарел-бәкайә рихләт әйләде
6) тайййибәллааһү сәрааһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Милади белән 1880 елның
3) 24 октябрендә Габделвәли
4) Әхмәдулла улы 56 яшендә
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.
6) Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Таш үлчәмнәре: 95х34х14.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 5 б. №42.

3. Бибифатыйма Габдессаттар кызына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү нәфсиң-зәәъикат-
2) -үл-мәүүт руми 1893 сәнә синтәбр
3) 13 ндә һиҗри 1311 сәнә
4) рабигыль-әүвәл 14 ндә Йаңа
5) Кишетнең Бибифатыйма Габдессаттар
6) кызы Күвәмнең Габдуллаҗан
7) Идрис углының хәлиләсе».

Уң ягы (калкытып язылган):
1) «23 йәшдә
2) дүшәнбә көн
3) даре бәкайә рихләт
4) кылды тайййибәллааһү
5) сәрааһәә әәмиин».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Әраад-дүнйәә хәраабән бигъ-тибәәрии
2) фәләә йәбкаа мүдәәмән бил-караарии
3) күрәрмен дөнйаны вәйран бары
4) һәмишә бакый ирмәс йук карары».

[192] Вертикаль рәвештә язылган.

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабру Бибифатыйма бинте Габд-
2) -ессаттар әл-Кишети хәлиләи
3) Габдуллажан бине Идрис
4) әл-Күвәми гафәраллаһү ләһәә вә ли-
вәәлидәйһәә
5) вә ли-мән кәәнә сәбәбән
6) ли-дүгааиһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне
2) татыячак». Милади 1893 елның 13
3) сентябрендә, һижри 1311 елның
4) 14 рабигыль-әүвәлендә Яңа
5) Кишеттән Бибифатыйма Габдессаттар
6) кызы, Күәмнән Габдуллажан
7) Идрис улының сөеклесе».

Уң ягы:
1) «23 яшьтә
2) дүшәмбе көн
3) мәңгелек дөньяга
4) күчте. Аллаһ аның туфрагын
5) яхшы [җиңел] кылсын, амин».

Сул ягы:
1) «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән,
2) һаман мәңге булмас, юк карары.
3) Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән,
4) һаман мәңге булмас, юк карары».

Арткы ягы:
1) «Бу Бибифатыйма бинте Габд-
2) -ессаттар Кишети,
3) Габдуллажан бине Идрис
4) Күәми сөеклесе. Аллаһ аның үзен, ата-
анасын
5) һәм аның өчен дога кылган кешене
6) гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 110(130)х39х22.

4. Хөббениса Габделвәли кызына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Хөббенниса
3) Габделвәли кызы
4) Габделкадыйр әһлийәсе
5) 1926 нчы йылда
6) 1 нче дикәбр 66 йәшдә
7) рахимәһәллаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Мән кәәнәә йәтълүүбә гыйбратән фәл-мәкаабиру тәкфиинһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Ин ләм тәкфәә фәл-мәүтү йәкфиинһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Хөббениса
3) Габделвәли кызы,
4) Габделкадыйр хатыны
5) 1926 елның
6) 1 декабрендә 66 яшьтә [вафат яки җирләнде].
7) Аллаһ аны рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Кем гыйбрәт таләп итсә, аңа каберлек җиткән».

Сул ягы: «Әгәр бу да җитмәсә, үлем җитәрлек булыр».

Таш үлчәмнәре: 90х34х8.

5. Габделкадыйр Габделвәли улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «[Әл-хүкмү лилләәһ]
2) бу кабер сахибе [мәрхүм]
3) Габделкадыйр Габделвәли
4) углы 1921 нче йылда
5) май 1 нчедә 72
6) йәшдә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «[Хөкем Аллаһта].
2) Бу кабер иясе [мәрхүм]
3) Габделкадыйр Габделвәли
4) улы 1921 елның
5) 1 маенда 72
6) яшьтә вафат».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаһ рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 60х30х8.

6. Габдуллажан Идрис улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) Габдуллажан
3) Идрис углы
4) 51 йәшендә
5) 18 гыйнварда
6) 1921 сәнәи миладиййә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада иде-
3) -ңез йад тәсадды-
4) -клә кыйлуңыз
5) рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Габдуллажан
3) Идрис улы
4) 51 яшендә
5) милади 1921 елның
6) 18 гыйнварында [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә
3) алыгыз, сәдака бирү
4) белән рухымны
5) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 84х31х7.

7. Галиәкбәр Габдессаттар улына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Галиәкбәр Габдессаттар
4) углы 1925 йыл
5) 20 нче үктәбрдә
6) рабигыль-әүвәл 5 ндә
7) 77 йәшдә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Галиәкбәр Габдессаттар
4) улы 1925 елның
5) 20 октябрендә,
6) 5 рабигыль-әүвәлендә
7) 77 яшьтә вафат».

Уң ягы: «Аллаһ рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 80х32х8.

8. Габдрахман Искәндәр улына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) һәзәә мәркадү Габдеррахман
3) Искәндәр углы румиййә
4) илән 1901 нче сәнәдә 10 нчы айында
5) агуст 25 нче йәүмендә шинбә көн мәдфүн
6) рахимәллааһү Тәгаалә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу Габдрахман
3) Искәндәр улы кабере, милади
4) белән 1901 елның 10 нчы аенда
5) августның 25 нче көнендә шимбә көн җирләнде.
6) Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 97х35х9.

9. Идрис Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) һәзәә мәркадү мәрхүм Идрис
3) әл-хәҗҗү Һибатулла углы
4) румиййә илән 1902 нче сәнәдә 55
5) йәшендә 13 нче мартда
6) рахимәллааһү Тәгаалә».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән мора-дым бер догадыр бу көн бәңа икән йарин сәңа-дыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылучыны Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу мәрхүм Идрис
3) хаҗи Һибатулла улы кабере,
4) милади белән 1902 елның 13 мартында
5) 55 яшендә [вафат яки җирләнде].
6) Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 90x34x23.

10. Һибатулла Әхмәдулла улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу кабергә дахил ахирәт мәнзилигә назил
3) мәрхүм әл-хәҗҗү Һибатулла ибне Әхмәдулла
4) румиййә илән 1899 нчы сәнә 85 йәшендә
5) 13 нче мартда хитаб иржигыый
6) Хакдан ирешүб шинбә көн мәдфүн
7) рахимәллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәңа икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылучыны Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә керүче, ахирәт йортына иңүче
3) мәрхүм хаҗи Һибатулла ибне Әхмәдулла
4) милади белән 1899 елның 13 мартында
5) 85 йәшендә Хактан «иржигый» [Аллаһның «кайт» дигән]
6) сүзенә ирешеп, шимбә көн җирләнде.
7) Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 92x34x14.

11. Мәлихә Гатиятулла кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ Тәгалә
2) рәхмәтенә васыйлә
3) улса иде
4) Мәлихә Гатийәт-
5) -улла кызы зәү-
6) -же Мифтахедд-
7) -ин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Руми
2) 1898 нче йыл
3) 11 нче дикәбрдә
4) 40 йәшендә
5) дәфен кылынды
6) баладан».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә
2) рәхмәтенә ирешсә
3) иде.
4) Мәлихә Гатият-
5) -улла кызы, ире
6) Мифтахедд-
7) -ин».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) 1898 елның
3) 11 декабрендә
4) 40 яшендә
5) җирләнде
6) бала табу сәбәпле [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 62x29x10.

12. Сафиулла Ишти улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Сафийулла

3) Ишти углы
4) 1911 нче йылда
5) 73 йәшендә вафат
6) Аллаһ рәхмәтендә
7) булсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Сафиулла
3) Ишти улы
4) 1911 елда
5) 73 яшендә вафат.
6) Аллаһ рәхмәтендә
7) булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 79x35x10.

13. Фә[тхе]рахман Шакир улына куелган кабер ташы, 1930 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабердә
2) дәфен булды
3) Шакир улы
4) Фә[тхе]рахман
5) туган 1867
6) йылда вафат
7) булды 1930
8) йылда Аллаһ
9) рәхмәт кыл-
10) -сын».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабердә
2) Шакир улы
3) Фә[тхе]рахман
4) җирләнде.
5) 1867
6) елда туган,
7) 1930 елда вафат булды.
8) Аллаһ
9) рәхим кыл-
10) -сын».

Таш үлчәмнәре: 80x26x10.

14. Сафиулла кызына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) Сафийулла кызы
2) вафат 1922
3) нче йылда 47
4) йәшендә Аллаһ
5) рәхмәт әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) Сафиулла кызы
2) 1922
3) елда 47
4) яшендә вафат. Аллаһ
5) рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 60x31x9.

15. Габдрахман Шаһиәхмәд улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) Габдеррахман Шаһи-
3) -әхмәд углы ...9
4) йәшендә 1904 сәнә
5) март 15 ндә вафат
6) рахимәһүллааһү Тәгааләә
7) рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Габдрахман Шаһи-
3) -әхмәд улы ...9
4) яшендә 1904 елның
5) 15 мартында вафат.
6) Аллаһ Тәгалә аны киң
7) рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 77x34x13.

Күәм авылының дүртенче (казаклар) зираты

1. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) нче... [рахимәһ]-
2) -үллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән [морадым бер догадыр]».

Сул ягы (уеп язылган): «[Бу көн бәндә икән йарин] сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) нче... Аллаһ Тәгалә аны
2) киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 33х32х12.

2. Габделмоталлиб Габделвәһһаб улына куелган кабер ташы, 1879 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәһүллаһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Габделмоталлиб Габделвәһһаб
4) углы вафат 1879
5) нчы җыл 21 нче април
6) 65 йәшендә рахимәһ-
7) -үллаһү рахмәтән вәәсигаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ мине зиярәт кылган кешене рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделмоталлиб Габделвәһһаб
4) улы, 1879
5) елның 21 апрелендә
6) 65 яшендә вафат. Аллаһ аны
7) киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Сул ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Таш үлчәмнәре: 81х34х10.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 5 б. №43.

3. Бибизарифә Габделмәннаф кызына куелган кабер ташы, 1916–1917 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) Бибизарифә
3) Габделмәннаф
4) кызы Хәйр-
5) -еддин зәүҗәсе
6) 63 йәшендә
7) 1335 сәнәи һиҗрииййә
8) ...».

Сул ягы (уеп язылган): «Рахимәһәәллаһү Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Бибизарифә
3) Габделмәннаф
4) кызы – Хәйр-
5) -еддин хатыны –
6) 63 яшендә
7) һиҗри 1335 елда [вафат]
8) ...».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 73х31х15.

4. Мөхәммәдшага куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Мөхәммәдшаһ
3) ... углы
4) 58 йәшендә
5) 1919 сәнә агусда
6) вафат рахимәһүллаһү
7) Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәраллаһү зүнүүбәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаһү мәркадәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Мөхәммәдшаһ

3) ... улы
4) 58 яшендә
5) 1919 елның августында
6) вафат. Аллаһ Тәгалә аны к
7) иң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 70х31х12.

5. Сәфәргали Габдерәхим улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) Сәфәргали
3) Габдеррәхим
4) углы
5) вафат
6) 64 йәшендә
7) 1906 сәнәи румиййә
8) фиврал 6 нда
9) рахимәһүллааһү Тәгааләә».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәраллааһү зүнүүбәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Җәгаләллааһү кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Сәфәргали
3) Габдерәхим
4) улы
5) 64 яшендә
6) милади 1906 елның
7) 6 февралендә
8) вафат.
9) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 105х32х15.

6. Өммегөлсем Әхмәҗән кызына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтү һәзиһил-кабри
2) Өммегөлсем Әхмәҗән кызы
3) Хәйреддин бине Габделмоталлиб
4) тәхтә никахында вафат
5) 1921 сәнәи миладиййә 6 нчы март
6) 1239 сәнәи һиҗриййә җөмадиәл-ахир
7) 28 ндә 45 йәшендә мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Әй гафил алданма бу дөнйага».

Сул ягы (уеп язылган): «Ахыры бер көн китәрсең бу гокбага».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) Өммегөлсем Әхмәҗән кызы
3) (Хәйреддин бине Габделмоталлиб
4) никахында)
5) милади 1921 елның 6 мартында,
6) һиҗри 1239 елның 28 җөмадиәл-ахирендә
7) 45 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Әй, ваемсыз, алданма бу дөнья-га».

Сул ягы: «Ахырдан беркөн китәрсең бу ахирәткә».

Таш үлчәмнәре: 73х31х11.

Күәм авылының бишенче (төньяктагы) зираты

1. Мөхәммәдгали Гайнулла улы Әмировка куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Мөхәммәдгали
3) Гайнулла
4) углы Әмирыф
5) 62 йәшендә
6) 1920 сәнә румиййә
7) нуйәбр 2 ндә
8) вафат Аллаһ
9) рәхмәт кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәһәәл-лааһү[193] Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ әәмиин вә би-хүрмәти нәбиййил-кәриим».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Мөхәммәдгали
3) Гайнулла
4) улы Әмиров
5) 62 яшендә
6) милади 1920 елның
7) 2 ноябрендә
8) вафат. Аллаһ
9) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин, юмарт пәйгамбәр хөрмәте белән».

Таш үлчәмнәре: 106х32х13.

2. Фазылҗан Хөсәен улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Фазылҗан
3) Хөсәйен
4) углы 59
5) йәшендә
6) 1335 сәнә һиҗриййә
7) 1917 сәнә румиййә
8) март 2 ндә
9) вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Җәгаләллааһү кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Фазылҗан
3) Хөсәен
4) улы 59
5) яшендә
6) һиҗри 1335 елда,
7) милади 1917 елның
8) 2 мартында
9) вафат».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 102х32х17.

3. Шакиржан Гыйззәтулла улына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) бу кабер сахибе
3) мәрхүм Шакиржан
4) Гыйззәтулла углы
5) 1919 нчы йылда
6) гыйнварның 15 ндә
7) 75 йәшендә
8) вафат булды».

Арткы ягы (уеп язылган)[194]:
1) «Бу
2) кабер сахибе
3) Шакиржан
4) Гыйззәтул-
5) -ла углы 1919
6) нчы йылда 15
7) гыйнварда
8) 75 йәшдә үлде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Шакиржан
4) Гыйззәтулла улы
5) 1919 елның
6) 15 гыйнварында
7) 75 яшендә
8) вафат булды».

Арткы ягы:
1) «Бу
2) кабер иясе
3) Шакиржан
4) Гыйззәтул-
5) -ла улы 1919
6) елның 15
7) гыйнварында
8) 75 яшьтә үлде».

Таш үлчәмнәре: 77х29х7.

[193] Ир-атка куелган таш булса да, хатын-кызга карата кулланыла торган кушымчалар белән язылган. Андый хаталар ташъязмаларда, сирәк булса да, очрый.

[194] Арткы ягындагы тексты латин графикасында язылган.

4. Бибимиһривафа Гыймадеддин кызына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) 1893 нче йылы
3) бишенче рамазан
4) шәрифдә кич атна
5) көн Казан
6) губернасы Чар
7) өйәзе Житлар-
8) -ның Бибимиһрива-
9) -фа Гыймадеддин
10) кызы 63 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) 1893 елның
3) бишенче рамазан
4) шәрифендә атна кич
5) көн Казан
6) губернасы Чар
7) өязе Житлар-
8) -дан Бибимиһрива-
9) -фа Гыймадеддин
10) кызы 63 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 105х40х12.

5. Галимулла Мостай улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) 1894 нче йылы
3) 15 нче ийүлдә
4) Казан губернасы
5) Чар өйәзе Күәм
6) авылыйның Галимулла
7) Мостай углы
8) 65 йәшендә вафат
9) рәхмәтле улсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) 1894 елның
3) 15 июлендә
4) Казан губернасы
5) Чар өязе Күәм
6) авылыннан Галимулла
7) Мостай улы
8) 65 яшендә вафат.
9) Рәхмәттә булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 101х37х10.

6. Төхфәтулла Хәйбулла улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахиб мәрхүм
3) Төхфәтулла Хәйб-
4) -улла углы
5) мәдфүн 1917
6) нче йылда үктә-
7) -брнең 18 ндә 67
8) йәшендә Аллаһның
9) рәхмәтендә улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә иллээллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүүллааһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Төхфәтулла Хәйб-
4) -улла улы
5) 1917
6) елның 18
7) октябрендә 67
8) яшендә җирләнде.Аллаһның
9) рәхмәтендә булсын».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Таш үлчәмнәре: 83х36х12.

7. Һажәрбикә Садыйк кызына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә
3) Һажәрбикә
4) Садыйк кызы
5) Сәфәргали
6) җәмәгате 1917

7) гыйнвар 23 ндә вафат
8) Аллаһ рәхмәтендә
9) улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Вә хүкмүл-мәүти бәйнән-нәәси җәәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Ә-ләм тәгъләм биәннәл-мәүти әәт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Мәрхүмә
3) Һаҗәрбикә
4) Садыйк кызы
5) Сәфәргали –
6) җәмәгате – 1917 [елның]
7) 23 гыйнварында вафат.
8) Аллаһ рәхмәтендә
9) булсын, амин».

Уң ягы: «Үлем хөкеме: ул кешеләр арасында йөри».

Сул ягы: «Үлемнең киләчәген белмәдегезме?»

Таш үлчәмнәре: 80х29х8.

8. Сәфәргали Сәлимҗан улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә иллээллаах Мүхәммәдүр-
расүүлүүллаах
2) мәрхүм Сәфәргали
3) Сәлимҗан углы
4) 1921 милади дикә-
5) -бр 5 ндә вафат
6) 72 йәшендә рахимәһ-
7) -үллаахү рахмәтән
8) вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[195].

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[196].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Мәрхүм Сәфәргали
3) Сәлимҗан улы
4) милади 1921 [елның] 5
5) декабрендә
6) 72 йәшендә вафат. Аллаһ аны
7) киң рәхмәте белән рәхим
8) кылсын, амин».

Уң ягы: «Аллаһ җәннәт бирсен өчен».

Сул ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, кардәшем»

Таш үлчәмнәре: 84х29х8.

9. Бибимәликә Гайсә кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабергә назилә Бибимәликә
3) Гайсә кызы румииййә илә
4) 1912 нче сәнә 65 йәшендә
5) 23 нче априлдә
6) мәдфүнә рахимәһәәллаахү Тәгаалләә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче Бибимәликә
3) Гайсә кызы милади белән
4) 1912 елның 23 апрелендә
5) 65 яшендә
6) җирләнде. Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 90х31х12.

10. Төхфәтулла Әхмәдулла улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалләә
2) бу кабер сахибе
3) Күәм авылыйның
4) мәрхүм Төхфәтулла
5) Әхмәдулла углы
6) мәдфүн 1912 нче
7) йылда 5 нче үктә-
8) -брдә 90 нчы йә-
9) -шендә Аллаһның
10) рәхмәтендә бу-
11) -лсын амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Карендәшләр дога кыйлунгызны үтенәмен».

[195] Дәвамы сул ягында.
[196] Башы уң ягында.

Сул ягы (уеп язылган): «Бу ташны йаздырды Сәйфулла Төхфәтулла углы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) Күәм авылының
4) мәрхүм Төхфәтулла
5) Әхмәдулла улы
6) 1912
7) елның 5 октя-
8) -брендә 90 нчы я-
9) -шендә җирләнде. Аллаһның
10) рәхмәтендә бу-
11) -лсын, амин».

Уң ягы: «Карендәшләр, дога кылуыгызны үтенәмен».

Сул ягы: «Бу ташны Сәйфулла Төхфәтулла улы яздырды».

Таш үлчәмнәре: 94х30х11.

11. Гайнекамал Хәсән кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) Гайнелкамал
3) Хәсән кызы
4) Гайнулла Әмирыф
5) зәүҗәсе 70 йәшендә
6) 1909 йылда март
7) 18 ндә вафат
8) рахимәһәәллааһү Тәгаалә
9) рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Гайнекамал
3) Хәсән кызы –
4) Гайнулла Әмиров
5) хатыны – 70 яшендә
6) 1909 елның 18
7) мартында вафат.
8) Аллаһ Тәгалә аны киң
9) рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 105х34х15.

12. Гайнулла Әмир улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе Гайнулла
3) Әмир углы румиййә илән 1909 сәнә
4) 95 йәшендә дикәбр 17 нче көн
5) йәүме җомга рәхмәте Рахманга ирешде
6) нәүвәраллааһү Тәгаалә кабраһ ээмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе Гайнулла
3) Әмир улы милади белән 1909 ел
4) декабренең 17 нче көнендә 95 яшендә
5) җомга көн Шәфкатьле [Аллаһ] рәхмәтенә иреште.
6) Аллаһ Тәгалә аның каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 91х31х11.

13. Бибишәмсевафа Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу кабергә дахилә мәрхүмә Бибишәмсевафа
3) Фәтхулла кызы Гайнулла
4) Әмир углыйның әһлийәсе румиййә илән
5) ... нче сәнә 65 йәшендә 2 нче фибралда
6) дарел-фәнадин дарел-бәкайә рихләт
7) кыйлды нәүвәраллааһү мәркадәһәә ээмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә керүче мәрхүмә Бибишәмсевафа
3) Фәтхулла кызы – Гайнулла
4) Әмир улының хатыны – милади белән
5) ... елның 2 февралендә 65 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 110х36х10.

14. Сәлимҗан Бикмәмәт улына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабергә назил Сәлимҗан
3) Бикмәмәт углы румииййә илән
4) 1889 нчы сәнә 95 йәшендә
5) 12 нче фибралда мәдфүн
6) рахимәллаһү Тәгаалә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче Сәлимҗан
3) Бикмәмәт улы милади белән
4) 1889 елның 12 февралендә
5) 95 яшендә җирләнде.
6) Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 90x31x13.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 5 б. №44.

15. Төхфәтулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) Рабби лää тәзәрнии фәрдәү-вә әңтә
3) хайруль-вәәрисиин
4) 1893 нче йыл 11
5) майда Чар өйәзе
6) Күәм авылыйның
7) бәндәи Хода Төхфәтулла
8) Һибатулла углы 51
9) йәшендә дарел-фәна-
10) -дан дарел-бәкайә
11) рихләт кыйлды
12) Аллаһүммә иҗгаль кабраһү
13) раудатән мин рийәәд-
14) -ыйль-җәннәһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) Йә, Раббы, мине ялгыз калдырма, Син -
3) варисларның Иң хәерлесесе.
4) 1893 елның 11
5) маенда Чар өязе
6) Күәм авылыннан
7) Хода бәндәсе Төхфәтулла
8) Һибатулла улы 51
9) яшендә фани дөнья-
10) -дан мәңгелек дөньяга
11) күчте.
12) Аллаһым, аның каберен җәннәт
13) бакчаларыннан бер
14) бакча ит, амин».

Таш үлчәмнәре: 114x34x9.

16. Әхмәҗан Сәйфулла улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Әхмәҗан
3) Сәйфулла углы
4) 68 йәшендә 1912 нче
5) йылда март 15 ндә
6) вафат рахимәһүллаһү
7) Тәгаалә рахмәтән
8) вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): Гафәраллаһү зүнүүбәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаһү мәркадәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Әхмәҗан
3) Сәйфулла улы
4) 68 яшендә 1912
5) елның 15 мартында
6) вафат. Аллаһ Тәгалә аны
7) киң рәхмәте белән
8) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 111x48x18.

17. Бибикафия мулла Хәлилулла кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабергә назилә мәрхүмә Бибикафийә
3) мулла Хәлилулла хәзрәт кызы
4) мулла Габделбари мулла Габделкадыйр

5) хәзрәт углыйның әһлийәи кәримә-
6) -се румиййә 1910 сәнә гыйнвар 8 нче көндә».

Уң ягы (уеп язылган): Мөхәррәмел-хәрам 10 нчы йәүме гашура дүшәнбә көн».

Сул ягы (уеп язылган): «41 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бар күңелләрдин йылы йомшак
2) синең каберең ташы шунда тамсун
3) күз йәшемнең иң ачы һәм татлысы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә мәрхүмә Бибикафия
3) мулла Хәлилулла хәзрәт кызы –
4) мулла Габделбари мулла Габделкадыйр
5) хәзрәт улының газиз хаты-
6) -ны – милади 1910 ел гыйнварының 8 нче көнендә иңде».

Уң ягы: 10 мөхәррәмдә – гашура көнендә дүшәмбе көн [җирләнде]».

Сул ягы: «41 яшендә [җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Бар күңелләрдән җылы, йомшак
2) синең каберең ташы. Шунда тамсын
3) күз яшемнең иң ачы һәм татлысы».

Таш үлчәмнәре: 78х32х11.

Күлле-Киме авылы зираты

1. Ризван Рәхмәтулла улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Ризван Рәхмәтулла
4) углы 1907 сәнәи миладиййә
5) 14 нче синтәбрдә 59
6) йәшендә мәдфүн
7) Аллаһ рәхмәт кыйлгай
8) иде амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән әнтә тәсыыйру мислии»[197].

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[198].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Ризван Рәхмәтулла
4) углы 1907 сәнәи миладиййә
5) 14 нче синтәбрдә 59
6) йәшендә җирләнде.
7) Аллаһ рәхим кылса
8) иде, амин».

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Таш үлчәмнәре: 86х31х10.

2. Әсхабҗамал Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Әсхабҗамал Габденнасыйр
4) кызы вафат 1912 нче сәнә
5) 14 нче фивралда 65 нче йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Ризван бине Рәхмәтулла әһлийәсе»[199].

Сул ягы (уеп язылган): «Вафат рахимәллааһү рахмәтән вәәсигаһ»[200].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Әсхабҗамал Габденнасыйр
4) кызы 1912 елның
5) 14 февралендә 65 нче яшендә вафат».

Уң ягы: «Ризван бине Рәхмәтулла хатыны».

[197] Башы сул ягында.

[198] Дәвамы уң ягында.
[199] Дәвамы сул ягында.
[200] Башы уң ягында.

Сул ягы: «Вафат. Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 80х31х11.

3. Гыйльмекамал Бикчәнтәй кызына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) Гыйльмекамал
3) Бикчәнтәй кызы
4) мулла Сибгатулла
5) әһлийәсе 1927 сәнә
6) 25 нче фивралда
7) 82 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә иллээллааһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Гыйльмекамал
3) Бикчәнтәй кызы –
4) мулла Сибгатулла
5) хатыны – 1927 елның
6) 25 февралендә
7) 82 яшендә вафат».

Уң ягы: «Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».
Сул ягы: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк».

Таш үлчәмнәре: 75х30х9.

4. Мулла Сибгатулла мулла Фазлулла улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу каберә куйылды
3) Киме авылыйның
4) әш-шәйхуль-фәәдыйлү
5) мулла Сибгатулла
6) ибне мулла Фазлулла
7) 1917 сәнә април 25 ндә
8) 77 йәшдә вафат».

Сул ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллааһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә
3) Киме авылыннан
4) хөрмәтле шәех
5) мулла Сибгатулла
6) ибне мулла Фазлулла куелды,
7) 1917 елның 25 апрелендә
8) 77 яшьтә вафат».

Сул ягы: «Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 94х30х13.

Әлеге кабер иясе Ш. Мәржанинең туганнан туган энесе. Аның фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Сибгатулла бине Фазлулла (Фазыл) бине Ибраһим бине Арслан бине Туйчы бине Тамә бине Иртуган[201]. Ризаэтдин Фәхретдин шәҗәрәсен бераз башкачарак бирә: Сибгатулла бине Фазыл бине Ибраһим бине Арслан бине Туймый бине Тимә бине Әмиртуган[202]. Сибгатулла хәзрәт 1863 елның 30 июлендә указ (указ номеры – №7021) алып, Күлле-Киме авылында күп еллар имам булып торган[203]. Шунысын да искәртергә кирәк: ул язучы, галим Галимҗан Ибраһимовның бабасы Нурмөхәммәднең туганнан туган энесе[204].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 5 б. №45.

5. Габдулла Габдрахман мулла улына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабергә куйылды Киме
3) авылыйның имам Габд-
4) -еррахман углы Габд-

[201] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 390–391; Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: II т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 214–215.

[202] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 137.

[203] Татарстан Республикасының Милли архивы: 2 ф., 2 тасвир., 7100 сак. берәм. – Б. 338 арты–339.

[204] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б.390–391; Әхмәтҗанов М.И. Татар археографиясе. Милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2011. – Б. 145.

5) -улла 1903 нче
6) йылда 1 нче априлдә
7) 2 йәшендә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә Киме
3) авылыннан имам Габд-
4) -рахман улы Габд-
5) -улла куелды, 1903
6) елның 1 апрелендә
7) 2 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 84х32х11.

6. Мулла Гыйнәятулла мулла Фазлулла улына куелган кабер ташы, 1886 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назил мөтәвәффа мәрхүм
3) хаҗел-хәрәмәйен мулла Гыйнәйәт-
4) -улла бине мулла Фазлулла
5) 41 йәшендә 1886 нчы
6) йыл 11 нче фивралда
7) кабере мөнәүвәр улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[205].

Сул ягы (уеп язылган)[206]:
1) «Таки рузи идә Аллаһ оҗмах[207]
2) кәтәбәһәә
3) мулла Сәлах».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә вафат булучы мәрхүм
3) хаҗи мулла Гыйнәят-
4) -улла бине мулла Фазлулла
5) 41 яшендә 1886
6) елның 11 февралендә иңде.
7) Кабере нурлы булсын, амин».

Уң ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, кардәшем».

Сул ягы:
1) «Аллаһ оҗмах бирсен өчен.
2) Моны язды:
3) мулла Сәлах».

Таш үлчәмнәре: 94х36х18.

Әлеге кабер иясе Ш. Мәрҗанинең туганнан туган энесе. Аның фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Гыйнәятулла бине Фазлулла (Фазыл) бине Ибраһим бине Арслан бине Туйчы бине Тамә бине Иртуган[208]. Ризаэтдин Фәхретдин шәҗәрәсен бераз башкачарак бирә: Гыйнәятулла бине Фазыл бине Ибраһим бине Арслан бине Туймый бине Тимә бине Әмиртуган[209]. Ул 1873 елда авыл халкы аны икенче имам итеп сайлаган[210]. Шунысын да искәртергә кирәк: ул язучы, галим Галимҗан Ибраһимовның бабасы Нурмөхәммәднең туганнан туган энесе[211].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №46.

7. Габделгалләм мулла Фазлулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтү[212] һәзәл-кабри
2) Габделгалләм мулла Фазлулла
3) углы 1920 сәнәи миладиййә
4) ийүл 28 1338 сәнәи һиҗриййә
5) зөл-кагдә 10 58 йәшдә
6) вафат рахимәһүллааһү рахмәтән
7) вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

[205] Башы сул ягында.
[206] Беренче юлы вертикаль, калган юллары диагональ рәвештә язылган.
[207] Дәвамы уң ягында.

[208] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 390–391; Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: II т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 214–215.
[209] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 137.
[210] Татарстан Республикасының Милли архивы: 2 ф., 2 тасвир., 367 сак. берәм. – Б. 3–4.
[211] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 390–391; Әхмәтҗанов М.И. Татар археографиясе. Милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2011. – Б.145.
[212] Ир-атка куелган таш булса да, хатын-кызга карата кулланыла торган кушымча белән язылган

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) Габделгалләм мулла Фазлулла
3) улы милади 1920 елның
4) 28 июлендә, һиҗри 1338 елның
5) 10 зөл-кагдәсендә 58 яшьтә
6) вафат. Аллаһ аны киң рәхмәте белән
7) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 81х31х11.

Әлеге кабер иясе Ш. Мәржанинең туганнан туган энесе. Аның фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габделгалләм бине Фазлулла (Фазыл) бине Ибраһим бине Арслан бине Туйчы бине Тамә бине Иртуган[213]. Ризаэтдин Фәхретдин шәҗәрәсен бераз башкачарак бирә: Габделгалләм бине Фазыл бине Ибраһим бине Арслан бине Туймый бине Тимә бине Әмиртуган[214]. Шунысын да искәртергә кирәк: ул язучы, галим Галимҗан Ибраһимовның бабасы Нурмөхәммәднең туганнан туган энесе[215].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №47.

8. Суфия Кәрим кызына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтү һәзәл-кабри
2) мәрхүмә Суфийа
3) Кәрим кызы вафат
4) 1921 сәнә миладиййә
5) 1 нче ийүлдә 3 нче
6) йәшдә Аллаһ рәхмәт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) мәрхүмә Суфия
3) Кәрим кызы
4) милади 1921 елның
5) 1 июлендә 3 нче
6) яшьтә вафат. Аллаһ рәхим [кылсын]».

Таш үлчәмнәре: 65х27х7.

9. Бибифатыйма Габделгазиз кызына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назилә мәрьәт мөтәдәййинә
3) Бибифатыйма Габделгазиз
4) кызы Сор илинең Җамал-
5) -еддин Габделгани углыйның
6) әһлийәсе 35 йәшендә 1893 нч
7) йыл 30 нчы мартда рамазан»[216].

Уң ягы (уеп язылган)[217]:
1) «Зүүруль-кубүүра фә-иннәһәә түзәккируль-мәүүт
2) кәтәбәһү Сәлах-
3) -еддин
4) әл-Казаклари».

Сул ягы (уеп язылган): «Шәрифнең 24 ндә кабере мөнәүвәр улсун амин»[218].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә диндар хатын
3) Бибифатыйма Габделгазиз
4) кызы – Сор Иленнән[219] Җамал-
5) -еддин Габделгани улының
6) хатыны – 35 яшендә 1893
7) елның 30 мартында, рамазан».

Уң ягы:
1) «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар үлемне искә төшерә.
2) Моны язучы: Сәлах-
3) -еддин
4) Казаклари».

[213] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 390–391; Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: II т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 214–215.

[214] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 137.

[215] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 390–391; Әхмәтҗанов М.И. Татар археографиясе. Милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2011. – Б.145.

[216] Дәвамы сул ягында.

[217] Беренче юлы вертикаль, калганнары диагональ рәвештә язылган

[218] Башы алгы ягында.

[219] Чуашстан Республикасындагы авыл булса кирәк.

Сул ягы: «Шәрифнең 24 ндә иңде. Кабере нурлы булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 93х35х15.

10. Мөәзин Шакиржан Гатаулла улына куелган кабер ташы, 1924 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаahү ли-мән зәәрании
2) мөәззин Шакир-
3) -җан Гатаулла
4) углы 1342 сәнәи
5) hижриййә шәүвәл
6) берендә 1924 сәнәи
7) миладиййә 5 нче
8) майда 67 йә-
9) -шендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннә лилләәhи вә иннә иләйhи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаhның рәхмәтендә булсын».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаh рәхим кылсын.
2) Мөәзин Шакир-
3) -җан Гатаулла
4) улы hижри 1342
5) ел шәүвәленең
6) берендә, милади 1924
7) елның 5
8) маенда 67 я-
9) -шендә вафат».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаhныкы hәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаhның рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 106х29х10.

Әлеге кабер иясенең фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Шакиржан бине Гатаулла бине Фазлулла бине Ибраhим бине Арслан бине Туйчы бине Шәмседдин бине Иртуган[220]. Аның 1890 елның 20 февралендә указ (указ номеры – №1133) алганлыгы мәгълүм.

11. Шәмсекамәр Габид кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) бу кабергә назилә Шәмсекамәр Габид
3) кызы Сәгъдеддин Хөсәйен углыйның
4) әhлийәсе румиййә 1898 нче сәнә
5) 72 йәшендә ийүн 29 нчы йәүмендә
6) мәдфүнә нәүвәраллаahү кабраhәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта.
2) Бу кабергә иңүче Шәмсекамәр Габид
3) кызы – Сәгъдеддин Хөсәен улының
4) хатыны – милади 1898 ел
5) июненең 29 нчы көнендә72 яшендә
6) җирләнде. Аллаh аның каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 77х30х10.

12. Шәмседдин Сәгъдеддин улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибү hәзәл-кабри мәрхүм
2) Шәмседдин Сәгъдеддин углы
3) 1918 нче сәнә дикәбр 12
4) рабигыль-әүвәл 19 чәhаршәнбә
5) көн 55 йәшдә вафат
6) рахимәhүлаahү рахмәтән вәәсигаh
7) әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлыңгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе мәрхүм
2) Шәмседдин Сәгъдеддин улы
3) 1918 елның 12 декабрендә,
4) 19 рабигыль-әүвәлендә чәршәмбе
5) көн 55 яшьтә вафат.
6) Аллаh аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын,
7) амин».

[220] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: II т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 214–215; Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 390–391.

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 80х35х14.

13. Һибатулла Габделфәез улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибе
3) Һибатулла Габделфәйез
4) углы 1911 нче сәнәдә
5) април 19 нда
6) ...».

Сул ягы (уеп язылган): «[Рахимәһүллааһү] рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) Һибатулла Габделфәез
4) улы 1911 елның
5) 19 апрелендә
6) [вафат яки җирләнде]».

Сул ягы: «[Аллаһ аны] киң рәхмәте белән [рәхим кылсын]».

Таш үлчәмнәре: 57(67)х31х11.

14. Заһидулла Гайсә улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
3) ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүү-
4) -үллааһ ышбу кабер ийәсе
5) мәрхүм Заһидулла
6) Гайсә углы 1912
7) май айында 72 йә-
8) -шендә вафат булды
9) Аллаһ рәхмәтендә булсын
10) вә үфәүвизу әмрии
11) иләәллааһи иннәллааһә
12) бәсыыйрум-бил-гыйбәәд
13) сүбхәәнәллааһи хааликан».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән.
3) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның
4) илчесе. Бу кабер иясе
5) мәрхүм Заһидулла
6) Гайсә улы 1912 [елның]
7) май аенда 72 я-
8) -шендә вафат булды.
9) Аллаһ рәхмәтендә булсын.
10) мин эшемне Аллаһуга
11) тапшырамын, чынлыкта, Аллаһ –
12) бәндәләрен Күрүче.
13) Бар итүче Аллаһ һәр кимчелектән пакь».

Таш үлчәмнәре: 86х32х9.

15. Мәхубкамал Әхмәдулла кызына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
3) ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүү-
4) -үллааһ ышбу кабер ийәсе
5) мәрхүмә Мәхубкамал
6) Әхмәдулла кызы Гайсә
7) Заһидулласының
8) җәмәгате 1926 йыл
9) март айында 71 йәшендә
10) вафат булды Аллаһ
11) рәхмәтендә булсын
12) вә үфәүвизу әмрии
13) иләәллааһи иннәллааһә
14) бәсыыйрум-[бил-гыйбәәд]».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән.
3) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның
4) илчесе. Бу кабер иясе
5) мәрхүмә Мәхубкамал
6) Әхмәдулла кызы – Гайсә
7) Заһидулласының
8) җәмәгате – 1926 елның
9) март аенда 71 яшендә
10) вафат булды. Аллаһ
11) рәхмәтендә булсын.

12) мин эшемне Аллаһуга
13) тапшырамын, чынлыкта, Аллаһ –
14) [бәндәләрен] Күрүче».

Таш үлчәмнәре: 87х32х9.

16. Хәлилулла Гайсә улына куелган кабер ташы, 1896 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахиб
3) мәрхүм Хәлилу-
4) -лла Гайсә
5) углы вафат
6) булды 1896
7) нчы йылда 20
8) нче ийүндә».

Уң ягы (уеп язылган): «Аллаһның рәхмәтендә булсун амин».

Сул ягы (уеп язылган): «66 йәшендә мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Хәлилу-
4) -лла Гайсә
5) улы
6) 1896
7) елның 20
8) июнендә вафат булды».

Уң ягы: «Аллаһның рәхмәтендә булсын, амин».

Сул ягы: «66 яшендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 78х30х9.

17. Сәлимә Нигъмәтулла кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
3) ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-
4) расүүллааһ ышбу кабер
5) ийәсе мәрхүмә Сә-
6) -лимә Нигъмәтулла
7) кызы Гайсә җәмәгате
8) 1906 йыл ийүн айында
9) 99 йәшендә вафат
10) булды Аллаһ рәхмәтендә
11) булсын минем каберемне
12) күреб әҗәлне итегез йад
13) дога белән рухымны
14) итегез шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән.
3) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд –
4) Аллаһның илчесе. Бу кабер
5) иясе мәрхүмә Сә-
6) -лимә Нигъмәтулла
7) кызы – Гайсә җәмәгате –
8) 1906 елның июнь аенда
9) 99 яшендә вафат
10) булды Аллаһ рәхмәтендә
11) булсын. Минем каберемне
12) күреп, әҗәлне искә алыгыз,
13) дога белән рухымны
14) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 86х31х9.

18. Мөхәммәдгыяс Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражиим
2) бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
3) ләә иләәһә илләәллааһ
4) Мүхәммәдүр-расүүллааһ
5) сәнәи миладиййә илә
6) 1914 нче йылда 10
7) нчы үктәбрдә вафат
8) булды Мөхәммәдгыяс
9) хаҗиел-хәрәмәйен Хәбибулла
10) углы Аллаһ
11) рәхмәт кылсын».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Тәгаалә[221]
2) би-хүкмилләәһи[222]
3) бу кабер са-
4) -хибе мәрхүм
5) Мөхәммәдгыяс
6) хаҗи Хәбибулла
7) углы вафат
8) 38 йәшендә».

[221] Башы икенче юлда.
[222] Дәвамы беренче юлда.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шайтаннан Аллаһка сыенам.
2) Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме беләи.
3) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,
4) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
5) Милади беләи
6) 1914 елның 10
7) октябрендә
8) Мөхәммәдгыяс
9) хаҗи Хәбибулла
10) улы вафат булды Аллаһ
11) рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә
2) хөкеме беләи.
3) Бу кабер ия-
4) -се мәрхүм
5) Мөхәммәдгыяс
6) хаҗи Хәбибулла
7) улы
8) 38 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 97х30х10.

19. Маһиҗамал Бикчәнтәй кызына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Маһиҗамал
3) Бикчәнтәй кызы
4) Хәбибулла Гайсә углы
5) әһлийәсе 1925 сәнә
6) август 26 нда
7) 82 йәшдә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт итсен».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәллааһү лимән зәәрании».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Маһиҗамал
3) Бикчәнтәй кызы –
4) Хәбибулла Гайсә улы
5) хатыны – 1925 елның
6) 26 августында
7) 82 яшьтә вафат».

Уң ягы: «Аллаһ рәхим кылсын».

Уң ягы: «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 90х32х12.

20. Габдрахман Хәкимулла улы Гайсинга куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Габдеррахман бине әл-хаҗҗе
4) Хәкимулла Гайсин
5) 1919 нчы сәнәи миладиййә
6) март 5 ндә 1337 һиҗриййә
7) җөмадиәл-ахир 3 вафат
8) 24 йәшдә рахимәһүллааһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл ән-нәдәәмәтү лләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Ничә йөрсәң бу дөнйада гомергә бары бер көн керүрсен бу кабергә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабер иясе
3) Габдрахман бине хаҗи
4) Хәкимулла Гайсин
5) милади 1919 елның
6) 5 мартында, һиҗри 1337 [елның]
7) 3 җөмадиәл-ахирендә
8) 24 яшьтә вафат. Аллаһ аны рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит. Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: ««Ничаклы йөрсәң дә бу дөньяда гомергә, бары беркөн керерсең бу кабергә».

Таш үлчәмнәре: 86х31х11.

21. Хәбибулла Гайсә улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) бу кабер сахибе

3) Киме авылыйның
4) хаҗи Хәбибулла
5) Гайсә углы
6) 1341 сәнәи һиҗриййә»[223].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Зөлкагдә 27 ндә
2) 90 йәшендә
3) вафат итде»[224].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Бу кабер иясе
3) [Күлле] Киме авылыннан
4) хаҗи Хәбибулла
5) Гайсә улы
6) һиҗри 1341 елның».

Арткы ягы:
1) «27 зөлкагдәсендә
2) 90 яшендә
3) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 94x28x10.

22. Гыйләҗетдин Йосыф улына куелган кабер ташы, 1929 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабергә күмелде
2) мәрхүм
3) Гыйләҗетдин Йосыф
4) улы 1929 йыл
5) мартның 3 ндә
6) 74 йәшендә
7) дөнйадан
8) күчде».

Арткы ягы (уеп язылган)[225]:
1) «Гыйләҗттин
2) Йосыф улы
3) исдәлек
4) куйучы улы
5) Җамалттин.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабергә
2) мәрхүм
3) Гыйлаҗетдин Йосыф
4) улы күмелде, 1929 елның
5) 3 мартында
6) 74 яшендә
7) дөньядан
8) күчте».

Арткы ягы:
1) «Гыйләҗетдин
2) Йосыф улы.
3) Истәлек
4) куючы: улы
5) Җамалетдин.

Таш үлчәмнәре: 81x31x9.

23. Гыйнәятулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Гыйнәйәтулла бине Һибатулла
4) 1920 сәнәи миладиййә
5) нуйәбр 23 ндә...
6) дүшәнбә көн дарел-фәнадин
7) дарел-бәкайә рихләт кыйлды
8) рахимәһүллаһү рахмәтән вәәсигаһ
9) әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әй гафил алданма бу дөнйага ахыры бер көн китәрсең бу гокбага».

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый таки рузи идә Аллаһ оҗмахы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Гыйнәятулла бине Һибатулла
4) милади 1920 елның
5) 23 ноябрендә...
6) дүшәмбе көн фани дөньядан
7) мәңгелек дөньяга күчте.
8) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын
9) амин».

Уң ягы: «Әй, ваемсыз, алданма бу дөньяга. Ахырдан беркөн китәрсең бу ахирәткә».

Сул ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Таш үлчәмнәре: 123x37x16.

[223] Дәвамы арткы ягында.
[224] Башы алгы ягында.
[225] Арткы ягы латин графикасында язылган, ахыргы өч юлы ромб эченә алынган.

24. Зөләйха Ибраһим кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-хәккуль-м... зүүл-җәләәл
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Зөләйха Ибраһим кызы
4) Гыйнийәтулла Һибатулла углыйның
5) тәхтә никахында вафат
6) 1920 нче йылда 20 нче
7) үктәбрдә 67 йәшендә
8) нәүвәраллаһү кабраһәә әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән бикабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[226].

Сул ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[227].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Хак..., Бөеклек иясе.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Зөләйха Ибраһим кызы
4) (Гыйнәятулла Һибатулла улының
5) никахында)
6) 1920 елның 20
7) октябрендә 67 яшендә вафат.
8) Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Сул ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 112x35x15.

25. Фатыйма Габдулла кызына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәһәәллаһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Фатыйма Габдулла кызы
4) 1919 сәнә март 25 вафат
5) Аллаһ шәфәгатьче әйләсүн[228]».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ аны рәхим кылсын.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Фатыйма Габдулла кызы
4) 1919 елның 25 мартында вафат.
5) Аллаһ шәфәгатьче итсен».

Таш үлчәмнәре: 60x32x13.

26. Әхмәдша Фәйзулла улына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) бу каберә назил
3) шәйех мөтәдәййин
4) Әхмәдшаһ Фәйзулла
5) углы 62 йәшендә 1900 нч
6) йыл 26 нчы ийүндә тарих
7) һиҗрииййә 1318 нче сәнә 12 нче рабигыль-әүвәлдә
8) кабере мөнәүвәр улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән бикабрии мүтәфәккиран күнтү мислүкә тәсыыйру мислии».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәфәәл-мәүтү лил-мәръи вәәгыйзаа кәтәбәһү Сәлах әл-Казаклари».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Бу кабергә
3) диндар шәех
4) Әхмәдша Фәйзулла
5) улы 62 яшендә 1900
6) елның 26 июнендә,
7) һиҗри 1318 елның 12 рабигыль-әүвәлендә иңде.
8) Кабере нурлы булсын, амин».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче, мин синең кебек идем, син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Кеше өчен үлем вәгазьче буларак җиткән. Моны язды: Сәлах Казаклари».

Таш үлчәмнәре: 107(116)x37x16.

[226] Дәвамы сул ягында.
[227] Башы уң ягында.
[228] Ислам дине өйрәтүенчә, сабый вакытында вафат булган балалар Кыямәт көнендә ата-аналары өчен Аллаһ каршында шәфәгать кылачаклар, әлеге догада шул нәрсә күздә тотыла.

27. Хөсәен Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаahү ли-мән зәәрании
2) бу кабер сахибе
3) Хөсәйен Исмәгыйль
4) углы 1905 нче җыл
5) гыйнвар 8 ндә вафат
6) Аллаh рәхмәт әйлә-»[229].

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәhи вә иннәә иләйhи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «-сүн амин»[230].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаh рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе
3) Хөсәен Исмәгыйль
4) улы 1905 елның
5) 8 гыйнварында вафат.
6) Аллаh рәхим кыл-».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаhныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».
Сул ягы: «-сын, амин».

Таш үлчәмнәре: 63x31x7.

28. Бибилатыйфа мулла Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1886 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) бу каберә назилә мөтәвәффийә мәрхүмә
3) мәрьәт салиха Бибилатыйфа
4) мулла Фәтхулла кызы мулла
5) Фазлулла әhлийәсе 44 йәшендә
6) 1886 нчы сәнә үктәбр 23 ндә
7) кабере мөнәүвәр улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрүб каберүм хәлеңне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Бу кабергә вафат булучы мәрхүмә
3) изге хатын Бибилатыйфа
4) мулла Фәтхулла кызы – мулла
5) Фазлулла хатыны – 44 яшендә
6) 1886 елның 23 октябрендә иңде.
7) Кабере нурлы булсын, амин».

Уң ягы: «Каберемне күреп, хәлеңне искә ал».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 98x38x17.

29. Гыймадеддин Шәмседдин улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Йә Аллаh
2) әл-кабру гыйбраh
3) бу каберә назилә
4) Гыймадеддин
5) Шәмседд-
6) -ин углы
7) ... йәшендә...
8) ... җөмадиәл-ахир-
9) -нең чәһаршәнбә
10) көн»[231].

Уң ягы (уеп язылган): «Дарел-бәкайә рихләт әйләде»[232].

Сул ягы (уеп язылган): «Амин 1916 йылда дарел-фәнадин»[233].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Йә, Аллаh.
2) Кабер – гыйбрәт.
3) Бу кабергә иңүче
4) Гыймадеддин
5) Шәмседд-
6) -ин улы
7) ... яшендә...
8) ... җөмадиәл-ахир-
9) -дә чәршәмбе
10) көн».

Уң ягы: «Мәңгелек дөньяга күчте».

[229] Дәвамы сул ягында.
[230] Башы алгы ягында.
[231] Дәвамы сул ягында.
[232] Башы сул ягында.
[233] Башы алгы ягында, дәвамы уң ягында.

Сул ягы: «(Амин) 1916 елда фани дөньядан».

Таш үлчәмнәре: 97х36х16.

30. Төхфәтулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер сахибе
3) Төхфәтулла Һибатулла
4) углы 1891 нче сәнә 65 йәшендә
5) дикәбр 8 нче йәүмендә бу фәнадин
6) бәкайә рихләт әйләде рахим-
7) -әллаһү Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәңа икән йарын сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылучыны Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе
3) Төхфәтулла Һибатулла
4) улы 1891 ел декабренең
5) 8 нче көнендә 65 яшендә бу фанилыктан
6) бакыйлыкка күчте. Аллаһ
7) Тәгалә киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә синадыр».

Таш үлчәмнәре: 82(95)х31х13.

31. Бибимәфтуха Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабергә назилә Бибимәфтуха
3) Фәтхулла кызы Төхфәтулла
4) Һибатулла углының җәмәгате
5) румиййә илә 1910 нчы сәнә 73 йәшендә
6) април 4 ндә рәхмәте Рахманга ирешде
7) нәүвәраллаһү кабраһәә әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу җиһан ханәсе кәрвансарай көн бикөн күчәр кидәр шаһ гидай».

Сул ягы (уеп язылган): «Ләү кәәнәтид-дүнйәә түдүүмү ләкәәнә расүүлүллаһи фииһәә мүхлидәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче Бибимәфтуха
3) Фәтхулла кызы – Төхфәтулла
4) Һибатулла улының җәмәгате –
5) милади белән 1910 елның 4 апрелендә
6) 73 яшендә Шәфкатьле [Аллаһ] рәхмәтенә иреште.
7) Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Уң ягы: «Бу җиһан кәрван сарай: көн саен күчәр, китәр шаһ та, ярлы кеше дә».

Сул ягы: «Әгәр дә дөнья дәвамлы булса, Аллаһның илчесе анда мәңге булыр иде».

Таш үлчәмнәре: 90(106)х31х11.

32. Сәхибҗамал Хөсәен кызына куелган кабер ташы, 1877 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер ийәсе мөтәвәффийә
3) мәрхүмә Сәхибҗамал
4) Хөсәйен кызы
5) Фәхреддин әһлийәсе
6) 52 йәшендә 1877 нче сәнә
7) 9 нчы майда 6 углы 4 кызы
8) калды кабере мөнәүвәр улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[234].

Сул ягы (уеп язылган): «Таки рузи кыйла Аллаһ җәннәте»[235].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.

[234] Башы сул ягында.
[235] Дәвамы уң ягында.

2) Бу кабер иясе вафат булучы
3) мәрхүмә Сәхибҗамал
4) Хөсәен кызы –
5) Фәхреддин хатыны –
6) 52 яшендә 1877 елның
7) 9 маенда [вафат яки җирләнде]. 6 улы, 4 кызы
8) калды. Кабере нурлы булсын».

Уң ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Сул ягы: «Аллаһ җәннәт бирсен өчен».

Таш үлчәмнәре: 119(130)х34х17.

33. Габделхаликъ Габбас улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назил мөтәвәффа мәрхүм
3) Габделхаликъ Габбас углы
4) 88 йәшендә 1892 нче
5) йыл аугусның
6) 7 нче көнендә
7) кабере мөнәүвәр
8) улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Күреб каберүм хәлеңне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә вафат булучы мәрхүм
3) Габделхаликъ Габбас улы
4) 88 яшендә 1892
5) ел августының
6) 7 нче көнендә иңде.
7) Кабере нурлы
8) булсын, амин».

Уң ягы: «Каберемне күреп, хәлеңне искә ал».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 99х34х15.

Әлеге кабер иясенең фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габделхаликъ бине Габбас бине Гомәр бине Исмәгыйль бине Арслан бине Туйчы бине Тамә бине Иртуган нәселе[236].

34. Фәхреддин Сабит улына куелган кабер ташы, 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер ийәсе мөтәвәффа
3) мәрхүм Фәхреддин
4) Сабит углы 63 йәшендә
5) 1882 нче сәнә 16 нчы
6) мартда 6 углы 4 кызы
7) калды кабере мөнәүвәр
8) улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрүб каберүм әҗәлне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе вафат булучы
3) мәрхүм Фәхреддин
4) Сабит улы 63 яшендә
5) 1882 елның 16
6) мартында [вафат яки җирләнде]. 6 улы, 4 кызы
7) калды. Кабере нурлы
8) булсын, амин».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 119(130)х38х16.

35. Фазылҗан Галиәкбәр улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер сахибе
2) Фазылҗан Галиәкбәр
3) углы 1912 нче җыл
4) 12 нче синтәбр 62 йә-
5) -шендә вафат Аллаһ
6) рәхмәтендә булсун».

[236] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 390–391.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) Фазылҗан Галиәкбәр
3) улы 1912 елның
4) 12 сентябрендә 62 я-
5) -шендә вафат. Аллаһ
6) рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 65х25х9.

36. Гыйнәятулла Фазлулла улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Гыйнәйәтулла бине Фазлулла
4) 1918 нче йылда
5) гыйнвар 11 ндә
6) чәһаршәнбә көн
7) 33 йәшдә
8) рахимәһүллаахү рахмәтән вәәсигаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Әәмиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хаҗҗе
2) Фәтхулла
3) бине Хәлилулла
4) әмере илә йазылды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Гыйнәятулла бине Фазлулла
4) 1918 елның
5) 11 гыйнварында
6) чәршәмбе көн
7) 33 яшьтә [вафат яки җирләнде].
8) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Сул ягы: «Амин».

Арткы ягы:
1) «Хаҗи
2) Фәтхулла
3) бине Хәлилулла
4) әмере белән язылды».

Таш үлчәмнәре: 81х27х8.

37. Мөхәммәҗән Әхмәдулла улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Йә Аллаһ
2) Мөхәммәҗән
3) Әхмәдулла
4) углы
5) 1917 сәнә 12 нч
6) мартда 70
7) йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәллаахү лимән зәәрании».

Сул ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Йә, Аллаһ.
2) Мөхәммәҗән
3) Әхмәдулла
4) улы
5) 1917 елның 12
6) мартында 70
7) яшендә вафат».

Уң ягы: «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын».

Сул ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Таш үлчәмнәре: 77(98)х29х14.

38. Бибигафифә Мөхәммәҗән кызына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бибигафифә
2) Мөхәммәҗән кызы
3) Габдулла җәмәгате
4) 1918 сәнә 6 нҗы фивралда
5) 53 йәшендә вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Газизә бинте
2) Габдессаттар
3) кызы бина кылдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бибигафифә

2) Мөхәммәҗан кызы –
3) Габдулла җәмәгате –
4) 1918 елның 6 февралендә
5) 53 яшендә вафат».

Арткы ягы:
1) «Газизә бинте
2) Габдессаттар
3) кызы куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 48(57)х29х7.

39. Гыйльмебаян Әхмәдша кызына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабернең ийәсе
3) Гыйльмебайан Әхмәд-
4) -шаһ кызы».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих
2) милади белә
3) 1925 нче йыл 9 нчы
4) ийүлдә җомга
5) көн вафат ...7 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабернең иясе
3) Гыйльмебаян Әхмәд-
4) -ша кызы».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Милади
2) белән
3) 1925 елның 9
4) июлендә җомга
5) көн ...7 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 41(57)х27х10.

40. Низамеддин Галәви улына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу кабер
3) сахибе
4) мәрхүм Га-
5) -ләви уг-
6) -лы Низамедд-
7) -ин вафат 62»[237].

Уң ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә иллләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүүллааһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәшендә Аллаһ рәхмәтендә [булсун]»[238].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабер
3) иясе
4) мәрхүм Га-
5) -ләви у-
6) -лы Низамедд-
7) -ин 62».

Уң ягы: «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Сул ягы: «Яшендә вафат. Аллаһ рәхмәтендә [булсын]».

Таш үлчәмнәре: 65х30х10.

41. Маһирә Хәбибулла кызы Вахитовага куелган кабер ташы, 1938 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1880 – 1938
2) Маһирә
3) Хәбибулла
4) кызы
5) Вахитова».

Таш үлчәмнәре: 55х29х8.

42. Мөхәммәҗан Габделҗаббар улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) бу каберә назил мәрхүм
4) Мөхәммәҗан Габделҗаббар
5) углы 1907 сәнә фиврал
6) 28 ндә 60 йәшдә
7) вафат рахимәллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсиң күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[239].

[237] Дәвамы сул ягында.
[238] Башы алгы ягында.

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[240].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
3) Бу кабергә иңүче мәрхүм
4) Мөхәммәҗән Габделҗаббар
5) улы 1907 елның 28
6) февралендә 60 яшьтә
7) вафат. Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Таш үлчәмнәре: 119x30x11.

43. Бибигайшә Гатаулла кызына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә
3) Бибигайшә Гатаулла
4) кызы әл-хаҗҗе Фәтхулла
5) бине Хәлилулла әһлийәсе
6) 1908 сәнәи миладиййә 27 нч
7) април һиҗриййә 1326
8) рабигыль-ахир 9 нчы йәүмендә»[241].

Уң ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад дога берлә кыйлугыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «25 йәшендә мәдфүнә нәүвәраллаһү кабраһәә әәмиин»[242].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Бибигайшә Гатаулла
4) кызы – хаҗи Фәтхулла
5) бине Хәлилулла хатыны –
6) милади 1908 елның 27
7) апрелендә, һиҗри 1326 [ел]
8) рабигыль-ахиренең 9 нчы көнендә».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал, дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «25 яшендә җирләнде. Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 93x31x11.

44. Хәлилулла Зәйнулла улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Хәлилулла Зәйнулла
4) углы 1910 сәнәи миладиййә
5) 22 нче май һиҗриййә 1328
6) җөмадиәл-әүвәл 26 нчы йәүмендә
7) 62 йәшендә вафат
8) Аллаһ рәхмәт кылгай иде амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Хәлилулла Зәйнулла
4) улы милади 1910 елның
5) 22 маенда, һиҗри 1328 [ел]
6) җөмадиәл-әүвәленең 26 нчы көнендә
7) 62 яшендә вафат.
8) Аллаһ рәхим кылса иде, амин».

Уң ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 93x32x10.

45. Бибилатыйфа Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә

[239] Башы сул ягында.
[240] Дәвамы уң ягында.
[241] Дәвамы сул ягында.
[242] Башы алгы ягында.

3) Бибилатыйфа Хәбибулла кызы
4) Хәлилулла бине Зәйнулла
5) әһлийәсе 1920 сәнә 28 гынвар
6) 1338 сәнәи һиҗрииййә җөмадиәл-әүвәл
7) 7 ндә чәһаршәнбә көн 65 йәшдә
8) рахимәһәәллаһү рахмәтән вәәсигаһ
9) әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[243].

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[244].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә мәрхүмә
3) Бибилатыйфа Хәбибулла кызы –
4) Хәлилулла бине Зәйнулла
5) хатыны – 1920 елның 28 гынварында,
6) һиҗри 1338 елның 7 җөмадиәл-
7) әүвәлендә чәршәмбе көн 65 яшьтә иңде.
8) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын,
9) амин».

Уң ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Сул ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Таш үлчәмнәре: 92(107)x30x13.

46. Хәмидулла Габделхәмид улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
3) ләә иләәһә илләәллаһ Мүхәммәдүр-расүүлүллаһ
4) сәнәи миладиййә илә
5) 1916 нчы йылда 16 нчы
6) үктәбрдә Хәмидулла Габд-
7) -елхәмид углы 71 йәшендә дар-
8) -ел-фәнадан дарел-бәкайә
9) рихләт әйләде Аллаһ Тәга-
10) -ләнең рәхмәтендә булсын
11) амин би-хүрмәтин-нәбии салләә-
12) -ллаһү галәйһи вә сәлләм әй борадә-
13) -рләр догада булыңыз».

Уң ягы (уеп язылган): «Әл-мәүт әл-мәүт күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүт бу кабер сахибе Хәмид».

Сул ягы (уеп язылган): «Каалүү иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун күллү мән галәйһәә фәән».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бер мең өч йөз
3) 35 нче сәнәдә
4) 1 нче маһе мөхәррәм-
5) -ел-хәрамда вафат
6) булды Хәмидулла
7) Габделхәмид углы
8) 71 йәшендә Аллаһ-
9) -ның рәхмәтендә булсын
10) мин һиҗратин-нәбии салләәллаһү
11) галәйһи вә сәлләм».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән.
3) Аллаһтан башка табынырлык зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
4) Милади белән
5) 1916 елның 16
6) октябрендә Хәмидулла Габд-
7) -елхәмид улы 71 яшендә фани
8) дөньядан мәңгелек дөньяга
9) күчте. Аллаһ Тәга-
10) -ләнең рәхмәтендә булсын,
11) амин. Пәйгамбәр, Аллаһ аны олыласын һәм
12) сәламләсен, хөрмәте белән. Әй, кардәш-
13) -ләр, догада булыгыз».

Уң ягы: «Үлем. Үлем. Һәр җан иясе үлемне татыячак. Бу кабер иясе – Хәмид».

Сул ягы: «Әйттеләр [изге бәндәләр]: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз». Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Пәйгамбәр, Аллаһ аны олыласын һәм
3) сәламләсен, һиҗрәте белән
4) бер мең өч йөз
5) утыз бишенче елның
6) 1 мөхәррәмендә
7) Хәмидулла
8) Габделхәмид улы
9) 71 яшендә
10) вафат булды. Аллаһ-
11) -ның рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 90x31x11.

[243] Дәвамы сул ягында.
[244] Башы уң ягында.

47. Сәхибә Халид кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) саахибәтү һәзиһил-кабри Сәхибә
3) Халид кызы Хәмид әһлийәсе
4) румиййә иләи 1903 нче сәнә 80 йәшендә
5) ийүн 3 нче йәүмендә мәдфүнә
6) нәүвәраллааһү мәркадәһәә әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәңа икән йарин сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылучыны Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе Сәхибә
3) Халид кызы – Хәмид хатыны –
4) милади белән 1903 ел июненең
5) 3 нче көнендә 80 яшендә җирләнде.
6) Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 87х37х13.

48. Зәйнулла хатынына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер иясе мөтәвәффийә мәрхүмә
3) Бибихә... кызы
4) Зәйнулла әһлийәсе 78 йәшендә
5) 1905 нче сәнә 26 нчы ийүндә
6) 1323 нче сәнә һиҗриййә 7 нче җөмади-
7) -әл-әүвәлдә кабере мөнәүвәр улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрүб каберүм әҗәлне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган)[245]:
1) «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад
2) кәтәбәһәә мулла Сәлах-
3) -еддин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе вафат булучы мәрхүмә
3) Бибихә... кызы –
4) Зәйнулла хатыны 78 яшендә
5) 1905 елның 26 июнендә,
6) һиҗри 1323 елның 7 җөмади-
7) -әл-әүвәлендә [вафат]. Кабере нурлы булсын».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Сул ягы:
1) «Дога белән рухымны шатландырыгыз.
2) Моны язды: мулла Сәлах-
3) -еддин».

Таш үлчәмнәре: 90х36х16.

49. Фазылҗан Хәмидулла улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Фазылҗан бине Хәмидулла
4) 1904 сәнәи миладиййә
5) гыйнвар 30 нда
6) 71 йәшендә»[246].

Уң ягы (уеп язылган): «Вафат рахимәллааһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин»[247].

Сул ягы (уеп язылган): Фазылҗан Хәмидулла углы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Фазылҗан бине Хәмидулла
4) милади 1904 елның
5) 30 гыйнварында

[245] Беренче юлы вертикаль, калганнары диагональ буенча язылганнар.
[246] Дәвамы уң ягында.
[247] Башы алгы ягында.

6) 71 яшендә».

Уң ягы: «Вафат. Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Сул ягы: Фазылҗан Хәмидулла улы».

Таш үлчәмнәре: 82х31х9.

50. Гайниҗамал Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтү һәзәл-кабри
2) мәрхүмә Гайниҗамал Гобәйдулла
3) кызы Казан мишчаны
4) Төхфәтулла Нигъмәтулла углы
5) әһлийәсе 1898 сәнәи миладиййә
6) гыйнвар 11 ндә шәриф
7) рамазанда 72 йәшдә
8) мәдфүнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) мәрхүмә Гайниҗамал Гобәйдулла
3) кызы – Казан мещаны
4) Төхфәтулла Нигъмәтулла улының
5) хатыны – милади 1898 елның
6) 11 гыйнварында, рамазан
7) шәрифтә 72 яшьтә
8) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 83х31х10.

51. Бибифаизә Габдерәшид кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әгуузү биллээһи минәш-шәйтаанирраҗиим
2) бисмиллээһир-рахмээнир-рахиим
3) ләә иләәһә иллээллаah Мүхәммәдүррасүүлүллаah
4) әл-хүкмү лилләәһи Тәгааләәл-кәбиир күллү мән галәйһәә
5) фәән вә йәбкаа вәҗһү
6) Раббикә зү-
7) -л-җәләәли вәл-икраам әл-мәүүт әлмәүүт
8) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт 1910
9) нчы йылда нуйәбрнең 12 нч
10) көнендә Киме карйәсендә
11) Таҗеддин Гайсә углы-
12) -ның зәүҗә мөкәррәмәсе
13) Бибифаизә Габдерәшид
14) кызы дарел-фәнадин дарел-бәкайә»[248].

Уң ягы (уеп язылган):
1) «1328 нче йылда зөлкагдәнең 15 нче көнендә җомга көн вафат булды
2) Киме карйәсинең Таҗеддин Гайсә углы җәмәгате Фаизә».

Сул ягы (уеп язылган)[249]:
1) «Бер мең тугыз йөздә унынчы йылда Таҗеддин җәмәгате
2) Бибифаизә Габдеррәшид кызы 68 йәшендә вафат булды
3) рихләт
4) әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шайтаннан Аллаһка сыенам.
2) Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ исеме белән.
3) Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
4) Хөкем Бөек Аллаһ Тәгаләдә. Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә
5) фани, фәкать Раббыңның
6) Олуглык һәм хөрмәткә ия
7) булган йөзе генә калачак. Үлем. Үлем.
8) Һәр җан иясе үлемне татыячак. 1910
9) ел ноябренең 12 нче
10) көнендә [Күлле-]Киме авылындагы
11) Таҗеддин Гайсә улы-
12) -ның хөрмәтле хатыны
13) Бибифаизә Габдерәшид
14) кызы фани дөньядан мәңгелек дөньяга».

Уң ягы:
1) «1328 ел зөлкагдәсенең 15 нче көнендә җомга көн
2) [Күлле-]Киме авылыннан Таҗеддин Гайсә улы җәмәгате Фаизә вафат булды».

Сул ягы:
1) «Бер мең тугыз йөз дә унынчы елда Таҗеддин җәмәгате
2) Бибифаизә Габдерәшид кызы 68 яшендә вафат булды.
3) Күч-
4) -те».

Таш үлчәмнәре: 96х31х13.

[248] Алгы якта урын җитмәү сәбәпле, «рихләт кылды» («күчте») сүзләре сул ягына язылган.
[249] Беренче ике юлы вертикаль, ахыргы ике юлы горизонталь рәвештә язылган.

52. Габделгаффар Диньяр улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Габделгаффар Динйар
4) углы 1894 нче
5) миладиййә дикәбр
6) 30 нда 75 йәшдә
7) вафат итде
8) рахимәллааһү рахмәтән
9) вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү лә түфиидү бәгъдә-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделгаффар Диньяр
4) улы милади 1894
5) елның 30
6) декабрендә 75 яшьтә
7) вафат булды.
8) Аллаһ киң рәхмәте белән
9) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Сул ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Таш үлчәмнәре: 111(138)х32х14.

53. Сәрвиҗамал Габделкәрим кызына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Сәрвиҗамал Габделкәрим кызы
4) Габдессаттар әһлийәсе
5) вафат 1921 нче сәнәдә
6) шәгъбан 30 март 10 да
7) 73 йәшдә рахимәһәәллааһү
8) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Гакыйбәт бер көн китәрсең ул гокбага».

Сул ягы (уеп язылган): «Әй гафил алданма бу дөнйага».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Сәрвиҗамал Габделкәрим кызы –
4) Габдессаттар хатыны –
5) 1921 елның
6) 10 мартында, 30 шәгъбанында
7) 73 яшьтә вафат. Аллаһ аны киң рәхмәте
8) белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Ахырдан беркөн китәрсең ул ахирәткә».

Сул ягы: «Әй, ваемсыз, алданма бу дөньяга».

Таш үлчәмнәре: 90(103)х28х9.

54. Гыйззәтулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
2) каалүү иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи
3) рааҗигуун бу кабер
4) ийәсе Гыйззәтулла
5) Һибатулла углы
6) 79 йәшендә вафа-
7) -т булды Аллаһның
8) рәхмәтенә гарикъ у-
9) -лсун амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) лә иләәһә иллә әллаах
3) Мүхәммәдүр-расүүлүллаах
4) сәнәи миладиййә илә
5) 1915 нче йылда 1 нче ма-
6) -йда мәрхүм Гыйззәту-
7) -лла Һибатулла
8) углы вафат булды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән.
2) Әйттеләр [изге бәндәләр]: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа
3) кайтачакбыз. Бу кабер
4) иясе Гыйззәтулла
5) Һибатулла улы
6) 79 яшендә вафа-
7) -т булды. Аллаһның

8) рәхмәтенә күмел-
9) -сен, амин».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,
3) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
4) Милади белән
5) 1915 елның 1 ма-
6) -енда мәрхүм Гыйззәту-
7) -лла Һибатулла
8) улы вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 88х30х10.

Күңгәр авылы зираты

1. Нәбиулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Нәбийулла
2) Гобәйдулла
3) углы».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1920
2) нче йылда
3) 17 фибрал
4) вафат
5) Нәбийулла
6) кабере».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Нәбиулла
2) Гобәйдулла
3) улы».

Арткы ягы:
1) «1920
2) елның
3) 17 февралендә
4) вафат [булган]
5) Нәбиулла
6) кабере».

Таш үлчәмнәре: 93(110)х31х10.

2. Шәмсениса Биккенә кызына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Шәмсениса
2) Биккенә
3) кызы».

Таш үлчәмнәре: 55х30х9.

3. Сафагәрәй Мөхәммәдша улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәһ
2) Сафагәрәй
3) Мөхәммәдшаһ углы
4) 56 йәшендә
5) 28 нче априлдә
6) 1334 сәнәи һиҗриййә
7) 1916 сәнәи миладиййә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйлә-
2) -б догада
3) идеңез йа-
4) -д тәсаддыклә
5) кыйлуңыз ру-
6) -хымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта гына.
2) Сафагәрәй
3) Мөхәммәдша улы
4) 56 яшендә
5) милади 1916 елның
6) 28 апрелендә,
7) һиҗри 1334 елда [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада
3) искә алыгыз.
4) Сәдака бирү белән
5) рухымны
6) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 102х35х14.

4. Мөхәммәдша Габденнасыйр улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) ошбу кабернең ийәсе Мөхәммәд-
4) -шаһ Габденнасыйр углы вафат
5) улды 1904 нче йылда румиййә

6) илә 7 нче үктәбрдә 1322 сәнә
7) һиҗриййә илә 10 нчы шәгъбанда
8) 72 йәшендә мәдфүн
9) гаффәә ганһүмәәл-мәликүл-мәннәән
10) әл-мәүтү кәффәәратүн ли-күлли мүслим».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Каалә расүүлүллааһи
2) салләәллааһү галәйһи вә сәлләм
3) әл-мәүтү йәәътии ләә бүддә мин нүзүүл
4) фә-күүнүү мин әбнәәъил-әәхыйрати
5) вә ләә тәкүүнүү мин әбнәәъид-дүнйәә фә-инн-
6) -әл-йәүмә гамәлүн вә ләә хисәәбүн вә иннә гадән
7) хисәәбүн вә ләә гамәл әксируу мин-
8) -әл-гамәли фии һәзәәл-йәүми фә-иннәкүм
9) ләә тәкъдиру гадән галәәл-гамәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Бу кабернең иясе Мөхәммәд-
4) -ша Габденнасыйр улы
5) милади белән 1904 елның
6) 7 октябрендә, һиҗри белән
7) 1322 елның 10 шәгъбанында вафат булды,
8) 72 яшендә җирләнде.
9) Рәхимле Патша [Аллаһ] аларның икесен дә кичерсен
10) Үлем – һәр мөселман өчен гөнаһлардан арыну».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ илчесе (аны
2) Аллаһ олыласын һәм сәламләсен) әйтте:
3) «Үлем һичшиксез киләчәк, кабергә төшү булачак.
4) Ахирәт балалары булыгыз,
5) дөнья балалары булмагыз, чынлыкта,
6) бүген гамәл бар, хисап кылу юк, ә иртәгә
7) хисап кылу булачак, гамәл булмаячак. [Изге] гамәлләрегезне
8) бүген күбәйтегез, чынлыкта, сез
9) иртәгә гамәл кыла алмаячаксыз».

Таш үлчәмнәре: 106x35x14.

5. Хубҗамал Насыйбулла кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) ошбу кабер ийәсе
4) Хубҗамал Насыйбулла
5) кызы вафат
6) улды 1914 нче йылда румиййә илә
7) 20 нчы дикәбрдә 1332 нче
8) һиҗриййә илә 15 нче сәфәр-
9) -ел-хәйердә 75 йәшендә мәдфүн
10) гаффәә ганһүмәәл-мәликүл-мәннәән
11) әл-мәүтү кәффәәратүн ли-күлли мүслим».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Каалә расүүлүллааһи
2) салләәллааһү галәйһи вә сәлләм
3) әл-мәүтү йәәътии ләә бүддә мин
4) нүзүүл фә-күүнүү мин
5) әбнәәъил-әәхыйрати вә ләә
6) тәкүүнүү мин әбнәәъид-дүнйәә
7) фә-иннәл-йәүмә гамәлүн ләә
8) хисәәбүн гадән хисәәбүн
9) вә ләә гамәл әксир минәл-гамәли
10) фии һәзәәл-йәүми фә-иннәкүм ләә
11) тәкъдируунә гадән галәә-
12) -л-гамәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Бу кабер иясе
4) Хубҗамал Насыйбулла
5) кызы
6) милади белән 1914 елның
7) 20 декабрендә, һиҗри белән
8) 1332 елның 15 сәфәрендә
9) вафат булды, 75 яшендә җирләнде.
10) Рәхимле Патша [Аллаһ] аларның икесен дә кичерсен
11) Үлем – һәр мөселман өчен гөнаһлардан арыну».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ илчесе, аны
2) Аллаһ олыласын һәм сәламләсен, әйтте:
3) «Үлем һичшиксез киләчәк, кабергә
4) төшү булачак. Ахирәт
5) балалары булыгыз,
6) дөнья балалары булмагыз,
7) чынлыкта, бүген гамәл бар, хисап
8) кылу юк, ә иртәгә хисап кылу булачак,
9) гамәл булмаячак. [Изге] гамәлләрегезне
10) бүген күбәйтегез, чынлыкта,
11) сез иртәгә гамәл
12) кыла алмаячаксыз».

Таш үлчәмнәре: 109x32x11.

6. Әхмәҗән Галиәсгар улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1913 нче сәнә
2) 20 гыйнварда
3) 62 йәшендә
4) вафат улды
5) Әхмәҗән Галиәсгар
6) углы».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1331 нче
2) һиҗриййә илә
3) 23 нче сәфәрдә
4) вафат Әхмәҗән
5) Галиәсгар углы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1913 елның
2) 20 гыйнварында
3) 62 яшендә
4) Әхмәҗән Галиәсгар
5) углы
6) вафат улды».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән
2) 1331 [елның]
3) 23 сәфәрендә
4) Әхмәҗән
5) Галиәсгар улы вафат».

Таш үлчәмнәре: 80(97)x24x7.

7. Мөхәммәдсадыйк Габделфәез улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) миладиййә илә 1912 нч
3) йыл 2 нче май Мөхәммәд-
4) -садыйк Габделфәйез
5) углы чәһаршәнбә
6) көн 84 йәшендә
7) даре бәкайә рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Кыйл шәфәгать йә Мөхәммәд Мостафа»[250].

Сул ягы (уеп язылган): «Рәхмәт илә кич гөнаһын әй Хода».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) кәрәм әйләб дога-
3) -да идеңез йад
4) тәсаддыклә кыйлу-
5) -ңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади белән 1912
3) елның 2 маенда Мөхәммәд-
4) -садыйк Габделфәез
5) улы чәршәмбе
6) көн 84 яшендә
7) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Шәфәгать кыл, йә, Мөхәммәд Мостафа».

Сул ягы: «Рәхмәтең белән кичер гөнаһын, әй, Хода».

Арткы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Юмартлык кылып, дога-
3) -да искә алыгыз.
4) Сәдака бирү белән
5) рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 93(104)x31x10.

8. Хөснежамал Халид кызына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1913 нче йыл
3) 26 синтәбр
4) Хөснелҗамал
5) Халид кызы
6) 73 йәшенд вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Кыйл шәфәгать йә Мөхәммәд Мостафа».

Сул ягы (уеп язылган): «Мәүлүдинә ирде 73 сәнә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗриййә илә
2) 1331 нче йыл
3) 8 зөлкагдә

[250] Ислам дине өйрәтүе буенча, кыямәт көне башлангач, Мөхәммәд пәйгамбәр үз өммәте өчен шәфәгать кылачак, ягъни яклаучы булачак.Ләкин Аллаһ аңа Үзе теләгән кешеләргә генә шәфәгать кылырга рөхсәт итәчәк. Шуңа күрә мөселманнар пәйгамбәрнең яклавын Аллаһтан гына сорыйлар, чөнки турыдан-туры пәйгамбәргә ялвару – зур гөнаһ. Шуңа карамастан, кайбер ташъязмаларда шәфәгатьне Мөхәммәд пәйгамбәрдән сорау күренеше күзәтелә.

4) Хөснелҗамал
5) Габделлатыйф
6) зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән
2) 1913 елның
3) 26 сентябрендә
4) Хөснеҗамал
5) Халид кызы
6) 73 яшендә вафат».

Уң ягы: «Шәфәгать кыл, йә, Мөхәммәд Мостафа».
Сул ягы: «Тууына 73 ел иде».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән
2) 1331 елның
3) 8 зөлкагдәсендә
4) Хөснеҗамал
5) Габделлатыйф
6) хатыны [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 83(99)x33x12.

9. Мифтахеддин Әсфәндияр улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер сахибе Мифтахеддин
3) Әсфәндийар углы румиййә илән
4) 1905 нче сәнә үктәбр 25 нче йәүмендә
5) 57 йәшендә даре дөнйадин даре гокбайә
6) рихләт кыйлды нәүвәраллаһү мәркадәһ
7) әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».
Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәндә икән йарын сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе Мифтахеддин
3) Әсфәндияр улы милади белән
4) 1905 ел октябренең 25 нче көнендә
5) 57 яшендә дөньядан ахирәт йортына
6) күчте. Аллаһ аның каберен нурландырсын,
7) амин».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».
Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 108(116)x35x15.

10. Бибихәйрелбанатка куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1915 нч
2) 25 нче априлдә
3) 27 йәшендә вафат
4) Бибихәйрелбанат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1333 нче
2) 24 нче җөмадиәл-ахир
3) шинбә көн вафат
4) Бибихәйрелбанат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1915 [елның]
2) 25 апрелендә
3) 27 яшендә
4) Бибихәйрелбанат вафат».

Арткы ягы:
1) «1333 [елның]
2) 24 җөмадиәл-ахирендә
3) шимбә көн
4) Бибихәйрелбанат вафат».

Таш үлчәмнәре: 45x27x7.

11. Мөлхибә Муса кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) 1897 нче йылында
3) майның 1 нче көнендә
4) Галийулла Мөхәммәдгани
5) углының җәмәгате
6) Мөлхибә Мамай авылы-
7) -ның Муса кызы
8) 57 йәшендә баде
9) әҗәл шәмгы рухыны набуд
10) кыйлды Аллаһүммә-җгаль
11) кабрәһә раудатән мин рийәәд-
12) -ыйль-җәннәһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) 1897 ел
3) маеның 1 нче көнендә
4) Галиулла Мөхәммәдгани
5) улының җәмәгате –
6) Мөлхибә Мамай авылын-
7) -нан Муса кызы
8) 57 яшендә әҗәл
9) җиле рух шәмен
10) бетерде. Аллаһым, аның каберен
11) җәннәт бакчаларыннан бер
12) бакча ит, амин».

Таш үлчәмнәре: 103x36x8.

12. Гыйззәтулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1886 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Гыйззәтулла
2) ибне
3) Гобәйдулла».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1886 нчы
2) сәнә
3) 31 нче мартда
4) 56 йәшдә
5) мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Гыйззәтулла
2) ибне
3) Гобәйдулла».

Арткы ягы:
1) «1886
2) елның
3) 31 мартында
4) 56 яшьтә
5) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 85(95)x33x12.

13. Хәбибҗамал Сөләйман кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1909 нчы
2) Хәбибҗамал
3) Сөләйман
4) кызы 27
5) ийүндә вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Хәбиб-
2) -җамал
3) Гыйззәтулла
4) җәмәгате 77
5) йәшдә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1909 [елның]
2) 27 июнендә
3) Хәбибҗамал
4) Сөләйман
5) кызы вафат».

Арткы ягы:
1) «Хәбиб-
2) -җамал
3) Гыйззәтулла
4) җәмәгате 77
5) яшьтә вафат».

Таш үлчәмнәре: 91(110)x31x11.

14. Габдрахман Габделбасыйр улына һәм Шәмсекамәр Шаһгали кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу кабердә
2) Габдеррахман бине
3) Габделбасыйр
4) 1910 нчы йылда 13 нч
5) нуйәбрдә 27 нч
6) йәшдә мәдфүн».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Габделбасыйр җәмәгате
2) Шәмсекамәр Шаһ-
3) -гали кызы 1910 нч
4) йылда 14 нче дикә-
5) -брдә 57 йәшендә
6) мәдфүнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабердә
2) Габдрахман бине
3) Габделбасыйр
4) 1910 елның 13
5) ноябрендә 27
6) яшьтә җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Габделбасыйр җәмәгате –
2) Шәмсекамәр Шаһ-
3) -гали кызы – 1910
4) елның 14 дека-
5) -брендә 57 яшендә
6) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 73(81)х34х10.

15. Шәмсежамал Хөсәен кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу
2) каберстанда
3) Сабиржан
4) җәмәгате Шәмсе-
5) -җамал Хөсәйен
6) кызы вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Милади
2) 1914 нче йылда
3) 5 нче фибралда
4) 57 йәшендә
5) дәфен кылынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу
2) каберстанда
3) Сабиржан
4) җәмәгате – Шәмсе-
5) -җамал Хөсәен
6) кызы – вафат».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) 1914 елның
3) 5 февралендә
4) 57 яшендә
5) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 108х34х13.

16. Мөхәммәдвәли Әсфәндияр улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Вә фии-
2) -с-сәнәтил-камәриййәти минәл-һижрат-
3) -ин-нәбиййи галәйһис-сәләәм
4) Мөхәммәдвәли бине Әсфәндийар
5) әл-Күңәри би-хүкми Хода
6) вә би-тәкъдиири Иләһи даре фәнадан
7) даре бәкайә рихләт әйләде».

Уң ягы (калкытып язылган): «Бу көн бәндә икән йарын сәңадыр».

Сул ягы (калкытып язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мәдфүн
2) 1324 нче сәнәдә 8
3) нче мөхәррәм җомга көн
4) 1906 нчы йылда 17 нче
5) фибралда 73 йәшендә
6) үлүмемез гассасани йийалем
7) дайим әстәгъфирулла дийәлем».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һижри
2) ел исәбе, пәйгамбәр (аңа
3) сәлам булсын) һижрәте [Мәккәдән Мәдинәгә күченүеннән саналган ел исәбе] белән.
4) Мөхәммәдвәли бине Әсфәндияр
5) Күңгәри Хода хөкеме
6) һәм Илаһ тәкъдире белән фани дөньядан
7) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Арткы ягы:
1) «1324 елның 8
2) мөхәррәмендә җомга көн,
3) 1906 елның 17
4) февралендә 73 яшендә
5) җирләнде.
6) Үлемебез газабын татыйм,
7) даими «Кичер, Аллаһ», дип әйтәм».

Таш үлчәмнәре: 93(105)х34х14.

17. Бибилатыйфа Сәйфелмөлек кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1914 нче йыл
3) 31 нче гыйнвар
4) Бибилатыйфа Сәйф-
5) -елмөлек кызы
6) 70 йәшендә
7) мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Мәүлүдинә ирде 70 сәнә».

Сул ягы (уеп язылган): «Кыйл шәфәгать йә Мөхәммәд Мостафа».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗриййә илә
2) 1332 нче йыл
3) рабигыль-әүвәл
4) 18 җомга
5) Бибилатыйфа
6) Исхак
7) зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән
2) 1914 елның
3) 31 гыйнварында
4) Бибилатыйфа Сәйф-
5) -елмөлек кызы
6) 70 яшендә
7) җирләнде».

Уң ягы: «Тууына 70 ел иде».

Сул ягы: «Шәфәгать кыл, йә, Мөхәммәд Мостафа».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән
2) 1332 елның
3) 18 рабигыль-әүвәлендә
4) җомга
5) Бибилатыйфа
6) Исхак
7) хатыны [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 105(126)x31x11.

18. Исхак Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү
2) лилләәһ 1903 нче йылда
3) 19 нчы агустда
4) Исхак Ибраһим
5) углы вафат улуб
6) ошбу каберстанда
7) дәфен кылынды 70 йәшендә
8) 1321 нче сәнәи һиҗриййәдә
9) 10 нчы җөмадиәл-ахирдә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әгуузү
2) биллләәһи минәш-шәйтаан-
3) -ир-раҗиим бисмилләәһир-ра-
4) -хмәәнир-рахиим күллү
5) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
6) вә ләй йүәххыйраллаахү
7) нәфсән изәә җәәъә
8) әҗәлүһәә түүбүү иләә-
9) -ллаахи Тәгааләә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем
2) Аллаһта. 1903 елның
3) 19 августында
4) Исхак Ибраһим
5) улы, вафат булып,
6) бу каберстанда
7) 70 яшендә,
8) һиҗри 1321 елның
9) 10 җөмадиәл-ахирендә җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган
2) шәйтаннан Аллаһка
3) сыенам. Шәфкатьле, Рәхимле
4) Аллаһ исеме белән. Һәр
5) җан иясе үлемне татыячак.
6) әгәр кемнеңдер әҗәле килсә,
7) Аллаһ аны һичберегездән
8) кичектермәс. Аллаһ Тәгаләгә
9) тәүбә итегез».

Таш үлчәмнәре: 95x36x11.

19. Гайнелхәят Әхмәдулла кызына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә
2) иләйһи рааҗигуун
3) дарел-фәнадин
4) дарел-бәкайә интикаль
5) кылды Вәлиәхмәд
6) җәмәгате Гайн-
7) -елхәйәт Әхмәдулла
8) кызы».

Уң ягы (уеп язылган): «Мәүлүдинә ирде илле алты сәнә».

Сул ягы (уеп язылган): «Кыйл шәфәгать йә Мөхәммәд Мостафа».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1911 нче йыл
3) 6 нчы үктәбрдә

4) һиҗрәтү расүүл-
5) -илләәһи саллләәллааһү галәйһи вә сәлләм
6) 1329 нчы йылда
7) 26 нчы шәүвәл-
8) -дә 56 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.
3) Вәлиәхмәд
4) җәмәгате – Гайн-
5) -елхәят Әхмәдулла
6) кызы – фани дөньядан
7) мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Уң ягы: «Тууына илле алты ел иде».

Сул ягы: «Шәфәгать кыл, йә, Мөхәммәд Мостафа».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1911 елның
3) 6 октябрендә
4) Аллаһ илчесе (Аны
5) Аллаһ олыласын һәм сәламләсен) һиҗрәте белән
6) 1329 елның
7) 26 шәүвәлен-
8) -дә 56 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 103x31x13.

20. Вәлиәхмәд Әхмәр Габдрахман улының улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи
2) рааҗигуун дәфен
3) кылынды Вәлиәхмәд
4) атасы Әхмәр
5) Габдеррахман
6) углы рахимәһүллааһү
7) Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Үхърус лидүнйәәкә кәъәннәкә тәгыыйшү әбәдә».

Сул ягы (уеп язылган): «Вә игъмәл лиәәхыйратикә кәъәннәкә тәмүүтү гадә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1899 нчы йылда
3) 20 нче ийүндә һиҗриййә
4) илә 1317 нче
5) йылда 23 нче сәфәр-
6) -ел-хәйердә 88 йәшендә
7) йәкшәнбә көн вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.
3) Вәлиәхмәд
4) (атасы Әхмәр
5) Габдрахман
6) улы) җирләнде. Аллаһ Тәгалә аны
7) киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Бу дөнья өчен, мәңге яшәячәксең кебек тырыш».

Сул ягы: «Ахирәт өчен, иртәгә үләячәксең кебек гамәл кыл».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1899 елның
3) 20 июнендә, һиҗри
4) белән 1317
5) елның 23 сәфәрен-
6) -дә 88 яшендә
7) якшәмбе көн вафат».

Таш үлчәмнәре: 90x32x10.

21. Мөхәммәдлатыйф Мөхәммәди улы Тимерпулатовка куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1904 нче
2) миладиййә илә 2 нч
3) иййүлдә вафат улды
4) Мөхәммәдлатыйф Мөхәммәди
5) углы Тимерпулатыф
6) 61 йәшендә мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Каалә расүүлүллааһи салләә әд-дүнйәә мәзрагатүл-әәхыйраһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Кааләллааһү Тәгаалә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1322 нче
2) һиҗриййә илә 21 нче

3) җөмадиәл-әүвәлдә даре
4) фәнадан даре бәкайә рихләт
5) әйләде Мөхәммәдлатыйф
6) бине Мөхәммәди әл-Күңәри».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади беләи
2) 1904 [елның] 2
3) июлендә
4) Мөхәммәдлатыйф Мөхәммәди
5) улы Тимерпулатов вафат булды,
6) 61 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Аллаһ илчесе ([Аллаһ аны] олыласын) әйтте: «Дөнья – ахирәт басуы».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри беләи
2) 1322 [елның] 21
3) җөмадиәл-әүвәлендә
4) Мөхәммәдлатыйф
5) бине Мөхәммәди Күңгәри
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 94(103)х36х16.

22. Зөһрә Корби кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) Габдессаттар
3) җәмәгате Зөһрә
4) Корби кызы
5) җәгаләллаһү
6) кабраһәә мүнәүвәран
7) би-нүүрил-иимәән».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Милади
2) 1902 нче йылда
3) 3 нче дикәбр
4) 18 нче рамазан
5) шәрифдә йитмеш
6) йәшендә дәфен
7) кылынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Габдессаттар
3) җәмәгате – Зөһрә
4) Корби кызы.
5) Аллаһ аның
6) каберен иман нуры
7) белән нурландырсын».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) 1902 елның
3) 3 декабрендә,
4) 18 рамазан
5) шәрифендә җитмеш
6) яшендә
7) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 75(81)х31х11.

23. Маһирә Хәсән кызына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Маһирә Хәсән
3) кызы Шәйхедд-
4) -ин зәүҗәсе
5) 48 йәшендә
6) ... нче майда вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәллаһү лимән зәәрании».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1919 сәнәи миладииййә
2) кәрәм әйләб
3) догада иде-
4) -ңез йад
5) тәсаддыклә кыйлу-
6) -ңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Маһирә Хәсән
3) кызы – Шәйхедд-
4) -ин хатыны –
5) 48 яшендә
6) ... майда вафат».

Уң ягы: «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Милади 1919 елда [вафат].
2) Юмартлык кылып,
3) догада
4) искә алыгыз,
5) сәдака бирү белән
6) рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 85х28х9.

24. Сиражеддин Сәгъдеддин улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Сиражеддин
3) Сәгъдеддин у-
4) -глы 72 йәшендә
5) 1333 сәнәи һиҗриййә
6) 1915 сәнәи миладиййә»[251].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «15 нче ийүндә
2) ихване
3) мөслиминдә-
4) -н дога рәҗа
5) идәмез»[252].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Сиражеддин
3) Сәгъдеддин у-
4) -лы 72 яшендә
5) һиҗри 1333 елда,
6) милади 1915 елның».

Арткы ягы:
1) «15 июнендә [вафат яки җирләнде].
2) Мөселман
3) кардәшләрдә-
4) -н дога өмет
5) итәбез».

Таш үлчәмнәре: 79(87)x28x10.

25. Хәдичә Әхмәд кызына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабернең ийәсе
3) Күңәр авылы 1 нче мәхәллә
4) Габделбари Шиһабеддин
5) углыйның хатуны Коллар
6) авылыйның Хәдичә Әхмәд
7) [кызы]».

Уң ягы (уеп язылган): «Аллаһ Тәгалә каберин»[253].

Сул ягы (уеп язылган): «Нурлы кылсун амин»[254].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих милади белә
2) 1927 нче йыл 1 нче аугыст
3) тарих һиҗри белә
4) 1346 нчы йыл 2 нче сәфәр-
5) -ел-хәйердә...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабернең иясе:
3) Күңгәр авылының 1 нче мәхәлләсеннән
4) Габделбари Шиһабеддин
5) угының хатыны – Коллар
6) авылыннан Хәдичә Әхмәд
7) [кызы]».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә каберен».

Сул ягы: «Нурлы итсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1927 елның 1 августында,
3) һиҗри белән
4) 1346 елның 2 сәфәрен-
5) -дә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 60(67)x34x9.

26. Хөсәен Сиражеддин улына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Хөсәйен Сира-
3) -жеддин углы
4) 27 йәшендә
5) 15 нче ийүндә
6) 313[255] сәнәи һиҗриййә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1995[256] сәнәи миладиййә
2) ихване мөслимин-
3) -дән дога рә-
4) -жа идәмез».

[251] Дәвамы арткы ягында.
[252] Башы алгы ягында.
[253] Дәвамы сул ягында.
[254] Башы уң ягында.
[255] 1313 ел күздә тотыла.
[256] Ялгыш язылган, 1895 ел булырга тиеш.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Хөсәен Сира-
3) -җеддин улы
4) 27 яшендә
5) 15 июндә,
6) һиҗри [1]313 елда [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Милади 1895 елда [вафат яки җирләнде].
2) Мөселман кардәшләр-
3) -дән дога
4) өмет итәбез».

Таш үлчәмнәре: 82x31x10.

27. Габдессаттар Мозаффар улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ Тәгалә-
2) -нең рәхмәтенә
3) васыйл улса
4) иде Габд-
5) -ессаттар Мозаффар
6) углы рахимәһ-
7) -үллаһү Тәгаалә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Милади илә
2) 1907 нче йылда
3) 9 нчы үктәбр
4) 15 нче рамазан
5) шәрифдә 73
6) йәшендә дәфен
7) кылынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә-
2) -нең рәхмәтенә
3) ирешсә
4) иде. Габд-
5) -ессаттар Мозаффар
6) улы. Аллаһ Тәгалә
7) аны рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1907 елның
3) 9 октябрендә,
4) 15 рамазан
5) шәрифендә 73
6) яшендә
7) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 94x32x12.

28. Әсхабҗамал Сәгыйдь Габид улының кызына куелган кабер ташы, 1887 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып һәм уеп язылган[257]):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ
2) Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
3) ошбу кабердә дәфен кылынды Касыйм
4) Вәли углының җәмәгате
5) Әсхабҗамал Сәгыйдь Габид
6) углының кызы 1887 нч
7) йылда миладиййәдә май 12 ндә 55
8) йәшендә галәмәтдән морадым бер до-
9) -гадыр бу көн бәңа икән йарын
10) сәңадыр».

Арткы ягы (калкытып һәм уеп язылган[258]):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) һиҗриййә илә 1304 нче йылда
4) рамазан әүвәлге көнендә даре
5) фәнадан даре бәкайә рихләт әйләде
6) Касыйм җәмәгате Әсхаб-
7) -җамал Сәгыйдь кызы әл-кабру
8) раудатүн мин рийәәдыйль-җәннәти әү хүфратүн
9) мин хүфәрин-нәйраан».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,
2) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
3) Бу кабердә Касыйм
4) Вәли улының җәмәгате –
5) Әсхабҗамал Сәгыйдь Габид
6) улының кызы – милади
7) 1887 елның 12 маенда 55
8) яшендә җирләнде. Галәмәттән морадым бер до-
9) -гадыр, бу көн миңа икән, иртәгә
10) сиңадыр».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Һиҗри белән 1304 ел
4) рамазанының әүвәлге көнендә
5) Касыйм җәмәгате – Әсхаб-
6) -җамал Сәгыйдь кызы –

[257] Беренче ике юлы калкытып, калганнары уеп язылган.
[258] Беренче ике юлы калкытып, калганнары уеп язылган.

7) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Кабер -
8) җәннәт бакчаларыннан бер бакча яки
9) утлар чокырларыннан бер чокыр».

Таш үлчәмнәре: 101(117)x36x14.

29. Гайнекамал Зөбәер кызына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Гайнелкамал
3) Зөбәйер кызы вафат
4) миладиййә 1891 нче йылда
5) 27 нче гыйнвар-
6) -да 55 йәшендә
7) Сиражеддин
8) зәүҗәсе».

Уң ягы (уеп язылган): «Беләсез бу каберә киләчәк вакытыңыз йакыйн».

Сул ягы (уеп язылган): «Йә әхый гафил улма сакыйн».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Ихване мөслимин-
2) -дән дога рәҗа
3) идәмез».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Гайнекамал
3) Зөбәер кызы –
4) Сиражеддин
5) хатыны –
6) милади 1891 елның
7) 27 гыйнварын-
8) -да 55 яшендә вафат».

Уң ягы: «Беләсез: бу кабергә киләчәк вакытыгыз якын».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, гафил булма, сак бул».

Арткы ягы:
1) «Мөселман кардәшләр-
2) -дән дога өмет
3) итәбез».

Таш үлчәмнәре: 110x32x13.

30. Мулла Мөхәммәдъяр Мөхәммәдгали улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) руми 1892 сәнә гыйнвар
3) 29 нда Күңәрнең
4) Мөхәммәдъяр Мөхәммәдгали
5) углы 67 йәшендә
6) иржигыый хитабына ижабәт»[259].

Уң ягы (уеп язылган): «Бу кабер мулла Мөхәммәдъяр хәлфәнең мәркадидүр рахимәһүллаһү Тәгааләә».

Сул ягы (уеп язылган): «Ибүб тәслиме рух әйләде таййибәллаһү сәраһ»[260].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1892 елның 29
3) гыйнварында Күңгәрдән
4) Мөхәммәдъяр Мөхәммәдгали
5) улы 67 яшендә
6) «[Раббыңа] кайт» сүзенә җавап».

Уң ягы: «Бу кабер мулла Мөхәммәдъяр хәлфәнең кабере. Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Сул ягы: «Биреп, рух [җан] тәслим кылды. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Таш үлчәмнәре: 99x31x15.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №48.

31. Сабира Хәсән кызына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Сабира
3) Хәсән кызы
4) Нуриәхмәд зәү[җә]се
5) 23 йәшендә
6) 12 нче мартда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1913 сәнәи миладиййә

[259] Дәвамы сул ягында.
[260] Башы алгы ягында.

2) кәрәм әйләб до-
3) -гада идеңез
4) йад тәсаддыклә
5) кыйлуңыз ру-
6) -хымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем аллаһта.
2) Сабира
3) Хәсән кызы –
4) Нуриәхмәд хатыны –
5) 23 яшендә
6) 12 мартта [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Милади 1913 елда [вафат яки җирләнде].
2) Юмартлык кылып, до-
3) -гада искә
4) алыгыз, сәдака бирү белән
5) рухымны
6) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 87x30x8.

32. Фәхреддин Габделҗаббар улы Сәйфуллинга куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи раажигуун
2) Фәхреддин Габделҗаббар
3) углы Сәйфуллин
4) 62 йәшендә руми илә
5) 1907 йылда гыйнвар
6) 2 ндә һиҗриййә 1324 сәнә
7) мәдфүн гарикы
8) рәхмәт улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Фәхреддин Габделҗаббар
3) улы Сәйфуллин
4) 62 яшендә милади белән
5) 1907 елның 2
6) гыйнварында, һиҗри 1324 елда
7) җирләнде. Рәхмәткә
8) күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 63x31x8.

33. Әсфәндияр Фәтхулла улына куелган кабер ташы, XIX гасыр ахыры.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаа-
2) -ләә күллү нәфсиң зәә-
3) -икатүл-мәүүт
4) 18...
5) йылда 8 нче абр-
6) -илдә Күңәр авы-
7) -лыйның Әсфәндийа-
8) -р Фәтхулла углы
9) йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе
3) үлемне татыячак».
4) 18...
5) елның 8 апр-
6) -елендә Күңгәр авы-
7) -лыннан Әсфәндия-
8) -р Фәтхулла улы
9) яшендә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 103x32x14.

34. Бибимәхбубҗамал Мостай кызына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) Рабби ләә тәзәрнии фәрдәү вә әнтә хайр-
3) -уль-вәәрисиин
4) 1891 нче тарихында 31
5) агустда хаҗҗел-хәрәмәйен
6) Әсфәндийар җәмәгате Биби-
7) -мәхбубҗамал Күәм авылы-
8) -ның Мостай кызы
9) 71 йәшендә дарел-фәнадан
10) дарел-бәкага шинбә көн
11) рихләт итде Аллаһүммәҗгаль
12) кабраһәә раудатән мин рийәәд-
13) -ыйль-җәннәһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) Раббым, мине ялгыз калдырма, Син – варисларның
3) иң хәерлесесе.
4) 1891 [елның] 31

5) августында хаҗи
6) Әсфәндияр җәмәгате – Биби-
7) -мәхбубҗамал Күәм авылын-
8) -нан Мостай кызы –
9) 71 яшендә фани дөньядан
10) мәңгелек дөньяга шимбә көн
11) күчте. Аллаһым, аның каберен
12) җәннәт бакчаларыннан бер
13) бакча ит, амин».

Таш үлчәмнәре: 117х48х13.

35. Баһаеддин Мохтар улына куелган кабер ташы, 1877 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһүммәҗгаль кабрыһү раудатән
2) мин рийәәдыйль-җәннәһ
3) 1877 нче йылда
4) беренче гынварда сиһ-
5) -шәнбә көн Күңләр
6) авылыйның Баһаэддин
7) Мохтар углы 64
8) йәшендә вафат
9) нәүвәраллаһү Тәгаһ[261] мәркадәһ
10) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһым, аның каберен җәннәт
2) бакчаларыннан бер бакча ит.
3) 1877 елның
4) беренче гынварында си-
5) -шәмбе көн Күңгәр
6) авылыннан Баһаеддин
7) Мохтар улы 64
8) яшендә вафат.
9) Аллаһ Тәгалә аның каберен нурландырсын,
10) амин».

Таш үлчәмнәре: 90х36х8.

36. Шәмсениса Әхмәдулла кызына куелган кабер ташы, 1865 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) мәрхүүмәтүл-мәгъфүүратү Шәмсенниса Әхмәдулла кызы
3) мулла Мөхәммәдшәриф хәләле утуз йыл бергә
4) мәгыйшәт кыйлуб мең ике йөз сиксән
5) икенче йылда маһе рәҗәбнең әүвәл көнендә
6) вә румиййә мең сигез йөз алтмыш бишенче
7) йылда үктәбрнең ун сигезендә
8) шәһид улды кәәнәт мүгаллимәһ».

Сул ягы (калкытып язылган): «Шәмсенниса Мөхәммәдшәриф мулла җәмәгате 1865 сәнә 51 йәшендә».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Ләү кәәнәтид-дүнйәә түдүүмү бивәәхидин
2) лә-кәәнә расүүлүллааһи фиихәә мүхълидәә
3) гозерем шул сәңа әй зәүҗе гакыйл
4) сәүчем гафу ит бәңа даим дога кыйл
5) уйан буйан бакуб дога көтәрмез
6) әгәр табылса сүенүшүб китәрмез
7) безем Коръән укурга телемез йук
8) хәйер ихсан кыйлурга пулымыз йук».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Рәхим кылынган, гафу ителгән Шәмсениса Әхмәдулла кызы –
3) мулла Мөхәммәдшәриф хәләле – утыз ел бергә
4) яшәп, мең ике йөз сиксән
5) икенче ел рәҗәб аеның әүвәлге көнендә,
6) милади мең сигез йөз алтмыш бишенче
7) елның унсигезенче октябрендә
8) шәһид булды. Мөгаллимә иде».

Сул ягы: «Шәмсениса Мөхәммәдшәриф мулла җәмәгате 1865 елда 51 яшендә [вафат]».

Арткы ягы:
1) «Әгәр дә дөнья берәр зат өчен дәвам итсә,
2) Аллаһның илчесе [Мөхәммәд пәйгамбәр] анда мәңге булыр иде.
3) Гозерем шул сиңа, әй, акыллы ирем,
4) гафу ит, миңа даими дога кыл.
5) Ул якка, бу якка карап, дога көтәрбез;
6) әгәр табылса, сөенешеп китәрбез.
7) Безнең Коръән укырга телебез юк,
8) хәерлек-изгелек кылырга көчебез юк».

Таш үлчәмнәре: 105х43х20.

[261] Тәгаалләә.

37. Төхфәтулла Хәлилулла улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибүл-мәркади
2) Төхфәтулла бине
3) Хәлилулла 73 йәшендә
4) 1328 сәнә һиҗриййә зөлкагдә
5) 6 нда вафат Аллаһ Тәгалә
6) гөнаһларины мәгъфирәт
7) әйләгәй иде».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһү вә җәгаләл-җәннәтә мәәъвәәһү вә мәсвәәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер иясе
2) Төхфәтулла бине
3) Хәлилулла 73 яшендә
4) һиҗри 1328 елның 6
5) зөлкагдәсендә вафат. Аллаһ Тәгалә
6) гөнаһларын гафу
7) итсә иде».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Сул ягы: ««Аллаһ аның каберен нурландырсын һәм урынын, барачак йортын җәннәт итсен».

Таш үлчәмнәре: 81(96)х31х12.

38. Хөсәен Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә иллләәллааһ
2) Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ түвүффийә
3) рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәә-
4) -сигаһ фии сәнәти 1903 нче мила-
5) -диййә 18 нче иййүндә
6) Хәсәйен Һибатулла
7) углы 76 йәшендә
8) вә гуддә нәфсәкә мин әһлил-кубүүр».

Арткы ягы (уеп язылган)[262]:
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт вә ләй йүәххыйраллааһү нәфсән изәә җәәъә әҗәлүһәә
2) каалә расүүлүллааһи салләәллааһү Тәгааләә галәйһи вә сәлләмә әд-дүнйәә сәәгатүн фәҗгальһәә таагаһ ләйсә фииһи раахәһ әл-мәүтү йәәътии ләә бүддә мин нүзүүл күн фиид-дүнйәә кә-әннәһү гарииб».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,
2) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
3) Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын
4) Милади 1903 елның
5) 18 июнендә
6) Хәсәен Һибатулла
7) улы 76 яшендә вафат булды.
8) Үзеңне кабер әһелләреннән дип сана».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак». «Әгәр кемнеңдер әҗәле килсә, Аллаһ аны һичберегездән кичектермәс.
2) Аллаһ илчесе (аны Аллаһ Тәгалә олыласын һәм сәламләсен) әйтте: «Дөнья – бер сәгатьлек, аны итагать белән үткәр, анда рәхәтлек юк». «Үлем һичшиксез киләчәк, кабергә төшү булачак». «Дөньяда чит кеше кебек бул».

Таш үлчәмнәре: 109(127)х35х18.

39. Әхмәдшакир Әхмәдвәли улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1329 һиҗриййә
2) 1912 нче
3) йылда вафат
4) Әхмәдшакир
5) Әхмәдвәли углы
6) 77 йәшендә
7) дарел-фәнадин
8) рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Изәә җәәъә әҗәлүһүм фә-ләә йәстәәъхыйруунә сәәгатән вә ләә йәстәкъдимүүн».

[262] Беренче юлы ташның үзәк өлешендә вертикаль рәвештә, икенче юлы ташның периметры буенча язылган.

Сул ягы (уеп язылган): «Раббигъфир вәрхәм вә әнтә хайрур-раахимиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи
2) вә иннәә иләйһи раажигуун
3) 8 нче ийүндә
4) миладиййә илә
5) 1912 нчедә
6) 1835 нче йылда
7) 15 нче агустда
8) вөжүдә килде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һиҗри 1329 [елда],
2) милади 1912
3) елда
4) Әхмәдшакир
5) Әхмәдвәли улы вафат,
6) 77 яшендә
7) фани дөньядан
8) күчте».

Уң ягы: «Әгәр аларга әҗәлләре килсә, бер сәгать иртә килмәс һәм бер сәгатькә кичекмәс».

Сул ягы: «Раббым, гафу ит, рәхим кыл. Син – рәхимлеләрнең Иң хәерлесе».

Арткы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы
2) һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз
3) Милади белән
4) 1912 [елның]
5) 8 июнендә [вафат].
6) 1835 елның
7) 15 августында
8) дөньяга килде».

Таш үлчәмнәре: 90(106)x30x12.

40. Бәдигылҗамал Биккенә кызына куелган кабер ташы, 1884 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) руми 1884 сәнә май 10 нда
3) Иске Өҗемнең Бәдигылҗамал
4) Биккенә кызы Хәбибулла Һибатулла
5) углының хәләле 55 йәшендә
6) чәһаршәнбә көн мәдфүн улды».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт идүб җайын җәннәт кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1884 елның 10 маенда
3) Иске Өҗемнән Бәдигылҗамал
4) Биккенә кызы – Хәбибулла Һибатулла
5) улының хәләле – 55 яшендә
6) чәршәмбе көн җирләнде».

Сул ягы: «Аллаһ, рәхим кылып, урынын җәннәт итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 99(123)x35x12.

41. Маһруй Муса кызына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Маһруй
3) бинте
4) Муса».

Уң ягы (уеп язылган): «70 йәшендә мәдфүн».

Сул ягы (уеп язылган): «Йә әхый гафил улма сакыйн».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1916
2) 10 нчы март
3) вафат улды
4) Маһруй
5) Насреддин
6) зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Маһруй
3) бинте
4) Муса».

Уң ягы: «70 яшендә җирләнде».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, гафил булма, сак бул».

Арткы ягы:
1) «1916 [елның]
2) 10 мартында
3) Маһруй
4) Насреддин

5) хатыны
6) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 70x30x9.

42. Лотфулла Нәбиулла улы Насыйровка куелган кабер ташы[263], 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәүвәраллаahү
2) мәркадәh
3) Лотфулла
4) бине
5) Нәбийулла
6) Насыйрыф».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «1891 нче
2) йыл
3) 10 нчы
4) нуйәбрдә
5) 9
6) йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh аның
2) каберен нурландырсын.
3) Лотфулла
4) бине
5) Нәбиулла
6) Насыйров».

Арткы ягы:
1) «1891
2) елның
3) 10
4) ноябрендә
5) 9
6) яшендә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 69x21x16.

43. Әхмәдулла Габденнасыйр улына куелган кабер ташы[264], 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы

Беренче ягы (калкытып язылган)[265]: «Әлмәрхүүмүл-мәгъфүүру Әхмәдулла»[266].

Икенче ягы (калкытып язылган)[267]: «Габденнасыйр углы вафат 82»[268].

Өченче ягы (калкытып язылган)[269]: «Йәшендә 1882 нче йылда ийүл»[270].

Дүртенче ягы (калкытып язылган)[271]: «Һәр кеше бу мәркад кыйлса нәзар»[272].

Бишенче ягы (калкытып язылган)[273]: «Сахибене бел догада йат идәр»[274].

Алтынчы ягы (калкытып язылган)[275]: «Ни кадәр итсә кеше сәйр дийәрә»[276].

Җиденче ягы (калкытып язылган)[277]: «Гакыйбәт улмас фәнд пайда»[278].

Сигезенче ягы (калкытып язылган)[279]: «Рухыйна фатиха амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Беренче ягы: «Рәхим кылынган, гафу ителгән Әхмәдулла».

Икенче ягы: «Габденнасыйр улы 82 [яшендә] вафат».

Өченче ягы: «[82] яшендә 1882 елның июлендә [вафат]».

Дүртенче ягы: «Һәр кеше бу кабергә караса».

Бишенче ягы: «Иясен белеп, догада искә алыр».

Алтынчы ягы: «Ни кадәр кеше дөньяда торса да».

Җиденче ягы: «Ахырдан булмас, алданганын белер».

---

[263] Бу таш аеруча үзенең оста һәм оригиналь эшләнеше белән сәнгати яктан бик зур игътибарга лаек.
[264] Бу таш аеруча үзенең оста һәм оригиналь эшләнеше белән сәнгати яктан бик зур игътибарга лаек.
[265] Вертикаль рәвештә язылган.
[266] Дәвамы икенче һәм өченче якларында.
[267] Вертикаль рәвештә язылган.
[268] Башы беренче, дәвамы өченче якларында.
[269] Вертикаль рәвештә язылган.
[270] Башы беренче һәм икенче якларында.
[271] Вертикаль рәвештә язылган.
[272] Дәвамы бишенче, алтынчы һәм җиденче якларында
[273] Вертикаль рәвештә язылган.
[274] Башы дүртенче, дәвамы алтынчы һәм җиденче якларында.
[275] Вертикаль рәвештә язылган.
[276] Башы дүртенче һәм бишенче, дәвамы җиденче якларында.
[277] Вертикаль рәвештә язылган.
[278] Башы дүртенче, бишенче һәм алтынчы якларында.
[279] Вертикаль рәвештә язылган.

Сигезенче ягы: «Рухына «Фатиха» [сүрәсе укы], амин»

Таш үлчәмнәре: 93х26/27.

44. Бибимәгърифә Бикмөхәммәд кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) Күңәр Заһидулла җәмәгате
4) Бибимәгърифә Бикмөхәммәд кызы вафат
5) һиҗрииййә илән 1328 нче
6) йылда рәҗәб 4 ндә румииййә илән
7) 1910 нчы йылда ийүн 28 ндә
8) 72 йәшендә мәдфүн
9) гаффәә ганһүмәәл-мәликүл-мәннәән
10) әл-мәүтү кәффәәратүн [ли-]күлли мүслим».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләрасүүлүллаahи
2) салләәллаahү галәйһи вә сәлләм
3) әл-мәүтү йәәътии ләә бүддә мин нүзүүл
4) фә-күүнүү мин әбнәәъил-әәхыйрати
5) вә ләә тәкүүнүү мин әбнәәъид-дүнйәә
6) фә-иннәл-йәүмә гамәлүн ләә хисәәбүн
7) вә иннә гадән хисәәбүн вә ләә гамәл
8) әксируу минәл-гамәли фии һәзәә-
9) -л-йәүми фә-иннәкүм ләә тәкъдируунә
10) гадән галәәл-гамәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Күңгәр Заһидулла җәмәгате –
4) Бибимәгърифә Бикмөхәммәд кызы –
5) һиҗри белән 1328
6) елның 4 рәҗәбендә, милади белән
7) 1910 елның 28 июнендә вафат,
8) 72 яшендә җирләнде.
9) Рәхимле Патша [Аллаһ] аларның икесен дә кичерсен
10) Үлем – һәр мөселман өчен гөнаһлардан арыну».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ илчесе, аны
2) Аллаһ олыласын һәм сәламләсен, әйтте:
3) «Үлем һичшиксез киләчәк, кабергә төшү булачак.
4) Ахирәт балалары булыгыз,
5) дөнья балалары булмагыз,
6) чынлыкта, бүген гамәл бар, хисап кылу юк,
7) ә иртәгә хисап кылу булачак, гамәл булмаячак.
8) [Изге] гамәлләрегезне бүген
9) күбәйтегез, чынлыкта, сез иртәгә гамәл
10) кыла алмаячаксыз».

Таш үлчәмнәре: 99х31х11.

45. Мәрьям Мөгаллим кызына куелган кабер ташы фрагменты, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) 1915 нче
...»[280].

Уң ягы (уеп язылган): «... амин».

Сул ягы (уеп язылган): «... безләрә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Тәгааләә
2) Мәрйәм бинте Мөгаллим
...»[281].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) 1915
...».

Уң ягы: «... амин».

Сул ягы: «... безгә».

Арткы ягы:
1) «Тәгалә.
2) Мәрьям бинте Мөгаллим
...».

Таш үлчәмнәре: 26х27х6.

46. Мулла Мөхәммәдшәриф мулла Мөхәммәдкәрим улына куелган кабер ташы, 1870 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаahү ли-мән зәәрании
2) бу кабергә дахил мулла Мөхәммәд-
3) -шәриф мулла Мөхәммәд-
4) -кәрим углы румииййә илән
5) 1870 нче сәнә 63 йәшендә

[280] Беренче юлның дәвамы арткы ягындагы беренче юлында.
[281] Беренче юлның башы алгы ягындагы беренче юлында.

6) 22 нче априлдә мәдфүн
7) рахимәллаһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәңа икән йарин сәңадур».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә керүче мулла Мөхәммәд-
3) -шәриф мулла Мөхәммәд-
4) -кәрим улы милади белән
5) 1870 елның 22 апрелендә
6) 63 яшендә җирләнде.
7) Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 84х37х24.

Әлеге кабер иясе 1835 елның 15 октябреннән вафатына хәтле авылда озак еллар имам-хатыйб вазыйфасын башкарган[282].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №49.

47. Мулла Мөхәммәдгариф дамелла Мөхәммәдшәриф улына куелган кабер ташы, 1929 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[283]:
1) «Аллааһ ләә иләәһә илләәллааһ кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) каалә расүүлүллааһи салләә-
3) -ллааһү галәйһи вә сәлләм әл-кабру
4) раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ
5) Аллааһүммәжгаль кабра
6) һәзәәл-мәййити мин рийәәдыйль-җәннәһ
7) мулла Мөхәммәдгариф бине
8) дамелла Мөхәммәдшәриф».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1929 нчы сәнә
2) 1348 нҗе һиҗри
3) 9 нҗы априлдә
4) шәүвәл 8 ндә
5) 73 йәшендә мәдфүн
6) шулук карйәдә 3 нҗе
7) имам булыб 50 йыл
8) тәгълим кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ. Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк. Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Аллаһ илчесе (аны Аллаһ
3) олыласын һәм сәламләсен) әйтте: «Кабер -
4) җәннәт бакчаларыннан бер бакча.
5) Аллаһым, бу мәет каберен
6) җәннәт бакчаларыннан ит.
7) Мулла Мөхәммәдгариф бине
8) дамелла Мөхәммәдшәриф».

Арткы ягы:
1) «1929 елның
2) 9 апрелендә,
3) һиҗри 1348 [елның]
4) 8 шәүвәлендә
5) 73 яшендә җирләнде.
6) Шул ук авылда 3 нче
7) имам булып, 50 ел
8) укытты».

Таш үлчәмнәре: 97х36х9.

Әлеге кабер иясе, 1886 елның 11 сентябрендә указ алып, авылда имам-хатыйб һәм мөгаллим вазыйфаларын башкарган[284].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №50.

48. Мөхәммәдгалим Әсфәндияр улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1910 нчы йылда
2) 11 нче априлдә Мөхәммәд-
3) -галим Әсфәндийар
4) углы вафат улуб
5) ошбу каберстанда
6) дәфен кылынды 72

[282] Татарстан Республикасының Милли архивы: 2 ф., 2 тасвир., 8 сак. берәм. – Б. 3 арты.
[283] Беренче юлы түгәрәк формасында язылган.
[284] Башкортстан Республикасы Милли архивы: И–295 ф., 2 тасвир., 2 сак. берәм.

7) йәшендә рахимәһүллаһү
8) рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Әү хүфратүн мин хүфратин-нәйраан»[285].

Сул ягы (уеп язылган): «Әл-кабру раудатүн мин рийәәдыйль-җәннәһ»[286].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Аһ дәрига ничә гүзәл-
2) -ләре дәр гүр әйләде бу
3) әҗәл ширбәте илә Газраил-
4) -нең хәмләсе хөкем шәр-
5) -гый дотмыш ирде гайрәт
6) илә ул һәммам хәвеф
7) Хаклә дәмгы гайне ирад
8) ирде инфиҗар».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1910 елның
2) 11 апрелендә Мөхәммәд-
3) -галим Әсфәндияр
4) улы, вафат булып,
5) бу каберстанда
6) 72 йәшендә
7) җирләнде. Аллаһ аны киң рәхмәте
8) белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Яки утлар чокырыннан бер чокыр».

Сул ягы: «Кабер – җәннәт бакчаларыннан бер бакча».

Арткы ягы:
1) «Аһ, ни аяныч, ничә гүзәл-
2) -ләрне гүр иясе итте бу
3) әҗәл ширбәте белән Газраил-
4) -нең һөҗүме, шәригать
5) хөкеме тоткан иде. Гайрәт
6) белән ул дәртле хәвеф
7) хаклык белән күз яше, дәлил китерү,
8) чыгу иде».

Таш үлчәмнәре: 82(101)х35х12.

49. Мулла Зариф мулла Габделгафур улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Икенче
2) мәсҗеднең
3) беренче имам
4) мулла Зариф
5) мулла Габделгафур
6) углы».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1340 нчы йыл
2) 17 нче шәгъбан
3) 1922 нче йыл
4) 1 нче април
5) 40 йәшендә
6) җомга көн
7) мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Икенче
2) мәчетнең
3) беренче имамы
4) мулла Зариф
5) мулла Габделгафур
6) улы».

Арткы ягы:
1) «[Һиҗри] 1340 елның
2) 17 шәгъбанында,
3) 1922 елның
4) 1 апрелендә
5) 40 яшендә
6) җомга көн
7) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 66(80)х29х7.

Әлеге кабер иясе, 1908 елның 6 октябрендә указ алып, авылга мулла итеп билгеләнгән[287].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №51.

50. Бибиməхүбә Халид кызына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаалəə күллү
2) зəəъикатүл-мəүүт[288] румиййə илə 1889
3) сəнə 22 нче дикəбрдə һиҗриййə илə
4) 1307 нче сəнə җөмадиəл-əүвəл-
5) -нең 11 ндə Күнңəрнең Бибиməхүбə
6) Халид кызы Əсфəндийар мулла Фəтхулла
7) углының зəүҗəсе 67
8) йəшдə даре бəкайə рихлəт идүб

[285] Башы сул ягында.
[286] Дәвамы уң ягында.
[287] Башкортстан Республикасы Милли архивы: И–295 ф., 2 тасвир., 2 сак. берәм.
[288] Бу аяттә «нәфсиң» сүзе ялгыш төшеп калган.

9) җомга көн мәдфүн улды Аллаһ
10) Тәгалә мәркаден пөр нур әйләсүн».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Бу кабер Күнҗәрнең Бибиməхүбə
2) Халид кызы Әсфәндийар мулла Фәтхулла
3) углының зәүҗәсенең мәркаде-
4) -дүр таййибәллаһү сəраһү вə җəгалəл-җəннəтə
5) мəсвəəһ[289] əəмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр
2) [җан иясе] үлемне татыячак. Милади белән 1889
3) елның 22 декабрендә, һиҗри белән
4) 1307 елның 11
5) җөмадиәл-әүвәлендә Күңгәрдән Бибиməхүбə
6) Халид кызы – Әсфәндияр мулла Фәтхулла
7) улының хатыны – 67
8) яшьтә, мәңгелек дөньяга күчеп,
9) җомга көн җирләнде. Аллаһ
10) Тәгалә каберен нурга күмсен».

Арткы ягы:
1) «Бу кабер Күңгәрдән Бибиməхүбə
2) Халид кызы – Әсфәндияр мулла Фәтхулла
3) улы хатынының кабере-
4) -дер. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һəм урынын
5) җәннәт итсен, амин».

Таш үлчəмнəре: 116x35x23.

Билгесез вандаллар XX гасыр урталарында бу ташбилгенең арткы һəм уң якларына төрле сүзләр уеп язып куйганнар.

51. Маһиҗамал Сәгыйдь кызына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һəзиһи мəкъбəратү Маһиҗамал бинте Сəгыйдь
2) əл-Путчарави зəүҗəти мүъəззини һəзиһил-карйəти
3) Йушаг бине дамелла Хафизеддин əл-Бəрəнгəви
4) түвүффийəт фиил-йəүмис-сəəнии минəл-гашəрас-сəəнии
5) минəш-шəһрис-сəəлиси мин сəнəти 1318 бил-һиҗрийəһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Румиййə илə 1900 нче йылда
2) ийүл 26 нда Йушаг мөəзин
3) хатуны Маһиҗамал Сəгыйдь
4) кызы вафат улды
5) кəтəбə 1901 сəнə би-йəди Əхмəд
6) əл-Бəрəнгəви».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу Маһиҗамал бинте Сәгыйдь
2) Путчарави, бу авыл мөəзине
3) Юшаг бине дамелла Хафизеддин Бəрəңгəви хатынының кабере,
4) дүшəмбе көн һиҗри 1318 елның 20
5) рабигыль-əүвəлендə вафат булды».

Арткы ягы:
1) «Милади белән 1900 елның
2) 26 июлендə Юшаг мөəзин
3) хатыны Маһиҗамал Сəгыйдь
4) кызы вафат булды.
5) 1901 елда Əхмəд Бəрəңгəви
6) кулы белəн язылды».

Таш үлчəмнəре: 81(103)x36x11.

52. Төхфәтулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилləəһи Тəгаалəə
2) руми 1891 сəнə април
3) 7 ндə Күңəрнең Төхфəтулла
4) Һибатулла углы 71 йəшендə
5) дарe бəкайə рихлəт
6) кыйлды рахимəһүллааһү»[290].

Сул ягы (уеп язылган): «Тəгаалəə рахмəтəн вəəсигаһ əəмиин»[291].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1891 елның 7
3) апрелендә Күңгәрдән Төхфәтулла
4) Һибатулла улы 71 яшендә
5) мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһ аны рәхим кылсын».

[289] Бу җөмлə ир-атка карата кулланыла торган кушымчалар белəн язылган.

[290] Дəвамы сул ягында.

[291] Башы алгы ягында.

Сул ягы: «[Аллаһ] Тәгалә киң рәхмәте белән [рәхим кылсын]».

Таш үлчәмнәре: 105(133)х37х13.

53. Хәбибулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1893
3) сәнә гыйнвар 24 ндә Күңәр
4) авылының Хәбибулла Һибатулла
5) углы 70 йәшендә җомга
6) көн даре бәкайә рихләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәндә икән йарин сәңадур».

Сул ягы (уеп язылган): «Рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак». Милади 1893
3) елның 24 гыйнварында Күңәр
4) авылыннан Хәбибулла Һибатулла
5) улы 70 яшендә җомга
6) көн мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 111(119)х35х15.

54. Хәсән Гомәр улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләһүл-хүкмү
2) вә иләйһи түрҗәгуун
3) Хәсән
4) Гомәр углы
5) вафат
6) 77 йәшендә
7) вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1926 нче
2) сәнәдә
3) 22 фибралда
4) дәфен
5) кылынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда (Аллаһта) хөкем
2) һәм Аңа кайтачаксыз.
3) Хәсән
4) Гомәр улы
5) вафат,
6) 77 яшендә
7) вафат».

Арткы ягы:
1) «1926
2) елның
3) 22 февралендә
4) җир-
5) -ләнде».

Таш үлчәмнәре: 71х29х7.

55. Мәйсәрә Сафиулла кызына куелган кабер ташы, 1936 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) 1936
2) йылда вафат
3) Мәйсәрә
4) Сафийулла
5) кызы».

Таш үлчәмнәре: 60х28х12.

56. Бибифатиха Биккенә кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) Күнгәр илендә
3) вафат улды
4) румиййә илә 1905 сәнә
5) 59 йәшендә гыйнвар
6) 1 ндә Бибифатиха бинте Биккенә
7) Фәхреддин бине Габделҗаббар җәмәгате».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Күңгәр илендә
3) милади белән 1905 елның
4) 1 гыйнварында 59

5) яшендә Бибифатиха бинте Биккенә -
6) Фәхреддин бине Габделҗаббар җәмәгате –
7) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 89х29х10.

57. Әхмәдша Мостафа улына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әхмәдшаһ
2) Мостафа углы
3) 1927 нче сәнә нуйәбр
4) 9 нда 73 йәшендә
5) җан тәслим әйләде
6) Аллаһ рәхмәт әйләйә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Күңәр авылы
2) Мәүледеддин Әхмәд-
3) -шаһ углы
4) бина кылдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Әхмәдша
2) Мостафа улы
3) 1927 елның 9
4) ноябрендә 73 яшендә
5) җан тәслим кылды.
6) Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Күңгәр авылыннан
2) Мәүледеддин Әхмәд-
3) -ша улы
4) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 63х29х8.

58. Мөхәммәдҗан Гали улына куелган кабер ташы, 1879 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1879 нч
2) нуйәбр 29 нч
3) Мөхәммәдҗан
4) Гали углы
5) вафат
6) 68 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү
2) нәфсиң
3) зәәъикат-
4) -үл-мәүүт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1879 [елның]
2) 29 ноябрендә
3) Мөхәммәдҗан
4) Гали улы
5) 68 йәшендә
6) вафат».

Арткы ягы:
1) «һәр
2) җан иясе
3) үлемне
4) татыячак».

Таш үлчәмнәре: 91х30х10.

59. Әхмәдҗан Галиәкбәр улына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Әхмәдҗан Гали-
3) -әкбәр углы 72
4) йәшендә 10
5) нчы фибралда
6) 1343 сәнәи һиҗриййә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1925 сәнәи миладиййә
2) кәрәм әйләб
3) догада идеңез
4) йад тәсаддыклә кыйлу-
5) -ңыз рухымы
6) шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Әхмәдҗан Гали-
3) -әкбәр улы 72
4) яшендә 10
5) февральдә,
6) һиҗри 1343 елда [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Милади 1925 елда [вафат яки җирләнде]».
2) Юмартлык кылып,
3) догада искә
4) алыгыз, сәдака бирү белән
5) рухымны
6) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 83х30х8.

60. Хөснеддин Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу
2) кабер ийәсе
3) Хөснеддин
4) Хәбибулла
5) углы
6) мәдфүн
7) кырык йәшдә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Румиййә
2) 1922
3) 28 нче
4) априлдә
5) рәхмәтән
6) вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу
2) кабер иясе
3) Хөснеддин
4) Хәбибулла
5) улы
6) кырык яшьтә
7) җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) 1922 [елның]
3) 28
4) апрелендә [вафат яки җирләнде].
5) Киң
6) рәхмәт».

Таш үлчәмнәре: 70x28x8.

Күшәр авылы зираты

1. Бибифатыйма Һибатулла кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) бу каберә назилә Бибифатыйма
3) Һибатулла кызы сәнәи
4) миладиййә илә 1905 нче
5) йылда 10 нчы гыйнварда Олу-
6) -г Мәнгәрнең Муса
7) мөәзин әһлийәсе
8) 85 йәшендә»[292].

Уң ягы (уеп язылган)[293]: «Мәтүү интәбәһүү»[294].

Сул ягы (уеп язылган)[295]: «Ән-нәәсү нийәәмүн изәә»[296].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Дарел-фәнадан
2) дарел-бәкайә рихләт
3) әйләде Аллаһ Тәгалә
4) гарикы рәхмәт
5) кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче Бибифатыйма
3) Һибатулла кызы –
4) Олы Мәнгәрдән Муса
5) мөәзин хатыны –
6) милади белән 1905
7) елның 10 гыйнварында
8) 85 яшендә».

Уң ягы: «Үлгәч уяналар».

Сул ягы: «Кешеләр йоклыйлар».

Арткы ягы:
1) «Фани дөньядан
2) мәңгелек дөньяга
3) күчте. Аллаһ Тәгалә
4) рәхмәткә
5) күмсен».

Таш үлчәмнәре: 111(123)x35x14.

2.Мулла Галибша мулла Гатаулла улына куелган кабер ташы, 1879 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) ошбу кабер сахибе
3) мәрхүм кирам мулла Галиб-
4) -шаһ бине мулла Гатаулла Күшәрдә
5) 25 сәнә имам улыб миладиййә
6) илә 1879 нчы йылда 4 нче
7) фибралда 48 йәшендә да-
8) -рел-фәнадан дарел-бәкайә рихләт
9) әйләде».

[292] Дәвамы арткы ягында.
[293] Диагональ рәвештә язылган.
[294] Башы сул ягында.
[295] Диагональ рәвештә язылган.
[296] Дәвамы уң ягында.

Уң ягы (уеп язылган): «Әл-мәүтү бәхру мәүжүһү таафихү йәгъраку фиихир-ражүлүс-сәәбих».

Сул ягы (уеп язылган): «Мәә йәнфәгуль-инсәәнү фии кабриһи [и]ллээт-түкаа вәл-гамәлүс-саалих».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Бу кабер иясе
3) хөрмәтле мәрхүм мулла Галиб-
4) -ша бине мулла Гатаулла, Күшәрдә
5) 25 ел имам булып, милади
6) белән 1879 елның 4
7) февралендә 48 яшендә фа-
8) -ни дөньядан мәңгелек дөньяга
9) күчте».

Уң ягы: «Үлем – дулкынланган, ташыган диңгез; анда йөзүче кеше бата».

Сул ягы: «Тәкъвалык һәм изге гамәл генә кешегә каберендә файда китерә ала».

Таш үлчәмнәре: 106х33х13.

Әлеге кабер иясенең фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Галибша бине Гатаулла бине Габбас бине Габдерәшид бине Әхмәд бине Шөкер бине Хәсән бине Хөсәен бине Котлыгмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Дусмөхәммәд бине Багыш бине Яуш[297]. Димәк, ул Күшәрдәге атаклы Яушев морзалары нәселеннән чыккан. Галибша 1856 елның 5 июлендә (указ номеры – 5803) имам-хатыйб итеп билгеләнгән.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №52.

3. Мөхибҗамал Сәйфулла кызына, мулла Габбас мулла Габдерәшид улына һәм Хәмидә Баязид кызына куелган кабер ташы, 1849 һәм 1854 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып һәм уеп язылган[298]):
1) «Әл-мәрхүүмүл-мүкәррамү
2) мулла Габбас Габд-
3) -еррәшид мулла у-
4) -глы 91 нче йәшдә
5) дарел-фәнадан дар-
6) -ел-бәкайә рихләт
7) әйләдe 1854
8) лилләәһил-фәәтихәтү йылда иләә руух
9) бу җиһан ханәсе кәрван сарай
10) көн бикөн күчәр китәр шаһ гидай
11) каф бер каф хөкем идүрсәң чара нә
12) гакыйбәт зире зәминдә ула җай».

Уң ягы (калкытып язылган): «Икенче хәләле Хәмидә Байазид кызы вафат 60 йәшдә 1854 нче йылда кятиб Габделҗаббар».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-мәрхүүмәтүл-мүкәррамәтү
2) мулла Габбас хәләле
3) Мөхибҗамал Сәйфулла
4) кызы вафат 58 нче
5) йәшдә 1849 йылда
6) әл-мәүтү кәфәә вәәгыйзаа».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөрмәтле мәрхүм
2) мулла Габбас Габд-
3) -ерәшид мулла у-
4) -лы 91 нче яшьтә
5) 1854 елда
6) фани дөньядан
7) мәңгелек дөньяга
8) күчте. Рухына «Фатиха» [сүрәсе укы].
9) Бу җиһан – кәрван сарай,
10) көн саен күчәр, китәр шаһ та, ярлы кеше дә,
11) күп кешеләрне хөкем итсәң дә – чара юк,
12) ахырдан туфракта булыр урының».

Уң ягы: «Икенче хәләле Хәмидә Баязид кызы 60 яшьтә 1854 елда вафат. Язучы: Габделҗаббар».

Арткы ягы:
1) «Хөрмәтле мәрхүмә
2) мулла Габбас хәләле –
3) Мөхибҗамал Сәйфулла
4) кызы – 58 нче
5) яшьтә 1849 елда вафат.
6) Үлем вәгазьче буларак җиткән».

Таш үлчәмнәре: 150х26х14.

Мулла Габбасның фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габбас бине Габдерәшид бине Әхмәд бине Шөкер бине Хәсән бине Хөсәен бине Котлыгмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Дусмөхәммәд бине Багыш бине

[297] Мәржани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 308–310.

[298] Беренче җиде юлы тулысынча һәм сигезенче юлы өлешчә («әйләдe» сүзе) калкытып, калган урыннары уеп язылган. Сигезенче юлдагы дүрт сүз вертикаль рәвештә язылган.

Яуш[299]. Димәк, ул Күшәрдәге атаклы Яушев морзалары нәселеннән чыккан. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабын хәзерге татар теленә күчерүче Габбас хәзрәтнең үлгән елы, ягъни һиҗри 1270 ел милади 1853 елга туры килә, дип ялгыш күрсәткән[300], чынлыкта исә, әлеге дата 1854 елга карый булып чыга, чөнки ташта шулай язылган. Ш. Мәржани, Габбас хәзрәт хакында төрле кызык хәлләр сөйләгәндә, аны бик үк яхшы яктан искә алмаган[301].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №53.

4. Хәдичә Муса кызына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) мәрхүмә Хәдиҗә
3) Муса кызы
4) мулла Габдеррахман
5) әһлиййәсе миладиййә илә
6) 1911 нче йылда 21 нче
7) үктәбрдә 52 йә-
8) -шендә Аллаһ Тәгалә
9) гарикы рәхмәт
10) кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәзүүдү минәддүнйәә фә-иннәкә раахилүн вә кум лилләәһи вәгъмәл хайра зәәд».

Сул ягы (уеп язылган): «Фә-мәәл-мәәлү вәл-әһлүүнә илләә вәәдигатүн вә ләә бүддә йәүмән ән түраддәл-вәдәәигъ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Мәрхүмә Хәдичә
3) Муса кызы –
4) мулла Габдрахман
5) хатыны – милади белән
6) 1911 елның 21
7) октябрендә 52 я-
8) -шендә [вафат яки җирләнде]. Аллаһ Тәгалә
9) рәхмәткә
10) күмсен».

Уң ягы: «Дөньяда [изге гамәлләреңне] арттыр, чынлыкта, син аннан китәчәксең, һәм хәерле гамәлләр кыл».

Сул ягы: «Мал һәм гаилә фәкать амәнәт итеп бирелгән нәрсә генә һәм син һичшиксез бүген аны кире кайтарачаксың».

Таш үлчәмнәре: 100х30х14.

5. Бибигайшә Тимергали кызына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) ошбу кабер сахибәсе
3) Бибигайшә бинте
4) Тимергали Күшәр има-
5) -мы Галибшаһ әһлийә-
6) -се миладиййә илә 1901
7) нче йылда 10 нчы фибралда
8) 65 йәшендә дарел-фәна-
9) -дан рихләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «Рөштәи гомери кисәр әлбәттә микъразы әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Каберемең ташын күрән вакыйф улыб кыйл игътибар».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе
3) Бибигайшә бинте
4) Тимергали – Күшәр има-
5) -мы Галибша хаты-
6) -ны милади белән 1901
7) елның 10 февралендә
8) 65 яшендә фани дөнья-
9) -дан күчте».

Уң ягы: «Гомер җебен кисәр, әлбәттә, әҗәл кайчысы».

Сул ягы: «Каберемнең ташын күргән кеше, басып торып, игътибар ит».

Таш үлчәмнәре: 112х32х10.

6. Бибифатыйма Габделвәһһаб кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә

[299] Мәржани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 308.
[300] Шунда ук. – Б. 310.
[301] Шунда ук. – Б. 308–310.

2) саахибәтү һәзиһи-
3) -л-кабри мәрхүмә
4) Бибифатыйма Габд-
5) -елваһһаб кызы
6) 1910 нчы йыл
7) 1 нче март
8) 79 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Күрүб каберүм әҗәлне әйләгел йад
2) тәсаддыклә кылыңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер
3) иясе мәрхүмә
4) Бибифатыйма Габд-
5) -елваһһаб кызы
6) 1910 елның
7) 1 мартында
8) 79 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы:
1) «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал,
2) сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 69x26x11.

7. Галимҗан Габид улына куелган кабер ташы, 1885 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) саахиб-
3) -үл-кабри Галимҗан
4) Габид мәрхүм
5) углы 1885 нч
6) йылда 8 нче
7) мартда вафат
8) 47 йәшендә
9) Аллаһ рәхмәт итсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Кабер
3) иясе Галимҗан
4) Габид мәрхүм
5) улы 1885
6) елның 8
7) мартында
8) 47 яшендә вафат.
9) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 85(93)x27x12.

8. Мөхәммәдзакир Мортаза улы Яушевка куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаалә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1892 сәнә
3) април 4 ндә һиҗри
4) 1309 сәнә рамазан 19 нда
5) Күшәрнең Мөхәммәдзакир ибне
6) әл-хаҗҗе Мортаза Йәвушыф
7) 42 йәшдә шинбә көн»[302].

Сул ягы (калкытып язылган): «Даре бәкайә рихләт кылды таййибәллаһү сәраһ әәмиин»[303].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1892 елның
3) 4 апрелендә, һиҗри
4) 1309 елның 19 рамазанында
5) Күшәрдән Мөхәммәдзакир ибне
6) хаҗи Мортаза Яушев
7) 42 яшьтә шимбә көн».

Сул ягы: «Мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 140x36x18.

Әлеге кабер иясе атаклы Яушев морзалары нәселеннән.

9. Гөлсем Мөхәммәдзакир кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) руми 1899 сәнә гыйнвар
3) 6 нда һиҗри 1316 сәнә рамазан
4) 17 ндә Гөлсем Мөхәммәдзакир
5) кызы Мостафа Гайнулла
6) углының зәүҗәсе 25»[304].

Уң ягы (уеп язылган): «Баладан вафат улды шәһидләр илә кубарылсун».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәшдә чәһаршәнбә көн даре бәкайә рихләт кылды»[305].

---

[302] Дәвамы сул ягында.
[303] Башы алгы ягында.
[304] Дәвамы сул ягында.
[305] Башы алгы ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади 1899 елның 6
3) гыйнварында, һиҗри 1316 елның 17
4) рамазанында Гөлсем Мөхәммәдзакир
5) кызы – Мостафа Гайнулла
6) улының хатыны 25».

Уң ягы: «Баладан вафат булды. Шәһидләр белән кубарылсын».

Сул ягы: «[25] яшьтә чәршәмбе көн мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 92х34х17.

10. Мортаза Мостафа улына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән руми 1895
3) сәнә май 9 нда һиҗри
4) 1312 сәнә зөлкагдә 27 ндә
5) Күшәрнең хаҗҗел-хәрәмәйен
6) Мортаза Мостафа углы
7) 82 йәшдә сиһшәнбә көн»[306].

Сул ягы (калкытып язылган): «Даре фәнадин даре бәкайә рихләт кылды тааййибәллаһү сәраһ»[307].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы
2) һәркем, һәрнәрсә фани. Милади 1895
3) елның 9 маенда, һиҗри
4) 1312 елның 27 зөлкагдәсендә
5) Күшәрдән хаҗи
6) Мортаза Мостафа улы
7) 82 яшьтә сишәмбе көн».

Сул ягы: «Фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Таш үлчәмнәре: 122х36х18.

11. Бибихәбибҗамал Халид кызына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1892 сәнә
3) март 16 нда һиҗри 1315 сәнә
4) зөлкагдә 5 ндә Күшәрнең
5) Бибихәбибелҗамал Халид кызы
6) хаҗҗел-хәрәмәйен Мортаза Мостафа
7) углының зәүҗәсе 80 йәшдә»[308].

Уң ягы (уеп язылган): «Тааййибәллаһү сәраһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә әәмиин».

Сул ягы (уеп язылган): «Даре бәкайә рихләт кылды дүшәнбә көн мәдфүн»[309].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабруль-мәрхүүмәти Бибихәбиб-
2) -елҗамал бинте Халид зәүҗәтүл-хәәҗҗи
3) Мортаза бине Мостафа әл-Күшәри».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1892 елның
3) 16 мартында, һиҗри 1315 елның
4) 5 зөлкагдәсендә Күшәрдән
5) Бибихәбибҗамал Халид кызы –
6) хаҗи Мортаза Мостафа
7) улының хатыны 80 яшьтә».

Уң ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Сул ягы: «Мәңгелек дөньяга күчте, дүшәмбе көн җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Бу Бибихәбиб-
2) -җамал бинте Халид – хаҗи
3) Мортаза бине Мостафа Күшәри – кабере».

Таш үлчәмнәре: 122х36х18.

[306] Дәвамы сул ягында.
[307] Башы алгы ягында.
[308] Дәвамы сул ягында.
[309] Башы алгы ягында.

12. Бибизөһрә Фәхреддин кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) мәрхүмә Бибизөһрә
3) Фәхреддин кызы
4) Мөхәммәдсиддыйк зәүҗә-
5) -се вафат һиҗриййә илә 18
6) 13[310] нче йылда 1899
7) нчы йылда 5 нче мартда
8) 80 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Мәрхүмә Бибизөһрә
3) Фәхреддин кызы –
4) Мөхәммәдсиддыйк хаты-
5) -ны һиҗри белән 1318
6) елда, 1899
7) елның 5 мартында
8) 80 яшендә вафат».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 95x31x12.

13. Зөләйха Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәһ
2) мәрхүмә Зөләйха Хәбиб-
3) -улла кызы 83 йәшендә
4) 1325 сәнәи һиҗриййә 9 нда
5) җөмадиәл-әүвәл
6) 1907 сәнәи миладиййә
7) Мөхәммәдгалим зәүҗә-
8) -се 7 нче ийүлдә
9) мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта гына.
2) Мәрхүмә Зөләйха Хәбиб-
3) -улла кызы – Мөхәммәдгалим
4) хатыны – 83 яшендә
5) һиҗри 1325 елның 9
6) җөмадиәл-әүвәлендә,
7) милади 1907 елның
8) 7 июлендә
9) җирләнде».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 110x36x14.

14. Мөхәммәдгалим Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәһ
2) мәрхүм Мөхәммәдгалим Ибра-
3) -һим углы 94
4) йәшендә 1328 сәнәи
5) һиҗриййә 2 ндә шәүвәл
6) 1910 сәнәи миладиййә
7) синтәбр 25 ндә
8) пәнҗешәнбә көн дәфен кылынды».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта гына.
2) Мәрхүм Мөхәммәдгалим Ибра-
3) -һим улы 94
4) яшендә һиҗри 1328
5) елның 2 шәүвәлендә,
6) милади 1910 елның
7) 25 сентябрендә
8) пәнҗешәмбе көн җирләнде».

[310] «1318» саны шул рәвешле бүленеп язылган

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 108x33x13.

15. Фаизә Фәхреддин кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) 1898 сәнә синтәбр 2 дә
3) һиҗри 1316 сәнә Фаизә
4) Фәхреддин кызы Ногман
5) Сөләйман углы зәүҗәсе
6) 60 йәшдә даре бәкайә
7) рихләт кылды таййибәллааһү сәрааһәә»[311].

Сул ягы (уеп язылган): «Вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә әәмиин»[312].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) 1898 елның 2 сентябрендә,
3) һиҗри 1316 елда Фаизә
4) Фәхреддин кызы – Ногман
5) Сөләйман улының хатыны –
6) 60 яшьтә мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Сул ягы (уеп язылган): «Һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 107x36x17.

16. Ногман Сөләйман улына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) 1889 сәнә фибрал 4 дә
3) һиҗри 1306 сәнә Күшә-
4) -рнең Ногман Сөләйман
5) углы 59 йәшдә даре
6) бәкайә рихләт кылды».

Сул ягы (уеп язылган): «Таййибәллааһү сәрааһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) 1889 елның 4 февралендә,
3) һиҗри 1306 елда Күшә-
4) -рдән Ногман Сөләйман
5) улы 59 яшьтә мәңгелек
6) дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 95(106)x36x17.

17. Бибихәдичә Габдессаттар кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) мәрхүмә Бибихәдичә
3) Габдессаттар кызы
4) Мөхәммәдйосыф зәүҗәсе
5) һиҗриййә илә 1315 нче йылда
6) румиййә илә 1897 нче йылда
7) 29 нчы агуст
8) 42 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Йә әхый гафил улма сакыйн».

Сул ягы (уеп язылган): «Беләсез бу кабер киләчәк вакытыңыз йакыйн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Мәрхүмә Бибихәдичә
3) Габдессаттар кызы –
4) Мөхәммәдйосыф хатыны –
5) һиҗри белән 1315 елда,
6) милади белән 1897 елның
7) 29 августында
8) 42 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Әй, кардәшем, гафил булма, сак бул».

Сул ягы: «Беләсез: бу кабергә киләчәк вакытыгыз якын».

Таш үлчәмнәре: 96x31x11.

[311] Дәвамы сул ягында.
[312] Башы алгы ягында.

18. Мөхәммәдсиддыйкка яки аның баласына куелган кабер ташы, XIX гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллаah Мүхәммәдүр-
расүүлүллаah салләәллаahү галәйhи вә сәлләм
2) hижриййә...
3) 29 нда... Мөхәммәдсиддыйк...
4) 63 йәшендә дарел-фәнадан дарел-
бәкайә
5) рихләт кыйлды Аллаh Тәгалә
6) ...».

Уң ягы (уеп язылган[313]):
1) «Йәә вәәкыйфән фии кабрии
2) мүтәфәккиран фии-әмрии
3) бил-әмси күнтү мислүкә
4) гадән тәсыыйру мислии».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Калиилү гумринәә фии дәәри дүнйәә
2) вә мәрҗигунәә иләә бәйтит-түрааби
3) ләhү мәләкүн йәнәәдии күллә йәүмин
4) лидүү лил-мәүти вәбнүү лил-хараааб».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе, Аллаh аны олыласын һәм сәламләсен.
2) hижри...
3) 29 нда... Мөхәммәдсиддыйк...
4) 63 яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга
5) күчте. Аллаh Тәгалә
6) ...».

Уң ягы:
1) «Әй, каберем янында басып торучы,
2) минем эшем хакында фикерләүче,
3) кичә мин синең кебек идем,
4) иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы:
1) «Безнең гомеребезнең аз өлеше генә дөньяда
2) һәм кайтачак җиребез туфрак йорты».
3) Көн саен фәрештә аңа [кешегә] әйтә:
4) «Туыгыз – барыбер үләчәксез, биналар төзегез – барыбер җимереләчәк».

Таш үлчәмнәре: 87x36x18.

[313] Диагональ буенча язылган.

19. Мөхәммәднәби Габделлатыйф улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) тарих 1911 нче сәнә
3) синтәбр 20 ндә шәүвәл
4) 11 мәрхүм Мөхәммәднәби
5) Габделлатыйф
6) углы 46 йәшдә
7) вафат Аллаh рәхмәт әйлә-»[314].

Сул ягы (уеп язылган): «-сүн амин»[315].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта.
2) 1911 елның
3) 20 сентябрендә, 11
4) шәүвәлендә мәрхүм Мөхәммәднәби
5) Габделлатыйф
6) улы 46 яшьтә
7) вафат. Аллаh рәхим кыл-»[316].

Сул ягы: «-сын, амин».

Таш үлчәмнәре: 92(102)x27x11.

20. Бибигайшә Әбелхәер кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәh
2) бу каберә назилә Бибигайшә
3) Әбелхәйер кызы
4) hижриййә 1320 нче йылда
5) румиййә 1902 нче йылда
6) 2 нче мартда вафат
7) 70 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Би-хүкмилләәh
2) Бу кабергә иңүче Бибигайшә
3) Әбелхәер кызы
4) hижри 1320 елда,

[314] Дәвамы сул ягында.
[315] Башы алгы ягында.
[316] Дәвамы сул ягында.

5) милади 1902 елның
6) 2 мартында
7) 70 яшендә вафат».

Уң ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 95(109)x31x15.

21. Габделлатыйф Халид улына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) Габделлатыйф Халид
3) углы тарих
4) 1891 нче сәнә
5) април 25 ндә
6) 63 йәшдә вафат
7) Аллаһ рәхмәт кыйлгай»[317].

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблəл-әҗəл ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдəл-әҗəл».

Сул ягы (уеп язылган): «Иде амин»[318].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Габделлатыйф Халид
3) улы
4) 1891 елның
5) 25 апрелендә
6) 63 яшьтә вафат.
7) Аллаһ рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әй, кардәшем, әҗəл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит. Әҗəл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 101x31x11.

22. Бибимәрхүмә Сәйфулла кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Əл-хүкмү лилләәһдер
2) 1915 нҗе руми 20
3) нҗе дикəбрдə һиҗриййə
4) 1335 нҗе дə рабигыль-əүвəл
5) 8 нҗе көнендə вафат
6) Йаңа Ийə башының Биби-
7) -мәрхүмə Сəйфулла кызы
8) 80 йəшендə бу кабергə
9) дəфен улынды йат йирдə
10) мөсафир хəлдə вафат
11) булган карчыкны
12) дога илə йад итсəгез
13) икəн».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бəңа исə йарин сəңа».

Сул ягы (уеп язылган): «Бер дога кыйл əй кардəшем бəңа».

Текстның хəзерге татар теленə күчермəсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһтадыр.
2) Милади 1915 [елның] 20
3) декабрендə, һиҗри
4) 1335 [ел] рабигыль-əүвəленең
5) 8 нче көнендə
6) Яңа Иябаштан Биби-
7) -мәрхүмə Сəйфулла кызы вафат,
8) 80 яшендə бу кабергə
9) җирлəнде. Ят җирдə
10) мөсафир хəлдə вафат
11) булган карчыкны
12) дога белəн искə алсагыз
13) икəн».

Уң ягы: «Бу көн миңа исə, иртəгə сиңа».

Сул ягы: «Бер дога кыл, əй, кардəшем, миңа».

Таш үлчəмнəре: 83(92)x31x11.

23. Зөһрə Мортаза кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Əл-хүкмү лилләəһ
2) Зөһрə Мортаза
3) кызы Габделгалләм
4) зəүҗəсе 2 нч
5) мартда 48 йəшендə
6) 1334 сəнəи һиҗриййə
7) 1915 сəнəи миладиййə
8) гарикы рəхмəт у-
9) -лсун».

[317] Дəвамы сул ягында.
[318] Башы алгы ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Зөһрә Мортаза
3) кызы – Габделгалләм
4) хатыны – 2
5) мартында 48 яшендә
6) һиҗри 1334 елда,
7) милади 1915 елда [вафат яки җирләнде].
8) Рәхмәткә
9) күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 101(107)x30x12.

24. Маһибәдәр Әхмәдгәрәй кызына куелган кабер ташы, 1930 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Маһибәдәр Әхмәдгәр-
3) -әй кызы Жули
4) кисәдә Зиннәт-
5) -улла зәүҗәсе
6) 63 йәшендә
7) ийүн 25 ндә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1930 сәнәи миладиййә
2) кәрәм әйләб
3) догада идеңез
4) йад тәсаддыклә
5) кыйлуңыз ру-
6) -хымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Маһибәдәр Әхмәдгәр-
3) -әй кызы – Жули-
4) -кисәдә Зиннәт-
5) -улла хатыны –
6) 63 яшендә
7) 25 июньдә [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Милади 1930 елда [вафат яки җирләнде].
2) Юмартлык кылып,
3) догада искә
4) алыгыз. Сәдака бирү белән
5) рухымны
6) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 90x30x9.

25. Гайнежамал Баязид кызына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) мәрхүмә Гайнелҗамал
3) Байазид кызы
4) миладиййә 1891 нче йылда
5) 20 нче синтәбрдә
6) Фазылҗан зәүҗәсе
7) 57 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Мәрхүмә Гайнежамал
3) Баязид кызы –
4) Фазылҗан хатыны –
5) милади 1891 елның
6) 20 сентябрендә
7) 57 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 85x31x15.

26. Фазылҗан Габделхәмид улына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) мәрхүм Фазылҗан
3) Габделхәмид углы
4) миладиййә илә 1889 нчы йылда
5) 21 нче нуйәбрдә
6) 58 йәшендә вафат
7) гарикы рәхмәт улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Мәрхүм Фазылҗан
3) Габделхәмид улы
4) милади белән 1889 елның
5) 21 ноябрендә
6) 58 яшендә вафат.
7) Рәхмәткә күмелсен».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 83x31x11.

27. Исәнәй морза Симәнәй бәк улына куелган кабер ташы, 1693 – 1694 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәл-хәйүл-ләзии ләә йәмүүтү вә күллү хәййин сәйәмүүт каал-
2) -ән-нәбии галәйһис-сәлләәм әд-дүнйәә сәәгатүн фәҗгальһәә таагать садак
3) кааләп-нәбии галәйһис-сәлләәм әд-дүнйәә сиҗҗиинүл-мүъмини
4) вә җәннәәтүл-кәәфир әд-дүнйәә җиифәәтүн вә таалибүһәә киләәб
5) тарих меңдә йүздә бишдә дирләр ирде Исәнәй морза
6) Симәнәй бик углы бу билекен куйд ирәнләрдин дога өмүт
7) өҗүн.

Уң ягы (калкытып язылган): «Кәтәбәһү Килмөхәммәд углы Колмөхәммәд...».

Сул ягы (калкытып язылган): «Дарел-фәнадин дарел-бәкага рихләт кылды Ходай рәхмәт кылсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Тере, Үлмәүче һәм һәр җан иясе үләчәк. Пәйгамбәр, аңа сәлам
2) булсын, әйтте: «Дөнья бер сәгатьлек, аны [Аллаһка] итагать белән үткәр», дөрес әйткән.
3) Пәйгамбәр, аңа сәлам булсын, әйтте: «Бу дөнья иманлы өчен төрмә,
4) имансыз өчен җәннәт». «Дөнья – үләксә, аны этләр генә тели».
5) Мең дә йөз дә бишенче елда Исәнәй морза
6) Симәнәй бәк улы кешеләрдән дога өмет итү өчен бу билгене
7) куйды.

Уң ягы: «Моны Килмөхәммәд улы Колмөхәммәд язды...».

Сул ягы: «Фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Ходай рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 103x46x19.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 6 б. №54.

28. Гыйльмебаян Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назилә Гыйльмебайан
3) Гобәйдулла кызы 24 нч
4) йәшендә 1897 нче сәнә
5) 20 нче априлдә кабере
6) мөнәүвәр улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Зүүрууль-кубүүра фә-иннәһәә түзәккируль-мәүүт».

Сул ягы (уеп язылган): «Мән әксәру зәкәраль-кабра вәҗәдә раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».
Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәтәбәһү Сәлахеддин
2) әл-Казаклари».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә Гыйльмебаян
3) Гобәйдулла кызы 24 нче
4) яшендә 1897 елның
5) 20 апрелендә иңде. Кабере
6) нурлы булсын, амин».

Уң ягы: «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар үлемне искә төшерә».

Сул ягы: «Кем каберне еш искә алса, шул җәннәт бакчаларыннан бер бакчага юлыгыр».

Арткы ягы:
1) «Моны Сәлахеддин
2) Казаклари язды».

Таш үлчәмнәре: 77(83)x34x15.

29. Гарифҗан Мөхәммәҗҗан улына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү зәәрании[319]
2) бу кабер сахибе Гарифҗан
3) Мөхәммәҗҗан углы румиййә илән
4) 1889 нчы сәнә 47 йәшендә
5) фибрал берендә йәүме йәкшәнбә мәдфүн
6) нәүвәраллаһү Тәгаалә кабраһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган [кешене] Аллаһ рәхим кылсын.
2) бу кабер иясе Гарифҗан
3) Мөхәммәҗҗан улы милади белән
4) 1889 елның беренче февралендә
5) 47 яшендә якшәмбе көн җирләнде.
6) Аллаһ Тәгалә каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 87(98)x30x13.

Кызыл Утар авылы зираты

Бу авыл элегрәк Житлар дип йөртелгән, шуңа күрә эпиграфик истәлекләрдә дә шул атама язылган.

1. Мөәзин Хөсәен Хәсән улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) мөәзин Хөсәйен
4) Хәсән углы
5) 1920 нче йылда
6) 20 нче ийүндә
7) 62 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) мөәзин Хөсәен
4) Хәсән улы
5) 1920 елның
6) 20 июнендә
7) 62 яшендә вафат».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаһ рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 77x32x8.

Әлеге кабер иясенең атасы Хәсән Габдельмән улы 1851 елның 31 мартыннан башлап авылда муллалык хезмәтен башкарган[320].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 7 б. №55.

2. Госман Гомәр улына куелган кабер ташы, 1896 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) 1896 сәнәдә 31 нч
3) үктәбрдә Госман Гомәр углы
4) 75 йәшендә мәдфүн
5) рахимәкүмүллаһү
6) Тәгаалә».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәүбәллаһү сәраһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ».

Арткы ягы (уеп язылган)[321]:
1) «Әл-кабру гыйбрат Аллаһ йәә Кәриим
2) кәрәм әйләб догада идеңез йад
3) тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1896 елның 31
3) октябрендә Госман Гомәр улы
4) 75 яшендә җирләнде.
5) Аллаһ Тәгалә сезне
6) рәхим кылсын».

[319] Бу җөмләдә «ли-мән» сүзе төшеп калган.

[320] Татарстан Республикасының Милли архивы: 2 ф., 2 тасвир., 8 сак. берәм. – Б. 2 арты.

[321] Беренче юлы түгәрәк эченә алынган.

Уң ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт. Аллаһ, йә, Юмарт зат.
2) Юмартлык кылып, догада искә алыгыз.
3) Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 110х31х10.

3. Әүхәди Габделвәли улына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) румиййә илә 1893 нче
3) йыл 8 нче гыйнварда
4) Әүхәди Габделвәли
5) углы 60 йәшендә
6) даре фәнадан даре бәкайә
7) рихләт әйләде нәүвәраллааһү кабраһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Ләһү мәләкүн йәнәәдии күллә йәүүм»[322].

Сул ягы (уеп язылган): «Лидүү лил-мәүти вәбнүү лил-харааб»[323].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Милади белән 1893
3) елның 8 гыйнварында
4) Әүхәди Габделвәли
5) улы 60 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Уң ягы: «Көн саен фәрештә аңа [кешегә] әйтә».

Сул ягы: «Туыгыз – барыбер үләчәксез, биналар төзегез – барыбер җимереләчәк».

Таш үлчәмнәре: 83(92)х33х9.

4. Мөхәммәдгариф Мөхәммәдшакир улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[324]:
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) милади 1913 сәнә
3) үктәбр 20 ндә
4) Мөхәммәдгариф Мөхәммәдшакир
5) углы 65 йәшендә
6) мәдфүн».

Арткы ягы (уеп язылган)[325]:
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) саахибүл-мәркади
3) Мөхәммәдгариф Мөхәммәдшакир
4) углы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Милади 1913 елның
3) 20 октябрендә
4) Мөхәммәдгариф Мөхәммәдшакир
5) улы 65 яшендә
6) җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Кабер иясе -
3) Мөхәммәдгариф Мөхәммәдшакир
4) улы».

Таш үлчәмнәре: 81х30х11.

5. Мифтахеддин Хөсәен улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) мөтәвәффа вә мәрхүм Мифтах-
3) -еддин Хөсәйен углы
4) 1906 нчы йылда 13
5) нче мартда даре фәнадан
6) рихләт әйләде нәүвәраллааһү кабраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Вафат булучы һәм мәрхүм Мифтах-
3) -еддин Хөсәен улы
4) 1906 елның 13
5) мартында фани дөньядан

[322] Дәвамы сул ягында.
[323] Башы уң ягында.
[324] Беренче юлы бизәкле түгәрәк эченә алынган.
[325] Беренче юлы бизәкле түгәрәк эченә алынган.

6) күчте. Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 115(128)х36х12.

6. Фәхрениса Сәфәргали кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт 1903 сәнә
3) синтәбр 6 нда Йаңа Кенәрнең
4) Фәхренниса Сәфәргали кызы
5) Тимергали хәләле 80 йәшендә
6) даре бәкайә рихләт кыйлды».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ Тәгалә гарикы рәхмәт кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак». 1903 елның
3) 6 сентябрендә Яңа Кенәрдән
4) Фәхрениса Сәфәргали кызы –
5) Тимергали хәләле – 80 яшендә
6) мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә рәхмәткә күмсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 95(113)х38х13.

7. Тимергали Мәхмүд улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) руми 1907 нче
3) йылда нуйәбр 28 ндә
4) Житлар карйәсинең
5) Тимергали Мәхмүд
6) углы 88 йәшендә
7) дарел-фәнадин
8) дарел-бәкайә ри-
9) -хләт әйләде
10) Аллаһ Тәгалә рәхмәт
11) гарикъ кыйлсун
12) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1907
3) елның 28 ноябрендә
4) Житлар авылыннан
5) Тимергали Мәхмүд
6) улы 88 яшендә
7) фани дөньядан
8) мәңгелек дөньяга
9) күчте.
10) Аллаһ Тәгалә рәхмәткә
11) күмсен,
12) амин».

Таш үлчәмнәре: 101х31х11.

8. Бибифатыйма Сәйфелмөлек кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә иллләллаһ Мүхәммәдүр-
расүүлүллаһ салләәллаһү галәйһи вә сәлләм
2) кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа ру-
3) -миййә илә 1907 нче йылда
4) 16 синтәбрдә Бибифатыйма Сәйф-
5) -елмөлек кызы даре фәнадан рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Күллү шәйъин һәәликүн илләә вәҗһәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе, Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен.
2) Үлем вәгазьче буларак җиткән. Ми-
3) -лади белән 1907 елның
4) 16 сентябрендә Бибифатыйма Сәйф-
5) -елмөлек кызы фани дөньядан күчте».

Уң ягы: «Аның [Аллаһның] Йөзеннән башка һәрбер нәрсә һәлак булучы».

Сул ягы: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».

Таш үлчәмнәре: 116х31х12.

9. Сиражеддин Насреддин улына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[326]:
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ

[326] Беренче юлы түгәрәк эченә алынган, ай һәм йолдызлар рәсемнәре төшерелгән.

2) милади 1908 нче йылда
3) май 11 ндә Сиражеддин
4) Насреддин углы
5) 65 йәшендә
6) мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Милади 1908 елның
3) 11 маенда Сиражеддин
4) Насреддин улы
5) 65 яшендә
6) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 82x29x11.

10. Мөхәммәдшакир Сәйфулла улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә
2) иләйһи рааҗигуун
3) Аллаһ Тәгаләнең
4) рәхмәтенә васыйл
5) улса иде Мөхәммәд-
6) -шакир Сәйфулла
7) углы рахимәһ-
8) -үллаһү Тәгааләә рахмәтән
9) вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әд-дәәру дәәру нәгыыймин ин гамилтә биһәә»[327].

Сул ягы (уеп язылган): «Йүрдааль-иләәһә вә ин хааләфтә фән-нәәр»[328].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Милади илә
2) 1913 нче йыл
3) 24 нче ийүлдә
4) 60 йәшендә вафат
5) улды Аллаһ Тәгалә
6) каберен җәннәт багча-
7) -ларындан бөр
8) багча кылса
9) иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.

[327] Дәвамы сул ягында.
[328] Башы уң ягында.

3) Мөхәммәд-
4) -шакир Сәйфулла
5) улы Аллаһ Тәгаләнең
6) рәхмәтенә ирешсә
7) иде. Аллаһ Тәгалә
8) аны киң рәхмәте белән
9) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Әгәр [Раббың риза булырлык] гамәлләр кылсаң, барачак урының җәннәт йорты булыр».

Сул ягы: «Раббың риза булырлык. Әгәр каршы килсәң, урының ут булыр».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1913 елның
3) 24 июлендә
4) 60 яшендә вафат
5) булды. Аллаһ Тәгалә
6) каберен җәннәт бакча-
7) -ларыннан бер
8) бакча итсә
9) иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 112x31x14.

11. Хәлилулла Насыйбулла улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Житлар авылының
2) Хәлилулла Насыйбулла
3) углы 80 йәшенд
4) 1913 нче сәнә үктәбр
5) 20 нче көне вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Житлар авылыннан
2) Хәлилулла Насыйбулла
3) улы 80 яшендә
4) 1913 ел октябренең
5) 20 нче көнендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 70(83)x32x9.

12. Сафиулла Сәйфулла улына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә
2) иләйһи рааҗигуун
3) Аллаһ Тәгаләнең

4) рәхмәтенә васыйл
5) улса иде
6) Сафийулла Сәйф-
7) -улла углы
8) рахимәһүллаһү Тәгаалә
9) рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Әл-мәүтү бәәбүн вә күллүн-нәәси дәәхыйлүһ»[329].

Сул ягы (уеп язылган): «Фә-ләйтә шәгърийә бәгъдәл-мәүти мәәд-дәәр»[330].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә
2) илә 1914 нч
3) йыл 9 нчы синтәбрдә
4) 74 йәшендә
5) дәфен кыйлынды
6) Аллаһ Тәгалә каберен
7) җәннәт багчалары-
8) -ндан бер багча
9) кылса иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.
3) Сафиулла Сәйф-
4) -улла улы
5) Аллаһ Тәгаләнең
6) рәхмәтенә
7) ирешсә иде.
8) Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте
9) белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Үлем – ишек, һәр кеше аннан керәчәк».

Сул ягы: «Үлгәннән соң нинди урын әзерләнгәндер».

Арткы ягы :
1) «Милади
2) белән 1914
3) елның 9 сентябрендә
4) 74 яшендә
5) җирләнде.
6) Аллаһ Тәгалә каберен
7) җәннәт бакчалары-
8) -ннан бер бакча
9) итсә иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 106x31x11.

13. Гарифә Вәлиша кызына һәм Мөхәммәди Вәли улына куелган кабер ташы, 1917 һәм 1918 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллаһ
2) Мүхәммәдүр-расүүлүллаһ
3) ошбу Мөхәммәддин җәмәгате
4) Иске Тазлар Вәли-
5) -ша кызы Гарифә дәфен
6) кылынды 72 йәшендә
7) 1917 йылда 28
8) нче ийүндә».

Уң ягы (уеп язылган): «Углы иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун»[331].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1918 йылда 14 нч
3) ийүндә 84 йәшендә
4) дәфен кылынды Аллаһ
5) Тәгалә каберен җәннәт
6) багчаларындан
7) бер багча кылса иде
8) амин Мөхәммәди Вәли»[332].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,
2) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
3) Бу Мөхәммәддин җәмәгате –
4) Иске Тазлардан Вәли-
5) -ша кызы Гарифә
6) 72 яшендә
7) 1917 елның 28
8) июнендә җирләнде».

Уң ягы: «Улы. Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1918 елның 14
3) июнендә 84 яшендә
4) Мөхәммәди Вәли [улы]
5) җирләнде. Аллаһ
6) Тәгалә каберен җәннәт
7) бакчаларыннан
8) бер бакча итсә иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 79x32x10.

[329] Дәвамы сул ягында.
[330] Башы уң ягында.
[331] Башы арткы ягында.
[332] Дәвамы уң ягында.

14. Хәерниса Баһаведдин кызына һәм Мөхәммәҗҗан Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1899 һәм 1920 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Хәйренниса
2) Баһаэддин кызы
3) 1899 нчы йылда ийүн
4) 4 нче көне 55 йәшендә
5) җан тәслим әйләде
6) рахмәтүллааһи рахмәтән вәәсигаһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мөхәммәҗҗан
2) бине Хәбибулла
3) 1920 нче йылда април
4) 28 ндә 80 йәшендә
5) даре фәнадан рихләт
6) әйләде хәлим фөкара-
7) -га ярдәмле адәм иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хәерниса
2) Баһаведдин кызы
3) 1899 ел июненең
4) 4 нче көнендә 55 яшендә
5) җан тәслим кылды.
6) Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Арткы ягы:
1) «Мөхәммәҗҗан
2) бине Хәбибулла
3) 1920 елның 28
4) апрелендә 80 яшендә
5) фани дөньядан
6) күчте. Юмарт, фәкыйрьләр-
7) -гә ярдәмле адәм иде».

Таш үлчәмнәре: 96х30х11.

15. Маһисорур Шаһиәхмәд кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкый
2) Маһисорур ибнәте Шаһи-
3) -әхмәд 1920 сәнә
4) ийүн 14 ндә
5) 72 йәшендә вафат
6) рахимәһәллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Маһисорур бинте Шаһи-
3) -әхмәд 1920 елның
4) 14 июнендә
5) 72 яшендә вафат.
6) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 80х30х6.

16. Исхак кари Хөсәен улы Габдуллинга куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) хаҗи вә хафиз
3) кәлямулла Исхак
4) кари бине Хөсәйен
5) Габдуллин
6) миладиййә илә»[333].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1923 нче сәнә
2) 1 нче үктәбрдә
3) һиҗри 1342 сәнә
4) сәфәр 21 ндә 45
5) йәшендә сиһшәнбә
6) көн вафат»[334].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Хаҗи, Аллаһ китабын [Коръәнне]
3) яттан белүче Исхак
4) кари бине Хөсәен
5) Габдуллин
6) милади белән».

Арткы ягы:
1) «1923 елның
2) 1 октябрендә,
3) һиҗри 1342 елның
4) 21 сәфәрендә 45
5) яшендә сишәмбе
6) көн вафат».

Таш үлчәмнәре: 67х29х9.

[333] Дәвамы арткы ягында.
[334] Башы алгы ягында.

17. Гайнулла Хәмидулла улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[335]:
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Житлар авылыйның
3) Гайнулла Хәмидулла
4) углы 1926 нчы йылда
5) 25 нче синтәбр 70 йәшендә
6) җан тәслим әйләде
7) Аллаһ рәхмәт әйләйә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Житлар авылыннан
3) Гайнулла Хәмидулла
4) улы 1926 елның
5) 25 сентябрендә 70 яшендә
6) җан тәслим кылды.
7) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 87х29х9.

18. Бикчәнтәй Ирүлкәй улына һәм аның хатыны Бәлхискә куелган кабер ташы, 1855 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Тарих румиййә илән 1855 нч
2) сәнәдә Бикчәнтәй Ирүлкәй углы вафат
3) табды әһлийәсе Бәлхис мәдфүн бу-
4) -лды йаздургучы Мөхәммәдшәриф»[336].

Сул ягы (уеп язылган): «Бикчәнтәй углы»[337].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән 1855
2) елда Бикчәнтәй Ирүлкәй улы вафат
3) булды, хатыны Бәлхис җирлән-
4) -де. Яздыручы Мөхәммәдшәриф».

Сул ягы: «Бикчәнтәй улы».

Таш үлчәмнәре: 63х37х17.

[335] Өске ягында ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.
[336] Дәвамы сул ягында.
[337] Башы алгы ягында.

Кышлау авылы зираты

Бу авыл элегрәк Котаймас дип йөртелгән. Татар халык мәкальләрендә дә бу атама чагылыш тапкан: «Бәхәсләшеп Кытайга киткән Котаймастан кире кайтыр».

1. Мортаза Мөстәкыйм улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер сахибе
2) Котаймас авылыйның
3) Мортаза Мөстәкыйм углы
4) 65 йәшендә даре
5) фәнадан даре бәкайә рихләт әйләде
6) 1917 нче йылда мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) Котаймас авылыннан
3) Мортаза Мөстәкыйм улы
4) 65 яшендә фани
5) дөньядан мәңгелек дөньяга күчте,
6) 1917 елда җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 103х32х11.

2. Шакиржан Хәкимҗан улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Котаймас
3) авылында
4) Шакиржан
5) Хәкимҗан
6) углы дарел-
7) -фәнадин
8) дарел-бәкайә
9) рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Майның (?) 19 нда».

Сул ягы (уеп язылган): «1917 нче йылда 18 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган): «18 йәшдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Котаймас

3) авылында
4) Шакиржан
5) Хәкимжан
6) улы фани
7) дөньядан
8) мәңгелек дөньяга
9) күчте».

Уң ягы: «Майның (?) 19 нда».

Сул ягы: «1917 елда 18 яшендә [вафат]».

Арткы ягы: «18 яшьтә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 71x27x11.

3. Гажиябикә Мортаза хатынына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер сахибе Гажийәбикә
2) Котаймас авылыйның Мортаза Мөстәкыйм
3) углыйның хәләле 1910 нчы йыл
4) гыйнвар 1 нче көне даре фәнадан даре
5) бәкайә рихләт итде Аллаһ Тәгалә
6) гарикы рәхмәт әйләгәй иде
7) 75 йәшендә углы Ибра... бина кылды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Сәнә һиҗрииййә илә
2) 1328 маһе мөхәррәмнең 10 нчы көне
3) җомга һәм Гашура көне
4) гүр ийәсе улды җәннәт әһеле
5) улса иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе Гажиябикә –
2) Котаймас авылыннан Мортаза Мөстәкыйм
3) улының хәләле – 1910 ел
4) гыйнварының 1 нче көнендә 75 яшендә фани дөньядан мәңгелек
5) дөньяга күчте. Аллаһ Тәгалә
6) рәхмәткә күмсә иде.
7) Улы Ибра[һим] куйды».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән
2) 1328 ел мөхәррәм аеның 10 нчы көнендә
3) (җомга һәм Гашура көнендә)
4) гүр иясе булды. Җәннәт әһеле
5) булса иде».

Таш үлчәмнәре: 90x31x11.

4. Бибигафифә Габделхаликъ кызына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[338]:
1) «Бибигафифә
2) Габделхаликъ
3) кызы Мөхәммәдвәли
4) җәмәгате вафат
5) милади 1923 сәнә
6) ийүл 5 66 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бибигафифә
2) Габделхаликъ
3) кызы – Мөхәммәдвәли
4) җәмәгате –
5) милади 1923 елның
6) 5 июлендә 66 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 85x28x11.

5. Шәрифҗамал Мөхәммәдгали Садыйк улының кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Румииййә 1910 нчы
2) йыл 31 нче майда
3) Шәрифелҗамал
4) Мамыши Мөхәммәдгали
5) Садыйк углының
6) кызы»[339].

Сул ягы (уеп язылган): «Дәфен кылынды 8 йәшендә»[340].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади 1910
2) елның 31 маенда
3) Шәрифҗамал
4) Мамыштан Мөхәммәдгали
5) Садыйк улының
6) кызы».

Сул ягы: «8 яшендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 72(83)x28x11.

[338] Өске өлешендә ай рәсеме уелган.
[339] Дәвамы сул ягында.
[340] Башы алгы ягында.

6. Гыйнәятулла Гатаулла улына куелган кабер ташы[341], 1936 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) милади 1936 сәнә
3) 13 нче априлдә
4) дүшәнбә көн
5) Гыйнәйәтулла Гатаулла
6) мәрхүм углы даре-
7) -л-фәнадан дарел-бәкайә
8) рихләт әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Галәмәтдән
2) морадым бер догадыр
3) раудатән мин рийәәд-
4) -ыйль-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Милади 1936 елның
3) 13 апрелендә
4) дүшәмбе көн
5) Гыйнәятулла Гатаулла
6) мәрхүм улы фани
7) дөньядан мәңгелек дөньяга
8) күчте.».

Арткы ягы:
1) «Галәмәттән
2) морадым бер догадыр.
3) [Аллаһ каберен] җәннәт бакчаларыннан бер
4) бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 95х26х4.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Гыйнәятулла бине Гатаулла бине Гобәйдулла бине Баязид бине Биктимер бине Уразай бине Байбахты[342].

7. Һидиятулла Гатаулла улына куелган кабер ташы[343], 1935 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) милади 1935 сәнә
3) майның 24 ндә
4) җомга көн
5) Һидийәтулла Гатаулла
6) мәрхүм углы
7) дарел-фәнадан даре-
8) -л-бәкайә рихләт әйләде
9) 71 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган)[344]:
1) «Галәмәтдән
2) морадым бер догадыр
3) җәгаләллаһү мәркадәһү
4) раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Милади 1935 елның
3) 24 маенда
4) җомга көн
5) Һидиятулла Гатаулла
6) мәрхүм улы
7) 71 яшендә
8) фани дөньядан мәңгелек
9) дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Галәмәттән
2) морадым бер догадыр.
3) Аллаһ аның каберен
4) җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 97(113)х25х4.

8. Гатаулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы[345], 1924 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) милади 1924 сәнә
3) дикәбрнең 16 сында
4) дүшәнбә көн
5) Гатаулла Гобәйдулла
6) мәрхүм углы даре
7) җәфадан дарер-рәхәт-
8) -кә күчде
9) 77 йәшендә».

[341] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә игътибарга лаек.

[342] Фәйзрахманов Ж.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 175–176.

[343] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә игътибарга лаек.

[344] Беренче ике юлы горизонталь, калганнары вертикаль рәвештә язылган.

[345] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә игътибарга лаек.

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Галәмәтдән
2) морадым бер догадыр
3) һәзәә мәркадүл-мәрхүүм».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Милади 1924 елның
3) 16 декабрендә
4) дүшәмбе көн
5) Гатаулла Гобәйдулла
6) мәрхүм улы
7) 77 яшендә
8) җәфа йортыннан рәхәтлек йорты-
9) -на күчте».

Арткы ягы:
1) «Галәмәттән
2) морадым бер догадыр.
3) Бу – мәрхүм кабере».

Таш үлчәмнәре: 108(121)х24х4.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Гатаулла бине Гобәйдулла бине Баязид бине Биктимер бине Уразай бине Байбахты[346].

9. Әхмәҗҗан Әмир улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Әхмәҗҗан
3) Әмир углы
4) һиҗрииййә 1309 нчы йылда
5) миладиййә 1892 нче йылда
6) 70 нче йәшендә
7) 10 нчы синтәбрдә».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Әхмәҗҗан
3) Әмир улы
4) һиҗри 1309 елда
5) милади 1892 елның
6) 10 сентябрендә
7) 70 нче яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 75(92)х31х13.

10. Сәмигулла Фәтхулла улы Мохтаровка куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Сәмигулла Фәтхулла
3) углы Мохтаруф
4) 57 йәшендә
5) 1892 сәнәи румииййә
6) синтәбр 5 ндә
7) дәфен иделде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Сәмигулла Фәтхулла
3) улы Мохтаров
4) 57 яшендә
5) милади 1892 елның
6) 5 сентябрендә
7) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 96х31х11.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Сәмигулла бине Фәтхулла бине Мохтар бине Юлдаш бине Уразай бине Юртук (Юртмәмәт) бине Уразмәт[347].

11. Гыйльмелбаян Мифтахеддин кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) милади 1899 сәнә
3) дикәбр 23 ндә
4) Гыйльмелбайан
5) Мифтахеддин кызы
6) 62 йәшендә
7) дәфен иделде».

[346] Фәйзрахманов Җ.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 175–176.

[347] Фәйзрахманов Җ.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 185.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Милади 1899 елның
3) 23 декабрендә
4) Гыйльмелбаян
5) Мифтахеддин кызы
6) 62 яшендә
7) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 98x31x11.

12. Мифтахеддингә куелган кабер ташы[348], 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Йә Аллаh
2) румиййә илә
3) 1922 сәнә
4) 4 нче агусда
5) Мифтахедд-
6) -ин»[349].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Дәфен кыйлынд-
2) -ы 62 йә-
3) -шендә сез-
4) -дән мора-
5) -дым бер дога-
6) -дыр»[350].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Йә, Аллаh.
2) Милади белән
3) 1922 елның
4) 4 августында
5) Мифтахедд-
6) -ин».

Арткы ягы:
1) «62 яшендә
2) җирләнде.
3) Сез-
4) -дән мора-
5) -дым бер дога-
6) -дыр».

Таш үлчәмнәре: 68x26x3.

13. Шәмсекамәр Сөләйман кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh руух
2) Котаймас авылында
3) Шәмсекамәр Сөләйма-
4) -н кызы
5) Сәгъданша зәү-
6) -җәсе
7) дарел-фәнадин
8) дарел-бәкайә
9) рихләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «Май 5 ндә 75 йәшендә».

Сул ягы (уеп язылган): «1905 нче җылда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Хөкем Аллаһта.
2) Котаймас авылында
3) Шәмсекамәр Сөләйма-
4) -н кызы –
5) Сәгъданша ха-
6) -тыны –
7) фани дөньядан
8) мәңгелек дөньяга
9) күчте».

Уң ягы: «Майның 5 ндә 75 яшендә [вафат]».

Сул ягы: «1905 елда [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 75x31x11.

14. Сәгъданша Салих улына куелган кабер ташы, 1890 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh руух
2) Котаймас алда
3) Сәгъданшаh
4) Салих углы
5) дарел-фәнадин
6) дарел-бәкайә
7) рихләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «1890 нчы җылда 65 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Үктәбрнүн 5 ндә амин».

[348] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә игътибарга лаек.
[349] Дәвамы арткы ягында.
[350] Башы алгы ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Котаймас а[вы]л[ын]да
3) Сәгъданша
4) Салих углы
5) фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга
7) күчте».

Уң ягы: «1890 елда 65 яшендә [вафат]».

Уң ягы: «Октябрьнең 5 ндә [вафат], амин».

Таш үлчәмнәре: 85(99)х32х10.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Сәгъданша бине Салих бине Сәгыйдь бине Бикчәнтәй бине Апка бине Юртук (Юртмәмәт) бине Уразмәт[351].

15. Миңлебай Сәгъданша улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[352]:
1) «Милади 1923 сәнә
2) майның 15 ндә
3) Миңлебай Сәгъдан-
4) -шаһ улы вафат
5) 64 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади 1923 елның
2) 15 маенда
3) Миңлебай Сәгъдан-
4) -ша улы
5) 64 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 69х31х10.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Миңлебай бине Сәгъданша бине Салих бине Сәгыйдь бине Бикчәнтәй бине Апка бине Юртук (Юртмәмәт) бине Уразмәт[353].

16. Шәрәфеддин Җамаледдин улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) Котаймас авылыйның Шәрәф-
3) -еддин Җамаледдин углы
4) 1892 нче йылда синтәбр
5) 11 нче көне 45 йәшендә
6) даре фәнадан даре бәкайә
7) рихләт әйләде Хода рәхмәт әйләйә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу фәнаның гыйззе вә җаһы
3) гыйшнуш пөр хыйал
4) күрмәдем бер гыйззәтен кем
5) ахыр булмыйа зәвал».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Котаймас авылыннан Шәрәф-
3) -еддин Җамаледдин улы
4) 1892 ел сентябренең
5) 11 нче көнендә 45 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Хода рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу фанилыкның кадере һәм дәрәҗәсе –
3) типтерү, хыял белән тулы.
4) Күрмәдем бер кадерен,
5) ахырдан юкка чыгу булыр».

Таш үлчәмнәре: 77х33х11.

17. Галәведдин Габделҗаббар улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ
2) румиййә илә 1910 сәнә
3) 20 нче үктәбрдә
4) Галәэддин Габделҗаббар
5) углы дәфен кылынды
6) 64 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәңа икән таңда сәңадыр».

[351] Фәйзрахманов Ж.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 185.
[352] Өске өлешендә матур чәчәк һәм үсемлек орнаменты төшерелгән.
[353] Фәйзрахманов Ж.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 185.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ.
2) Милади белән 1910 елның
3) 20 октябрендә
4) Галәведдин Габделҗаббар
5) улы 64 яшендә
6) җирләнде».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миңа икән, таңда сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 96(110)х32х11.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Галәведдин бине Габделҗаббар бине Рәфыйк бине Мөхәммәд бине Рысай бине Алмәмәт бине Уразгилде[354].

18. Әминә Әхмәдсафа кызына куелган кабер ташы[355], 1939 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) милади 1939 сәнә
3) Әминә Әхмәд-
4) -сафа кызы 20
5) йәшендә даре
6) бәкайә күчде
7) раудатән мин рийәәд-
8) -ыйль-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Милади 1939 елда
3) Әминә Әхмәд-
4) -сафа кызы 20
5) яшендә мәңгелек
6) дөньяга күчте.
7) [Аллаһ каберен] җәннәт бакчаларыннан бер
8) бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 82х25х6.

19. Фәизәгә куелган кабер ташы[356], XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Фәизә Мөхәммәд-
3) -... кызы Г...
4) ...җан углының зәү-
5) -җәсе дәфен
6) кылынды 51
7) йәшендә
8) 192... сәнәдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Фәизә Мөхәммәд-
3) -... кызы Г...
4) ...җан улының ха-
5) -тыны
6) 51
7) яшендә
8) 192... елда җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 97х24х10.

20. Сәмигулла Вәлиулла улына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу кабер
2) Сәмигулла
3) Вәлийулла
4) углының».

Таш үлчәмнәре: 51х24х5.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Сәмигулла бине Вәлиулла бине Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим бине Әхмәр бине Мусай бине Сәед бине Акбулат[357].

21. Бибизөһрә Габделгафур кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Румиййә 1914 нче

[354] Фәйзрахманов Ж.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 183.

[355] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә игътибарга лаек.

[356] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә игътибарга лаек.

[357] Фәйзрахманов Ж.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 175.

2) йыл 24 нче аугыстда
3) Бибизәһрә Габд-
4) -елгафур кызы Мөхәммәд-
5) -шаһ Мөэмин углы-
6) -ның зәүҗәсе»[358].

Сул ягы (уеп язылган): «Дәфен кылынды 65 йәшендә»[359].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади 1914
2) елның 24 августында
3) Бибизәһрә Габд-
4) -елгафур кызы – Мөхәммәд-
5) -ша Мөэмин улы-
6) -ның хатыны».

Сул ягы: «65 яшендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 75(90)x31x11.

22. Фазыләхмәд Хәмзә улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) руми 1905 сәнә ийүл 13 ндә
3) Котаймасның Фазыл-
4) -әхмәд Хәмзә углы
5) даре бәкайә рихләт кыйлды».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ Тәгалә рәхмәт кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Милади 1905 елның 13 июлендә
3) Котаймастан Фазыл-
4) -әхмәд Хәмзә улы
5) мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 77(99)x31x14.

23. Бибимәхфүзә Мозаффар кызына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт 1901 сәнә
3) фибрал 10 нда Колларның Биби-
4) -мәхфүзә Мозаффар кызы
5) Котаймасның Хәмзә
6) хәләле 70 йәшендә»[360].

Сул ягы (уеп язылган): «Вафат итде Аллаһ рәхмәт кыйлсун амин»[361].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак». 1901 елның
3) 10 февралендә Коллардан Биби-
4) -мәхфүзә Мозаффар кызы –
5) Котаймастан Хәмзә
6) хәләле – 70 яшендә».

Сул ягы: «Вафат булды. Аллаһ рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 84x35x14.

24. Кадыйр Мөхәммәдкамал улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) милади 1923 сәнә
3) април 29 да Кадыйр
4) Мөхәммәдкамал улы
5) дәфен ителде».

Сул ягы (уеп язылган): «67 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Милади 1923 елның
3) 29 апрелендә Кадыйр
4) Мөхәммәдкамал улы
5) җирләнде».

Сул ягы: «67 яшендә [җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 57(65)x24x8.

[358] Дәвамы сул ягында.
[359] Башы алгы ягында.
[360] Дәвамы сул ягында.
[361] Башы алгы ягында.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Кадыйр бине Мөхәммәдкамал бине Мәннаф бине Гобәйдулла бине Рәхмәт бине Килкә (Килмөхәммәд) бине Минкә (Миңлекәй) бине Байбахты[362].

25. Бибимиһербан Сәбкол кызына куелган кабер ташы, 1826 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Гарәбиййә илә меңдә ике йөздә
2) кырык икенче йыл рамазан шәрифнең 5 нче
3) көнендә мулла Габделкәрим хәләле Бибимиһербан
4) Сәбкол кызы 77 йәшендә нәкыль итде
5) сәнә 1826 нчы йыл вафат нәүвәраллаahү Тәгааләә мәркадәһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Гарәп ел исәбе белән мең дә ике йөз дә
2) кырык икенче ел рамазан шәрифенең 5нче
3) көнендә мулла Габделкәрим хәләле – Бибимиһербан
4) Сәбкол кызы 77 яшендә күчте,
5) [милади] 1826 елда вафат. Аллаһ Тәгалә аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 89х42х16.

Ревизия кенәгәләрендә әлеге кабер иясенең чыгышы хәзерге Биектау районы Айбаш авылыннан икәнлеге күрсәтелгән.

26. Сафия Садыйк Корбангали улының кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт
3) Котаймас авылыйның
4) Садыйк Корбангали углы-
5) -ның кызы Сафийә 23 йәшендә
6) 1912 нче сәнә 27 нче март
7) җан тәслим әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак.
3) Котаймас авылыннан
4) Садыйк Корбангали улы-
5) -ның кызы Сафия 23 яшендә
6) 1912 елның 27 мартында
7) җан тәслим кылды».

Таш үлчәмнәре: 94(113)х32х12.

27. Хәмидулла Сөләйман улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Котаймас авылыйның
2) Хәмидулла Сөләйман углы
3) 1910 нчы сәнә 10 нчы үктәбр
4) 80 йәшендә җан
5) тәслим әйләде
6) Аллаahүммәжгаль кабраhү
7) раудатән мин рийәәдыйль-җәннәh».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әхмәдгәрәй
2) Сафийулла углы
3) хәрәҗәте илә бина
4) кыйлынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Котаймас авылыннан
2) Хәмидулла Сөләйман улы
3) 1910 елның 10 октябрендә
4) 80 яшендә җан
5) тәслим кылды.
6) Аллаһым, аның каберен җәннәт
7) бакчаларыннан бер бакча ит».

Арткы ягы:
1) «Әхмәдгәрәй
2) Сафиулла улы
3) акчасына
4) куелды».

Таш үлчәмнәре: 94(104)х33х13.

28. Насыйбулла Сөләйман улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[363]:
1) «Һәзәә мәркадүл-мәрхүүми
2) Насыйбулла бине Сөләйман
3) румиййә илә 1915 нч
4) йылда фивралның 13 дә

[362] Фәйзрахманов Җ.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 175–177.

[363] Өске өлешендә матур чәчәк һәм үсемлек орнаменты төшерелгән.

5) дарел-фәнадан дар-
6) -ел-бәкайә күчде
7) 85 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу мәрхүм
2) Насыйбулла бине Сөләйман кабере,
3) милади беләn 1915
4) елның 13 февралендә
5) 85 йәшендә
6) фани дөньядан мәңгелек
7) дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 95х31х11.

29. Фәизә Фәхреддин кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) Фәизә Фәхреддин
3) кызы Хәмидулла
4) Сөләйман улының
5) зәүҗәсе вафат
6) милади 1914 сәнә
7) април 12 76 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Фәизә Фәхреддин
3) кызы – Хәмидулла
4) Сөләйман улының
5) хатыны –
6) милади 1914 елның
7) 12 апрелендә 76 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 96(104)х31х8.

30. Фәйзрахман Сибгатулла улына куелган кабер ташы, 1930 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Котаймас
2) Фәйзрахман Сибгатулла
3) углы 1930 нчы йыл
4) дикәбр 23 нче көне
5) 54 йәшендә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Котаймастан
2) Фәйзрахман Сибгатулла
3) улы 1930 ел
4) декабренең 23 нче көнендә
5) 54 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 53(61)х30х6.

31. Хәйрулла Нигъмәтулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраh
2) милади 1920 сәнә
3) март 21 Хәйрулла
4) Нигъмәтулла улы
5) дарел-фәнадан дар-
6) -ел-бәкайә күчде
7) җәгаләллаahү мәркадәhү
8) раудатән мин рийәәдыйль-җәннәh
9) 75 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер гыйбрәт.
2) Милади 1920 елның
3) 21 мартында Хәйрулла
4) Нигъмәтулла улы
5) 75 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек
7) дөньяга күчте.
8) Аллаh аның каберен җәннәт
9) бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 102(113)х30х9.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Хәйрулла бине Нигъмәтулла бине Фәйзулла бине Бикбау бине Килкә (Килмөхәммәд) бине Минкә (Миңлекәй) бине Байбахты[364].

32. Шәрифҗамал Сәйфулла кызына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәh
2) Шәрифелҗамал
3) Сәйфулла
4) кызы 70 йәшендә
5) 1916 сәнә 20 нче
6) үктәбрдә вафат».

[364] Фәйзрахманов Җ.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 175–176.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Шәрифҗамал
3) Сәйфулла
4) кызы 70 яшендә
5) 1916 елның 20
6) октябрендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 83x32x8.

33. Бибифатиха Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1905 сәнә
3) гыйнвар 12 ндә Бибифатиха Габденна-
4) -сыйр кызы Сибгатулла Сафийулла
5) углының зәүҗәсе 60 йәшендә
6) чәһаршәнбә көн даре бәкайә»[365].

Уң ягы (уеп язылган): «Һиҗриййә илә 1323 сәнә маһе зөлкагдәнең 20 ндә вафат».

Сул ягы (уеп язылган): «Рихләт кыйлды таййибәллаһү сәраһәә әәмиин»[366].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1905 елның
3) 12 гыйнварында Бибифатиха Габденна-
4) -сыйр кызы – Сибгатулла Сафиулла
5) улының хатыны – 60 яшендә
6) чәршәмбе көн мәңгелек дөньяга».

Уң ягы: «Һиҗри белән 1323 елның 20 зөлкагдәсендә вафат».

Сул ягы: «Күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 96(122)x35x14.

34. Гаҗбикамал Бикмөхәммәд кызына куелган кабер ташы, 1896 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1896
3) сәнә април 24 ндә һиҗри
4) 1313 сәнә зөлкагдә 24 ндә
5) Котаймасның Гаҗбикамал
6) Бикмөхәммәд кызы Биккенә Мәһди
7) углының зәүҗәсе 65 йәшдә»[367].

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (уеп язылган): «Даре бәкайә рихләт кыйлды таййибәллаһү сәраһәә әәмиин»[368].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер Гаҗбикамал Бикмөхәммәд
2) кызы Биккенә Мәһди углы-
3) -ның зәүҗәсе 65 йәшдә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1896
3) елның 24 апрелендә, һиҗри
4) 1313 елның 24 зөлкагдәсендә
5) Котаймастан Гаҗбикамал
6) Бикмөхәммәд кызы – Биккенә Мәһди
7) улының хатыны – 65 яшьтә».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын, амин».

Арткы ягы:
1) «Бу кабер Гаҗбикамал Бикмөхәммәд
2) кызы – Биккенә Мәһди улы-
3) -ның хатынкы, 65 яшьтә вафат».

Таш үлчәмнәре: 108x35x18.

35. Бибихәдичә Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1895
3) сәнә ийүн 28 ндә һиҗри
4) 1313 сәнә рабигыль-әүвәл
5) 15 ндә Котаймасның
6) Бибихәдичә Гобәйдулла кызы
7) әл-хаҗҗе Гайнулла Сафийулла»[369].

[365] Дәвамы сул ягында.
[366] Башы алгы ягында.
[367] Дәвамы сул ягында.
[368] Башы алгы ягында.
[369] Дәвамы сул ягында.

Уң ягы (уеп язылган): «Ләһү мәләкүн йәнәәдии күллә йәүмин лидүү лил-мәүти вәбнүү лил-харааб».

Сул ягы (уеп язылган): «Углының хәлиләсе 60 йәшдә чәһаршәнбә көн даре бәкайә рихләт кылды»[370].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә мәркадү Бибихәдичә бинте
2) Гобәйдулла халииләтүл-хәәҗҗи
3) Гайнулла бине Сафийулла мәәтә
4) 1313 сәнәһ гаашә 60 сәнәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1895
3) елның 28 июнендә, һиҗри
4) 1313 елның 15 рабигыль-
5) әүвәлендә Котаймастан
6) Бибихәдичә Гобәйдулла кызы –
7) хаҗи Гайнулла Сафиулла».

Уң ягы: «Көн саен фәрештә аңа [кешегә] әйтә: «Туыгыз – барыбер үләчәксез, биналар төзегез – барыбер җимереләчәк».

Сул ягы: «Улының сөеклесе 60 яшьтә чәршәмбе көн мәңгелек дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Бу Бибихәдичә бинте
2) Гобәйдулла – хаҗи Гайнулла
3) бине Сафиулла сөеклесе – кабере,
4) 1313 елда вафат, 60 ел яшәде».

Таш үлчәмнәре: 109x36x18.

36. Мөәзин Габдрахман мулла Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1898
3) сәнә синтәбр 9 нда Котаймас
4) карйәсендә мөәзин Габдеррахман
5) мулла Исмәгыйль углы 67
6) йәшендә җомга көн
7) мәдфүн улды рахимәһүллааһ»[371].

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (калкытып язылган): «Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ әәмиин»[372].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1898
3) елның 9 сентябрендә Котаймас
4) авылында мөәзин Габдрахман
5) мулла Исмәгыйль улы 67
6) яшендә җомга көн
7) җирләнде. Аллаһ аны рәхим кылсын».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Киң рәхмәт белән [Аллаһ] Тәгалә [рәхим кылсын], амин».

Таш үлчәмнәре: 115(136)x36x14.

Әлеге кабер иясе, 1868 елның 11 мартында указ (указ номеры – №273) алып, икенче мәхәллә мәчетенә мөәзин итеп билгеләнгән, шул ук вакытта аның имам вазыйфасын да башкарырга хокукы булган. Улы Фәйзрахман (1864–1910) да 1899 елдан Кышлауның шул ук мәчетендә мөәзин булып торган.

37. Бибиәсма мулла Төхфәтулла кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) руми 1899 сәнә май 5 ндә
3) Габдеррахман мөәзин
4) зәүҗәсе Бибиәсма
5) Шекәнең мулла Төхфәтулла
6) кызы 65 йәшендә
7) чәһаршәнбә көн тәслиме
8) рух әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Тайййибәллааһү сәрааһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади 1899 елның 5 маенда
3) Габдрахман мөәзин
4) хатыны Бибиәсма –
5) Шекәдән мулла Төхфәтулла
6) кызы – 65 яшендә

[370] Башы алгы ягында.
[371] Дәвамы сул ягында.
[372] Башы алгы ягында.

7) чәршәмбе көн рух [җан]
8) тәслим кылды».

Уң ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 132(165)х35х14.

38. Бибихәмсәнә Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1896 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаалә күллү
2) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт руми
3) 1896 сәнә ийүл 24 ндә
4) һиҗри 1314 сәнә сәфәр 24
5) ндә Котаймасның Бибихәмсәнә
6) Габденнасыйр кызы Хәбибулла
7) Насыйбулла углының зәүҗәсе»[373].

Уң ягы (уеп язылган): «Таййибәллаһү сәраһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә әәмиин».

Сул ягы (калкытып язылган): «58 йәшдә чәһаршәнбә көн даре бәкайә рихләт кылды»[374].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) Бу кабер Бибихәмсәнә Габденнасыйр
2) кызы Хәбибулла Насыйбулла углы-
3) -ның зәүҗәсе 58 йәшдә
4) даре фәнадин рихләт кылды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Һәр
2) җан иясе үлемне татыячак.
3) Милади 1896 елның 24 июлендә,
4) һиҗри 1314 елның 24 сәфәрендә
5) Котаймастан Бибихәмсәнә
6) Габденнасыйр кызы – Хәбибулла
7) Насыйбулла улының хатыны».

Уң ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Сул ягы: «58 яшьтә чәршәмбе көн мәңгелек дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) Бу кабер Бибихәмсәнә Габденнасыйр
2) кызы – Хәбибулла Насыйбулла улы-
3) -ның хатынныкы, 58 яшьтә
4) фани дөньядан күчте».

Таш үлчәмнәре: 110(120)х36х21.

39. Сибгатулла Сафиулла улы Сабитовка куелган кабер ташы, 1887 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаалә күллү нәфсиң зәәъикат-
2) -үл-мәүүт тарих румиййә илә 1887 нче йыл
3) алтынчы ийүндә һиҗриййә илә 1304 нче сәнә
4) рамазан шәрифнең 26 нчы көнендә Кадер
5) кичәсендә Котаймас авылының сахибел-хәйрат
6) Сибгатулла Сафийулла углы Сабитуф
7) 46 йәшдә даре бәкайә рихләт идүб
8) шинбә көн мәдфүн улды таййибәллаһү
9) сәраһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ әәмиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) Бу кабер Котаймасның Сибгатулла
2) Сафийулла углы Сабитуф-
3) -ның мәркадидүр ләйләи кадердә
4) мәдфүн улды бәррадәллаһү мәдъҗәгаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Һәр җан иясе үлемне
2) татыячак. Милади белән 1887 елның
3) алтынчы июнендә, һиҗри белән 1304 ел
4) рамазан шәрифенең 26 нчы көнендә – Кадер
5) кичәсендә – Котаймас авылыннан изгелек иясе
6) Сибгатулла Сафиулла улы Сабитов,
7) 46 яшьтә мәңгелек дөньяга күчеп,
8) шимбә көн җирләнде. Аллаһ аның туфрагын
9) яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Арткы ягы:
1) Бу – Котаймастан Сибгатулла
2) Сафиулла улы Сабитов-
3) -ның кабередер, Кадер кичәсендә
4) җирләнде. Аллаһ аның урынын суытсын».

Таш үлчәмнәре: 119х40х23.

[373] Дәвамы сул ягында.
[374] Башы алгы ягында.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Сибгатулла бине Сафиулла бине Сабит бине Фәйзулла бине Бикбау бине Килкә (Килмөхәммәд) бине Минкә (Миңлекәй) бине Байбахты[375].

40. Бибигайшә Фәхреддин кызына куелган кабер ташы, 1886 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән тарих румиййә илә
3) 1886 нчы йылда синтәбрнең 27
4) нче көнендә hиҗриййә илә 1304
5) сәнәдә mahe мөхәррәмнең 10 нчы йәүмендә
6) Бибигайшә Фәхреддин кызы Сафий-
7) -улла Сабит углының зәүҗәсе 70
8) йәшдә вафат улуб шинбә көн мәдфүн улды».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Калиилү гумринәә фи дәәри дүнйәә вә мәржигунәә илә бәйтит-түрааб
2) ләһү мәләкүн йәнәәдии күллә йәүмин лидүү лил-мәүти вәбнүү лил-хараab».

Сул ягы (калкытып язылган): «Ходай Тәгалә мәркаден мөнәүвәр әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә әйтте: Анда [җир йөзендә] булучы
2) һәркем, һәрнәрсә фани. Милади белән
3) 1886 ел сентябренең 27
4) нче көнендә, hиҗри белән 1304
5) ел мөхәррәм аеның 10 нчы көнендә
6) Бибигайшә Фәхреддин кызы – Сафи-
7) -улла Сабит улының хатыны – 70
8) яшьтә вафат булып, шинбә көн җирләнде».

Уң ягы:
1) «Безнең гомеребезнең аз өлеше генә дөньяда һәм кайтачак җиребез туфрак йорты.
2) Көн саен фәрештә аңа [кешегә] әйтә: «Туыгыз – барыбер үләчәксез, биналар төзегез – барыбер җимереләчәк».

Сул ягы: «Ходай Тәгалә каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 95х43/36х22.

41. Сафиулла Сабит улына куелган кабер ташы, 1885 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) тарих hиҗриййә илә меңдә
3) өч йөздә икенче йылда
4) рабигыль-ахирдә Сафийулла бине
5) Сабит даре фәнадин интикаль
6) вә даре бәкайә иртихаль әйләде Ходай
7) Тәгалә рәхмәтинә гарикъ әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Тарих румиййә илә 1885 нче сәнәдә 1 нче мартда 71 йәшдә мәрхүм».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта.
2) Hиҗри белән мең дә
3) өч йөз дә икенче елның
4) рабигыль-ахирендә Сафиулла бине
5) Сабит фани дөньядан күченде
6) hәм мәңгелек дөньяга күчте. Ходай
7) Тәгалә рәхмәтенә күмелсен».

Уң ягы: «Милади белән 1885 елның 1 мартында 71 яшьтә мәрхүм [булды]».

Таш үлчәмнәре: 100х39х20.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Сафиулла бине Сабит бине Фәйзулла бине Бикбау бине Килкә (Килмөхәммәд) бине Минкә (Миңлекәй) бине Байбахты[376].

42. Мөэзин Зариф Хәсән улына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих румиййә илә
2) 1914 сәнә фибрал 15 ндә
3) галим гамил Зариф
4) Хәсән углы
5) даре бәкайә интикаль әйләде
6) тайййибәллаahү сәраahү
7) вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәh».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Hәзәә түрбәи шәриф
2) мөэзин Зариф бине

[375] Фәйзрахманов Җ.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 175–177.

[376] Фәйзрахманов Җ.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 175–176.

3) Хәсән әл-Морадыми
4) рахимәһүллаһү Тәгаалә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән
2) 1914 елның 15 февралендә
3) галим, гамәл кылучы Зариф
4) Хәсән улы
5) мәңгелек дөньяга күчте.
6) Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын
7) һәм урынын җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Бу –
2) мөәзин Зариф бине
3) Хәсән Морадыми төрбәсе.
4) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 99x31x12.

Әлеге кабер иясе, 1877 елның 8 мартында указ (указ номеры – №1285) алганнан соң, беренче мәхәллә мәчетендә мөәзинлек вазыйфасын башкарган. Атасы Хәсән Габделгаффар улы (1808–1884) хәзерге Арча районы Орнашбаш авылыннан күченеп, 1835 елдан Кышлау авылының 1 нче мәчетендә мөәзин булып торган.

Лотфулла хәзрәт әле шәкертләр дә укыткан. Бу турыда Кышлау авылы кешесе Гарәбша Мөхәммәдша улы (1887–1961) түбәндәгечә язып калдырган: «Безнең остазыбыз мөәзин Зариф абзый Морадыймов Хәсән улы безнең кебек ятим, фәкыйррәк кешеләрнең дә малайларын башка хәллерәк кешеләрнең балаларына караганда яхшырак аңлатып: «Кыямәт көнендә безләрне укыткан остазыбыз ярлысынып, ихлас күңеле белән укытмады, диярлек булмагыз», – дип әйтәдер иде»[377].

43. Мөхлисә мулла Камал кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[378]:
1) «Фәгъләм әннәһү
2) ләә иләәһә илләәллаһ
3) Мүхәммәдүр-расүүлүллаһ
4) румиййә илә 1910 йылда
5) май 19 да дәфен кылынды
6) Мөхлисә мулла Камал кызы
7) мөәзин Мөхәммәдзариф
8) зәүҗәсе 52
9) йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бел:
2) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк,
3) Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
4) Милади белән 1910 елның
5) 19 маенда
6) Мөхлисә мулла Камал кызы –
7) мөәзин Мөхәммәдзариф
8) хатыны – 52
9) яшендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 98x31x10.

44. Мулла Лотфулла мулла Сибгатулла Габделкадыйр улының улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) мулла Лотфулла бине
3) мулла Сибгатулла
4) бине Габделкадыйр бине Сөләйман
5) бине Мостафа бине Сүнәй
6) бине Ишали бине Инанмас бине
7) Ханмирза бине Хантимер бине Каракай».

Уң ягы (уеп язылган): «Һәзәә мәкәәнүн йүсәәвәә фииһил-әгыйззүл-әзләә».

Сул ягы (уеп язылган): «Кыйф вәгъ-тәбир фәкариибән тәхәллә һәзәәл-мәхәләә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) милади 1912 сәнә
3) 16 нчы үктәбрдә
4) һиҗри 1330 сәнә
5) 18 нче зөлкагдә
6) сиһшәнбә көн мәдфүн
7) 69 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Мулла Лотфулла бине
3) мулла Сибгатулла
4) бине Габделкадыйр бине Сөләйман
5) бине Мостафа бине Сүнәй

[377] Гарәбша Мөхәммәдша улының көндәлек дәфтәре. Шәхси кулларда саклана.
[378] Бу ягында дүрт тажлы ике чәчәк рәсеме төшерелгән.

6) бине Ишали бине Инанмас бине
7) Ханмирза бине Хантимер бине Каракай».

Уң ягы: «Бу урын олыны һәм кечене тигезли».

Сул ягы: «Тукта һәм игътибар ит: тиздән бу урынга күченерсең».

Арткы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Милади 1912 елның
3) 16 октябрендә,
4) һиҗри 1330 елның
5) 18 зөлкагдәсендә
6) сишәмбе көн
7) 69 яшендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 85х30х11.

Әлеге кабер иясе хәзерге Арча районы Түбән Оры авылында дөньяга килгән. 1872 елның 12 июлендә указ (указ номеры – №4779) алгач, авылда имам-хатыйб булган. Аның шәҗәрәсе ташта ук күрсәтелгән. Ризаэтдин Фәхреддин аның атасының шәҗәрәсен бераз гына башкачарак биргән: Сибгатулла бине Габделкадыйр бине Сөләйман бине Мостафа бине Юныс бине Ишали бине Инанмыш бине Ханмирза бине Хантимер бине Каракай[379]. Сибгатулла хәзрәт Уфа өязенең (хәзер Башкортстан Республикасы) Каршин Шәриф авылында 1798 елда туган, башта Казан шәһәренең алтынчы мәчете каршындагы мәдрәсәдә укыткан, соңра Түбән Оры мәдрәсәсенә күчкән. Фәтхулла ахун вафат булгач, бу авылда беренче җамигъ мәчетендә имам да булып торган[380]. Аның атасы Габделкадыйр – атаклы ахун, шулай ук бабасы Сөләйман Каршин Шәриф авылында (хәзерге Башкортстан Республикасы), атасының карендәше Габдессаттар (1778–1841) Оренбург шәһәрендә ахуннар булганнар[381].

Кышлау авылы кешесе Гарәбша Мөхәммәдша улы (1887–1961) Лотфулла хәзрәткә түбәндәгечә характеристика биргән: «Ул Лотфулла хәзрәт акыллы, зур белемле, гаять сүзгә тапкырлы, ышанычлы. Электән данлыклы нәселләрдән булганлыктан, алтмыш мәхәлләгә мөхтәсиб, ахун булып та үзенең сәламәтлек вакытларында хезмәт иткән. Соңгы гомерләрендә зәгыйфьләнеп, шушы Котаймас авылында үзе исән вакытында улы Габдулла хәзрәтне [үз] урынына имам кылып, вафат булып, үз авылыбызның зиратына дәфен кылынган (җирләнгән). Кабер шәрифендә бик һәйбәт итеп тарихи бөтен бабалары белән язылып куелган таш бар»[382].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 7 б. №56.

45. Мулла Габдулла мулла Лотфулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбрah
2) милади 1920 сәнә
3) март 2 һиҗри 1338 сәнә
4) җөмадиәл-үхра 13
5) мулла Габдулла бине мулла
6) Лотфулла мәдфүн
7) 42 йәшендә сиһшәнбә көн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Милади 1920 елның
3) 2 мартында, һиҗри 1338 елның
4) 13 җөмадиәл-ахирендә
5) мулла Габдулла бине мулла
6) Лотфулла
7) 42 яшендә сишәмбе көн җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 86х33х9.

Әлеге кабер иясенең ата-бабалары хакында мәгълүмат югарыда язылган иде. Ул 1902 елның 15 гыйнварыннан Кышлау авылының беренче мәхәлләсе мәчетендә имам-хатыйб һәм мөдәррис вазыйфаларын үтәгән, бу якларда беренчеләрдән булып җәдидчә укытуга күчкән.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 7 б. №57.

46. Хәлилулла Әмир улына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Хәлилулла
3) Әмир улы мәдфүн
4) милади 1903 сәнә

[379] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 66.
[380] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 338.
[381] Ислам на Урале: энциклопедический словарь / Сост. и отв. ред. Д.З. Хайретдинов. – М.: Издательский дом «Медина», 2009. – С. 347.
[382] Гарәбша Мөхәммәдша улының көндәлек дәфтәре. Шәхси кулларда саклана.

5) 31 нче ийүлдә
6) пәнҗешәнбә көн
7) 80 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Хәлилулла
3) Әмир улы
4) милади 1903 елның
5) 31 июлендә
6) пәнҗешәмбе көн
7) 80 яшендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 90(98)x32x11.

47. Габделвәли Габделгани улына куелган кабер ташы, 1884 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ
2) милади 1884 сәнә
3) 30 нчы нуйәбрдә мәрхүм Габделвәли
4) Габделгани углы дарел-фәнадан
5) дарел-бәкайә рихләт ителде
6) 40 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһның рәхмәтендә булсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ.
2) Милади 1884 елның
3) 30 ноябрендә мәрхүм Габделвәли
4) Габделгани улы 40 йәшендә
5) фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Аллаһның рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 80(88)x31x8.

48. Мөхәммәдгали Габделгани улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ
2) милади 1910 сәнә
3) 8 нче фибралда мәрхүм
4) Мөхәммәдгали Габделгани
5) углы дәфен ителде
6) 53 йәшендә
7) Аллаһның рәхмәтендә булсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ.
2) Милади 1910 елның
3) 8 февралендә мәрхүм
4) Мөхәммәдгали Габделгани
5) улы
6) 53 яшендә җирләнде.
7) Аллаһның рәхмәтендә булсын».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 82x31x9.

49. Хәбибуллага куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә
2) иләйһи рааҗигуун
3) Аллаһ Тәгалә рәхмәтенә
4) васыйл улса иде
5) Хәбибулла
6) ...».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1918 нче йылда
3) беренче фибрал 76
4) йәшендә дәфен
5) кылынды җәгаләллааһү
6) мәркадәһү раудатән мин рийәәдыйльҗәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.
3) Аллаһ Тәгалә рәхмәтенә
4) ирешсә иде.
5) Хәбибулла
6) ...».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1918 елның

3) беренче февралендә 76
4) яшендә
5) җирләнде. Аллаһ аның каберен
6) җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 60х34х14.

50. Бибинурания Габделкамал Габделхаликъ улының кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер сахибәсе
2) өч айлык кыз бала
3) Бибинурания Мамыш
4) карйәсе Габделкамал
5) Габделхаликъ углы
6) Фәтхуллин кызы
7) анасы Таййибә Хәбибулла
8) кызы 1912 нче
9) йылда 10 нчы гыйнварда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер иясе
2) өч айлык кыз бала
3) Бибинурания Мамыш
4) авылыннан Габделкамал
5) Габделхаликъ улы
6) Фәтхуллин кызы
7) (анасы – Тайиибә Хәбибулла
8) кызы) 1912
9) елның 10 гыйнварында [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 77х32х10.

51. Бибихәбибҗамал Насыйбулла кызына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми
3) 1894 сәнә ийүн 8 ндә
4) Бибихәбибҗамал Насыйбулла
5) кызы Төхфәтулла Габделкәрим
6) углының хәләле 72
7) йәшендә чәһаршәнбә көн»[383].

Уң ягы (уеп язылган): «Бу кабер хәлләрин сагышлайасыз безә Коръән укыб багышлайасыз».

Сул ягы (уеп язылган): «Дәфен иделде Аллаһ рәхмәт итсүн амин»[384].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади
3) 1894 елның 8 июнендә
4) Бибихәбибҗамал Насыйбулла
5) кызы – Төхфәтулла Габделкәрим
6) улының хәләле – 72
7) яшендә чәршәмбе көн».

Уң ягы: «Бу кабер хәлләренә сагышланыгыз, безгә Коръән укып багышлагыз».

Сул ягы: «Җирләнде. Аллаһ рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 103х34х17.

52. Зәйнәб Габдрахман кызына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Мамыш авылыйның Габдеррахман
3) Габделмәҗид углыйның
4) зәүҗәсе Зәйнәб Габдеррахман
5) кызы 1918 нче йылда 25 нче
6) нуйәбр 21 йәшендә вафат
7) нәүвәраллаһү кабраһ[385]».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗрииә илә 1339 нчы сәнә
2) рабигыль-әүвәл 10 нчы көне
3) җан тәслим әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Мамыш авылыннан Габдрахман
3) Габделмәҗид улының
4) хатыны – Зәйнәб Габдрахман
5) кызы – 1918 елның 25
6) ноябрендә 21 яшендә вафат.
7) Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән 1339 ел

[383] Дәвамы сул ягында.

[384] Башы алгы ягында.

[385] Ир затына карата кулланыла торган кушымча белән, ягъни хаталы язылган.

2) рабигыль-әүвәленең 10 нчы көнендә
3) җан тәслим кылды».

Таш үлчәмнәре: 94x30x10.

53. Мөхәммәдкасыйм Габделкадыйр улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[386]:
1) «Мөхәммәдкасыйм
2) Габделкадыйр
3) улы вафат
4) милади 1920 сәнә
5) дикәбр 24 ндә».

Сул ягы (уеп язылган): «23 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мөхәммәдкасыйм
2) Габделкадыйр
3) улы
4) милади 1920 елның
5) 24 декабрендә вафат».

Сул ягы: «23 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 89(100)x29x8.

54. Әбелхәер Әхмәдәбрар улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) Әбелхәйер Әхмәдәбрар
3) углы 1922 нче йылда
4) април 10 нчы көне 14 йәшендә
5) даре фәнадан даре бәкайә
6) рихләт әйләде нәүвәраллаahү кабраһ».

Арткы ягы (уеп язылган)[387]:
1) «Атасы Әхмәдәбрар
2) бина кылдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Әбелхәер Әхмәдәбрар
3) улы 1922 ел
4) апреленең 10 нчы көнендә 14 яшендә
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Арткы ягы:
1) «Атасы Әхмәдәбрар
2) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 84(96)x28x9.

55. Сәхибкамал Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1900 нче
2) сәнә
3) 20 нч
4) ийүлдә вафат
5) Сәхибкамал
6) Хәбибулла кызы».

Сул ягы (уеп язылган): «Би-рахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1318 нче
2) сәнә
3) 8 рабигыль-ахир
4) кырыкда вафат
5) Сәхибкамал
6) Сәмигулла
7) зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1900
2) елның
3) 20
4) июлендә
5) Сәхибкамал
6) Хәбибулла кызы вафат».

Сул ягы: «Синең рәхмәтең белән, я, Рәхимлеләрнең Иң Рәхимлесе».

Арткы ягы:
1) «[Һиҗри] 1318
2) елның
3) 8 рабигыль-ахирендә
4) кырыкта [40 яшендә]
5) Сәхибкамал
6) Сәмигулла
7) хатыны вафат».

Таш үлчәмнәре: 115x34x12.

[386] Өске өлешендә түгәрәк эчендә йолдыз рәсеме төшерелгән.
[387] Өске өлешендә ай, йолдыз һ.б. төрле рәсемнәр уелган.

56. Хөсәен Мөхәммәдшәриф улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Хөсәйен
3) Мөхәммәдшәриф
4) улы вафат
5) милади 1923 сәнә
6) гыйнвар 21 85 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Хөсәен
3) Мөхәммәдшәриф
4) улы
5) милади 1923 елның
6) 21 гыйнварында 85 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 100х31х9.

57. Фатыйма Әхмәҗән кызына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[388]:
1) «Фатыйма Әхмәд-
2) -җан кызы
3) румиййә 1925 сәнә
4) 2 нче агуст
5) 74 йәшендә
6) вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Фатыйма Әхмәд-
2) -җан кызы
3) милади 1925 елның
4) 2 августында
5) 74 яшендә
6) вафат».

Таш үлчәмнәре: 87(93)х29х7.

58. Фәизә Вәлиулла кызына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Фәизә Вәлийулла
3) кызы Вәлийулла
4) Гозәйер улының
5) зәүҗәсе вафат
6) милади 1916 сәнә
7) фиврал 12 75 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Фәизә Вәлиулла
3) кызы – Вәлиулла
4) Гозәер улының
5) хатыны –
6) милади 1916 елның
7) 12 февралендә 75 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 84х31х10.

59. Гафифәбану Гыйззәтулла кызына куелган кабер ташы, 1924 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Котаймас авылыйның
3) Гали зәүҗәсе
4) Гафифәбану бинте
5) Гыйззәтулла вафат
6) 1924 нче йыл
7) април 12 нче көне».

Арткы ягы (уеп язылган)[389]:
1) «Һиҗрииййә илә 1341 сәнә
2) рамазан 21 нче көне
3) җомга көн төнге сәгать
4) 3 дә җан тәслим
5) әйләдe Аллаһ иман
6) әһелендән әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Котаймас авылыннан
3) Гали хатыны –
4) Гафифәбану бинте
5) Гыйззәтулла –
6) 1924 ел
7) апреленең 12 нче көнендә вафат».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән 1341 ел
2) рамазанының 21 нче көнендә
3) җомга көн төнге сәгать
4) 3 тә җан тәслим
5) кылды. Аллаһ иман
6) әһеленнән итсен».

Таш үлчәмнәре: 105(114)х30х9.

[388] Өске өлешендә ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.

[389] Өске өлешендә ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.

60. Закир Мөхәммәдшәриф улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[390]:
1) «Һәзәә мәркадүл-мәрхүүми
2) Закир бине Мөхәммәдшәриф
3) румә илә 1913 нч
4) йылда дарел-фәнадан дар-
5) -ел-бәкайә рихләт әйләде».

Сул ягы (уеп язылган): «23 агуст».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу – мәрхүм
2) Закир бине Мөхәммәдшәриф кабере,
3) милади белән 1913
4) елда фани дөньядан мәңгелек
5) дөньяга күчте».

Сул ягы: «23 августта [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 71х31х7.

Әлеге кабер иясенең билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Закир бине Мөхәммәдшәриф бине Сабит бине Сәедкол бине Рахманкол бине Килмәмәт[391].

61. Сафиулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[392]:
1) «Аллаһ
2) миладиййә 1912 йылда
3) ийүл 20 Сафийулла
4) Һибатулла углы
5) даре фәнадан даре
6) бәкайә рихләт әйлә-
7) -де 76 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада кыйлыңыз йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ.
2) Милади 1912 елның
3) 20 июлендә Сафиулла
4) Һибатулла улы
5) 76 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек
7) дөньяга күчте».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Сул ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 99(106)х30х12.

62. Камилә Хәмидиулла кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[393]:
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Камилә Хәмидиулла
3) кызы Сибгатулла
4) Сафийулла улы-
5) -ның зәүҗәсе
6) милади 1904 сәнә
7) гыйнвар 20 33 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Камилә Хәмидиулла
3) кызы – Сибгатулла
4) Сафиулла улы-
5) -ның хатыны –
6) милади 1904 елның
7) 20 гыйнварында 33 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 89(101)х31х9.

63. Салиха Ибнеябин кызына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) румиййә 1900 йылда
3) агуст 9 да Салиха
4) Ибнейәбин кызы 75 йәшендә
5) Сафийулла Һибатулла углыйның
6) зәүҗәсе даре фәнадан
7) интикаль кыйлды».

[390] Өске өлешендә уелган бизәге бар.
[391] Фәйзрахманов Җ.Ә. Кышлау авылы тарихы. – Казан: Яз, 2017. – Б. 179–180.
[392] Өске өлешендә уелган бизәге бар.
[393] Өске өлешендә ай рәсеме уелган.

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәңа икән таңда сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Милади 1900 елның
3) 9 августында Салиха
4) Ибнеябин кызы –
5) Сафиулла Һибатулла улының
6) хатыны – 75 яшендә фани дөньядан
7) күчте».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миңа икән, таңда сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 101(114)х32х12.

64. Кәүсәрия Габделхак Габделкаюм улының кызына куелган кабер ташы, 1928 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күңәр авылыйның
2) Габделхак Габделкаййум
3) углының кызы Кәүсәрийә
4) 1928 нче сәнә 18 нче май
5) 3 йәшендә җан
6) тәслим әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Күңгәр авылыннан
2) Габделхак Габделкаюм
3) улының кызы Кәүсәрия
4) 1928 елның 18 маенда
5) 3 яшендә җан
6) тәслим кылды».

Таш үлчәмнәре: 86х32х11.

65. Гөлвафа Гыймадеддин кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә
2) бил-мәүти вәәгыйзаа
3) бу кабер сахибе Гөлва-
4) -фа Гыймадеддин кызы
5) Мөхәммәдшаһ Вәлид
6) углыйның җәүҗәсе
7) 1920 нче йылда 6 нчы
8) ийүлдә 64 йәшендә
9) бакый дөнйага күчде
10) Аллаһ рәхмәт әйләгәй
11) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Догаңыздан фәрамуш итмәңезләр».

Сул ягы (уеп язылган): «Баш өстемдән догасыз китмәңезләр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Углы Зариф
2) бина кыйлдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем
2) вәгазьче буларак җиткән.
3) Бу кабер иясе Гөлва-
4) -фа Гыймадеддин кызы –
5) Мөхәммәдша Вәлид
6) улының хатыны –
7) 1920 елның 6
8) июлендә 64 яшендә
9) бакый дөньяга күчте.
10) Аллаһ рәхим кылсын,
11) амин».

Уң ягы: «Догагызда [мине] истән чыгармагыз».

Сул ягы: «Баш өстемнән догасыз китмәгез».

Арткы ягы:
1) «Улы Зариф
2) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 84х27х9.

66. Мөхәммәдша Вәлид улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Котаймас авылының
4) Мөхәммәдшаһ бине
5) Вәлид 1906 нч
6) йылда 26 нчы апр-
7) -илдә 63 йәшендә
8) бакый дөнйага күч-

9) -чде Аллаһ има-
10) -н сахибе итсен
11) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу фәнаның гыйззе вә җаһы гыйшнуш пөр хыйал».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрмәдем бер гыйззәтен кем булмайа ахыр зәвал».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Углы Зариф
2) бина кыйлдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе
3) Котаймас авылыннан
4) Мөхәммәдша бине
5) Вәлид 1906
6) елның 26 апр-
7) -елендә 63 яшендә
8) бакый дөньяга кү-
9) -чте Аллаһ има-
10) -н әһеле итсен,
11) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу фанилыкның кадере һәм дәрәҗәсе – типтерү, хыял белән тулы».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрмәдем бер кадерен, ахырдан юкка чыгу булыр».

Арткы ягы:
1) «Улы Зариф
2) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 88х29х9.

67. Җәпи Котлымәт улына куелган кабер ташы, 1874 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) миладиййә 1874
3) нҗе йылда 1 нҗе
4) гыйнварда Җәпи
5) Котлымәт углы
6) йөз йәшендә даре
7) фәнадан даре бәкайә
8) рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога кыйлсаң безнидә куш догаңда».

Сул ягы (уеп язылган): «Ышаныч йук гомерең ахыры таңда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Милади 1874
3) елның 1
4) гыйнварында Җәпи
5) Котлымәт улы
6) йөз яшендә фани
7) дөньядан мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Уң ягы: «Дога кылсаң, безне дә куш догаңда».

Сул ягы: «Ышаныч юк: гомерең ахыры таңда».

Таш үлчәмнәре: 100(112)х31х11.

Мамыш авылы зираты

1. Сәгъдеддин Камаледдин улына куелган кабер ташы, 1929 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1929
2) йылда 5 нче
3) синтәбрдә
4) вафат
5) Сәгъдеддин
6) Камаледдин
7) углы».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1368
2) рабигыль-әүвәл
3) 3 нче
4) көндә 65 йәш
5) мәдфүн
6) фии йәүми
7) җүмгаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1929
2) елның 5
3) сентябрендә
4) Сәгъдеддин
5) Камаледдин
6) улы
7) вафат».

Арткы ягы:
1) «1368 [ел]
2) рабигыль-әүвәленең
3) 3 нче
4) көнендә 65 яшьтә
5) җомга
6) көн
7) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 95х30х8.

2. Галиәсгар Исмәгыйль улы Кулаковка куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Галиәсгар Исмәгыйль
4) углы Кулакыф
5) 1916 сәнәи миладиййә нуйәбр
6) 8 ндә 72 йәшендә
7) вафат итде рахимәллаахү
8) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[394].

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[395].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Галиәсгар Исмәгыйль
4) улы Кулаков
5) милади 1916 елның 8
6) ноябрендә 72 яшендә
7) вафат булды. Аллаһ киң рәхмәте
8) белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче».

Таш үлчәмнәре: 123(130)х35х13.

3. Маһисорур Габдрахман мөәзин кызына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) руми 1901 сәнә ийүл
3) 7 ндә Маһисорур Габдеррахман
4) мөәзин кызы Мамышның Гали-
5) -әсгар зәүҗәсе йәкшәнбә
6) көн мәдфүн улды».

Сул ягы (уеп язылган): «Рахимәһәәллаахү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1901 елның 7
3) июлендә Маһисорур Габдрахман
4) мөәзин кызы – Мамыштан Гали-
5) -әсгар хатыны – якшәмбе
6) көн җирләнде».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 106(114)х36х18.

4. Бибисәгадәтбану Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1888 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаахү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1888
3) сәнә ийүл 14 ндә Бибисәгадәт-
4) -бану Габденнасыйр кызы Мамышның
5) Галиәсгар Исмәгыйль углы-
6) -ның хәләле пәнҗешәнбә көн»[396].

Уң ягы (уеп язылган): «Мән таләбә гыйбратән фәл-мәкаабиратү тәкфиин».

Сул ягы (калкытып язылган): «Көн даре бәкайә рихләт кыйлды тайиибәллаахү сәраһәә»[397].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак». 1888
3) елның 14 июлендә Бибисәгадәт-

[394] Башы сул ягында.
[395] Дәвамы уң ягында.
[396] Дәвамы сул ягында.
[397] Башы алгы ягында.

4) -бану Габденнасыйр кызы – Мамыштан
5) Галиәсгар Исмәгыйль улы-
6) -ның хәләле пәнҗешәмбе көн».

Уң ягы: «Кем гыйбрәт сораса, аңа зират җиткән».

Сул ягы: «Мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Таш үлчәмнәре: 102(119)x36x17.

5. Хөснижамал Гайсә кызына куелган кабер ташы, 1874 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-
2) расүүлүллааһ салләәллааһү галәйһи вә сәлләм
3) румиййә илә 1874 нче сәнәдә 19 нчы
4) агустда
5) Хөснижамал бинте Гайсә вә зәүҗәи
6) Исмәгыйль 70 йәшендә
7) даре фәнадан даре бәкайә интикаль
8) әйләде
9) рахмәтүллааһи галәйһәә рахмәтән
10) вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга
2) лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе,
3) Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен.
4) Милади белән 1874 елның 19
5) августында
6) Хөснижамал бинте Гайсә – Исмәгыйль
7) хатыны – 70 яшендә
8) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.
9) Аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын,
10) амин».

Таш үлчәмнәре: 84x37x13.

6. Дамелла Габдрахман дамелла Вәлид улына куелган кабер ташы, 1870 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу кабер
2) дамелла Габдеррахман
3) дамелла Вәлид углы-
4) -ныңдур меңдә
5) сигез йөздә
6) йитмешенче сәнәдә
7) икенче гыйнварда
8) маһе рамазан-
9) -ел-мөбарәкдә алтмыш
10) өч йәшдә вафат
11) рахмәтүллааһи галәйһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер
2) дамелла Габдрахман
3) дамелла Вәлид улы-
4) -ныкыдыр, мең дә
5) сигез йөз дә
6) җитмешенче елның
7) икенче гыйнварында
8) мөбарәк рамазан
9) аенда алтмыш
10) өч яшьтә вафат.
11) Аңа Аллаһның рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 92x31x13.

Әлеге кабер иясе, 1847 елның 31 декабрендә указ алып, имам-хатыйб итеп билгеләнгән[398].

7. Габделхаликъ Госман улына куелган кабер ташы, 1856 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһил-Кәбиирил-
2) Мүтәгааль
3) түвүффийәл-мәрхүүмүл-мәгъфүүру
4) Габде-
5) -лхаликъ бине Госман галәйһиммәәр-
6) рахмәтү
7) вәр-ридъвәәнү фии сәнәти 1272 минәл-
8) һиҗриййәти
9) фии синни ситтәтин вә ситтиинә йәә
10) ихъвәәнии үнзуруу
11) иләә әхвәәлии бәкыйтү фәриидән вә
12) вәәхиидән хәәлиййән
13) ганит-таагаати вәс-садәкаати вәл-
14) хайраати
15) вә-ржүүл-йәүмә минкүмүд-дүгааъә фә-
16) иннәһү хайрун лии
17) минәд-дүнйәә вә мәә фииһәә фии
18) сәнәти 1856».

Уң ягы (калкытып язылган):
1) «Йәә вәәкыйфән фии кабрии
2) мүтәфәккиран би-әмрии бил-әмси күнтү
3) мислүкә гадән тәсыыйру мислии
4) ничә мәсҗед мәдарис кыйлды бина аңа
5) да кыйлмады вафа бу дөнйа».

[398] Татарстан Республикасының Милли архивы: 2 ф., 2 тасвир., 8 сак. берәм. – Б. 4 арты.

Сул ягы (калкытып язылган):

1) «Тарих румиййә илә 1856 сәнә mahe мөбарәк рамазан шәрифнең йегерме өченче көнендә

2) Габделхаликъ бине Госман алтмыш алты йәшендә даре бәкайә интикаль кыйлды гарикы рәхмәт улгай».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Хөкем Бөек, Югарыда булучы Аллаһта.

2) Рәхим кылынган, гафу ителгән Габде-

3) -лхаликъ бине Госман (аларның икесенә дә Аллаһның рәхмәте

4) һәм ризалыгы булсын) һиҗри 1272 елда

5) алтмыш алты яшендә вафат. Әй, кардәшләрем, минем [хәзерге] хәлемә

6) карагыз: Аллаһка буйсынуда, сәдака бирүдә, изгелек

7) кылуда бердәнбер идем,

8) бүген инде сездән дога көтәм. Чынлыкта, ул [дога] миңа дөньядан

9) һәм анда булган һәрнәрсәдән хәерлерәк. 1856 елда [вафат]».

Уң ягы:

1) «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың.

2) Ничә мәчет-мәдрәсәләр салды, аңа да бу дөнья тугры булмады».

Сул ягы:

1) «Милади белән 1856 ел мөбарәк рамазан шәрифенең егерме өченче көнендә

2) Габделхаликъ бине Госман алтмыш алты яшендә мәңгелек дөньяга күчте. Рәхмәткә күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 152x55x26.

8. Гайшәбану Мөхәммәдрәхим кызына куелган кабер ташы, 1878 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Саахибәтүл-мәркади Гайшәбану бинте Мөхәммәдрәхим

2) зәүҗәи Габделхаликъ һиҗрәте нәбәвиййәнең 1295 нче-

3) -дә mahe рабигыль-ахирнең 2 нче көне пәнҗешәнбә көн

4) вә һиҗрәте румиййә 1878 нчедә мартның 21

5) ндә 62 йәшдә имкәән ләә йәстәъхыйруунә сәәгатән вә ләә йәстәкъдимүүн

6) вәгъдәсе ирешүб иржигыый илләә раббикә раадыйәтәм-мәрдиййәһ әмеринә ита-

7) -гать идеб рухы пөр фөтухы калыб фаниларны видаг әйләб»[399].

Уң ягы (уеп язылган):

1) «Мән кәәнә таләбән вәәгыйзан

2) фәл-мәүтү кәфәә вә ләм мән йәкфииһ

3) һәзәә фәл-мәкаабиру тәкфииһ сүммә и-

4) -ләйнәә рааҗигуун раакыймүн әл-хәәҗҗү

5) Фәтхулла бине Галиәкбәр».

Сул ягы (уеп язылган):

1) «Тараф гыйләленә пәрваз

2) әйләде Хак Тәга[400] сәгый мәшкүр бәлигыны

3) вә мәркад шәрифене пөр нур әйләб

4) мөкаррәбән дәргяһ җөмлә-

5) -сендән әйләсен амин»[401].

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Кааләл-Хәййү-лләзии ләә йүмүүтү күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа

2) вәҗһү Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам йәә ибнү Әдәмин әнтүм-

3) -үл-йәүмә фиил-кусуури вә гадән фиил-кубүүри вә бәгъдә гадән

4) фиин-нүшүүр вә әммәә илләәл-хүүри вәл-кусуури

5) вә ләммәә илләәл-вәйли вәл-кубүүр вә мәәл-хәйәәт-

6) -үд-дүнйәә иллләә мәтәәгуль-гуруур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Кабер иясе Гайшәбану бинте Мөхәммәдрәхим –

2) Габделхаликъ хатыны – һиҗри 1295

3) [ел] рабигыль-ахиренең 2 нче көнендә пәнҗешәмбе көн,

4) милади 1878 [елның] 21 мартында

5) 62 яшьтә [әҗәл] «бер сәгать иртә килмәс һәм бер сәгатькә кичекмәс»

6) вәгъдәсе ирешеп, мөмкин булган «Аллаһтан риза булган хәлдә һәм Аллаһ синнән риза булган хәлдә Раббыңа кайт» әмеринә ита-

7) -гать итеп, рухы тулысынча ачылып, фани нәрсәләр белән саубуллашып».

Уң ягы:

1) «Кем вәгазьче сораса,

2) аңа үлем җиткән. Әгәр җитәрлек булмаса,

3) бу каберләр җитәр. Соңыннан Безгә

[399] Дәвамы сул ягында.

[400] «Тәгалә» сүзе шул рәвешле кыскартып язылган.

[401] Башы алгы ягында.

4) [Аллаһка] кайтачаксыз. Язучы: хаҗи
5) Фәтхулла бине Галиәкбәр».

Сул ягы:
1) «Сәбәп тарафына
2) очты. Хак Тәгалә мактаулы урынын
3) һәм хөрмәтле каберен нурга күмеп,
4) якын кешеләре җөмлә-
5) -сеннән итсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Тере, Үлмәүче [Аллаһ] әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә
2) фани, фәкать Раббыңның Олуглык һәм хөрмәт иясе булган йөзе генә калачак». Әй, адәм баласы, сез
3) бүген патша сарайларында, иртәгә каберләрдә булырсыз, аннан соң
4) яңадан терелерсез. Кайберәүләр хур кызларына һәм патша сарайларына,
5) кайберләрегез үкенечкә һәм каберләргә таба китәр. Дөнья тормышы
6) алданудан башка нәрсә түгел».

Таш үлчәмнәре: 95(136)x40x19.

9. Маһисорур Таһир кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) Маһисорур Таһир кызы Габделмәҗид Госманыф
3) зәүҗәсе 48 йәшендә даре бәкайә рихләт әйләде
4) 1325 сәнәи һиҗрииййә маһе шәгъбан-
5) -ның 8 нче йәүмендә миладиййә 1907 нче йылда
6) 3 нче синтәбрдә мәдфүнә улды
7) рахимәһәәллаһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Маһисорур Таһир кызы – Габделмәҗид Госманов
3) хатыны – 48 яшендә мәңгелек дөньяга күчте,
4) һиҗри 1325 ел шәгъбан
5) аеның 8 нче көнендә, милади 1907 елның
6) 3 сентябрендә җирләнде.
7) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 109x36x18.

10. Мортаза Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Мортаза Исмәгыйль
4) углыныңдур
5) 1913 нче сәнәдә
6) 21 нче ийүлдә
7) вафат улды рахимәһ-
8) -үллаһү рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер иясе
3) Мортаза Исмәгыйль
4) углыдыр,
5) 1913 елның
6) 21 июлендә
7) вафат булды. Аллаһ аны киң
8) рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 95x40x13.

11. Гарифә Мөхәммәдша кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү
2) лилләәһ ошбу кабер-
3) -станда дәфен
4) кылынды Әхмәдулла
5) мөәзин әһлийәсе Гарифә
6) Мөхәммәдшаһ кызы».

Уң ягы (уеп язылган): «Күн ли-дүнйәәкә кәъәннәһү тәгыыйшү әбәдәә».

Сул ягы (уеп язылган): «Вә күн ли-әәхыйратикә кәъәннәһү тәмүүтү гадәә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1910 нчы сәнә
3) 22 нче дикәбр-
4) -дә җомга көн
5) мәдфүндер».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем
2) Аллаһта. Бу кабер-
3) -станда
4) Әхмәдулла

5) мөәзин хатыны – Гарифә
6) Мөхәммәдша кызы – җирләнде».

Уң ягы: «Дөнья өчен булганда мәңге яшим кебек бул».

Сул ягы: «Ахирәт өчен булганда иртәгә үләсе кеше кебек бул».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1910 елның
3) 22 декабрен-
4) -дә җомга көн
5) җирләнгәндер».

Таш үлчәмнәре: 80(85)x33x12.

12. Бибимәгърифә Хисамеддин кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер Бибимәгърифә
3) Хисамеддин
4) кызыныңдур
5) Шакиржан Мөхәммәджан
6) углының зәүҗәсе
7) 1914 нче йылда 5 нче
8) синтәбрдә 65
9) йәшендә вафат
10) булды рахимәһ-
11) -үллаһү рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер Бибимәгърифә
3) Хисамеддин
4) кызыныкыдыр,
5) Шакиржан Мөхәммәджан
6) улының хатыны
7) 1914 елның 5
8) сентябрендә 65
9) яшендә вафат
10) булды. Аллаһ аны киң
11) рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 103x33x11.

13. Мөәзин Шакиржан Мөхәммәджан улына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) мөәзин Шакир-
3) -җан Мөхәммәджан
4) углы миладиййә
5) илә 1927 нче йыл
6) 27 нче мартда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих һиҗриййә
2) илә 1345 нче
3) йыл 6 нчы шәүвәл
4) җомга көн 83
5) йәшендә вафат
6) рахимәһүллаһү Тәгаалә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Мөәзин Шакир-
3) -җан Мөхәммәджан
4) улы милади
5) белән 1927 елның
6) 27 мартында [вафат]».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри
2) белән 1345
3) елның 6 шәүвәлендә
4) җомга көн 83
5) яшендә вафат.
6) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 73x30x12.

14. Мөәзин Әхмәдулла Халид улына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Мамыш карйә-
2) -сүндә мөәзин
3) хаҗҗел-хәрәмәйен Әхмәдулла
4) Халид углы румиййә
5) илә 1902 нче йыл
6) 7 нче фибралда 88
7) йәшендә даре бәкайә
8) рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «... әйләмеш».

Сул ягы (уеп язылган): «Китәрсен бу хәйә.. әййүһәән-нәәс».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мамыш авы-
2) -лында мөәзин
3) хаҗи Әхмәдулла
4) Халид улы милади

5) белән 1902 елның
6) 7 февралендә 88
7) яшендә мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Уң ягы: «... иткән».

Сул ягы: «Китәрсең бу.. әй, кешеләр».

Таш үлчәмнәре: 95х31х10.

15. Мөхәммәдвәли Мөхәммәджан улына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мөтәваффа Мөхәммәдвәли Мөхәммәджан
3) углы 1919 нчы сәнә дикәбр 20
4) нче көне һиҗриййә илә 1337
5) нче сәнә рабигыль-ахирдә
6) 64 йәшендә мәдфүн
7) нәүвәраллаһү кабраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Вафат булучы Мөхәммәдвәли Мөхәммәджан
3) улы 1919 ел декабренең 20
4) нче көнендә, һиҗри белән 1337
5) елның рабигыль-ахирендә
6) 64 яшендә җирләнде.
7) Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 90х28х11.

16. Мөгаллим Мөхәммәдсабир мулла Батырша улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мөгаллимес-сыйбйан Мөхәммәдсабир
3) мулла Батырша углы
4) 1918 нче сәнә 20 нче ийүндә
5) һиҗриййә илә 1336 нчы йылда
6) рамазан 30 нчы көнендә
7) 63 йәшендә мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Балалар мөгаллиме Мөхәммәдсабир
3) мулла Батырша улы
4) 1918 елның 20 июнендә,
5) һиҗри белән 1336 ел
6) рамазанының 30 нчы көнендә
7) 63 яшендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 92х30х10.

17. Зарифә Бикмөхәммәд кызына куелган кабер ташы, 1935 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Зарифә Бикмөхәммәд
3) кызы 75 йәшендә
4) рамазан 17 сендә дүшәнбә көн
5) 1355 сәнә руми
6) 1935 нче йыл гыйнвар мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Зарифә Бикмөхәммәд
3) кызы 75 яшендә
4) [һиҗри] 1355 елның
5) 17 рамазанында дүшәмбе көн, милади
6) 1935 елның гыйнварында җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 57(68)х31х8.

18. Сибгатулла Фәтхулла улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) Сибгатулла Фәтхулла
3) углы 1922 нче йылда
4) 58 йәшендә даре
5) фәнадан даре бәкайә
6) рихләт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Сибгатулла Фәтхулла
3) улы 1922 елда
4) 58 яшендә фани
5) дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте».

Таш үлчәмнәре: 80(93)х31х12.

19. Фәрхенур Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Вә сәәригуу иләә мәгъфиратим-мир-раббикүм вә җәннәтин гардуһәәс-сәмәәвәәтү
2) вәл-әрду үгыйддәт лил-мүттәкыыйн
3) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
4) ошбу мәкъбәр[ә]дә Мамыш
5) карйәсенең Фәрхенур
6) Фәтхулла кызы».

Уң ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә илләәллаah Мүхәммәдүр-расүүлүллаah».

Сул ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә илләәллаah Мүхәммәдүр-расүүлүллаah».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Милади 1925 сәнә
2) һиҗри 1343 нче сәнә 20
3) шәүвәл чәһаршәнбә көн май
4) бердә Фәрхенур Фәтхулла кызы
5) Габделмәҗид бине Фәтхулла зәүҗәсе
6) 70 йәшендә мәдфүн ачык йөзле
7) холыклы сабыр ана иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) ««Раббыгызның ярлыкавына һәм җир, күкләр киңлегендә булган җәннәткә
2) ашыгыгыз. Ул җәннәтләр Аллаһтан куркучыларга әзерләнде».
3) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
4) Бу каберлектә Мамыш
5) авылыннан Фәрхенур
6) Фәтхулла кызы [җирләнде]».

Уң ягы: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Сул ягы: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Арткы ягы:
1) «Милади 1925 елның беренче
2) маенда, һиҗри 1343 елның 20
3) шәүвәлендә чәршәмбе көн
4) Фәрхенур Фәтхулла кызы –
5) Габделмәҗид бине Фәтхулла хатыны –
6) 70 яшендә җирләнде. Ачык йөзле,
7) холыклы, сабыр ана иде».

Таш үлчәмнәре: 75x35x15.

20. Хәерниса Сәгыйдь кызына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-Хәйй
2) Хәйренниса бинте
3) Сәгыйдь 1921 сәнә
4) 22 нче мартда
5) 75 йәшендә
6) даре фәнадан
7) даре бәкайә рихләт
8) әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Тере.
2) Хәерниса бинте
3) Сәгыйдь 1921 елның
4) 22 мартында
5) 75 яшендә
6) фани дөньядан
7) мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Таш үлчәмнәре: 102x30x9.

21. Сәфәргали Хөсәен улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбраһ
2) Сәфәргали бине
3) Хөсәйен 1920 сәнә
4) май 2 ндә 48 йәшендә
5) даре фәнадан
6) даре бәкайә рихләт
7) әйләде Аллаһ
8) рахимәһү вә гафәраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Сәфәргали бине
3) Хөсәен 1920 елның
4) 2 маенда 48 яшендә
5) фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ
8) аны рәхим кылсын һәм гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 109x31x9.

22. Бәйрәмгали Хөсәен улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер ийәсе
3) Бәйрәмгали
4) Хөсәйен углы-
5) -ныңдур 1907
6) нче йылда дикәбр-
7) -нең 15 нче көн
8) вафат булды
9) 34 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабер иясе
3) Бәйрәмгали
4) Хөсәен улы-
5) -дыр, 1907
6) ел декабре-
7) -нең 15 нче көнендә
8) 34 йәшендә
9) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 101x35x18.

23. Ибраһим Габдерәхим улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) тарих румиййә 1905 нче
3) 7 нче ийүндә сәнәи
4) һиҗриййә 1323
5) маһе рабигыль-ахир 7 нче
6) Ибраһим Габдеррәхим
7) углы сиһшәнбә көн
8) вафат әйләде
9) 78 йәшендә Аллаһ
10) рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Милади 1905 [елның]
3) 7 июнендә, һиҗри
4) 1323 елның
5) 7 рабигыль-ахирендә
6) Ибраһим Габдерәхим
7) улы сишәмбе көн
8) 78 йәшендә
9) вафат булды. Аллаһ
10) рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 117x36x14.

24. Әүхәди Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер Әүхәди
3) Ибраһим углы-
4) -ныңдур 1906
5) нчы йылда үктәбр 12
6) нче көнендә рамазан
7) 6 нда 39 йәшдә
8) йәүмел-хамис вафат
9) әйләде Аллаһ рәхмәте
10) гарикъ әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер Әүхәди
3) Ибраһим улы-
4) -ныкыдыр, 1906
5) ел октябренең 12
6) нче көнендә, 6 рамазанында
7) 39 яшьтә
8) пәнҗешәнбе вафат
9) булды. Аллаһ рәхмәткә
10) күмсен».

Таш үлчәмнәре: 98x35x13.

25. Бибифәсәхәт Хөсәен кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер Бибифәсәхәт
3) Хөсәйен кызы Габд-
4) -елгазиз Габделвәли
5) углының зәүҗәсе
6) 1906 нчы йылда 17 нче
7) үктәбрдә маһе рамазан
8) 13 нче көнендә 26
9) йәшдә вафат
10) Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер Бибифәсәхәт
3) Хөсәен кызы – Габд-

4) -елгазиз Габделвәли
5) улының хатыныкы,
6) 1906 елның 17
7) октябрендә, рамазанның
8) 13 нче көнендә 26
9) яшьтә вафат.
10) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 100х36х13.

26. Гайшә Габделхаликъ кызына һәм Фатыйма Фазылҗан кызына куелган кабер ташы, 1905 һәм 1909 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1905 нче йылда
2) 19 нчы агустда Фазыл-
3) -җан җәмәгате Гайшә
4) Габделхаликъ кызы 23
5) йәшендә ошбу каберста-
6) -нда дәфен кыйлынды».

Уң ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Әл-кабру раудатүн мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1909 нчы йылда
2) 4 нче синтәбрдә
3) Фатыйма Фазылҗан
4) кызы 2 йәшендә вафат
5) улуб ошбу кабер-
6) -станда дәфен кыйлынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1905 елның
2) 19 августында Фазыл-
3) -җан җәмәгате – Гайшә
4) Габделхаликъ кызы – 23
5) яшендә бу каберста-
6) -нда җирләнде».

Уң ягы: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Сул ягы: «Кабер – җәннәт бакчаларыннан бер бакча».

Арткы ягы:
1) «1909 елның
2) 4 сентябрендә
3) Фатыйма Фазылҗан
4) кызы, 2 яшендә вафат
5) булып, бу кабер-
6) -станда җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 84х36х13.

27. Мөхибҗамал Сәлимҗан кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер Мөхибҗамал
3) Сәлимҗан кызыныңдыр
4) Фәтхулла Халид углы зәүҗәсе
5) 1915 нче йылда 23 нче агусда
6) тарих һиҗриййә илә 1333 сәнәдә
7) маһе шәүвәл 20 ндә 77 нче
8) йәшендә вафат
9) нәүвәраллааһү кабраһ[402]«.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер Мөхибҗамал
3) Сәлимҗан кызыныкыдыр,
4) Фәтхулла Халид улының хатыны
5) 1915 елның 23 августында,
6) һиҗри белән 1333 елның
7) 20 шәүвәлендә 77 нче
8) яшендә вафат.
9) Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 94х33х9.

28. Габделвәли Габдрахман улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү
2) Тәгааләә күллү нәфсиң
3) зәәъикатүл-мәүүт
4) бу кабер Габделвә-
5) -ли Габдеррахман
6) углының ва-
7) -фат булды
8) 71 йәшендә
9) 1331 нҗе һиҗриййә».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмиин йәә Раббәл-гааләмиин».

Сул ягы (уеп язылган): «1913 нҗе сәнәдә 2 нҗе ийүлдә».

[402] Бу гарәп телендәге җөмлә ир-атка карата кулланыла торган кушымчалар белән язылган.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә
2) әйтте: «Һәр җан иясе
3) үлемне татыячак».
4) Бу кабер Габделвә-
5) -ли Габдрахман
6) улыныкы,
7) 71 яшендә
8) һиҗри 1331 [елда]
9) вафат булды».

Уң ягы: «Амин, йә, Галәмнәрнең Хуҗасы».

Сул ягы: «1913 елның 2 июлендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 103х32х12.

29. Гыйльмелбаян Габделкәбир кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер Гыйльмелбайан
3) Габделкәбир кызы
4) Тажеддин Габделвәли
5) углының зәүҗә-
6) -се 1903 нче йылда
7) 6 нчы синтәбрдә
8) 44 йәшендә
9) вафат булды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабер Гыйльмелбаян
3) Габделкәбир кызы –
4) Тажеддин Габделвәли
5) улының хаты-
6) -ны 1903 елның
7) 6 сентябрендә
8) 44 яшендә
9) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 84х31х13.

30. Бибизөһрә Габделгафур кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер Бибизөһрә
3) Габделгафур кызы
4) Габделкәбир Баттал
5) углының зәүҗә-
6) -се 1903 нче йылда
7) 29 нчы март вафат
8) булды 73 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабер Бибизөһрә
3) Габделгафур кызы
4) Габделкәбир Баттал
5) улының хаты-
6) -ны 1903 елның
7) 29 мартында 73 яшендә
8) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 84х31х13.

31. Бибиәсма Насыйбулла кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ руми 1899 сәнә
2) ийүндә һиҗри 1317 сәнә
3) Мамыш карйәсендә Бибиәсма
4) Насыйбулла кызы Габделвәли
5) Габдеррахман углы зәүҗәсе
6) 55 йәшдә даре бәкайә рихләт кылды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер Бибиәсма Насыйбулла
2) кызының мәркадедер».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта. Милади 1899 елның
2) июнендә, һиҗри 1317 елда
3) Мамыш авылында Бибиәсма
4) Насыйбулла кызы – Габделвәли
5) Габдрахман улының хатыны –
6) 55 яшьтә мәңгелек дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Бу Бибиәсма Насыйбулла
2) кызының кабередер».

Таш үлчәмнәре: 95х35х10.

32. Хөсәен Вилдан улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) тарих румиййә илә 1899
3) сәнә гыйнвар һәм маһе шәриф
4) 15 ндә Хөсәйен Вилдан углы
5) җомга көн дарел-бәкайә

6) интикаль әйләде
7) 58 йәшдә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Әд-дүнйәә сәәгатүн фәҗгальһәә таагаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ Тәгалә гарикы рәхмәт идүб җайын җәннәт кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади белән 1899
3) елның гыйнварында, 15
4) рамазанында Хөсәен Вилдан улы
5) җомга көн мәңгелек дөньяга
6) күчте,
7) 58 яшьтә вафат».

Уң ягы: «Дөнья бер сәгатьлек, аны [Аллаһка] итагать белән үткәр».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә, рәхмәткә күмеп, урынын җәннәт итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 114(140)х36х18.

33. Шәмсекамәр Ибраһим кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру раудатүн мин рийәәдыйль-җәннәти әү хүфратүн мин хүфәрин-нәйраан
2) би-хүкми Хода мәдфүнә
3) Шәрәфеддин җәмә-
4) -гате Шәмсекамәр
5) Ибраһим кызы
6) 53 нче йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Вә гаҗҗилүү бит-тәүбәти кабләл-мәүүт».

Сул ягы (уеп язылган): «Гаҗҗилүү бис-саләәти кабләл-фәүүт».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1902 нче йылда
3) 26 нчы ийүлдә
4) 1320 нче йылда
5) һиҗриййә илә 23 нче
6) рабигыль-ахирдә
7) мүүтүү каблә ән тәмүүтүү».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – җәннәт бакчаларыннан бер бакча яки җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр.
2) Хода хөкеме белән.
3) Шәрәфеддин җәмә-
4) -гате – Шәмсекамәр
5) Ибраһим кызы –
6) 53 нче яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Үлем килгәнче тәүбә итәргә ашыгыгыз».

Сул ягы: «Вакыты чыкканчы намазны укырга ашыгыгыз».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1902 елның
3) 26 июлендә,
4) һиҗри белән
5) 1320 елның 23
6) рабигыль-ахирендә [җирләнде].
7) Вафат булганчы ук үлегез».

Таш үлчәмнәре: 112(136)х35х18.

34. Маһишәрәф Габделмәҗид кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ 1899 сәнә
2) майда һиҗри 1317 сәнә
3) Маһишәрәф Габделмәҗид
4) кызы 8 йәшдә чәчәк
5) илә даре бәкайә рихләт
6) кылды тайййибәллааһү сәрааһәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән. 1899 елның
2) маенда, һиҗри 1317 елда
3) Маһишәрәф Габделмәҗид
4) кызы 8 яшьтә чәчәк [авыруы]
5) белән мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 85х32х12.

35. Габдулла Габделмәҗид улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ руми

2) 1899 сәнә майда һиҗри
3) 1317 сәнә Габдулла
4) Габделмәҗид углы
5) 10 йәшдә даре бәкайә
6) рихләт кылды таййибәллаahү сәраah».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh хөкеме белән. Милади
2) 1899 елның маенда, һиҗри
3) 1317 елда Габдулла
4) Габделмәҗид улы
5) 10 яшьтә мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаh аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Таш үлчәмнәре: 88x31x10.

36. Габделхак Габдрахман улы Хәмзингә куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәh
2) бу кабер сахибе Йаңа
3) Кишет карйәсе
4) Габделхак Габдеррахман
5) углы Хәмзин 1907
6) нче йылд 2 нче априлд
7) 2 нче йәшдә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаh әмере белән.
2) Бу кабер иясе Яңа
3) Кишет авылыннан
4) Габделхак Габдрахман
5) улы Хәмзин 1907
6) елның 2 апрелендә
7) 2 нче яшьтә вафат».

Таш үлчәмнәре: 75x36x14.

37. Бибимаһиҗиһан Габделмәҗид кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа руми
2) 1902 сәнә ийүлдә һиҗри 1319
3) Бибимаһиҗиһан Габделмәҗид
4) кызы 8 йәшдә
5) даре бәкайә рихләт кылды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән. Милади
2) 1902 елның июлендә, һиҗри 1319 [елда]
3) Бибимаһиҗиһан Габделмәҗид
4) кызы 8 яшьтә
5) мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 70x31x12.

38. Бибиәсхабҗамал Бикмөхәммәд кызына куелган кабер ташы, 1883 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү нәфсиң зәәъикат-
2) -үл-мәүүт румиййә илә 1883
3) сәнә дикәбр 2 ндә Бибиәсхаб-
4) -җамал Бикмөхәммәд кызы Мамышның
5) Ибраһим хәләле 55
6) йәшендә шинбә көн даре бәкайә
7) рихләт кыйлды».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәңа икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаh Тәгалә гарикы рәхмәт кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә әйтте: һәр җан иясе үлемне
2) татыячак. Милади белән 1883
3) елның 2 декабрендә Бибиәсхаб-
4) -җамал Бикмөхәммәд кызы – Мамыштан
5) Ибраһим хәләле – 55
6) яшендә шимбә көн мәңгелек дөньяга
7) күчте».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Аллаh Тәгалә рәхмәткә күмсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 114(133)x35x18.

39. Габделкәбир Җәлал улына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Габделкәбир Җәлал
4) углыныңдур
5) 1889 нчы йылда
6) 20 нче ийүлдә
7) 60 йәшендә
8) вафат булды
9) Аллаһ рәхмәт
10) әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер иясе
3) Габделкәбир Җәлал
4) улыдыр,
5) 1889 елның
6) 20 июлендә
7) 60 яшендә
8) вафат булды.
9) Аллаһ рәхим
10) кылсын».

Таш үлчәмнәре: 97х33х10.

40. Ильяс улына куелган кабер ташы, 1820–1821 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Саахиибү һәзәл-кабриш-шәриифи Симинең
2) тәәрииху һиҗрин-нәбиййи галәйһис-сәләәм меңдә
3) ике йөздә утуз алтынчы йылда...
4) икенче йәүмендә йитмеш йәшендә...
5) Илйас углы даре фәнадин даре бәкайә
6) интикаль кылытды гарикы рәхмәт улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу хөрмәтле кабер иясе Симидән [Семипалатинск шәһәреннән]
2) пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) һиҗрәте белән мең дә
3) ике йөз дә утыз алтынчы елның...
4) икенче көнендә җитмеш яшендә...
5) Ильяс улы фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Рәхмәткә күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 90х42х23.

41. Мулла Мирсәлим Ильяс улына куелган кабер ташы, 1819 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) румиййә илә тарих 1819 сәнә
3) мулла Мирсәлим Илйас углы
4) 80 йәшдә вафат улды
5) Симидән килүб гарикы
6) рәхмәт улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән
2) милади белән 1819 елда
3) мулла Мирсәлим Ильяс улы,
4) Симидән [Семипалатинск шәһәреннән] килеп,
5) 80 яшьтә вафат булды. Рәхмәткә
6) күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 86х21х19.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 7 б. №58.

42. Фәтхулла Халид улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) румиййә 1905 нче
3) 28 нче фибралда
4) һиҗриййә 1323
5) 7 нче мөхәррәм Фәтхулла
6) Халид углы
7) 85 йәшдә дар-
8) -ел-бәкага һиҗрәт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәтә гарикъ әйләсүн».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү кабраһү иләә йәүмил-кыйәәмәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) румиййә 1905 нче
3) фибрал 28 дә
4) һиҗриййә 1323
5) 7 нче мөхәррәм Фәтхулла
6) Халид углы

7) 85 йәшдә дар-
8) -ел-бәкага һиҗрәт әйләде
9) дүшәнбә мәдфүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Милади 1905 [елның]
3) 28 февралендә,
4) һиҗри 1323 [елның]
5) 7 мөхәррәмендә Фәтхулла
6) Халид улы
7) 85 яшьтә мәңгелек
8) дөньяга күчте».

Уң ягы: «Аллаһ рәхмәткә күмсен».

Сул ягы: «Нәүвәраллааһү кабраһү иләә йәүмил-кыйәәмәһ».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән
2) Милади 1905 [елның]
3) 28 февралендә,
4) һиҗри 1323 [елның]
5) 7 мөхәррәмендә Фәтхулла
6) Халид улы
7) 85 яшьтә мәңгелек
8) дөньяга күчте,
9) дүшәмбе җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 89x31x14.

43. Гыйззениса Муса кызына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһил-галиййил-кәбиир руми
2) 1891 сәнә май 25 ндә һиҗри 1308
3) сәнә шәүвәл 30 нда Гыйззенниса Муса кызы
4) Фәтхулла Халид углының зәүҗә-
5) -се 67 йәшдә даре бәкайә рихләт кылды».

Арткы ягы (уеп язылган): «Бу ләүхне углы Габделмәҗид бина кылдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Олуг, Бөек Аллаһта. Милади
2) 1891 елның 25 маенда, һиҗри 1308
3) елның 30 шәүвәлендә Гыйззениса Муса кызы –
4) Фәтхулла Халид улының хаты-
5) -ны – 67 яшьтә мәңгелек дөньяга күчте».

Арткы ягы: «Бу ташны улы Габделмәҗид куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 76x32x21.

44. Хәнифә Баязид хатынына куелган кабер ташы, 1835 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәл-хәййүлләзи ләә йәмүүт
2) кәфәә бил-мәүтии вәәгыйзаа
3) тарих румиййә меңдә сигез йөз утуз
4) бишенче йылда маһе рәҗәбнең сигезенче йәүмендә
5) 80 йәшдә Байазид хәләле Хәнифә иҗәәбәтү дәәгыйә-
6) -р-рахмәти вәр-ридъвәәни идүб рихләт вә рөжу-
7) -г итде нәүвәраллааһү Тәгаалә мәркадәһәә».

Сул ягы (калкытып язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии бил-әмси күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Тере, Үлмәүче.
2) Үлем вәгазьче буларак җиткән.
3) Милади мең дә сигез йөз утыз
4) бишенче ел рәҗәб аеның сигезенче көнендә
5) 80 яшьтә Баязид хәләле Хәнифә, Аллаһның рәхмәтен
6) һәм ризалыгын өмет итеп, [Раббысына]
7) кайтты. Аллаһ Тәгалә аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 97x41x20.

45. Госман Габдулла улына һәм Миһербан мулла Йосыф кызына куелган кабер ташы, 1809 һәм 1838 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) румиййә илә тарих 1809 сәнә-
3) -дә вафат улмышдур Госман

4) Габдулла углы гарикы
5) рәхмәт улсун
6) амин».

Сул ягы (калкытып язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран би-әмрии бил-әмси күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) румиййә илә тарих 1838 сәнәдә
3) нуйәбрдә зәүҗәи Госман
4) Миһербан бинте мулла Йосыф 82
5) йәшендә вафат улды гарикы
6) рәхмәт улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади белән 1809 ел-
3) -да Госман Габдулла улы
4) вафат булгандыр. Рәхмәткә
5) күмелсен,
6) амин».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади белән 1838 елның
3) ноябрендә Госман хатыны –
4) Миһербан бинте мулла Йосыф – 82
5) яшендә вафат булды. Рәхмәткә
6) күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 92(130)x39x19.

Авыл картлары сөйләвенчә, Мамыш авылына Шашыдан килгән 5 кеше нигез салган: Иманкол, Габделхак, Кулак, Фәтхулла һәм әлеге кабер иясе Госман.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 7 б. №59.

46. Исмәгыйль Мөхәммәдрәхим улына куелган кабер ташы, 1852 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә иллээллаah Мүхәммәдүр-расүүлүллаah салләәллаahү галәйhи вә сәлләм
2) румиййә илә 1852 нчедә гыйнварның 19 нда
3) Исмәгыйль ибне Мөхәммәдрәхим 68 йәшендә даре
4) фәнадан мөлке бәкайә интикаль әйләде
5) рахмәтүллаahи галәйhи рахмәтән вәәсигаh әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаhтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаhның илчесе, Аллаh аны олыласын һәм сәламләсен.
2) Милади белән 1852 [елның] 19 гыйнварында
3) Исмәгыйль ибне Мөхәммәдрәхим 68 яшендә фани
4) дөньядан мәңгелек патшалыкка күчте.
5) Аңа Аллаhның киң рәхмәте булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 75x35x18.

47. Баязид мулла Рәхмәтулла улына куелган кабер ташы, 1828 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәл-хәййүлләзи ләә йәмүүт
2) кәфәә бил-мәүтии вәәгыйзаа
3) тарих румиййә меңдә сигез йөз йегерме
4) сигезенче йыл маһе мөбарәк рамазанның 29 нчы
5) йәүмендә Байазид мулла Рәхмәтулла углы иҗәәбәтү
6) дәәгыйәр-рахмәти вәр-ридъвәәни идүб рихләт вә рөжуг
7) итдe нәүвәраллаahү мәркадәhү вә әдхалә фии рахмәтиһ».

Сул ягы (калкытып язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии бил-әмси күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаh] – Тере, Үлмәүче.
2) Үлем вәгазьче буларак җиткән.
3) Милади мең дә сигез йөз егерме
4) сигезенче ел мөбарәк рамазанының 29 нчы
5) көнендә Баязид мулла Рәхмәтулла улы, Аллаhның рәхмәтен
6) һәм ризалыгын өмет итеп, [Раббысына]
7) кайтты. Аллаh аның каберен нурландырсын һәм Үзенең рәхмәте астына кертсен».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Авыл картлары сөйләвенчә, әлеге кабер иясе авылга мәчет салдырган. Риваятьләргә караганда, аның атасы Рәхмәтулла 1773 елда Мамыш авылына нигез салган, ул килгәнче, бу урын аюлар, төлкеләр һәм бүреләр оясы булган[403].

Таш үлчәмнәре: 124х42х20.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 7 б. №60.

48. Бибизәлифә Ягъкуб кызына куелган кабер ташы, 1842 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәл-хәййүлләзи ләә йәмүүт
2) кәфәә бил-мәүтии вәәгыйзаа
3) тарих румиййә меңдә сигез йөз
4) кырык икенче йылда ийүлнең 23 нче
5) йәүмендә Галиәсгар Байазид углының
6) хәләле Бибизәлифә Йагкуб кызы иҗәәбәтү дәәгыйә-
7) -р-рахмәти вәр-ридъвәәни идүб рихләт
8) вә рөжуг итдe нәүвәраллаһү Тәгаалә мәркадәһәә».

Сул ягы (калкытып язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии бил-әмси күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Тере, Үлмәүче.
2) Үлем вәгазьче буларак җиткән.
3) Милади мең дә сигез йөз
4) кырык икенче ел июленең 23 нче
5) көнендә Галиәсгар Баязид улының
6) хәләле – Бибизәлифә Ягъкуб кызы – Аллаһның рәхмәтен
7) һәм ризалыгын өмет итеп, [Раббысына]
8) кайтты. Аллаһ Тәгалә аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 134х39х18.

49. Галиәсгар Баязид улы Иманколыйга куелган кабер ташы, 1874 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ салләәллааһү галәйһи вә сәлләм
2) румиййә илә 1874 нче сәнәдә дикәбрнең 26 сында
3) хаҗҗел-хәрәмәйен Галиәсгар бине Байазид әл-мәрхүм
4) әл-Иманколый 85 йәшендә даре фәнадан мөлке
5) бәкайә интикаль әйләде рахмәтүллааһи галәйһи рахмәтән
6) вәәсигаһ әәмиин би-хүрмәти сәййидил-мүрсәлиин».

Уң ягы (уеп язылган[404]):
1) «Кәрәм әйләб догада идеңез йад
2) тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган[405]):
1) «Бу кабер хәлләрин сагышлайасыз
2) безә Коръән укыб багышлайасыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе, Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен.
2) Милади белән 1874 елның 26 декабрендә
3) хаҗи Галиәсгар бине Баязид мәрхүм
4) Иманколый 85 яшендә фани дөньядан мәңгелек
5) патшалыкка күчте. Аңа Аллаһның киң рәхмәте
6) булсын, амин. Пәйгамбәрләр башлыгы [Мөхәммәд] хөрмәте өчен».

Уң ягы:
1) «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз,
2) сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы:
1) «Бу кабер хәлләренә сагышланыгыз,
2) безгә Коръән укып багышлагыз».

Таш үлчәмнәре: 94х39х17.

[403] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 3 һәм 4 томнар. – Казан: Рухият, 2010. – Б. 98.

[404] Диагональ буенча язылган.
[405] Диагональ буенча язылган.

50. Габделлатыйф Галиәсгар улы Иманколыйга куелган кабер ташы, 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибүл-мәркади
2) Габделлатыйф бине
3) Галиәсгар Иманколый
4) 34 нҗе йәшенд 1300 сәнә
5) һиҗрииййәдә шәһре шәүвәл 5 ндә
6) 1882 сәнә румииййә агуст 18 ндә
7) дәфен иделде нәүвәр-
8) -аллаһү мәркадәһү вә җәгаләллаһү
9) раудатән мин рийәәд-
10) -ыйль-җәннәһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган[406]):
1) «Рахимәһүллаһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ
2) кәтәбәһү Мулла илендә
3) мөәззин Фәтхелкадыйр».

Сул ягы (уеп язылган): «Ихване мөслиминдән рух шәрифләринә бер фатиха укымакларыны рәҗа идәмез».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер иясе
2) Габделлатыйф бине
3) Галиәсгар Иманколый
4) 34 нче яшендә һиҗри 1300
5) елның 5 шәүвәлендә,
6) милади 1882 елның 18 августында
7) җирләнде. Аллаһ аның
8) каберен нурландырсын һәм җәннәт
9) бакчаларыннан бер бакча
10) итсен, амин».

Уң ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын.
2) Моны язды: Мулла иленнән
3) мөәзин Фәтхелкадыйр».

Сул ягы: «Мөселман кардәшләрдән рух шәрифләренә бер «Фатиха» [сүрәсе] укуларын өмет итәбез».

Таш үлчәмнәре: 99(115)х35х21.

51. Мөхәммәдшакир Галиәкбәр улы Иманколовка куелган кабер ташы, 1875 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Ләә иләәһә иллээллаһ Мүхәммәдүр-
расүүлүллаһ салләәллаһү галәйһи вә сәлләм
2) румииййә илә 1875 нче йылда априлнең 26 сында
3) Мөхәммәдшакир Галиәкбәр углы Иманколыф 34 йәшендә
4) даре фәнадан даре бәкайә рихләт кылды гарикы
5) рәхмәт әйләгәй иде амин йәә раббәл-гааләмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу кабер хәлләрин сагышлайасыз безә Коръән укыб багышлайасыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе, Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен.
2) Милади белән 1875 елның 26 апрелендә
3) Мөхәммәдшакир Галиәкбәр улы Иманколов 34 яшендә
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Рәхмәткә
5) күмсә иде, амин, йә, Галәмнәрнең Хуҗасы».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Бу кабер хәлләренә сагышланыгыз, безгә Коръән укып багышлагыз».

Таш үлчәмнәре: 96х39х13.

52. Бибихәдичә Мәхмүд кызына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүтии вәәгыйзаа
2) тарих румииййә илә 1894 сәнә
3) гыйнвар 25 ндә Мамыш авылының
4) хаҗҗел-хәрәмәйен Галиәсгар Байазид
5) углының зәүҗәсе Бибихәдиҗә Мәхмүд

[406] Беренче юлы вертикаль, калганнары горизонталь рәвештә язылган.

6) кызы 84 йәшдә сиһшәнбә»[407].

Уң ягы (калкытып язылган): «Һиҗриййә илә 1311 сәнә маһе шәгъбан беренче йәүмендә».

Сул ягы (калкытып язылган): «Көн даре бәкайә рихләт кыйлды таййибәллаһү сәраһәә»[408].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб догада идеңез йад
2) тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади белән 1894 елның
3) 25 гыйнварында Мамыш авылыннан
4) хаҗи Галиәсгар Баязид
5) улының хатыны – Бибихәдичә Мәхмүд
6) кызы – 84 яшьтә сишәмбе».

Уң ягы: «Һиҗри белән 1311 ел шәгъбан аеның беренче көнендә [вафат]».

Сул ягы: «Көн мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз,
2) сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 91x36x17.

53. Бибимаһиҗиһан Әхмәделәбрар кызына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаләә күллү
2) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт тарих
3) румиййә илә 1895 сәнә март
4) 19 нда Мамыш карйәсенең Маһи-
5) -җиһан Әхмәделәбрар кызы
6) Габдулла Мөхәммәҗән углының
7) хәлиләсе 30 йәшдә шинбә көн»[409].

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (уеп язылган): «Иржигыый хитабына иҗабәт әйләб йәкшәнбә көн мәдфүн улды»[410].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтү һәзәәл-кабри Бибимаһиҗиһан
2) бинте Әхмәделәбрар әл-Иманколый
3) гафийә ганһүмәәл-мәликүл-гаалии
4) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: һәр
2) җан иясе үлемне татыячак.
3) Милади 1895 елның 19
4) мартында Мамыш авылыннан Маһи-
5) -җиһан Әхмәделәбрар кызы –
6) Габдулла Мөхәммәҗән улының
7) сөеклесе – 30 яшьтә шимбә көн».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: ««[Раббыңа] кайт» сүзенә җавап биреп, якшәмбе көн җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Бу кабер иясе – Бибимаһиҗиһан
2) бинте Әхмәделәбрар Иманколый.
3) Аларның икесен дә Патша, Олуг зат кичерсен,
4) амин».

Таш үлчәмнәре: 112x36x17.

54. Бибимаһруй Мөхәммәдшәриф кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаләә күллү мән галәйһәә
2) фәән руми 1906 сәнә април
3) 8 ндә әл-хаҗҗе Әхмәделәбрар
4) зәүҗәсе Бибимаһруй Мөхәммәдшәриф
5) кызы 64 йәшендә тәслиме рух
6) идүб йәкшәнбә көн мәдфүн
7) улды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб догада идеңез йад
2) тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы шад».

[407] Дәвамы сул ягында.
[408] Башы алгы ягында.
[409] Дәвамы сул ягында.
[410] Башы алгы ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә
2) фани. Милади 1906 елның 8
3) апрелендә хаҗи Әхмәделәбрар
4) хатыны – Бибимаһруй Мөхәммәдшәриф
5) кызы – 64 яшендә рух [җан] тәслим
6) кылып, якшәмбе көн
7) җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз,
2) сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 109х35х14.

55. Әхмәделәбрар Хөсәен улы Иманколовка куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һәр нә дәклү чук йәшәрсә бер кеше гакыйбәт үлмәк дорыр аның эше
2) би-хүкми Ходай мәдфүн
3) хаҗийел-хәрәмәйен
4) Әхмәделәбрар бине
5) Хөсәйен Иман-
6) -колыф».

Уң ягы (калкытып язылган): «Фә-ләйтә шәгърийә бәгъдәл-мәүти мәәд-дәәр»[411].

Сул ягы (калкытып язылган): «Әл-мәүтү бәәбүн вә күллүн-нәәси дәәхыйлүһ»[412].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1907 нче йылда
3) 19 нчы ийүндә
4) 1325 нче йылда
5) һиҗриййә илә 22 нче
6) җөмадиәл-әүвәлдә 70
7) йәшендә дәфен
8) кыйлынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ни тиклем озак яшәсә бер кеше, ахырдан үлү булыр аның эше.
2) Ходa хөкеме белән.
3) хаҗи
4) Әхмәделәбрар бине
5) Хөсәен Иман-
6) -колов җирләнде».

Уң ягы: «Үлгәннән соң нинди урын әзерләнгәндер».

Сул ягы: «Үлем – ишек, һәр кеше аннан керәчәк».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1907 елның
3) 19 июнендә,
4) һиҗри белән 1325
5) елның 22
6) җөмадиәл-әүвәлендә 70
7) яшендә
8) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 112(124)х36х17.

56. Әхмәдгәрәй Әхмәделәбрар улы Иманколовка куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмүллаһи Тәгаал[413]
2) Әхмәдгәрәй Әхмәдел-
3) -әбрар углы Иманколыф
4) 1926 йыл үктәбр 11 ндә
5) 63 йәшдә вафат
6) улды».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмиин, йәә Раббәл-гааләмиин»[414].

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәте гарикъ әйләсен»[415].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Әхмәдгәрәй Әхмәдел-
3) -әбрар улы Иманколов
4) 1926 елның 11 октябрендә
5) 63 яшьтә вафат
6) булды».

Уң ягы: «Амин, я, Галәмнәрнең Раббысы».

Сул ягы: «Аллаһ рәхмәткә күмсен».

Таш үлчәмнәре: 85х32х13.

[411] Башы сул ягында.
[412] Дәвамы уң ягында.
[413] Бу җөмлә хаталы язылган.
[414] Башы сул ягында.
[415] Дәвамы уң ягында.

57. Галиәкбәр Вәли улына куелган кабер ташы, 1887 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһил-галиий-
2) -ил-кәбиир руми 1887 сәнә
3) фибрал 29 нда Мамыш
4) карйәсенең Галиәкбәр Вәли
5) углы 58 йәшендә даре
6) бәкайә рихләт кыйлды Аллаһ
7) Тәгалә гарикы рәхмәт кыйлсун амин».

Арткы ягы (уеп язылган)[416]:
1) «Кәрәм әйләб догада идеңез йад
2) тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Олуг, Бөек
2) Аллаһта. Милади 1887 елның
3) 29 февралендә Мамыш
4) авылыннан Галиәкбәр Вәли
5) улы 58 яшендә мәңгелек
6) дөньяга күчте. Аллаһ
7) Тәгалә рәхмәткә күмсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз,
2) сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 117х31х12.

58. Бибимаһитаб Галиәкбәр кызына куелган кабер ташы, 1873 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгааләә
2) әл-мәрхүмә Бибимаһитаб
3) бинте Галиәкбәр зәүҗәте Габдулла
4) ...
5) ...
6) дахил улды рәхмәте гарикъ
7) улсун амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Руми илә 1873 нче сәнә
2) 2 нче ийүндә мәдфүн
...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Мәрхүмә Бибимаһитаб
3) бинте Галиәкбәр – Габдулла хатыны –
4) ...
5) ... [бу кабергә]
6) керде. Рәхмәткә
7) күмелсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Милади белән 1873 елның
2) 2 июнендә җирләнде
...».

Таш үлчәмнәре: 88х37х15.

59. Мөхәммәдйосыф Галиәкбәр улы Иманколовка куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән румиййә илә
3) 1899 сәнә ийүн 12 ндә
4) Мамыш карйәсендә Мөхәммәдйосыф
5) Галиәкбәр углы Иманколыф-
6) -ның әһлийәсе Бибимәймүнә Мәхмүд
7) кызы 48 йәшендә шинбә көн»[417].

Уң ягы (уеп язылган): «Сахибе дәүләт Сөләйман гали кадәр Мостафа китдиләр куйыб җиһанны килми калмаз һәм сәңа».

Сул ягы (калкытып язылган): «Даре фәнадин даре бәкайә рихләт кыйлды Аллаһ рәхмәт кыйлсун»[418].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Анда [җир йөзендә] булучы
2) һәркем, һәрнәрсә фани. Милади белән
3) 1899 елның 12 июнендә
4) Мамыш авылында Мөхәммәдйосыф
5) Галиәкбәр улы Иманколов-
6) -ның хатыны – Бибимәймүнә Мәхмүд
7) кызы – 48 яшендә шимбә көн».

Уң ягы: «Дәүләт иясе Сөләйман [пәйгамбәр], олуг Мостафа [Мөхәммәд пәйгамбәр] җиһанны калдырып киттеләр, килми калмас сиңа да [бу хәл]».

[416] Диагональ буенча язылган.

[417] Дәвамы сул ягында.

[418] Башы алгы ягында.

Сул ягы: «Фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 112(136)х36х17.

60. Сабиржан Хөснеддин улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү
2) мән галәйһәә фәән румиййә илә 1918 нче сәнә
3) һиҗриййә илә 1336 сәнә
4) Сабиржан Хөснеддин углы
5) үктәбр 26 нчы көне
6) дарел-фәнадан дарел-бәкайә
7) рихләт итде Аллаһ
8) рәхмәт әйләсен амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Вафат
2) 23 йәшендә
3) бу ләүхне агасы
4) Камилҗан бина
5) кыйлдырды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Анда [җир йөзендә]
2) булучы һәркем, һәрнәрсә фани. Милади белән 1918 ел
3) октябренең 26 нчы көнендә,
4) һиҗри белән 1336 елда
5) Сабиржан Хөснеддин улы
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ
8) рәхим кылсын, амин».

Арткы ягы:
1) «23 яшендә
2) вафат.
3) Бу ташны агасы
4) Камилҗан
5) куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 60х28х9.

61. Хөснеддин Камаледдин улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Милад 1918 сәнә
2) үктәбр 24 ндә
3) Хөснеддин
4) Камаледдин
5) улы дарел-фәнадан
6) күчде 65
7) йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милад[и] 1918 елның
2) 24 октябрендә
3) Хөснеддин
4) Камаледдин
5) улы 65 яшендә
6) фани дөньядан
7) күчте».

Таш үлчәмнәре: 90х28х10.

62. Нәфисә Габделлатыйф кызына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Нәфисә Габд-
3) -еллатыйф кызы
4) Хөснеддин
5) Камаледдин улы-
6) -ның зәүҗәсе
7) милади 1923 сәнә
8) үктәбр 20 63йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Нәфисә Габд-
3) -еллатыйф кызы –
4) Хөснеддин
5) Камаледдин улы-
6) -ның хатыны –
7) милади 1923 елның
8) 20 октябрендә 63яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 88х27х10.

Мәрҗән авылы зираты

1. Габделфаяз Рәхмәтулла улына куелган кабер ташы, 1867 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) тарих румиййә илән 1867
3) нче йылда гыйнварының 30 нчы

4) йәүмендә кад түвүффийә Габделфаййаз Рәхмәтулла
5) углы 96 йәшендә дарел-фәнадин дарел-бәкайә
6) нәкыль итде тарих гарәбиййә 1284
7) mahe шәүвәл алтынчы йәүмендә Аллаahүммәгъфир лии».

Уң ягы (калкытып язылган): «Гомер тиз үтәрин сагышлайасыз безә Коръән укуб багышлайасыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта.
2) Милади белән 1867
3) ел гыйнварының 30 нчы
4) көнендә Габделфаяз Рәхмәтулла улы
5) вафат булды, 96 яшендә hиҗри 1284 [ел]
6) шәүвәл аеның алтынчы көнендә
7) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Аллаhым, мине гафу ит».

Уң ягы: «Гомернең тиз үтүенә сагышланыгыз, безгә Коръән укып багышлагыз».

Таш үлчәмнәре: 112x44x17.

2. Мәрхәбә Мөхәммәдәмин кызына куелган кабер ташы, 1865 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) тарих румиййә 1865 нче йылда
3) априлнең 30 нчы йәүмендә мөтәвәффа мәрхүмә
4) Мәрхәбә Мөхәммәдәмин кызы Габделфаййаз хәләле
5) 72 йәшендә дарел-фәнадин дарел-бәкайә
6) нәкыль итде тарих гарәбиййә 1283
7) нче йыл зөлхиҗҗәнең 9 нчы йәүмендә».

Уң ягы (калкытып язылган): «Изәә тәхәйәртүм фиил-үмүүри фәстәгыыйнүү мин әhлил-кубүүр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади 1865 ел
3) апреленең 30 нчы көнендә вафат булучы мәрхүмә
4) Мәрхәбә Мөхәммәдәмин кызы – Габделфаяз хәләле –
5) 72 яшендә, hиҗри 1283
6) ел зөлхиҗҗәсенең 9 нчы көнендә.
7) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Әгәр [бу] эшләрдә аптырашта калсагыз, кабер әhелләреннән сорагыз».

Таш үлчәмнәре: 102x40x23.

3. Гайшә мулла Габдессаттар кызына hәм Хәмзә мулла Таhир улына куелган кабер ташы, 1867 hәм 1908 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйhәә фәән
2) мәрхүмә Гайшә бинте
3) мулла Габдессаттар
4) мулла Хәмзә зәүҗәсе
5) hиҗри 1286 рамазан-
6) -ның 18 ндә гыйнвар 12
7) ндә румиййә 1867 сәнә-
8) -дә 28 йәшендә
9) зийәрәт идән
10) ихван фатиха рәҗа идә».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә әййүhәәл-әхаль-газииз игътәбирнәә вәстәгыйд лир-рахиил».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаahү мәркадәhәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәhәә вә мәәъвәhәә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйhәә фәән
2) саахибү hәзәл-кабри
3) имәәмү hәзәл-карйәти Хәмзә
4) ибне мулла Таhир әл-Корыйбани
5) сәнәи hиҗриййә 1326 нчы
6) 18 нче җөмадиәл-ахирдә
7) сәнәи румиййә 1908 нче дә
8) 4 нче ийүл дүфинә фии
9) йәүмил-җүмгати рахимәhүллаahү рахмәтән
10) вәәсигаh нәржүүд-дүгаа».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы hәркем, hәрнәрсә фани.
2) Мәрхүмә Гайшә бинте
3) мулла Габдессаттар –
4) мулла Хәмзә хатыны –
5) hиҗри 1286 [елның] 18
6) рамазанында, милади 1867

7) елның 12 гыйнварында
8) 28 яшендә [вафат яки җирләнде].
9) Зиярәт иткән
10) кардәшләрдән «Фатиха» сүрәсе укуны өмет итә».

Уң ягы: «Әй, газиз кардәш, безгә игътибар ит һәм китәргә әзерлән».

Сул ягы: «Аллаһ аның [бу хатынның] каберен нурландырсын һәм урынын җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Әлеге кабер иясе
3) бу авыл имамы Хәмзә
4) ибне мулла Таһир Корыйбани
5) һиҗри 1326 елның
6) 18 җөмадиәл-ахирендә,
7) милади 1908 елның
8) 4 июлендә җомга көн
9) җирләнде. Аллаһ аны киң рәхмәте белән
10) рәхим кылсын. Дога кылуны сорыйбыз».

Таш үлчәмнәре: 112(118)х35х14.

Әлеге кабер иясе 1857 елның 10 гыйнварыннан авылда имам (указ номеры – №147 итеп билгеләнгән. Үзе чыгышы белән хәзерге Питрәч районы Пимәр авылыннан[419].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 7 б. №61.

4. Хәмсәнә мулла Вәли кызына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) саахибәтү һәзәл-кабри зәүҗәтү
3) мулла Хәмзә Хәмсәнә бинте
4) мулла Вәли әл-Мәнгәри фии-
5) -л-һиҗрииййәти 1309 нчы сәнә
6) вә бир-руумииййәти 1892 нче
7) фии шөбат 26 нчы
8) 45 йәшендә җөмад-
9) -иәл-ахир 27 ндә».

Уң ягы (уеп язылган): «Гаҗибтү лил-инсәәни фии фәхриһи вә һүвә гадән фии»[420].

Сул ягы (уеп язылган): «кабриһи йүкъбәр нәүвәраллаahү мәркадәһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә вә мәәъвәһәә»[421].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Йә әхый гафил улма
2) сакыйн беләсез
3) бу кабер киләчәк
4) вакытыңыз йакыйн
5) нәржүү мин ихъвәә-
6) -нинәәл-мүслимиин-
7) -әд-дүгааъә вәл-фәәтихәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабер иясе мулла
3) Хәмзә хатыны – Хәмсәнә бинте
4) мулла Вәли Мәңгәри
5) һиҗри 1309 елның
6) 27 җөмадиәл-ахирендә,
7) милади 1892 [елның]
8) 26 февралендә
9) 45 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Кешенең горурлануына гаҗәпләнәм: иртәгә ул».

Сул ягы: «каберенә керәчәк бит. Аллаһ аның [бу хатынның] каберен нурландырсын һәм урынын җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Әй, кардәш, гафил булма,
2) сак бул. Беләсез:
3) бу кабергә киләчәк
4) вакытыгыз якын.
5) Мөселман кардәшләребездән
6) дога кылуны һәм «Фатиха» сүрәсен
7) укуны сорыйбыз».

Таш үлчәмнәре: 101х31х15.

5. Бәлкыйс Габделҗәлил кызына һәм Сәгыйдь Корбан улына куелган кабер ташы, 1866 һәм 1883 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу каберә назилә Бәлкыйс
3) Габделҗәлил кызы
4) вафат һиҗриййә илә 1280
5) румиййә илә 1866 нчы йылда
6) 12 гыйнварда 50 йәшендә».

[419] Татарстан Республикасының Милли архивы: 2 ф., 2 тасвир., 6856 сак. берәм. – Б. 2–16.
[420] Дәвамы сул ягында.
[421] Башы уң ягында.

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) бу каберә назил Сәгыйдь
3) Корбан углы
4) вафат һиҗриййә илә 1301
5) румиййә илә 1883 нче йылда
6) 19 нчы дикәбрдә 80 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

7) Мөхәммәҗҗан углы
8) Фазылҗан 1885 нче
9) йылда туды
10) 1936 нчы йылда
11) вафат булды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шайтаннан
2) Аллаһка сыенам.
3) Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ
4) исеме белән. Аллаһтан башка табынырга лаеклы
5) зат юк, Мөхәммәд –
6) Аллаһның илчесе.
7) Мөхәммәҗҗан улы
8) Фазылҗан 1885
9) елда туды,
10) 1936 елда
11) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 80x21x11.

140. Маһитаб Сабиржан кызына куелган кабер ташы, 1938 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әгуузү биллээһи мин-
2) -әш-шәйтаанир-раҗиим
3) бисмилләәһир-рахмән-
4) -ир-рахиим ләә иләәһә
5) илләәллааһ мүхәммәдүр-
6) расүүлүллааһ
7) Сабиржан кызы
8) Маһитаб
9) 1890 нчы йылда
10) туды 1938 нче
11) йылда вафат
12) булды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шайтаннан
2) Аллаһка сыенам.
3) Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ
4) исеме белән. Аллаһтан башка табынырга
5) лаеклы зат юк, Мөхәммәд –
6) Аллаһның илчесе.
7) Сабиржан кызы
8) Маһитаб
9) 1890 елда
10) туды, 1938
11) елда вафат
12) булды».

Таш үлчәмнәре: 69x21x11.

141. Сабира Хисамеддин кызына куелган кабер ташы, 1936 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
2) Сабира
3) Хисамеддин
4) кызы туган
5) 1883 йылда
6) вафат
7) 1936 йылда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Сабира
3) Хисамеддин
4) кызы 1883
5) елда туган,
6) 1936 елда
7) вафат».

Таш үлчәмнәре: 77x27x11.

142. Әшрәфҗамал Гали Мохтар улының кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә

2) күллүг мән галәйһәә фәән
3) бу каберә назилә Олуг
4) Әтнәнең Әшрәф-
5) -җамал Гали Мохтар
6) углының кызы
7) Зарифҗан Мәннаф
8) углының әһлийә-
9) -се 60 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр бәне күр дә килүр йарагын сәндә күр».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары бакый ирмәс һичдә йук карары».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Сәнәи миладиййә 1906 нчы
2) 18 нче үктәбрдә
3) һиҗри 1324 нче 13
4) нче рамазан чәһар-
5) -шәнбә көн
6) дарел-фәнадин дар-
7) -ел-бәкайә һиҗрәт әйлә-
8) -де иман рузи әйлә-
9) -сүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани».
3) Бу кабергә Олы
4) Әтнәдән Әшрәф-
5) -җамал Гали Мохтар
6) улының кызы –
7) Зарифҗан Мәннаф
8) углының хаты-
9) -ны 60 яшендә иңде».

Уң ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачу, мине күр, мине күр дә килер өчен кирәк-ярагын син дә күр».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерек, һаман мәңге булмас, юк карары».

Арткы ягы:
1) «Милади 1906 елның
2) 18 октябрендә,
3) һиҗри 1324 [елның] 13
4) рамазанында чәр-
5) -шәмбе көн
6) фани дөньядан мәңгелек
7) дөньяга күчте.
8) Иманнан
9) өлеше бирелсен».

Таш үлчәмнәре: 98(106)x33x11.

143. Билгесез кабер ташы фрагменты, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«... [у]-
1) -глы 94 йәшендә
2) 1340 сәнәи һиҗриййә
3) 1922 сәнәимиладиййә
4) 6 нчы агусда
5) Аллаһ рәхмәт кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«... [у]-
1) -лы 94 яшендә
2) һиҗри 1340 елда,
3) милади 1922 елның
4) 6 августында [вафат яки җирләнде].
5) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 57(64)x30x10.

144. Бибифаизә Гыйззәтулла кызына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Бибифаизә
3) Гыйззәтулла кызы
4) 60 йәшендә
5) 1334 сәнәи һиҗриййә
6) 1916 сәнәи миладиййә
7) 10 нчы үктәбрдә
8) Зарифҗан зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бибифаизә
3) Гыйззәтулла кызы
4) 60 яшендә
5) һиҗри 1334 елда,
6) милади 1916 елның
7) 10 октябрендә [вафат яки җирләнде].
8) Зарифҗан хатыны».

Таш үлчәмнәре: 100x30x10.

145. Сидкыйсафа Гайнулла кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ

2) бу каберә назилә Олуг
3) Әтнә авылыйның Сид-
4) -кыйсафа Гайнулла
5) кызы Габделвәли Тәкәр-
6) -лек әһлийәсе 72
7) йәшендә 1914 нче
8) йылда 25 нче гыйнвар
9) 14 нче мәүлет».

Уң ягы (уеп язылган): «Бәне күр дә килүр йарагың сәндә күр».

Сул ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә Олы
3) Әтнә авылыннан Сид-
4) -кыйсафа Гайнулла
5) кызы – Габделвәли (Тәкәр-
6) -лек) хатыны 72
7) яшендә 1914
8) елның 25 гыйнварында,
9) 14 рабигыль-әүвәлендә иңде».

Уң ягы: «Мине күр дә килер өчен кирәк-ярагын син дә күр».

Сул ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачып йөрү, мине күр».

Таш үлчәмнәре: 111(120)x29x11.

146. Гөлрәйхан Мортаза кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) мәрхүмә Гөлрәйхан
3) Мортаза кызы
4) һиҗриййә илә 1327 нче йылда
5) миладиййә илә 1909 нчы йылда
6) 26 нчы гыйнварда
7) 80 йәшендә
8) Аллаһ гарикы рәхмәт
9) әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Арткы ягы (уеп язылган): «Мөхәррәм зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Мәрхүмә Гөлрәйхан
3) Мортаза кызы
4) һиҗри белән 1327 елда,
5) милади белән 1909 елның
6) 26 гыйнварында
7) 80 яшендә [вафат яки җирләнде].
8) Аллаһ рәхмәткә
9) күмсен».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Арткы ягы: «Мөхәррәм хатыны».

Таш үлчәмнәре: 110x35x17.

147. Мөхәммәҗән Мөхсин улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Мөхәммәҗән
3) Мөхсин углы
4) һиҗриййә 1325 нче йылда
5) миладиййә 1907 нче йылда
6) 7 нче майда вафат
7) 80 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Ихване мөслимин-
2) -дән дога рә-
3) -җа идәмез».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Мөхәммәҗән
3) Мөхсин улы
4) һиҗри 1325 елда,
5) милади 1907 елның
6) 7 маенда
7) 80 яшендә вафат».

Арткы ягы:
1) «Мөселман кардәшләр-
2) -дән дога ө-
3) -мет итәбез».

Таш үлчәмнәре: 119x31x10.

148. Бибимаһирә Мөхәммәҗән кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) бу каберә назилә Бибимаһирә
3) Мөхәммәҗән кызы
4) һиҗриййә 1325 нче йылда
5) румиййә 1907 нче йылда
6) мулла Әхмәд зәүҗәсе».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәәсү нийәәмүн изәә»[55].

Сул ягы (уеп язылган): «Мәтүү интәбәһүү»[56].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «19 нчы април
2) 27 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә Бибимаһирә
3) Мөхәммәҗән кызы
4) һиҗри 1325 елда,
5) милади 1907 елда иңде.
6) Мулла Әхмәд хатыны».

Уң ягы: «Кешеләр йоклыйлар».

Сул ягы: «Үлгәч уяналар».

Арткы ягы:
1) «19 апрельдә
2) 27 яшендә [җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 91x32x12.

149. Мөхәммәдгалим Мөхәммәдкәрим улына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә Олуг Әтнә
3) авылыйның Мөхәммәд-
4) -галим Мөхәммәдкәр-
5) -им углы 52 йә-
6) -шендә рабигыль-ахир
7) 25 нче йәүмендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Бакый ирмәс һичдә йук карары»[57].

Сул ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары»[58].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Румиййә илә 1903 нче
2) йылда 5 нче ау-
3) -гысда чишәнбә
4) көн дарел-бәка-
5) -йә һиҗрәт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабергә Олы Әтнә
3) авылыннан Мөхәммәд-
4) -галим Мөхәммәдкәр-
5) -им улы 52 я-
6) -шендә рабигыль-ахирнең
7) 25 нче көнендә [иңде]».

Уң ягы: «Мәңге булмас һич тә, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары».

Арткы ягы:
1) «Милади белән 1903
2) елның 5 ав-
3) -густында сишәмбе
4) көн мәңгелек дөнья-
5) -га күчте».

Таш үлчәмнәре: 61(91)x29x12.

150. Мулла Габдуллажан мулла Габдерәкыйб улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү мән галәйһәә
2) фәән 1904 нче сәнәи миладиййә
3) 6 нчы синтәбрдә 1322
4) нче сәнәи һиҗриййә 10 нчы маһе рәҗәб
5) имамел-мөслимин мулла Габдулла-
6) -жан мулла Габдеррәкыйб
7) углы 62 йыл гомер сөрүб
8) дүшәнбә көн дарел-фәна-
9) -дин дарел-бәкайә һиҗрәт әйләде».

[55] Дәвамы сул ягында.
[56] Башы уң ягында.
[57] Башы сул ягында.
[58] Дәвамы уң ягында.

Уң ягы (уеп язылган): «Безем Коръән укуга телемез йук тәсаддык һәм кыйлуга пулымыз йук».

Сул ягы (калкытып язылган): «Кәрәм әйләб догада кыйлыңгыз йат тәсаддыклә рухымы кыйлыңгыз шат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир
йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә
2) фани. Милади 1904 елның
3) 6 сентябрендә, һиҗри
4) 1322 елның 10 рәҗәбендә
5) мөселманнар имамы мулла Габдулла-
6) -җан мулла Габдерәкыйб
7) улы, 62 ел гомер сөреп,
8) дүшәмбе көн фани дөнья-
9) -дан мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Безнең Коръән укуга телебез юк, сәдака бирүгә дә көчебез юк».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 100(111)x29x14.

Әлеге кабер иясе, 1864 елның 4 ноябрендә указ (указ номеры – №8434) алып, беренче мәхәллә мәчетенә имам итеп билгеләнгән. Аның атасы да, бабасы Габдерәшид хәзрәт тә Олы Әтнә авылында мулла булганнар.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 8 б. №69.

151. Бәдрениса Габделвәли кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Бәдренниса
3) Габделвәли кызы
4) һиҗрииййә 1303 нче йылда
5) миладииййә 1905 нче йылда
6) 12 нче майда вафат
7) Габделхәким зәүҗәсе
8) 65 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Бәдрениса
3) Габделвәли кызы –
4) Габделхәким хатыны –
5) һиҗри 1303 елда,
6) милади 1905 елның
7) 12 маенда
8) 65 яшендә вафат».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 100(124)x31x14.

152. Сәхибҗамал Фатих кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи
рааҗигуун
2) мәрхүмә Сә-
3) -хибҗамал Фатих
4) кызы 51 йәшендә
5) 1905 нче йылда 21
6) нче ийүлдә мәдфүн
7) гарикы рәхмәтдә улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Галиәкбәр Габдесса... углының җәмәгате».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм,
чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Мәрхүмә Сә-
3) -хибҗамал Фатих
4) кызы 51 яшендә
5) 1905 елның 21
6) июлендә җирләнде.
7) Рәхмәткә күмелсен».

Уң ягы: «Галиәкбәр Габдесса... улының җәмәгате».

Таш үлчәмнәре: 87(96)x30x15.

153. Маһиҗамал Габдессаттар кызына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ

2) Маһиҗамал
3) Габдессаттар
4) кызы Сөләйман
5) зәүҗәсе
6) 75 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1927 сәнәи миладиййә
2) 12 нче майда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Маһиҗамал
3) Габдессаттар
4) кызы – Сөләйман
5) хатыны –
6) 75 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Милади 1927 елның
2) 12 маенда [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 82x31x11.

154. Гыйбадулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назил Олуг
3) Әтнәнең Гыйбадулла
4) Һибатулла углы
5) 65 йәшендә руми 1904
6) нче 7 нче аңлусда
7) һижри 1322 нче 10
8) нчы җөмадиәл-ахир чәр-
9) -шәнбә көн».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары бакый ирмәс һичдә йук карары».

Сул ягы (уеп язылган): «Ничә җәһедилә малы җәмегъ итдем сезә куйдым бары кәфенилә кидем».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә Олы
3) Әтнәдән Гыйбадулла
4) Һибатулла улы
5) 65 яшендә милади 1904
6) [елның] 7 августында,
7) һижри 1322 [елның] 10
8) җөмадиәл-ахирендә чәр-
9) -шәмбе көн иңде».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерек, мәңге булмас һич тә, юк карары».

Сул ягы: «Нихәтле тырышлык белән мал җыйдым – сезгә калдырдым, бары кәфен белән киттем».

Таш үлчәмнәре: 97(109)x31x13.

155. Бәдигылҗамал Хөсәен кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Бәдигыл-
3) -җамал Хөсәйен кызы
4) һижриййә 1330 нчы
5) йылда рабигыль-ахир
6) 5 нче көндә».

Уң ягы (уеп язылган): «Беләсез бу каберә киләчәк вакытыңыз йакыйн».

Сул ягы (уеп язылган): «Йә әхый гафил улма сакыйн».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә
2) 1912 нче йылда
3) 10 нчы мартда
4) Галийулла Гайнулла
5) углы зәүҗәсе
6) 67 йәшендә
7) мәдфүн Аллаһның
8) рәхмәтендә улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Бәдигыл-
3) -җамал Хөсәен кызы
4) һижри 1330
5) ел рабигыль-ахиренең
6) 5 нче көнендә [җирләнде]».

Уң ягы: «Беләсез: бу кабергә киләчәк вакытыгыз якын».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, гафил булма, сак бул».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) 1912 елның
3) 10 мартында

4) Галиулла Гайнулла
5) улы хатыны
6) 67 яшендә
7) җирләнде. Аллаһның
8) рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 78(104)х33х15.

156. Фазлулла Фәтхулла улына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) һәзәәл-кабру Фазлулла әл-хаҗ Фәтхулла
3) углы һиҗрииййә илән 1320 нче сәнә маһе шәгъбан
4) 15 ндә румииййә илән 1902 нче сәнә 55 йәшендә
5) җомга көн нуйәбр 1 нче көнендә мәдфүн
6) нәүвәраллааһү Тәгаалә мәркадәһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб дога-да идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән мора-дым бер догадур бу көн бәңа икән йарин сәңа-дур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу Фазлулла хаҗи Фәтхулла улы
3) кабере, һиҗри белән 1320 елның 15
4) шәгъбанында, милади белән 1902 ел ноябренең
5) 1 нче көнендә 55 йәшендә җомга көн җирләнде.
6) Аллаһ Тәгалә аның каберен нурландырсын, амин».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 104х36х18.

157. Гайнекамал Баязит Шәем улының кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә күллү мән галәйһә фәән бу
2) каберә назил улмыш Олуг
3) Әтнә авылыйның Гайнелкамал
4) Байазит Шәйем углының
5) кызы Хәйбулла Вәлийулла
6) углыйның әһлийәсе 68 йә-
7) -шендә руми 1906 нчы йылда 7
8) нче ийүлдә һиҗри 1319 нчы
9) йылда 23 нче рабигыль-әүвәл
10) пәнҗешәнбә көн һиҗрәт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары бакый ирмәс һичдә йук карары».

Сул ягы (калкытып язылган): «Кәрәм әйләб догада кыйлыңгыз йат тәсаддыклә рухы-мы кыйлыңгыз шат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани. Бу
2) кабергә иңгән Олы
3) Әтнә авылыннан Гайнекамал
4) Баязит Шәем улының
5) кызы – Хәйбулла Вәлиуллa
6) улының хатыны – 68 я-
7) -шендә милади 1906 елның 7
8) июлендә, һиҗри 1319
9) елның 23 рабигыль-әүвәлендә
10) пәнҗешәмбе көн күчте».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерек, мәңге булмас һич тә, юк карары».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 100(124)х30х16.

Олы Әтнә авылының икенче (көнбатыштагы) зираты

1. Мөәзин Габделхаликъ Габдерәшид улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбрah

2) мөәзин Габделхаликъ
3) Габдеррәшид
4) углы 33 йыл
5) мөәзинлек кылуб
6) 67 йәшендә
7) 1338 сәнә һиҗриййә 3 нче
8) рәҗәбдә 1920 йылда
9) мартында вафат».

Сул ягы (уеп язылган): «Җәгаләллаahү кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәh».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Мөәзин Габделхаликъ
3) Габдерәшид
4) улы, 33 ел
5) мөәзинлек итеп,
6) 67 яшендә
7) һиҗри 1338 елның 3
8) рәҗәбендә, 1920 елның
9) мартында вафат».

Сул ягы: «Аллаh аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 100x32x13.

2. Сабира Сәйфеддин кызына куелган кабер ташы, 1937 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бисмилләәh-
2) -ир-рахмәәнир-рахиим
3) Сабира Сәйф-
4) -еддин кызы
5) Нәҗмеддин
6) углы Гайн-
7) -еддин җәмәгате
8) вафат булды
9) 1937 нче йылда
10) 23 нче априлдә
11) җомга көн гү-
12) -р ийәсе булды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Шәфкатьле, Рәхимле
2) Аллаh исеме белән.
3) Сабира Сәйф-
4) -еддин кызы –
5) Нәҗмеддин
6) улы Гайн-
7) -еддин җәмәгате –
8) вафат булды,
9) 1937 елның
10) 23 апрелендә
11) җомга көн гү-
12) -р иясе булды».

Таш үлчәмнәре: 93(108)x37x11.

3. Бибимәликә Галиулла кызына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) Бибимәликә
3) Галийулла кызы
4) 50. йәшендә вафат
5) Хәбибулла зәүҗәсе
6) 1337 сәнәи һиҗриййә
7) 1919 сәнәи миладиййә
8) ийүл 19 нда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «3 нче шәүвәлдә
2) гарикы рәхмәт
3) улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бибимәликә
3) Галиулла кызы –
4) Хәбибулла хатыны –
5) 50 яшендә
6) һиҗри 1337 елда,
7) милади1919 елның
8) 19 июлендә вафат».

Арткы ягы:
1) «3 шәүвәлдә [вафат].
2) Рәхмәткә
3) күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 103x31x11.

4. Әшрәфҗамал Гайнулла кызына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh 1918 сәнә
2) агуст 14 дә
3) һиҗри 1339 сәнә
4) Әшрәфҗамал Гайнулла кызы
5) Гатаулла Гыйсмәтулла
6) углы зәүҗәсе 50 йәшдә»[59].

[59] Дәвамы арткы ягында.

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бәкайә рихләт кылды
2) Әшрәфҗамал Гайнулла
3) кызы»[60].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта. 1918 елның
2) 14 августында,
3) һиҗри 1339 елда
4) Әшрәфҗамал Гайнулла кызы –
5) Гатаулла Гыйсмәтулла
6) улы хатыны – 50 яшьтә».

Арткы ягы:
1) «Бакыйлыкка күчте.
2) Әшрәфҗамал Гайнулла
3) кызы».

Таш үлчәмнәре: 88х31х10.

5. Дәрданәбикә Мөхәммәдшәриф кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Дәрданәбикә
3) Мөхәммәдшәриф кызы
4) Фазлулла зәүҗәсе
5) 1330 сәнәи һиҗриййә
6) 1912 сәнәи миладиййә
7) 2 нче гыйнварда»[61].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Рабигыль-ахир 12 ндә
2) чәһаршәнбә
3) көн вафат»[62].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Дәрданәбикә
3) Мөхәммәдшәриф кызы –
4) Фазлулла хатыны –
5) һиҗри 1330 елда,
6) милади 1912 елның
7) 2 гыйнварында».

Арткы ягы:
1) «12 рабигыль-ахирдә
2) чәршәмбе
3) көн вафат».

Таш үлчәмнәре: 97(106)х29х9.

6. Билгесез кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) ... нче сәнәдә
2) 25 нче ийүлдә мәдфүн
3) Хак Җәлле вә Әгъля
4) хәзрәтенең
5) дидар рәхмәтендә улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «... гафу кыйл».

Сул ягы (уеп язылган): «Ахирәтдә җәннәт...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) ... елның
2) 25 июлендә җирләнде.
3) Хак Бөек һәм
4) Олуг [Аллаһның]
5) рәхмәтендә булсын».

Уң ягы: «... гафу ит».

Сул ягы: «Ахирәттә җәннәт...».

Таш үлчәмнәре: 55 (74)х30х15.

7. Лотфулла Хәкимулла улы Әкбировка куелган кабер ташы, 1937 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһүл-хүкмү
2) Әкбиров
3) Лотфулла
4) Хәкимулла
5) углы
6) тугды 1901 сә-
7) -нәдә вафат
8) булды
9) 1937 йылда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Әкбиров
3) Лотфулла
4) Хәкимулла
5) улы
6) 1901 елда
7) туды, 1937

[60] Башы алгы ягында.
[61] Дәвамы арткы ягында.
[62] Башы алгы ягында.

8) елда вафат
9) булды».

Таш үлчәмнәре: 94х27х9.

8. Әхмәдулла Хәйрулла улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Әхмәдулла Хәйрулла
3) углы 27 йәшендә
4) 1339 сәнәи һиҗриййә
5) 1918 сәнәи миладиййә»[63].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Сәфәрнең 12 ндә
2) нуйәбрнең 5 сендә
3) шинбә көн мәдфүн»[64].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Әхмәдулла Хәйрулла
3) улы 27 яшендә
4) һиҗри 1339 елның,
5) милади 1918 елның».

Арткы ягы:
1) «12 сәфәрендә,
2) 5 ноябрендә
3) шимбә көн җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 96х35х11.

9. Габделбакый Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) мәрхүм Габделбакый
3) ибне Ибраһим әл-Каза-
4) -ни вафат тарих румиййә берлә
5) 1907 нче сәнәдә март 21 ндә
6) 9 йәшендә сарай
7) ахирәтә иртихаль итде».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Әд-дүнйәә
2) сәәгаһ
3) фәжгальһәә
4) таагаһ
5) кәәтибүһү
6) имам
7) ...»[65].

Сул ягы: «Җәнабе Хак шәфәгатен...[66]».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Мәрхүм Габделбакый
3) ибне Ибраһим Каза-
4) -ни вафат, милади белән
5) 1907 елның 21 мартында
6) 9 яшендә ахирәт
7) сараена күчте».

Уң ягы:
1) «Дөнья –
2) бер сәгатьлек,
3) аны итагать
4) белән үткәр.
5) Язучысы:
6) имам
7) ...».

Сул ягы: «Җәнабе Хак шәфәгатен [насыйп итсен]»[67].

Таш үлчәмнәре: 76(86)х30х13.

10. Мөхәммәҗан Әхмәдулла улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Мөхәммәҗан
3) Әхмәдулла углы
4) миладиййә 1910 нчы йылда
5) 31 нче майда
6) 45 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Беләсез бу каберә керәчәк вакытыңыз йакыйн».

Сул ягы (уеп язылган): «Йә әхый гафил улма сакыйн».

[63] Дәвамы арткы ягында.
[64] Башы алгы ягында.
[65] Гадәттә, ташның уң һәм сул якларындагы язмалар вертикаль рәвештә язылса да, бу очракта, горизонталь рәвештә язылган.
[66] Ислам дине өйрәтүенчә, сабый вакытында вафат булган балалар Кыямәт көнендә ата-аналары өчен Аллаһ каршында шәфәгать кылачаклар, әлеге догада шул нәрсә күздә тотыла.
[67] Ислам дине өйрәтүенчә, үлгән сабый балалар Кыямәт көнендә ата-аналары өчен шәфәгатьче булачаклар, сүз шул хакта бара.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Мөхәммәджан
3) Әхмәдулла улы
4) милади 1910 елның
5) 31 маенда
6) 45 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Беләсез: бу кабергә керәчәк вакытыгыз якын».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, гафил булма, сак бул».

Таш үлчәмнәре: 72(75)x33x12.

11. Хөснежамал Заһидулла кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назилә Хөсне-
3) -җамал Заһидулла
4) кызы Әхмәджан
5) Мәхмүт углының
6) әһлийәсе руми
7) 1907 йылда 13 април»[68].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗри 1325 нче
2) рабигыль-әүвәл 14 нче
3) 80 йәшендә
4) җомга көн»[69].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә Хөсне-
3) -җамал Заһидулла
4) кызы – Әхмәджан
5) Мәхмүт улының
6) хатыны – милади
7) 1907 елның 13 апрелендә».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри 1325 [елның]
2) 14 рабигыль-әүвәлендә
3) 80 яшендә
4) җомга көн иңде».

Таш үлчәмнәре: 81(97)x35x11.

12. Гобәйдулла Төхфәтулла улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Гобәйдулла
3) Төхфәтулла углы
4) һиҗриййә 1328 нче йылда
5) миладиййә 1911 нче йылда
6) 9 нчы гыйнварда
7) 67 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Беләсез бу каберә керәчәк вакытыңыз йакыйн».

Сул ягы (уеп язылган): «Йә әхый гафил улма сакыйн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Гобәйдулла
3) Төхфәтулла улы
4) һиҗри 1328 елда,
5) милади 1911 елның
6) 9 гыйнварында
7) 67 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Беләсез: бу кабергә керәчәк вакытыгыз якын».
Сул ягы: «Әй, кардәшем, гафил булма, сак бул».

Таш үлчәмнәре: 88x31x11.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә булырга тиеш: Гобәйдулла бине Төхфәтулла бине Бәшир бине Вәлид бине Халид бине Арслан[70].

13. Гайнулла Төхфәтулла улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру мәнзилүн мин
2) мәнәәзилил-әәхыйрah
3) Гайнулла
4) Төхфәтулла
5) углы миладиййә
6) илә 1922 нче йыл
7) 10 нчы майда

[68] Дәвамы арткы ягында.
[69] Башы алгы ягында.
[70] Әхмәтҗанов М.И. Татар археографиясе. Милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. – Казан, 2011. – Б. 205.

8) 73 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Әд-дүнйәә мәзрагатүл-әәхыйраһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Таййибәллаһү сәраһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – ахирәттә [кеше] тора
2) торган урыннарның берсе.
3) Гайнулла
4) Төхфәтулла
5) улы милади
6) белән 1922 елның
7) 10 маенда
8) 73 яшендә вафат».

Уң ягы: «Дөнья – ахирәт басуы».

Сул ягы: «Аллаһ туфрагын яхшы (җиңел) кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Таш үлчәмнәре: 88х29х10.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Гайнулла бине Төхфәтулла бине Бәшир бине Вәлид бине Халид бине Арслан[71].

14. Сибгатулла Сәмигулла улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Сибгатулла
3) Сәмигулла у-
4) -глы 52 йәшендә
5) 2 нче гыйнварда
6) 1922 сәнәи миладиййә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада иде-
3) -ңез йад тәсадды-
4) -клә кыйлуңыз
5) рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Сибгатулла
3) Сәмигулла у-
4) -лы 52 яшендә
5) милади 1922 елның
6) 2 гыйнварында [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә
3) алыгыз, сәдака бирү
4) белән рухымны
5) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 89х32х9.

15. Билгесез кабер ташы фрагменты, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) ... 57
2) йәшендә 1339 сәнәи
3) һиҗриййә рабигыль-ахирдә
4) 1921 сәнә гыйнвар 28
5) вафат Аллаһ рәхмәт
6) кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәралл[аһү мәркадәһәә]».

Сул ягы (уеп язылган): «[Гафәраллаһү зү]нүүбәһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) ... 57
2) яшендә һиҗри 1339
3) елның рабигыль-ахирендә,
4) 1921 елның 28 гыйнварында
5) вафат. Аллаһ рәхим
6) кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 72(79)х29х9.

16. Бибигазизә Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ

[71] Әхмәтҗанов М.И. Татар археографиясе. Милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. – Казан, 2011. – Б. 205.

2) Бибигазизә
3) Гобәйдулла кызы
4) 1333 сәнәи һиҗриййә
5) 1915 сәнәи миладиййә
6) 12 нче майда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «70 йәшендә
2) Габделвәли җәмәгате
3) ихване
4) мөслиминдән
5) дога рәҗа
6) идәмез».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бибигазизә
3) Гобәйдулла кызы
4) һиҗри 1333 елда,
5) милади 1915 елның
6) 12 маенда [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «70 яшендә [вафат яки җирләнде].
2) Габделвәли җәмәгате.
3) Мөселман
4) кардәшләрдән
5) дога өмет
6) итәбез».

Таш үлчәмнәре: 47х32х12.

17. Мулла Габдрахман мулла Габделхәким улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу каберә назил мулла Габдерра-
3) -хман бине мулла Габд-
4) -елхәким һиҗриййә 1323 нче
5) йылда румиййә илә 1905 нче
6) йылда 12 нче синтәбрдә
7) 63 йәшендә
8) табибчы адәм иде».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаһү мәркадәһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә вә мәъвәәһәә».

Сул ягы (уеп язылган): «Иннәллаһү йүхиббү хифзал-кадиим».

Арткы ягы:
1) «Йә әхый гафил улма
2) сакыйн беләсез
3) бу кабер киләчәк
4) вакытыңыз йакыйн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабергә мулла Габдра-
3) -хман бине мулла Габд-
4) -елхәким һиҗри 1323
5) елда, милади белән 1905
6) елның 12 сентябрендә
7) 63 яшендә иңде.
8) Табибчы адәм иде».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын һәм урынын җәннәт итсен».

Сул ягы: «Чынлыкта, Аллаһ борынгылыкны саклаганны ярата».

Арткы ягы:
1) «Әй, кардәшем, гафил булма,
2) сак бул. Беләсез:
3) бу кабергә киләчәк
4) вакытыгыз якын».

Таш үлчәмнәре: 112(126)х33х13.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 8 б. №70.

18. Әхмәдулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) мәрхүм Әхмәдулла
3) Гобәйдулла углы
4) 63 йәшендә ...
5) нче ийүлдә 1906
6) нчы йылда тарих илә
7) 1323 нче сәнәдә вафат
8) гарикы рәхмәтдә улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Мәрхүм Әхмәдулла
3) Гобәйдулла улы
4) 63 яшендә
5) 1906 елның ...
6) июлендә, һиҗри белән
7) 1323 елда вафат.
8) Рәхмәткә күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 80х30х11.

19. Шәмсекамәр Габделвәли кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә
2) иләйһи рааҗигуун
3) Әхмәдулла
4) җәмәгате
5) Шәмсекамәр
6) Габделвәли
7) кызы».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1920 нче йыл
3) 11 нче майда
4) 74 йәшендә
5) дәфен кылынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
2) Аңа кайтачакбыз.
3) Әхмәдулла
4) җәмәгате –
5) Шәмсекамәр
6) Габделвәли
7) кызы».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1920 елның
3) 11 маенда
4) 74 яшендә
5) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 85x25x7.

20. Бибифатыйма Әхмәҗән кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу кабер назилә Бибифатыйма
3) Әхмәҗән кызы
4) һиҗриййә 1325 нче йылда
5) румиййә 1907 нче йылда
6) 26 нчы нуйәбрдә
7) 18 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә Бибифатыйма
3) Әхмәҗән кызы
4) һиҗри 1325 елда,
5) милади 1907 елның
6) 26 ноябрендә
7) 18 яшендә иңде».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 98x31x12.

21. Бибимәхубҗамал Мөхәммәдрәхим кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назилә
3) Бибимәхубҗамал
4) Мөхәммәдрәхим кызы Шәрә-
5) -феддин Хисамеддин
6) углының әһлийәсе 80
7) йәшендә руми 1907
8) нче йылда 5 нче гыйнвар
9) шинбә көн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә
3) Бибимәхубҗамал
4) Мөхәммәдрәхим кызы – Шәрә-
5) -феддин Хисамеддин
6) улының хатыны – 80
7) яшендә милади 1907
8) елның 5 гыйнварында
9) шимбә көн иңде».

Таш үлчәмнәре: 95(120)x32x12.

22. Хөснекамал Корбангали кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң зәәъикаһ
2) бу каберә назил
3) улмыш Олуг Әтнәдә тәрбийәләнмеш

4) Коллар авылыйның Хөснекамал Корба-
5) -нгали кызы Габделгаффар әһлийәсе
6) 70 йәшендә сәнәи миладиййә илә
7) 1906 нчы 6 нчы априлдә сәнәи
8) һиҗриййә илә 1324 нче 25
9) нче сәфәрел-хәйер пәнҗешәнбә кө-
10) -н дарел-фәнадин дарел-бәкайә һиҗрәт
11) әйләде таййибәллаahү сәраah».

Уң ягы (уеп язылган): «Безем Коръән укуга телемез йук тәсаддык һәм кыйлуга пулымыз йук».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада кыйлыңгыз йат тәсаддыклә рухымы кыйлыңгыз шат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
2) Бу кабергә иңгән,
3) Олы Әтнәдә тәрбияләнгән,
4) Коллар авылыннан Хөснекамал Корба-
5) -нгали кызы – Габделгаффар хатыны –
6) 70 яшендә милади белән
7) 1906 елның 6 апрелендә, һиҗри
8) белән 1324 елның 25
9) сәфәрендә пәнҗешәмбе кө-
10) -н фани дөньядан мәңгелек дөньяга
11) күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Уң ягы: «Безнең Коръән укуга телебез юк, сәдака бирүгә дә көчебез юк».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 116x34x13.

23. Камаледдин Хөснеддин улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Камаледдин
3) Хөснеддин
4) углы 29 йә-
5) -шендә вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1926 сәнәи миладиййә
2) 20 нче ийүндә
3) кәрәм әйләб дога-
4) -да идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Камаледдин
3) Хөснеддин
4) улы 29 я-
5) -шендә вафат».

Арткы ягы:
1) «Милади 1926 елның
2) 20 июнендә [вафат].
3) Юмартлык кылып, дога-
4) -да искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 62(73)x27x10.

24. Гафифә Гайсә кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгаалә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүт руми
3) илә 196[72] нчы йылда 18 нче
4) гыйнварда Олуг Әтнә авылыйның
5) Гайнулла Хәбибулла углыйның
6) зәүҗәсе мөтәвәффат мәрхүмә
7) Йукары Бәрәскә авылыйның
8) Гайсә (?) кызы Гафифә 75 йә-
9) -шендә мәдфүн улды һиҗри
10) 1324 нче йылда».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары бакый ирмәс һичдә йук карары».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада кыйлыңгыз йат тәсаддыклә рухымы кыйлыңгыз шат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак». Милади
3) белән 19[0]6 елның 18
4) гыйнварында Олы Әтнә авылыннан
5) Гайнулла Хәбибулла улының
6) хатыны – вафат булучы мәрхүмә
7) Югары Бәрәскә авылыннан
8) Гайсә (?) кызы Гафифә – 75 я-
9) -шендә, һиҗри
10) 1324 елда җирләнде».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерек, мәңге булмас һич тә, юк карары».

[72] «196» дип язылса да, 1906 ел күздә тотыла.

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 78x28/32x17.

25. Бибизәбидә Мөхәммәди кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун
2) мәрхүмә Бибизәбидә
3) Мөхәммәди кызы
4) 1906 нчы йылда
5) 9 нчы ийүлдә
6) 63 йәшендә
7) мәдфүнә Хак
8) Тәгаләнең рәхмәтендә
9) улсун».

Сул ягы (уеп язылган): «Мөхәммәдшаһ зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Мәрхүмә Бибизәбидә
3) Мөхәммәди кызы
4) 1906 елның
5) 9 июлендә
6) 63 яшендә
7) җирләнде. Хак
8) Тәгаләнең рәхмәтендә
9) булсын».

Сул ягы: «Мөхәммәдша хатыны».

Таш үлчәмнәре: 67x27x12.

26. Гыйсмәтулла Габид улына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Гыйсмәтулла Габид
3) углы 75 йәшендә
4) 1919 сәнәи миладиййә
5) 17 нче үктәбрдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Гыйсмәтулла Габид
3) улы 75 яшендә
4) милади 1919 елның
5) 17 октябрендә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 66x36x14/20.

27. Заһидулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Заһидулла
3) Һибатулла углы
4) 1333 сәнәи һиҗриййә
5) 1915 сәнәи миладиййә
6) 27 нче үктәбрдә
7) 82 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Зилхиҗҗәнең
2) 25 ндә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Заһидулла
3) Һибатулла улы
4) һиҗри 1333 елда,
5) милади 1915 елның
6) 27 октябрендә
7) 82 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Зөлхиҗҗәнең
2) 25 ндә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 103x33x11.

28. Гыйззәтулла Сибгатулла улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Гыйззәтулла
3) Сибгатулла углы
4) 1331 сәнәи һиҗриййә
5) 1913 сәнәи миладиййә
6) синтәбрнең 11 ндә
7) 18 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Гыйззәтулла
3) Сибгатулла улы
4) һиҗри 1331 елда,
5) милади 1913 елның
6) 11 сентябрендә
7) 18 яшендә вафат».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 88(98)x31x11.

29. Сәйдә Фәхреддин кызына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәһ
2) мәрхүмә Сәйдә
3) Фәхреддин кызы
4) 1331 сәнәи һиҗриййә
5) 1913 сәнәи миладиййә
6) 27 нче нуйәбрдә
7) 31 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта гына.
2) Мәрхүмә Сәйдә
3) Фәхреддин кызы
4) һиҗри 1331 елда,
5) милади 1913 елның
6) 27 ноябрендә
7) 31 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 90(94)x32x13.

30. Бибинәфисә Хафизулла кызына куелган кабер ташы,1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) мәрхүмә Бибинәфисә
3) Хафизулла кызы
4) ...
5) зәүҗәсе 32 йәшендә
6) һиҗриййә илә 1323 сәнәдә
7) руми илә 1906 йылда
8) март 6 сында
9) вафат гарикы рәхмәтдә
10) улсун».

Сул ягы (уеп язылган): «Йә Илаһым бу колыңны гафу кыйл ахирәтдә рәхмәт нурың насыйб кыйл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) мәрхүмә Бибинәфисә
3) Хафизулла кызы
4) ...
5) хатыны 32 яшендә
6) һиҗри белән 1323 елда,
7) милади белән 1906 елның
8) 6 мартында
9) вафат. Рәхмәткә
10) күмелсен».

Сул ягы: «Йә Илаһым, бу колыңны гафу ит, ахирәттә рәхмәт нурыңны насыйп ит».

Таш үлчәмнәре: 103(117)x30x12.

31. Нигъмәтҗан Әхмәҗан улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) мәрхүм Нигъмәтҗан(?) Әхмәд-
3) -җан углы 22 йәшендә
4) руми илә 1907 йылда
5) март 2 ндә һиҗриййә илә
6) 1324 сәнәдә...
7) 13 ндә мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәңа икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Мәрхүм Нигъмәтҗан(?) Әхмәд-
3) -җан улы 22 яшендә
4) милади белән 1907 елның
5) 2 мартында, һиҗри белән
6) 1324 елның 13 ...
7) җирләнде».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 82x38x12.

32. Әхмәҗән кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Бибиг...
3) -Әхмәҗән кызы
4) һиҗрииә 1325 нче йылда
5) миладииә 1907 нче йылда
6) 21 нче дикәбрдә
7) 27 йәшендә мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Арткы ягы (уеп язылган): «...киржән зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Бибиг...
3) -Әхмәҗән кызы
4) һиҗри 1325 елда,
5) милади 1907 елның
6) 21 декабрендә
7) 27 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Арткы ягы: «...киржән хатыны».

Таш үлчәмнәре: 84x31x11.

33. Мөхәммәдша Галим улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Мөхәммәдшаһ
3) Галим углы
4) 73 йәшендә
5) 15 нче фибралда».

Уң ягы (уеп язылган): «Рахимәллааһү лимән зәәрании».

Сул ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1917 сәнәи миладиййә
2) кәрәм әйләб д-
3) -огада идеңез
4) йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мөхәммәдша
3) Галим улы
4) 73 яшендә
5) 15 февральдә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Мине зирәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын».

Сул ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Арткы ягы:
1) «Милади 1917 елда [вафат яки җирләнде].
2) Юмартлык кылып, д-
3) -огада искә
4) алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 60(68)x29x7.

34. Хәбибулла Галим улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу каберә Олуг Әтнә авылыйның
2) Хәбибулла Галим углы
3) 67 йәшендә миладиййә
4) илә 1917 нче йылда 16 нчы
5) майда шинбә көн
6) дарел-фәнадин дарел-

7) бәкайә һиҗрәт
8) әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Бәне күр дә килүр йарагың сәндә күр».

Сул ягы (уеп язылган): «Үтде дәүран кичде сәйран бәне күр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабергә Олы Әтнә авылыннан
2) Хәбибулла Галим улы [иңде],
3) 67 яшендә милади
4) белән 1917 елның 16
5) шимбә көн
6) фани дөньядан мәңгелек
7) дөньяга
8) күчте».

Уң ягы: «Мине күр дә килер өчен кирәк-ярагын син дә күр».

Сул ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачып йөрү, мине күр».

Таш үлчәмнәре: 83(100)х43х16.

35. Бибисажидә Фазлулла кызына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Бибисажидә
3) Фазлулла
4) кызы 39 йәшендә
5) Гобәйдулла зәүҗә-
6) -се».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1918 сәнәи миладиййә
2) 2 нче ийүлдә
3) кәрәм әйләб д-
4) -огада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бибисажидә
3) Фазлулла
4) кызы 39 яшендә [вафат яки җирләнде].
5) Гобәйдулла хаты-
6) -ны».

Арткы ягы:
1) «Милади 1918 елның
2) 2 июлендә [вафат яки җирләнде]
3) Юмартлык кылып, д-
4) -огада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 59х25х7.

36. Галиулла Гайнулла улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Галийулла
3) Гайнулла
4) углы 1339
5) һиҗриййә рамазан
6) шәрифе-
7) -ндә
8) 47 йәшендә
9) 1920 сәнәи румиййә
10) ийүн...».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Бар күңелләрдән җылы йомшак синең каберең ташы
2) Шунда тамсун күз йәшемнең иң ачы һәм татлысы».

Сул ягы (уеп язылган): «Җәгаләллаһү кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Галиулла
3) Гайнулла
4) улы һиҗри
5) 1339 [елның]
6) рамазан шәрифе-
7) -ндә
8) 47 яшендә,
9) милади1920 елның
10) июнендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы:
1) «Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең каберең ташы,
2) Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 112х33х17.

37. Әмирхан Гыймадеддин улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-бәәкыый
2) мәрхүм Әмирхан
3) Гыймадеддин углы
4) румиййә берлә 1913 нче сәнәдә
5) нуйәбр 19 нда һиҗриййә 31 нче
6) сәнә мөхәррәм 3 ндә 35
7) йәшенд вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәраллаahү зүнүүбәһ әәмиин».

Сул ягы (уеп язылган): «Җәгаләллаahү кабраһү раудатәл-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Мәрхүм Әмирхан
3) Гыймадеддин улы
4) милади белән 1913 елның
5) 19 ноябрендә, һиҗри [13]31
6) елның 3 мөхәррәмендә 35
7) яшендә вафат».

Уң ягы: «Аллаһ аны гафу итсен».
Сул ягы: «Аллаһ аның каберен җәннәт бакчасы итсен».

Таш үлчәмнәре: 82(100)x33x12.

38. Фәхреддин Мохтар улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Фәхреддин
3) Мохтар углы
4) 75 йәшендә
5) 1330 сәнәи һиҗриййә
6) 1912 сәнәи миладиййә
7) 21 нче агусда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Ә-лээ йәә әййүһәә-
2) -л-мәгърууру мин түб[73] гайри тәәъ-
3) -хыйр фә-иннәл-мәү-
4) -тә кад йәәътии
5) вә ләү суййиртә
6) Кааруунәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Фәхреддин
3) Мохтар углы
4) 75 йәшендә
5) 1330 сәнәи һиҗриййә
6) 1912 сәнәи миладиййә
7) 21 нче агусда».

Арткы ягы:
1) «Әй, син,
2) горурланучы, соңга калмыйча тәүбә
3) ит! Чынлыкта, син
4) Карун бай кебек
5) булсаң да, үлем
6) киләчәк».

Таш үлчәмнәре: 104x30x11.

39. Мөхәммәдзакир мулла Мөхәммәдшакир улы Ишморатовка куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим
2) күллү мән галәйһәә фәән
3) мәрхүм Мөхәммәдзакир
4) мулла Мөхәммәдшакир углы
5) Ишморатыф 17 нче рабиг-
6) -ыль-әүвәлдә сәнәи һиҗриййә 1328 нче
7) сәнәи миладиййә 1910 нчы 15 нче
8) март 45 йәшендә
9) вафат гарикы рәхмәт улсун».

Уң ягы (уеп язылган)[74]: «Зүүрууль-кубүүра фә-иннәһәә түзәккиракүмүл-әәхыйраһ».

Сул ягы (уеп язылган)[75]: «Ән-нәәсү нийәәмүн изәә мәтүү интәбәһүү».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Безем Коръән
2) укырга телемез йук
3) тәсаддык һәм кыйлу-
4) -рга пулымыз йук».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән.

[73] Бу ике сүзнең урыннары алмашынган, шуңа күрә бераз хаталы язылган.

[74] Диагональ буенча язылган.
[75] Диагональ буенча язылган диярлек.

2) Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
3) Мәрхүм Мөхәммәдзакир
4) мулла Мөхәммәдшакир улы
5) Ишморатов һиҗри
6) 1328 елның 17
7) рабигыль-әүвәлендә, милади 1910 елның 15
8) мартында 45 яшендә
9) вафат. Рәхмәткә күмелсен».

Уң ягы: «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар сезгә ахирәтне искә төшерер».

Сул ягы: «Кешеләр йоклыйлар, үлгәч уяналар».

Арткы ягы:
1) «Безнең Коръән
2) укырга телебез юк,
3) сәдака бирергә
4) дә көчебез юк».

Таш үлчәмнәре: 82(96)х35х11.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 8 б. №71.

40. Гыйбадулла Заһидулла улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәәл-кабри мәрхүм
3) Гыйбадулла Заһидулла
4) углы 1917 сәнәи миладиййә
5) дикәбр 22 рабигыль-әүвәл
6) 21 ндә 1360 сәнәи һиҗриййәдә
7) 50 йәшендә дарел-бәкайә
8) рихләт кыйлды рахимәһ-
9) -үллааһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлыңгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Гыйбадулла Заһидулла
4) улы, милади 1917 елның
5) 22 декабрендә, һиҗри 1360 елның
6) 21 рабигыль-әүвәлендә
7) 50 яшендә мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ аны
9) киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 106х32х11.

41. Бибикамилә Мөхәммәдгали кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Бибикамилә Мөхәммәд-
3) -гали кызы Хәбиб-
4) -улла зәүҗәсе
5) 50 йәшендә
6) 1920 сәнәи миладиййә
7) 26 нчы гыйнвар».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада идеңез
3) йад тәсаддыклә
4) кыйлуңыз ру-
5) -хымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бибикамилә Мөхәммәд-
3) -гали кызы – Хәбиб-
4) -улла хатыны –
5) 50 яшендә
6) милади 1920 елның
7) 26 гыйнварында [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә
3) алыгыз. Сәдака бирү белән
4) рухымны
5) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 94(100)х30х10.

42. Бибитаййибә Әхмәд кызына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Бибитаййибә Әхмәд

3) кызы 26 йәшендә
4) 1922 йылда ийүн 7
5) вафат
6) рахимәһәәллаһү Тәгаалә
7) рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Габдеррахман зәүҗәсе».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллаһү зүнүүбәһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Бибитаййибә Әхмәд
3) кызы 26 яшендә
4) 1922 елның 7 июнендә
5) вафат.
6) Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте
7) белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Габдрахман хатыны».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 93(102)х30х13.

43. Әхмәдгали Гайнулла улына куелган кабер ташы, 1927 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабернең ийәсе
3) Әхмәдгали Гайнулла
4) углы вафат вакыты
5) тарих милади белә
6) 1927 нче йыл
7) 6 нчы март».

Уң ягы (уеп язылган): «Урыныйны җәннәт кылгай иде амин»[76].

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ Тәгалә каберине нурлы»[77].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Тарих һиҗри белә
2) 1345 нче йыл 2 нче
3) рамазан шәриф
4) йәкшәнбә көн
5) мәдфүн 48 йәшендә».

[76] Башы сул ягында.
[77] Дәвамы уң ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабернең иясе:
3) Әхмәдгали Гайнулла
4) улы, вафат вакыты:
5) милади белән
6) 1927 елның
7) 6 марты».

Уң ягы: «Урынын җәннәт итсә иде, амин».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә каберен нурлы».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән
2) 1345 елның 2
3) рамазан шәрифендә
4) якшәмбе көн
5) 48 яшендә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 74(84)х28х7.

Олы Бәрәзә авылы зираты

1. Хәерниса Фәйзулла кызына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) Хәйренниса Фәйзулла кызы
3) Мөхәммәдсадыйк зәүҗәсе
4) миладиййә 1917 сәнә агуст
5) 18 ндә 68 йәшендә вафат
6) Аллаһ Тәгалә рәхмәт кылсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә идеңез рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Хәерниса Фәйзулла кызы –
3) Мөхәммәдсадыйк хатыны –
4) милади 1917 елның 18
5) августында 68 яшендә вафат.
6) Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Сул ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 86х30х12.

4) шәүвәлендә изге хатын Биби-
5) -гафифәҗан Тимербулат кызы –
6) Олы Мәңгәрдән Төхфәтулла хатыны –
7) 73 яшьтә дүшәмбе көн
8) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
9) күчте. Аллаһ рәхмәте һәм юмартлыгы белән иминлек
10) йортына [җәннәткә] кертсә иде».

Уң ягы:
1) «Җиһанда тәкъдир кәсәсе су бирүче әҗәлме,
2) котылу юк һич кешегә, һичкайчан.
3) Кешеләр татлы эчемлек эчеп утырудан вәхи,
4) башка кәсә, башка су бирүче башкамы».

Сул ягы:
1) «Бервакыт әҗәл гомернең итәген төшерер,

[100] Әхмәтҗанов М. Олы Мәңгәр авылы тарихы / М. Әхмәтҗанов. – Казан: Идел-пресс, 2000. – Б.34.

2) караңгы җирдә бәйләгән урынныннан колны ычкындырыр.
3) Я, Раббы, бу юлларны укыган һәм мәет өчен
4) дога кылган кешенең иманын сакла».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «һәр җан иясе үлемне татыячак». Бу –
3) Бибигафифәжан бинте Тимер-
4) -булат – Төхфәтулла
5) Мәнңәри хатыны – кабере. Милади 1889
6) ел арслан йолдызлыгының беренче
7) көнендә, һиҗри 1306
8) елның унбишенче
9) шәүвәлендә дүшәмбе көн вафат булды. җитмеш өч
10) ел яшәде. Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте, юмартлыгы
11) белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 127x36x27.

3. Төхфәтулла Хәмид улы Сәлимҗановка куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1893
3) сәнә април 18 ндә һиҗри
4) 1310 сәнә шәүвәл 18 ндә Олуг
5) Мәнңәрнең хаҗҗел-хәрәмәйен
6) Төхфәтулла Хәмид углы
7) Сәлимҗаныф йәкшәнбә көн
8) даре бәкайә рихләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (калкытып язылган): «Таййибәллаһү сәраһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ әәмиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабруль-хәәҗҗи Төхфәтулла
2) бине Хәмид Сәлимҗаныф
3) әл-Мәнңәри гафийә ганһүл-Мәлик-
4) -үл-Гаалии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «һәр җан иясе
2) үлемне татыячак». Милади 1893
3) елның 18 апрелендә, һиҗри
4) 1310 елның 18 шәүвәлендә Олы
5) Мәңгәрдән хаҗи
6) Төхфәтулла Хәмид улы
7) Сәлимҗанов якшәмбе көн
8) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Аллаһ Тәгалә аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Бу – хаҗи Төхфәтулла
2) бине Хәмид Сәлимҗанов
3) Мәңгәри кабере. Патша, Олуг зат аны
4) кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 110x37x21.

4. Габделхәким Халид улына куелган кабер ташы, 1885 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт тарих һиҗрииййәнең мең өч
3) йөз икенче сәнә рәҗәбнең алтынчы көнендә
4) милади берлә меңдә сигез йөз сиксән бишенче
5) йыл тугызынчы април сиһшәнбә көн Олуг Мәнгәр-
6) -нең Габделхәким Халид углы бу би вафа-
7) -ны тәрк идүб даре икамәткә интикаль
8) итдe алтмыш ике йәшдә иннәә лилләәһи
9) вә иннәә иләйһи рааҗигуун Хак Сөбханәһү вә Тәгалә
10) гарикы рәхмәт идүб ликасыйлә мөшәрраф әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Җәзәәллаһү ганнәәл-мәүтә хайран фә-иннәһү әбәрру бинәә мин вәәлидәйнәә вә әръәф».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Габделхәким бине Халид әл-Мәнңәри
2) гафийә ганһүл-Бәәрии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «һәр җан иясе
2) үлемне татыячак». Һиҗри мең өч-
3) -йөз икенче ел рәҗәбенең алтынчы көнендә,
4) милади белән мең дә сигез йөз сиксән бишенче
5) елның тугызынчы апрелендә сишәмбе көн Олы Мәнгәр-

6) -нең Габделхәким Халид углы алтмыш ике яшьтә
7) бу тугры булмаган дөньяны калдырып,
8) басып тору урынына күчте. Чынлыкта, без Аллаһныкы
9) һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз. Хак Сөбханәһү вә Тәгалә
10) рәхмәткә күмеп, очрашуы белән хөрмәтләсен».

Уң ягы: ««Аллаһ безгә хәерле үлем бирсен, чынлыкта, Ул – безне ата-анадан да ныграк Яратучы һәм иң нык Кайгыртучы».

Арткы ягы:
1) «Габделхәким бине Халид Мәңгәри
2) Юктан бар итүче [Аллаһ] аны кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 128(155)х50х25.

5. Зәйнәб Габделвәли Бакиров кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһил-галиий-
2) -ил-кәбиир 1899 сәнә гыйнвар
3) 13 ндә һиҗри 1316 сәнә
4) рамазан 14 ндә Олуг Мәнңә-
5) -рнең Зәйнәб Габделвәли
6) Бакируф кызы 7 йәшдә
7) чәһаршәнбә көн даре бәкайә
8) рихләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (калкытып язылган): «Аллаһ шәфәгатен мөйәссәр әйләсүн амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабруль-мәгъсууәти Зәйнәб
2) бинте Габделвәли Бакируф әл-Мәнңә-
3) -ри гафийә ганһүл-Мәликүл-Бәәрии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Олуг, Бөек
2) Аллаһта. 1899 елның 13
3) гыйнварында, һижри 1316 елның
4) 14 рамазанында Олы Мәңгә-
5) -рдән Зәйнәб Габделвәли
6) Бакиров кызы 7 яшьтә
7) чәршәмбе көн мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Аллаһ шәфәгатен насыйп итсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Бу – гөнаһсыз Зәйнәб
2) бинте Габделвәли Бакиров Мәңгә-
3) -ри кабере. Патша, Юктан бар итүче [Аллаһ] аны кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 114(125)х36х17.

6. Бибигарифә Халид Бакиров кызына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән руми 1900 сәнә
3) гыйнвар 13 ндә һиҗри 1317 сәнә
4) рамазан шәриф 24 ндә
5) Олуг Мәнңәрнең Бибигарифә
6) Халид Бакируф кызы Оры
7) авылының Әхмәҗән Габдессәлам
8) углы Мәмәтеф зәүҗәсе 77
9) йәшдә пәнҗешәнбә көн даре
10) бәкайә рихләт әйләде».

Уң ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (уеп язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабру Бибигарифә бинте Халид
2) Бакируф әл-Мәнңәри хәлиләи
3) Әхмәҗән бине Габдессәлам Мәмәтеф
4) әл-Оруви».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы
2) һәркем, һәрнәрсә фани. Милади 1900 елның
3) 13 гыйнварында, һиҗри 1317 елның
4) 24 рамазан шәрифендә
5) Олы Мәңгәрдән Бибигарифә
6) Халид Бакиров кызы – Оры
7) авылыннан Әхмәҗән Габдессәлам
8) улы Мәмәтов хатыны – 77
9) яшьтә пәнҗешәмбе көн мәңгелек
10) дөньяга күчте».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Арткы ягы:
1) «Бу – Бибигарифә бинте Халид
2) Бакиров Мәңгәри – Әхмәҗҗан
3) бине Габдессәлам Мәмәтов Оруви
4) хатыны – кабере».

Таш үлчәмнәре: 136(147)х36х19.

Әлеге кабер иясенең ире Чар (Царевокошайск) өязенең 2 гильдияле сәүдәгәре булган. Әхмәҗҗан бине Габдессәлам бине Гали бине Шәриф бине Рахманкол бине Бикбулат бине Килмәмәт бине Морзагилдә бине Мәмәт (Мөхәммәд)[101], 1901 елның 22 июнендә вафат булып, Арча районы Түбән Оры авылы зиратында җирләнгән. Без аның кабер ташын шунда таптык[102].

7. Бибихәдичә Мөхәммәдшәриф Адәмев кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү
2) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) руми 1907 сәнә ийүл
4) 18 ндә һиҗри 1321 сәнә
5) 1 рәҗәбдә Бибихәдиҗә Мөхәммәд-
6) -шәриф Адәмеф кызы
7) Габделхәким Бакируф
8) зәүҗәсе 80 йәшдә»[103].

Уң ягы (уеп язылган): «Әййүһәәл-вәәкыйфү бил-кабри гыйшәәьән вә сәхәр иннә фил-кабри гыйзаамән бәәлийәәтин вә гыйбәр».

Сул ягы (калкытып язылган):
1) «Даре бәкайә рихләт
2) кылды тайййибәллаahү
3) сәраahәә вә җәгал-
4) -әл-җәннәтә мәсвәәhәә»[104].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бибихәдиҗә бинте Мөхәммәдшәриф
2) Адәмеф хәлиләи Габделхәким
3) Бакируф мәәтә 1907 сәнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр
2) җан иясе үлемне татыячак».
3) Милади 1907 елның 18
4) июлендә, һиҗри 1321 елның
5) 1 рәҗәбендә Бибихәдичә Мөхәммәд-
6) -шәриф Адәмев кызы –
7) Габделхәким Бакиров
8) хатыны – 80 яшьтә».

Уң ягы: «Әй, кич һәм иртән кабер янында басып торучы, чынлыкта, кабердә чергән сөякләр һәм гыйбрәтләр бар».

Сул ягы:
1) «мәңгелек дөньяга
2) күчте. Аллаһ аның туфрагын
3) яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын
4) җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Бибихәдичә бинте Мөхәммәдшәриф
2) Адәмев – Габделхәким Бакиров
3) сөеклесе – 1907 елда вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 122(141)х36х22.

8. Зыяддин мулла Габденнәгыйм улына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә 1908 сәнә
2) април 21 дә гарәби 1326 сәнә
3) Зыяэддин мулла Габденнәгыйм
4) углы Олуг Мәнңәрдә 15 сәнә
5) дәәгыый иләәллаah улуб 35 йә-
6) -шләрдә бәкайә рихләт кылды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мөхәммәдшәриф бине Әхмәҗҗан
2) Бакируф бина кылдурды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән. 1908 елның
2) 21 апрелендә, һиҗри 1326 елда
3) Зыяддин мулла Габденнәгыйм
4) улы, Олы Мәңгәрдә 15 ел
5) Аллаһка чакырып, 35 я-
6) -шьләрдә мәңгелеккә күчте».

[101] Салихов Р.Р. Служилая Ура: рождение татарского капитализма / Р.Р. Салихов. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015. – С. 226–242.
[102] Гайнетдинов А.М. Арча районы эпиграфик истәлекләре / А.М. Гайнетдинов. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2016. – Б. 274.
[103] Дәвамы сул ягында.
[104] Башы алгы ягында.

Арткы ягы:
1) «Мөхәммәдшәриф бине Әхмәҗән
2) Бакиров куйдырды».

Таш үлчәмнәре: 88(98)х31х12.

9. Хөснеҗамал Зиннур кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәһ
2) мәрхүмә Хөснеҗамал
3) Зиннур кызы
4) 1333 сәнәи һиҗриййә
5) 1914 сәнәи миладиййә
6) 75 йәшендә
7) Әхмәдулла хаҗи зәүҗә-
8) -се 7 нче фибралда
9) җомга көн вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта гына.
2) Мәрхүмә Хөснеҗамал
3) Зиннур кызы –
4) Әхмәдулла хаҗи хатыны –
5) һиҗри 1333 елда,
6) милади 1914 елның
7) 7 февралендә
8) 75 яшендә
9) җомга көн вафат».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 106х34х10.

10. Хәкимҗан Мөхәммәҗән улы Салиховка куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Хәкимҗан Мөхәммәд-
3) -җан углы
4) Салихыф 60 йә-
5) -шендә вафат
6) 1920 сәнәи миладиййә».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Арткы ягы (уеп язылган): «7 нҗе гыйнварда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Хәкимҗан Мөхәммәд-
3) -җан улы
4) Салихов 60 я-
5) -шендә милади
6) 1920 елда вафат».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Арткы ягы: «7 гыйнварда [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 71х31х7.

11. Рөстәм Лотфи Гасыйм Лотфи улына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1925 Рәстәм Лотфи
2) укытучы Гасыйм Лотфи баласы
3) 1924 нче җыл агуст 5 ндә тууб
4) 1925 нче җыл агуст 17 ндә
5) үлде дөнйада барлык»[105].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) торувы бер җыл 12 көн
3) төб авылы Иске Өҗүм»[106].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1925 [ел]. Рөстәм Лотфи
2) укытучы Гасыйм Лотфи баласы,
3) 1924 елның 5 августында туып,
4) 1925 елның 17 августында
5) үлде. Дөньяда барлык».

Арткы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) торуы: бер ел һәм 12 көн.
3) Төп авылы: Иске Өҗем».

Таш үлчәмнәре: 66х28х9.

[105] Дәвамы арткы ягының ахыргы ике юлында.
[106] Ахыргы ике юлның башы алгы ягында.

Әлеге кабер иясенең атасы Гасыйм Фатих улы Лотфуллин педагог, дәреслекләр авторы, тәрҗемәче, балалар язучысы булган.

12. Габделгазиз мулла Мөхәммәдъюныс дамелла Зыяддин улының улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Габделгазиз Олуг Мәнгәр-
2) -нең имам Мөхәммәдъюныс
3) дамелла Зыяэддин углы-
4) -ның углы 1904 сәнә румиййә
5) май 25 нҗе көнендә дәфен
6) идилде җәгаләллаһү кабраһү
7) раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Кятиб Мулла илендә
2) мөәзин Фәтхелкадыйр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Габделгазиз Олы Мәңгәр-
2) -дән имам Мөхәммәдъюныс
3) дамелла Зыяддин улы-
4) -ның улы милади 1904 ел
5) маеның 25 нче көнендә
6) җирләнде. Аллаһ каберен җәннәт
7) бакчаларыннан бер бакча итсен».

Сул ягы:
1) «Язучы: Мулла иленнән
2) мөәзин Фәтхелкадыйр».

Таш үлчәмнәре: 69х37х16.

Әлеге кабер иясенең кыскача шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габделгазиз бине Мөхәммәдъюныс бине Зыяддин бине Мөхәммәдкамал Арсланов. Атасы 1890 елның 28 сентябреннән, бабасы 1865 елдан бирле авылның икенче мәхәллә мәчетендә имам-хатыйб вазыйфасын башкарган[107].

13. Бибиәминә мулла Габделмәлик кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун
2) мәрхүмә Бибиәминә
3) мулла Габделмәлик
4) кызы 3 йәшендә
5) 1902 нче йылда 1 нче
6) рамазан шәрифдә».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһның рәхмәтендә улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Мәрхүмә Бибиәминә
3) мулла Габделмәлик
4) кызы 3 яшендә
5) 1902 елның 1
6) рамазан шәрифендә [вафат яки җирләнде]».

Сул ягы: «Аллаһның рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 68х29х13.

14. Бибигарифә Бикбау кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә
3) Бибигарифә Бикбау кызы
4) 1903 нче йылда
5) 5 нче нуйәбрдә
6) дарел-фәнадан
7) дарел-бәкайә
8) рихләт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Бибигарифә Бикбау кызы
4) 1903 елның
5) 5 ноябрендә
6) фани дөньядан
7) мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Таш үлчәмнәре: 77х31х12.

15. Бибирабига Зыяддин кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании

[107] Башкортстан Республикасы Милли архивы: И–295 ф., 2 тасвир., 2 сак. берәм.

2) бу кабергә дахилә ахирәт мәнзилигә назилә
3) Бибирабига бинте Зыяэддин дамелла Зыяэддин
4) хәзрәт әһлийәсе һиҗриййә иләи
5) 1316 нчы сәнә җөмадиәл-ахир 17 нче
6) йәүмендә 55 йәшендә йәкшәнбә көн мәдфүн
7) рахимәһүллаahү[108] рахмәтән вәәсигаh әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Һәр кем итсә минем өчүн Аллаh рәхмәт әйләсүн Хак Тәгалә ул кешене әһле җәннәт әйләсүн».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Галәмәтдән морадыйм бер догадыр
2) бу көн бәңа икән йарин сәңадыр
3) кәрәм әйләб догада идеңез йад
4) тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаh рәхим кылсын.
2) Бу кабергә керүче, ахирәт йортына иңүче
3) Бибирабига бинте Зыяддин – дамелла Зыяэддин
4) хәзрәт хатыны – һиҗри белән
5) 1316 ел җөмадиәл-ахиренең 17 нче
6) көнендә 55 яшендә якшәмбе көн җирләнде.
7) Аллаh аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Һәркем минем өчен [дога] кылса, Аллаh рәхим кылсын. Хак Тәгалә ул кешене җәннәт иясе итсен».

Сул ягы:
1) «Галәмәттән морадым бер догадыр,
2) бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр.
3) Юмартлык кылып, догада искә алыгыз.
4) Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 110(117)x34x14.

16. Бибимәфтуха Әхмәҗҗан Бакиров кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1898 сәнә
3) април 2 ндә һиҗри 1315 сәнә
4) зөлхиҗҗә 11 ндә Олуг Мәнңәр-
5) -нең Бибимәфтуха Әхмәҗҗан Бакируф
6) кызы Габделвәли Габделхәким
7) углы Бакируф хәлиләсе»[109].

Уң ягы (уеп язылган): «Гыйбрәтилә бак җиһанә күр ки бу вәйранәләр нә хараб улмыш йатур һәр бере абад әнкен».

Сул ягы (калкытып язылган): «41 йәшдә дүшәнбә көн даре бәкайә рихләт кылды тайййибәллаahү сәраahәә» [110].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабру Бибимәфтуха бинте Әхмәҗҗан
2) Бакируф хәлиләи Габделвәли бине
3) Габделхәким әл-Мәнңәри гаашә 41 сәнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1898 елның
3) 2 апрелендә, һиҗри 1315 елның
4) 11 зөлхиҗҗәсендә Олы Мәңгәр-
5) -дән Бибимәфтуха Әхмәҗҗан Бакиров
6) кызы – Габделвәли Габделхәким
7) улы Бакиров сөеклесе».

Уң ягы: «Гыйбрәт белән кара җиһанга, күр ки бу җимерелүләр, ниләр харап булган, ятар һәрберсе мәңгелеккә».

Сул ягы: «41 яшьтә дүшәнбә көн мәңгелек дөньяга күчте. Аллаh аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Арткы ягы:
1) «Бу – Бибимәфтуха бинте Әхмәҗҗан
2) Бакиров – Габделвәли бине Габделхәким
3) Мәңгәри сөеклесе – кабере, 41 ел яшәде».

Таш үлчәмнәре: 116x40x21.

17. Бибимәфтуха Гобәйдулла Хәмидулла улының кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә

[108] Хатын-кызга куелган таш булса да, ир-атка карата кулланыла торган кушымчалар белән язылган. Андый хаталар ташъязмаларда, сирәк булса да, очрый.

[109] Дәвамы сул ягында.

[110] Башы алгы ягында.

2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә
3) Бибиәфтуха Гобәйдулла Хәмид-
4) -улла углыйның кызы 1899
5) нчы йылда 6 нчы гыйнварда
6) 65 йәшендә вафат
7) булган Аллаһ гарикы
8) рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Васыйәтем будыр фәрзәнд гакыйл
2) кәрәм әйләб бәнга даим дога кыйл».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Уйан бу йан бакыб дога көтәрмез
2) хәйер ихсан дәхи өмид итәрмез».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Бибиәфтуха Гобәйдулла Хәмид-
4) -улла улының кызы 1899
5) елның 6 гыйнварында
6) 65 яшендә вафат
7) булган. Аллаһ рәхмәткә
8) күмсен».

Уң ягы:
1) «Васыятем будыр, акыллы балам:
2) юмартлык кылып, миңа даими [рәвештә] дога кыл».

Сул ягы:
1) «Ул якка, бу якка карап, дога көтәрбез,
2) хәер-изгелек шулай ук өмет итәрбез».

Таш үлчәмнәре: 82x31x11.

18. Халид Әбүбәкер улына куелган кабер ташы, 1867 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) тарих румиййә илә 1867
3) нче сәнә 15 нче ийүлдә һиҗриййә
4) илә 1283 йылда маһе рабиг-
5) -ыль-әүвәлдә Олуг Мәннәрнең
6) Халид Әбүбәкер углы 83
7) йәшдә шинбә көн даре
8) ахирәтә интикаль әйләде».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Халид бине Әбүбәкер әл-Мәннәри
2) галәйһи рахмәтүл-бәәрии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади белән 1867
3) елның 15 июлендә, һиҗри
4) белән 1283 елның рабиг-
5) -ыль-әүвәл аенда Олы Мәңгәрдән
6) Халид Әбүбәкер улы 83
7) яшьтә шимбә көн ахирәт
8) йортына күчте».

Арткы ягы:
1) «Халид бине Әбүбәкер Мәңгәри.
2) Аңа Юктан бар итүче [Аллаһның] рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 87(129)x36x20.

19. Дамелла Зыяддин Мөхәммәдкамал улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ салләәллааһү галәйһи вә сәлләм
2) милади 1918 нче сәнә
3) 27 нче гыйнварда
4) 90 йәшендә сәнә камәриййә илә[111]
5) дамелла Зыяэддин
6) Мөхәммәдкамал углы дәфен
7) иделде».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәңа икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Гафәраллааһү ли-саахиби
2) һәзәәл-кабри вә ли-мән зәәра
3) җәмиига зүнүүбиһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен).
2) Милади 1918 елның
3) 27 гыйнварында
4) 90 яшендә, һиҗри белән
5) дамелла Зыяддин
6) Мөхәммәдкамал улы
7) җирләнде».

Уң ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

[111] Болай язылса да, һиҗри елы күрсәтелмәгән.

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ бу кабер иясенең
2) һәм [аны] зиярәт кылган кешенең бөтен
3) гөнаһларын гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 103х34х13.

Әлеге кабер иясе Зыяддин Мөхәммәдкамал улы Арсланов 1865 елның 22 февралендә указ (указ номеры – №12702) алып, икенче мәхәллә мәчетендә муллалык вазыйфасын үтәгән. Чыгышы белән хәзерге Арча районы Яңа Кенәр авылыннан.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 9 б. №76.

20. Нурмөхәммәд Хәсән улы Шәфиевкә куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбрah
2) Нурмөхәммәд бине
3) Хәсән Шәфийев
4) 1869 нчы сәнә Казан
5) шәһәрендә туган
6) 1926 нчы сәнә 18 нче
7) априлдә вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әхляфе
2) заирин-
3) -дән мөтәва-
4) -зыйган дога
5) үтенәләр
6) җәгаләллаahү кабрahү раудатән
7) мин рийәәдыйль-җәннәh».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Нурмөхәммәд бине
3) Хәсән Шәфиев
4) 1869 елда Казан
5) шәһәрендә туган,
6) 1926 елның 18
7) апрелендә вафат».

Арткы ягы:
1) «Яңа буын
2) зиярәт
3) кылучылардан түбәнчелек
4) белән дога
5) үтенәләр.
6) Аллаһ аның каберен җәннәт
7) бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 101х33х11.

21. Сәфәргали Халид улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәh
2) бу каберә назил улмыш
3) Сәфәргали Халид у-
4) -глы 87 йәшендә румиййә
5) илә 1905 нче йылда 25
6) априлдә һижриййә
7) илә 1323 нче йылда 4
8) нче рабигыль-әүвәл дүшәнбә
9) көн һижрәт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Бакый ирмәс һичдә йук карары»[112].

Сул ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары»[113].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә
3) Сәфәргали Халид у-
4) -лы иңде, 87 яшендә милади
5) белән 1905 елның 25
6) апрелендә, һижри
7) белән 1323 елның 4
8) рабигыль-әүвәлендә дүшәмбе
9) көн күчте».

Уң ягы: «Мәңге булмас һич тә, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән».

Таш үлчәмнәре: 91х31х11.

22. Габделкоддүс Хуҗаәхмәд улына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh руми
2) 1908 сәнә гыйнвар 22 дә
3) һижри 1326 сәнә мөхәррәм

[112] Башы сул ягында.
[113] Дәвамы уң ягында.

4) 1 дә Олуг Мәңгәрдә
5) Габделкоддүс Хуҗа-
6) -әхмәд углы 54 йәшдә»[114].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Даре бәкайә рихләт кылды
2) таййибәллаһү сәраһү вә җәгаләл-
җәннәтә
3) мәсвәәһ»[115].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта. Милади
2) 1908 елның 22 гыйнварында,
3) һиҗри 1326 елның 1
4) мөхәррәмендә Олы Мәңгәрдә
5) Габделкоддүс Хуҗа-
6) -әхмәд улы 54 яшьтә».

Арткы ягы:
1) «мәңгелек дөньяга күчте.
2) Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел]
кылсын һәм урынын
3) җәннәт итсен».

Таш үлчәмнәре: 88(109)x31x10.

23. Хәерниса Мөхәммәдшәриф кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) Хәйренниса Мөхәммәдшәриф кызы
3) мулла Мөхәммәҗән зәүҗәсе 71
йәшендә
4) даре бәкайә күчде кабере
5) раудатүн мин рийәәдыйль-җәннәһ
улсун
6) үктәбр 15 ндә 1912 сәнәдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Хәерниса Мөхәммәдшәриф кызы –
3) мулла Мөхәммәҗән хатыны – 71
яшендә
4) 1912 елның 15 октябрендә
5) мәңгелек дөньяга күчте. Кабере
6) җәннәт бакчаларыннан бер бакча
булсын».

Таш үлчәмнәре: 95(105)x31x13.

[114] Дәвамы арткы ягында.
[115] Башы алгы ягында.

24. Мортаза Мостафа улы Дәминевкә куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Мортаза Мостафа углы
4) Дәминеф 1912 сәнәи руми
5) 16 нчы март 1330 сәнәи
6) һиҗриййә рабигыль-ахир 11
7) ндә җомга көн 28
8) йәшдә вафат Аллаһ рәхмәт»[116].

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән әнтә тәсыыйру мислии»[117].

Сул ягы (уеп язылган)[118]:
1) «Йәә вәәкыйфән би-кабрии
мүтәфәккиран фии әмрии
2) әйләсүн
3) амин»[119].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Мортаза Мостафа улы
4) Дәминев милади 1912 елның
5) 16 мартында, һиҗри 1330
6) елның 11 рабигыль-ахирендә
7) җомга көн 28
8) яшьтә вафат. Аллаһ рәхим [кылсын]».

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем,
иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы:
1) «Әй, каберем янында басып торучы,
минем эшем хакында фикерләүче.
2) [Рәхим] кылсын
3) амин».

Таш үлчәмнәре: 115x33x15.

25. Ибраһим Вәлиәхмәд улы Дәминевкә куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) Ибраһим бине Вәлиәхмәд

[116] Дәвамы сул ягының ахыргы ике юлында.
[117] Башы сул ягының беренче юлында.
[118] Беренче юлы вертикаль, калган юллары горизонталь рәвештә язылган.
[119] Беренче юлының дәвамы уң ягында, калган юлларының башы алгы ягында.

3) Дәминеф 15
4) йәшендә 1330 сәнәи һиҗриййә
5) рамазан шәриф 1 ндә
6) 1912 сәнәи румиййә агуст
7) берендә дәфен иделде
8) рахимәһүллаһү Тәгаалә
9) рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Һәр нә дәклү улса да гомерең тавил»[120].

Сул ягы (уеп язылган)[121]:
1) «Гакыйбәт бер көн әҗәл әйләр галил
2) кятиб
3) Фәтхелкадыйр
4) әл-Казани»[122].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Ибраһим бине Вәлиәхмәд
3) Дәминев 15
4) яшендә һиҗри 1330 елның
5) 1 рамазан шәрифендә,
6) милади 1912 елның беренче
7) августында җирләнде.
8) Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте
9) белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Ни тиклем гомерең озын булса да».

Сул ягы:
1) «Ахырдан беркөн әҗәл хәлсез итәр
2) Язучы:
3) Фәтхелкадыйр
4) Казани»[123].

Таш үлчәмнәре: 129(138)х40х20.

26. Габделхаликъ Габделхәмид улына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-Бәәкыый
2) Габделхаликъ
3) Габделхәмид
4) углы ...
5) йәшендә
6) 1914 сәнә румиййә
7) гыйнвар 13 ндә
8) вафат рахимәһ-
9) -үллаһү рахмәтән
10) вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәраллаһү зүнүүбәһ».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Нәүвәраллаһү
2) мәркадәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Габделхаликъ
3) Габделхәмид
4) улы ...
5) яшендә
6) милади 1914 елның
7) 13 гыйнварында
8) вафат. Аллаһ аны
9) киң рәхмәте белән
10) рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».

Сул ягы:
1) «Аллаһ аның каберен
2) нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 108х34х18.

27. Бибигалимә Фазлулла кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллаһ Мүхәммәдүр-расүүлүллаһ салләәллаһү галәйһи вә сәлләм
2) 1915 нче йылда
3) ийүннең 15 ндә
4) 28 йәшендә Бибигалимә
5) Фазлулла кызы
6) Гариф җәмәгате вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа».

Сул ягы (уеп язылган): «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен).

[120] Дәвамы сул ягында.
[121] Беренче юлы вертикаль, калганнары горизонталь рәвештә язылган.
[122] Беренче юлының башы уң ягында.
[123] Башы уң ягында.

2) 1915 елның
3) 15 июнендә
4) 28 яшендә Бибигалимә
5) Фазлулла кызы –
6) Гариф җәмәгате – вафат».

Уң ягы: «Үлем вәгазьче буларак җиткән».

Сул ягы: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».

Таш үлчәмнәре: 74x29x12.

28. Шәфигылкамал Биктаһир кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) бу кабергә назилә Шәфигылкамал
3) Биктаһир кызы Мостафа Дәминеф
4) әһлийәсе һиҗриййә илә 1321 сәнә
5) 57 йәшендә рамазан 24 нче йәүмендә
6) мәдфүнә рахимәһәллаһү Тәгаалә ааамиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадыйм бер догадур бу көн бәңа икән йарын сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә иңүче Шәфигылкамал
3) Биктаһир кызы – Мостафа Дәминев
4) хатыны – һиҗри белән 1321 ел
5) рамазанының 24 нче көнендә 57 яшендә
6) җирләнде. Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз. Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 101x32x14.

29. Сабиржан Мостафа улы Дәминевкә куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) бу мәнзиле ахирәтә назил улды Сабиржан
3) бине Мостафа Дәминеф гомер газизләре 47 йыл улмыш
4) рахимәһүллаһү рахмәтән вәәсигаһ маһе рамазанның сигезендә
5) һиҗриййә илә 1328 нче йылда румиййә меңдә тугыз йөздә 10 нчы йылда аугыст 30 нда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мадамики җан нәсдәдер
3) бу көн бел форсат сәндәдер
4) Хак закире хас бәндәдер
5) көлле форсаты фәүт әйләр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу ахирәт йортына Сабиржан
3) бине Мостафа Дәминев иңде, газиз гомерләре 47 ел булды.
4) Һиҗри белән 1328 елның сигезенче рамазанында,
5) милади мең дә тугыз йөздә унынчы елның 30 августында [вафат яки җирләнде]. Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Чынлыкта, җан нәрсәдер,
3) бел: бүген форсат синдәдер.
4) Хакны [Аллаһны] искә алучы бәндәдер,
5) һәр форсатны үлем алыр».

Таш үлчәмнәре: 96(105)x44x20.

30. Мостафа Мөхәммәдшәриф улы Дәминевкә куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-Бәәкыый
2) Мостафа Мөхәммәдшәриф
3) углы Дәминеф 87
4) йәшендә 1332 сәнәи һиҗриййә
5) зилхиҗҗә 12 ндә
6) 1913 сәнәи румиййә үктәбр
7) 30 нда дәфен ителде
8) рахимәһүллаһү Тәгаалә
9) рахмәтән вәәсигаһ
10) ааамиин
11) кятиб Кәлмитуф Казанда».

Уң ягы (уеп язылган): «Җәгаләллаһү кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Ләә тәзкүруу әмвәәтәкүм илләә бил-хайр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Мостафа Мөхәммәдшәриф
3) улы Дәминев 87
4) яшендә һиҗри 1332 елның
5) 12 зөлхиҗҗәсендә,
6) милади 1913 елның 30
7) октябрендә җирләнде.
8) Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте
9) белән рәхим кылсын,
10) амин.
11) Язучы: Казаннан Кәлмитев».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Сул ягы: «Мәетләрегезне яхшы яктан гына искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 115х36х18.

Әлеге кабер иясе шулхәтле абруйлы бай булган ки, хәтта аның үлеме хакында «Кояш» газетасында да хәбәр ителгән: җеназасында бөтен тирә-як галимнәре, дин әһелләре җыелды, дип язганнар[124].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 9 б. №77.

31. Шаһиәхмәд Мостафа улы Дәминевкә куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-Бәәкыый
2) Шаһиәхмәд
3) Мостафа углы
4) Дәминеф
5) 75 йәшендә
6) 1341 сәнәи һиҗриййә
7) җөмадиәл-ахир 23
8) 1923 сәнә гыйнвар 25
9) вафат Аллаһ рәхмәт
10) кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаһү мәркадәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллаһү зүнүүбәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Мәңге.
2) Шаһиәхмәд
3) Мостафа улы
4) Дәминев
5) 75 яшендә
6) һиҗри 1341 елның
7) 23 җөмадиәл-ахирендә,
8) 1923 елның 25 гыйнварында
9) вафат. Аллаһ рәхим
10) кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 93х33х16.

32. Өммегөлсем мулла Мөхәммәдҗан Габделкәрим улы Дәминевнең кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү
2) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) руми 1899 сәнә дикәбр
4) 28 ндә һиҗри 1317 сәнә
5) рамазан 7 ндә Олуг
6) Мәнңәрнең Өммегөлсүм
7) Бохари мулла Мөхәммәдҗан
8) Габделкәрим углы Дәминүф»[125].

Уң ягы (калкытып язылган): «Кызы пәнҗешәнбә көн даре бәкайә рихләт кылды»[126].

Сул ягы (уеп язылган): «Таййибәллаһү сәраһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә әәмиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мөхәммәдҗан[127]
2) һәзәә кабру Өммегөлсүм бинте мулла
3) бине Габделкәрим әл-Бохари
4) гафийә ганһәәл-Мәликүл-Гаалии»

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәрбер
2) җан иясе үлемне татыячак.

[124] Кояш. – 1913. – 3 ноябрь (№ 204). – Б. 3.

[125] Дәвамы уң ягында.
[126] Башы алгы ягында.
[127] Бу беренче юл икенче юлның дәвамы.

3) Милади 1899 елның 28
4) декабрендә, һиҗри 1317 елның
5) 7 рамазанында Олы
6) Мәңгәрдән Өммегөлсем
7) Бохарадан мулла Мөхәммәҗҗан
8) Габделкәрим улы Дәминов [кызы]».

Уң ягы: «Кызы пәнҗешәмбе көн мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Бу – Өммегөлсүм
2) бинте мулла Мөхәммәҗҗан
3) бине Габделкәрим Бохари кабере
4) Патша, Олуг зат аны кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 117x45x18.

33. Бибифатыйма Мостафа кызына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән руми 1893 сәнә
3) май 7 ндә һиҗри 1310 сәнә
4) зөлкагдә 2 ндә Олуг
5) Мәнңәрнең Бибифатыйма
6) Мостафа кызы Мөхәммәд-
7) -шәриф Әхмәҗҗан углы-
8) -ның хәлиләсе 22».

Сул ягы (уеп язылган): «Кыйф бил-мәкаабири вәнзур ин вәкафтә биһәә лилләәһи дәррукә мәәзәә тәстүруль-хүфәр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабру Бибифатыйма бинте
2) Мостафа әл-Мәнңәри зәүҗәи
3) Мөхәммәдшәриф бине Әхмәҗҗан
4) рахимәһүмүл-Мәликүл-Мәннәән».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы
2) һәркем, һәрнәрсә фани. Милади 1893 елның
3) 7 маенда, һиҗри 1310 елның
4) 2 зөлкагдәсендә Олы
5) Мәңгәрдән Бибифатыйма
6) Мостафа кызы – Мөхәммәд-
7) -шәриф Әхмәҗҗан улы-
8) -ның сөеклесе 22 [яшендә вафат]».

Сул ягы: «Тукта, әгәр син, туктап, басып торсаң, чокырлар нәрсә яшерә икәнен кара, бу яхшы гамәл булачак».

Арткы ягы:
1) «Бу – Бибифатыйма бинте
2) Мостафа Мәңгәри – Мөхәммәдшәриф
3) бине Әхмәҗҗан хатыны – кабере.
4) Патша, Нигъмәт бирүче [Аллаһ] аларны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 111x37x19.

34. Шәрифҗамал Ибраһим кызына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу кабергә назилә Хак Тәгалә
3) рәхмәтикә васыйлә Шәрифелҗамал
4) Ибраһим кызы Мортаза
5) зәүҗәсе 65 йәшендә рамазан 18 ндә
6) 1891 нче йылда румиййә 15 нче априлдә».

Уң ягы (уеп язылган): «Әл-мәүтү кәәъсүн вә күллү нәәсин шәәрибүһ вәл-кабру бәәбүн вә күллү нәәсин дәәхыйлүһ».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Нәсыйхәт
2) тормас бу форсат тиз күчәр
3) бу җан бер көн кафысдан очар
4) кәлфорсаты фәүт әйләмә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче, Хак Тәгалә
3) рәхмәтенә ирешүче Шәрифҗамал
4) Ибраһим кызы – Мортаза
5) хатыны – 65 яшендә милади 1891
6) елның 15 апрелендә, 18 рамазанында [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Үлем – савыт һәм һәрбер кеше аннан эчәчәк, кабер – ишек һәм һәрбер кеше аннан керәчәк».

Сул ягы:
1) «Нәсыйхәт:
2) тормас бу форсат, тиз күчәр,
3) бу җан беркөнне читлектән очар,
4) форсатны ычкындырма».

Таш үлчәмнәре: 110x36x23.

35. Мулла Мөхәммәджан Мөхәммәдкәрим улы Дәминевкә куелган кабер ташы, 1888 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән тарих румиййә илә
3) 1888 нче сәнә унынчы
4) априлдә һиҗриййә илә 1305
5) сәнәдә Олуг Мәнңәрнең
6) мулла Мөхәммәджан Мөхәммәдкәрим
7) углы Дәминүф 56 йәшдә
8) йәкшәнбә көн мәдфүн улды
9) Бохарада тәхсыйле гыйлем әйләде».

Уң ягы (калкытып язылган):
1) «Мин шәгъбәәни фии йәүм-
2) -ил-әхәди вә кәәнә
3) мүддәтү гумриһи ситтән
4) вә хамсиинә сәнәһ
5) рахимәллаahү Тәгааләә
6) галәйһи рахмәтән вәәсигаһ
7) әәмиин»[128].

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) саахибүл-гыйльми вәл-фәдааил-
3) -ил-мәкъбүүли гыйндә зәвиил-бәсааир-
4) -ил-габдүд-дагыыйфүл-мүхтәәҗү иләә
5) рахмәти Раббиһил-Ләтыыйфи мулла Мөхәммәджан
6) бине Мөхәммәдкәрим Дәминүф
7) әл-Мәнңәри мәүлүдән вәл-Бохари
8) тәхсыйләп түвүффийә сәнәтә 1888
9) бир-руумиййәти вә фии 10 мин априил
10) фии сәнәти 1305 бил-һиҗриййәти фии 9»[129].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы
2) һәркем, һәрнәрсә фани. Милади белән
3) 1888 елның унынчы
4) апрелендә, һиҗри белән 1305
5) елда Олы Мәңгәрдән
6) мулла Мөхәммәджан Мөхәммәдкәрим
7) улы Дәминев 56 яшьтә
8) якшәмбе көн җирләндe.
9) Бохарада гыйлем алды».

Уң ягы:
1) «шәгъбанында
2) якшәмбе
3) көн [вафат]. Гомере
4) 65 ел булды.
5) Аллаһ Тәгалә аны аны киң
6) рәхмәте белән рәхим кылсын,
7) амин».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Галимнәр каршында гыйлем һәм
3) яхшы табылган өстенлекләргә ия булган,
4) зәгыйфь кол, Мәрхәмәтле Раббысының
5) рәхмәтенә мохтаҗ мулла Мөхәммәджан
6) бине Мөхәммәдкәрим Дәминев
7) Мәңгәри (тумышы белән), Бохари
8) (гыйлем алуы белән) милади 1888
9) елның 10 апрелендә,
10) һиҗри 1305 елның 9 [шәгъбанында] вафат».

Таш үлчәмнәре: 129х36х26.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 9 б. №78.

36. Бибигазизә Шәмседдин кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү
2) мән галәйһәә фәән тарих руми 1898 сәнә
3) үктәбр17 ндә һиҗри
4) 1316 сәнә рәҗәб 15 ндә Олу-
5) -г Мәнңәрнең Бибигазизә
6) Шәмседдин кызы
7) Әхмәджан Исхак углы
8) Байазидуф зәүҗәсе»[130].

Уң ягы (калкытып язылган): «65 йәшдә шинбә көн даре бәкайә рихләт кылды»[131].

Сул ягы (уеп язылган): «Тайиибәллаahү сәраahәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә әәмиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабру Бибигазизә бинте
2) Шәмседдин хәлиләи Әхмәджан
3) бине Исхак Байазидуф әл-Мәнгәри».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы

[128] Башы арткы ягында.
[129] Дәвамы уң ягында.
[130] Дәвамы уң ягында.
[131] Башы алгы ягында.

2) һәркем, һәрнәрсә фани. Милади 1898 елның
3) 17 октябрендә, һиҗри
4) 1316 елның 15 рәҗәбендә Олы
5) Мәңгәрдән Бибигазизә
6) Шәмседдин кызы –
7) Әхмәҗән Исхак улы
8) Баязидов хатыны».

Уң ягы: «65 яшьтә шимбә көн мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Бу – Бибигазизә бинте
2) Шәмседдин – Әхмәҗән бине
3) Исхак Баязидов Мәңгәри сөеклесе – кабере».

Таш үлчәмнәре: 114x34x17.

37. Хөббениса Мөхәррәм кызына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабердә Хакга
3) иттисаль әйләде Мәнгәр иленең
4) Хөббениса Мөхәррәм кызы Исхак
5) Байазидыф зәүҗәсе 85 йәшендә
6) рабигыль-әүвәлдә 1309 нчы сәнәдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабердә Хакка [Аллаһка]
3) Мәңгәр иленнән
4) Хөббениса Мөхәррәм кызы – Исхак
5) Баязидов хатыны – 85 яшендә
6) [һиҗри] 1309 елның рабигыль-әүвәлендә иреште».

Таш үлчәмнәре: 139x31/49x17.

38. Хөснежамал Ибраһим кызына куелган кабер ташы, 1862 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Фә-рахимәллаһү имрааъән нәзара ли-нәфсиһи
2) вә мәһһәдә ли-рамсиһ руми 1862
3) сәнә үктәбрдә һиҗри 1280
4) сәнә җөмадиәл-әүвәлдә Хөснелҗамал
5) Ибраһим кызы Олуг Мәнҗә-
6) -рнең Сабит хаҗи зәүҗәсе
7) 30 йәшдә даре фәнадин
8) даре бәкайә рихләт кылды».

Уң ягы (калкытып язылган): «Таййибәллаһү сәраһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә әәмиин».

Сул ягы (уеп язылган): «Гыйбрәтилә бак җиһанә күр ки бу вәйранәләр нә хараб улмыш йатур җөмлә абад әнкен».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабру Хөснелҗа-
2) -мал бинте Ибраһим зәүҗәт-
3) -үл-хәәҗҗи Сабит әл-Мәнгәри
4) гафийә ганһүл[132]-мәликүл-бәәрии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үзен карап, тикшереп торучы һәм каберенә әзерләнүче
2) кешене Аллаһ рәхим кылсын. Милади 1862
3) елның октябрендә, һиҗри 1280
4) елның җөмадиәл-әүвәлендә Хөснежамал
5) Ибраһим кызы – Олы Мәңгә-
6) -рдән Сабит хаҗи хатыны –
7) 30 яшьтә фани дөньядан
8) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Сул ягы: «Гыйбрәт белән кара җиһанга, күр ки бу җимерелүләрне, ниләр харап булган, ятар һәрберсе мәңгелеккә».

Арткы ягы:
1) «Бу – Хөснежа-
2) -мал бинте Ибраһим – хаҗи
3) Сабит Мәңгәри хатыны – кабере.
4) Патша, Юктан бар итүче [Аллаһ] аны кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 130(145)x36x16.

[132] Хатын-кызга куелган таш булса да, ир-атка карата кулланыла торган кушымча белән язылган. Андый хаталар ташъязмаларда, сирәк булса да, очрый.

39. Габдулла Баязид улына куелган кабер ташы, 1863 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт
3) тарих румиййә илә 1863 нче сәнә 15 нче
4) ийүндә һижриййә илә 1280 нче йылда
5) мөхәррәм-
6) -нең унынчы көнендә шинбә көн Олуг
7) Мәнгәрнең Габдулла Байазид углы
8) 75 йәшдә даре бәкайә интикаль
9) итде Хак Тәгалә гарикы рәхмәт
10) идүб мәркаден пөр нур әйләсүн амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак».
3) Милади белән 1863 елның 15
4) июнендә, һижри белән 1280 ел
5) мөхәррәме-
6) -нең унынчы көнендә шимбә көн Олы
7) Мәңгәрдән Габдулла Баязид улы
8) 75 яшьтә мәңгелек дөньяга
9) күчте. Хак Тәгалә рәхмәткә
10) күмеп, каберен нурга күмсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 106х36х22.

40. Бибигөлбадан Габдерәззак мулла кызына куелган кабер ташы, 1858 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгааләә
2) әл-мәрхүүмәтүл-мәгъфүүратү
3) Бибигөлбадан
4) Габдеррәззак мулла кызы Байазид бай
5) хәләле
6) Һибатулла бай Төхфәтулла бай әнкәсе
7) йөз йәшендә
8) тарих мең ике йөз йитмеш бишенче
9) йылда
10) тарих румиййә мең сигез йөз илле
11) сигезенчедә
12) дикәбрнең йегерме йитенче көнендә бу
13) даре фәнадан даре бәкайә рихләт әйләде
14) мәкяне җәннәтдә улгай амин».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әгәр йөз йәшәсәң үлмәк кирәкдер гомернең кадерине белмәк кирәкдер».

Сул ягы (калкытып язылган): «Бибигөлбадан Байазид бай хәләле Габдеррәззак мулла кызы вафат фии сәнәти 1858».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәсайых
2) васыйәтем будыр әүлядларыйма
3) дәхи ихванларыйм әхфадларыйма
4) кәрәм әйләб догада идеңез йад
5) тәсаддыйклә кылуңыз рухымны шад
6) безә Коръән укуб багышлайасыз
7) бу каберә килмәке сагышлайасыз
8) уйан буйан бакуб дога көтәрмез
9) хәйер ихсан дәхи өмид итәрмез
10) әл-мәййитү кәл-гариикуль-
мүстәгыйсү йәнзуруд-дүгааъ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Рәхим кылынган, гафу ителгән
3) Бибигөлбадан
4) Габдерәззак мулла кызы – Баязид бай
5) хәләле –
6) Һибатулла бай, Төхфәтулла бай әнкәсе
7) – йөз яшендә
8) [һижри] мең ике йөз җитмеш бишенче
9) елда,
10) милади мең сигез йөз илле сигезенче
11) [ел]
12) декабренең егерме җиденче көнендә бу
13) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.
14) Урыны җәннәттә булсын, амин».

Уң ягы: «Әгәр йөз [ел] яшәсәң [дә], үләргә кирәктер, гомернең кадерен белергә кирәктер».

Сул ягы: «Бибигөлбадан Баязид бай хәләле – Габдерәззак мулла кызы – 1858 елда вафат».

Арткы ягы:
1) «Нәсихәтләр.
2) Васыятем будыр балаларыма
3) шулай ук кардәшләремә, оныкларыма:
4) юмартлык кылып, дога белән искә
5) алыгыз,
6) сәдака бирү белән рухымны
7) шатландырыгыз,
8) безгә Коръән укып багышлагыз,
9) бу кабергә килүгә сагышланыгыз,
10) ул якка, бу якка карап, дога көтәрбез,
11) хәер-изгелек шулай ук өмет итәрбез.
12) Мәет ярдәм сорый торган батучы
13) сыман, дога көтә».

Таш үлчәмнәре: 124х42х20.

41. Баязид Мөхсин Туктамыш улының улына куелган кабер ташы, 1846 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Байазид бине
2) Мөхсин бине Туктамыш
3) тарих мең ике йөз алтмыш икенче йылда
4) вә тарих румиййә мең сигез йөз кырык алтынчы йылда
5) майның йегерме өчүнче көнендә
6) сиксән биш йәшендә ошбу
7) даре фәнадан даре бәкайә рихләт әйләде
8) кәәнә раҗүлән саалихән кәсииральәүләәди
9) вәл-әхфәәди вә күллүһүм кәәнүү әгънийәәъән
10) вә минһүм Гобәйдулла вә Һибатулла вә Төхфәтулла».

Уң ягы (калкытып язылган): «Җарийә сәдакалар калдырасыз атаңыз өчүн мәсҗедем дә салдырасыз 1846».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) нәсыйхәтем будыр әүлядларыйма
3) дәхи ихванларыйм әхбабларыйма
4) ки мәгърур улмаңыз дөнйа малыйна
5) бакуңызлар атаңызның хәлинә
6) ничә җәһедилә малы җәмегъ итдим
7) сезә куйдыйм бары кәфенлә китдим
8) безә Коръән укурга телемез йук
9) тәсаддык һәм кыйлурга пулымыз йук
10) уйан буйан бакуб дога көтәрмез
11) хәйер ихсан дәхи өмид итәрмез
12) әл-мәййитү кәл-гариикуль-мүстәгыйсү йәнзуруд-дүгааъ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Баязид бине
2) Мөхсин бине Туктамыш
3) [һижри] мең ике йөз алтмыш икенче елда,
4) милади мең сигез йөз кырык алтынчы ел
5) маеның егерме өченче көнендә
6) сиксән биш яшендә бу
7) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.
8) Изге кеше иде, балалары һәм оныклары
9) күп булды. Аларның һәрберсе бай иде,
10) шулардан Гобәйдулла, Һибатулла, Төхфәтулла».

Уң ягы: «Үлгәннән соң да файда китерә торган сәдакалар калдырасыз, атагыз өчен мәчетемне дә салдырасыз. 1846 [ел]».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Нәсихәтем будыр балаларыма,
3) шулай ук кардәшләремә, дусларыма:
4) алданмагыз дөнья малына,
5) карагыз атагызның хәленә,
6) күпме тырышлык белән мал җыйдым,
7) сезгә калдырдым, бары кәфен белән киттем
8) безнең Коръән укырга телебез юк,
9) сәдака бирергә дә көчебез юк,
10) ул якка, бу якка карап, дога көтәрбез,
11) хәер-изгелек шулай ук өмет итәрбез.
12) Мәет ярдәм сорый торган батучы сыман, дога көтә».

Таш үлчәмнәре: 130х45х26.

42. Габделлатыйф Габдулла улы Баязидовка куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Тәгаалә күллү шәйьин һәәликүн илләә вәҗһәһ
3) ...
4) ... Габделлатыйф бине Габдулла
5) ...
6) ... даре бәкайә рихләт
7) әйләде...».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Тарих һижриййә
2) 13... сәнә зилхиҗҗәнең...
3) йәүмендә вафат... сәүдәгәре
4) Габделлатыйф Габдулла углы Байазидыф
5) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт 190... сәнә
6) фии йәүмис-сәәнии мин зилхиҗҗәти...
7) ...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ
2) Тәгаләдә. Аның [Аллаһның] йөзеннән кала һәрнәрсә һәлак булучы.
3) ...
4) ... Габделлатыйф бине Габдулла
5) ...
6) ... мәңгелек дөньяга
7) күчте...».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри
2) 13... ел зөлхиҗҗәсенең...
3) көнендә... сәүдәгәре
4) Габделлатыйф Габдулла улы Баязидов вафат.
5) Һәр җан иясе үлемне татыячак. 190... елда
6) дүшәмбе зөлхиҗҗәдә...
7) ...».

Таш үлчәмнәре: 110x39x24.

43. Билгесез кабер ташы, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы тулысынча ватылып төшкән.

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Мән зәәра кабрии фәлйәкүн мүүкыйнән
2) иннәл-ләзиил-каahә йәлкаah
3) фәйәрхәмүллаahү имраъә зәәрани
4) фәкаалә лии йәрхәмүкәллаah
5) рәкыйм Фәлахеддин
6) бине мулла Шәмседдин».

Сулягы (уеп язылган):
1) «Каалә галәйhис-сәләәм
2) әл-кабру раудатүн
3) мин рийәәдыйль-җәннәти
4) әү хүфратүн мин хүфәрин-нәйраан».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Уң ягы:
1) «Минем каберемә килгән кеше ышансын:
2) чынлыкта, мин дучар булган нәрсәгә ул да дучар булыр.
3) «Аллаh аны рәхим кылсын», – дип минем өчен дога кылган
4) кешене Аллаh үзен дә рәхим кылсын.
5) Язучы: Фәлахеддин
6) бине мулла Шәмседдин».

Сул ягы:
1) «[Пәйгамбәр] (Аңа сәлам булсын) әйтте:
2) «Кабер – җәннәт
3) бакчаларыннан бер бакча
4) яки утлар чокырларыннан бер чокыр».

Таш үлчәмнәре: 89x38x16.

44. Зөлхибә Мортаза кызына куелган кабер ташы, 1858 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һәзәл-кабру җәлисүс-садр
2) тарих hиҗриййә 1275 нче
3) йылда маhе рабигыль-ахирнең
4) 12 сенд Зөлхибә бинте Мортаза зәүҗе
5) Гобәйдулла нәүвәраллаahү мәркадиhимәә
6) 1858 сәнә румиййә дикәбрнең 6 сынд
7) 72 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Уң ягы:
1) «Бу кабер – күңел иптәше.
2) Һиҗри 1275
3) елның 12 рабигыль-
4) ахирендә Зөлхибә бинте Мортаза – Гобәйдулла
5) хатыны (Аллаh аларның икесенең дә каберләрен нурландырсын)
6) милади 1858 елның 6 декабрендә
7) 72 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 87x40x26.

45. Кишәкбикә Батикбикә кызына куелган кабер ташы, 1688–1689 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәл-хәййүл-ләзии ләә йәмүүтү вә күллү хәййин сәйәмүүт каалән-нәбии галәйh-
2) -ис-сәлләәм әд-дүнйәә сәәгатүн фәҗгальhәә таагать садак каалән-нәбии
3) галәйhис-сәлләәм әд-дүнйәә сиҗҗиинүл-мүъмини вә җәннәәтүл-кәәфир
4) тарих меңдә йөз йыл ирде Батик бикә кызы
5) Кишәк бикә үз вакытында бу
6) билгене куйды ирләрдин дога өмед
7) өҗүн.

Уң ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаh] – Тере, Үлмәүче һәм һәр җан иясе үләчәк. Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын)
2) әйтте: «Дөнья бер сәгатьлек, аны [Аллаhка] итагать белән үткәр», дөрес әйткән. Пәйгамбәр (аңа

3) сәлам булсын) әйтте: «Бу дөнья иманлы өчен төрмә, имансыз өчен җәннәт».
4) Мең дә йөзенче елда Батик бикә кызы
5) Кишәкбикә үз вакытында бу
6) билгене ирләрдән дога өмет итү өчен
7) куйды.

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән».

Таш үлчәмнәре: 85х42х22.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 9 б. №79.

46. Мулла Гали Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) мулла Гали Ибраһим углы
4) вафат 1915 сәнә март
5) 8 ндә 66 йәшдә
6) рахимәллааһү рахмәтән
7) вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) мулла Гали Ибраһим улы
4) 1915 елның 8 мартында
5) 66 яшьтә вафат.
6) Аллаһ аны киң рәхмәте
7) белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 89х32х10.

47. Бибифатиха Хәсән кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) руми 1902 сәнә синтәбр 10 да
3) һиҗри 1320 сәнә җөмади-
4) -әл-ахир 20 дә Бибифатиха Хәсән
5) кызы Мөхәммәдгали Әхмәҗән
6) углының зәүҗәсе 50
7) йәшдә даре бәкайә рихләт»[133].

Сул ягы (уеп язылган): «кылды таййибәллааһү сәрааһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә»[134].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер Бибифатиха Хәсән кызы
2) Мөхәммәдгали Әхмәҗән углы зәүҗә-
3) -се мәркадедер».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади 1902 елның 10 сентябрендә,
3) һиҗри 1320 елның 20 җөмади-
4) -әл-ахирендә Бибифатиха Хәсән
5) кызы – Мөхәммәдгали Әхмәҗән
6) улының хатыны – 50
7) яшьтә мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Бу – Бибифатиха Хәсән кызы –
2) Мөхәммәдгали Әхмәҗән улының хатыны –
3) кабередер».

Таш үлчәмнәре: 111(143)х35х16.

48. Габделһади Габделгани улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалләә
2) саахибү һәзәл-кабри
3) мәрхүм Габделһад-
4) -и Габделгани углы
5) Кече Әтнә авылыйның
6) 1913 нче йылда
7) 12 нче ийүндә йө-
8) -нче[135] йәшендә даре
9) бәкайә рихләт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Габделһад-
4) -и Габделгани улы
5) (Кече Әтнә авылыннан)
6) 1913 елның

[133] Дәвамы сул ягында.

[134] Башы алгы ягында.

[135] Бу сүздә «з» хәрефе язылмыйча калган булса кирәк.

7) 12 июнендә йө[зе]-
8) -нче яшендә мәңгелек
9) дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 80x27x11.

49. Габделхәким Габделлатыйб улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгаалә күллү мән
галәйhәә
2) фәән
3) тарих румиййә илә 1906
4) нчы йылда априлнең 25
5) нче йәүмендә hиҗриййә илә
6) 1324 нче сәнәдә mahe
7) рабигыль-әүвәлнең 16 нчы
8) көнендә Олуг Мәнңәр авы-
9) -лыйның Габделхәким Габде-
10) -ллатыйб углы 75 йыл
11) гомер сөрүб шинбә көн»[136].

Уң ягы (уеп язылган): «дарел-фәнадин дарел-бәкайә hиҗрәт әйләде таййибәллаahү сәраahү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәh»[137].

Сул ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр бәне күр дә килүр йарагын сәндә күр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә әйтте: «Анда [җир
йөзендә] булучы hәркем, hәрнәрсә
2) фани.
3) Милади белән 1906
4) ел апреленең 25
5) нче көнендә, hиҗри белән
6) 1324 ел рабигыль-
7) әүвәл аеның 16 нчы
8) көнендә Олы Мәңгәр авы-
9) -лыннан Габделхәким Габде-
10) -ллатыйб улы, 75 ел
11) гомер сөреп, шимбә көн».

Уң ягы: «Фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Аллаh аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын hәм урынын җәннәт итсен».

Сул ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачу, мине күр, мине күр дә килер өчен кирәк-ярагын син дә күр».

Таш үлчәмнәре: 100(120)x29x13.

50. Габделлатыйб Газиз улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) тарих румиййә илә
4) 1892 нче йылда гыйнва-
5) -рның 25 нче йәүмендә
6) Габделлатыйб Газиз
7) углы 80 йыл гомүр
8) сөрүб даре фәнадин
9) даре бәкайә рихләт әйләде».

Уң ягы (калкытып язылган): «Уйан бу йан бакуб дога көтәрмез хәйер ихсан дәхи өмид итәрмез».

Сул ягы (калкытып язылган): «Ничә җәhед илә малы җәмегъ итдем сезә куйдым бары кәфенлә китдем».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу каберә Олуг Мәңңәр
2) илинең мәрхүм Габделлатыйб
3) Газиз углы 75 йыл
4) гомер сөреб 1892 сәнә
5) гыйнварның 25 нче йәүмендә
6) дарел-бәкайә рихләт итде
7) таййибәллаahү сәраah».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә әйтте:
2) «hәр җан иясе үлемне татыячак.
3) Милади белән
4) 1892 ел гыйнва-
5) -рының 25 нче көнендә
6) Габделлатыйб Газиз
7) улы, 80 ел гомер
8) сөреп, фани дөньядан
9) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Ул якка, бу якка карап, дога көтәрбез, хәер-изгелек шулай ук өмет итәрбез».

Сул ягы: «Күпме тырышлык белән мал җыйдым, сезгә калдырдым, бары кәфен белән киттем».

Арткы ягы:
1) «Бу кабердәге Олы Мәңгәр
2) иленнән мәрхүм Габделлатыйб
3) Газиз улы, 75 ел
4) гомер сөреп, 1892 ел

[136] Дәвамы уң ягында.
[137] Башы алгы ягында.

5) гыйнварының 25 нче көнендә
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Таш үлчәмнәре: 96х29х13.

51. Хәтимә Мөхәммәҗҗан Хәлил улының кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән
3) бу каберә назилә Олуг Мәнгәр
4) илинең мөтәвәффат мәрхүмә
5) кызы Габделлатыйф Газиз углы-
6) -ның әһлийәсе 55 йәшендә сәнәи
7) миладиййә илә 1903 нче 8 нче
8) дикәбрдә дарел-бәкайә һиҗрәт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары бакый ирмәс һич дә йук карары».

Сул ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр бәне кү дә гилүр йарагын сәндә күр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабергә иңүче, Олы Мәңгәр
3) иленнән вафат булучы мәрхүмә
4) Хәтимә Мөхәммәҗҗан Хәлил улының
5) кызы – Габделлатыйф Газиз улы-
6) -ның хатыны – 55 яшендә милади
7) белән 1903 елның 8
8) декабрендә мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һич тә мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачу, мине күр, мине кү[р] дә килер өчен кирәк-ярагын син дә күр».

Таш үлчәмнәре: 87х33х12.

52. Бибизарифә Габдессаттар кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Бибизарифә
3) Габдессаттар кызы
4) миладиййә 1909 нчы йылда
5) 14 нче дикәбрдә
6) 42 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарун сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Габделхәким зәүҗә-
2) -се».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Бибизарифә
3) Габдессаттар кызы
4) милади 1909 елның
5) 14 декабрендә
6) 42 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Арткы ягы:
1) «Габделхәким хаты-
2) -ны».

Таш үлчәмнәре: 81х31х12.

53. Мөхәммәдша Әхмәдша улына куелган кабер ташы, 1924 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Мөхәммәдшаһ
3) Әхмәдшаһ
4) углы 70 йәшендә
5) вафат 2 нче
6) ийүн җомга
7) көн вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1924 сәнәи миладиййә
2) кәрәм әйләб
3) догада иде-
4) -нез йад тәсадды-
5) -клә кыйлуңыз
6) рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мөхәммәдша
3) Әхмәдша
4) улы 70 яшендә
5) 2
6) июньдә җомга
7) көн вафат».

Арткы ягы:
1) «Милади 1924 елда [вафат].
2) Юмартлык кылып,
3) догада искә
4) алыгыз. Сәдака
5) бирү белән
6) рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 94x31x10.

54. Бибизөбәйдә Исмәгыйль кызына куелган кабер ташы, 1861 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) әл-мәрхүүмәтүл-мәгъфүүратү Бибизөбәйдә
3) Исмәгыйль кызы Мохтар бай хәләле
4) тарих һиҗриййә мең ике йөз йитмеш сигезенче йылда
5) тарих румиййә мең сигез йөз алтмыш беренчедә
6) дикәбрнең йегерме беренче көнендә
7) алтмыш алты йәшендә ошбу
8) даре фәнадан даре бәкайә рихләт
9) әйләде рахимә ләһәә вә ли-вәәлидәйһәә
10) вә ли-җәмиигыйль-мүъминиинә вәл-мүъминәәт
11) һиҗриййә 1278 вә румиййә 1861».

Уң ягы (калкытып язылган): «Зөбәйдә Исмәгыйль кызы Мохтар бай җәмәгате 66 йәшендә 1861 сәнә мәрхүмә».

Сул ягы (калкытып язылган): «Әксируу зикра һәәдимил-ләззәәт мүүтүү каблә ән тәмүүтүү кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Мәвәәгыйз
2) васыйәтем будыр әй зәүҗ гакыйл
3) кәрәм илә бәңа дайим дога кыйл
4) балаларым догада идүңез йад
5) тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад
6) дәхи Коръән укуб һибә идәсез
7) сәдака җарийәләр һәм идәсез
8) безим Коръән укурга телемез йук
9) хәйер ихсан кыйлурга пулымыз йук
10) уйан буйан бакуб дога көтәрмез
11) әгәр табулса сәвүнешеб китәрмез
12) иннәл-мәййитә кәл-гариикуль-мүстәгыйсү
13) йәнзуруд-дүгааъә вә изәә вәҗәдә хайрун мин-
14) -әд-дүнйәә вә мәә фиихәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Рәхим кылынган, гафу ителгән Бибизөбәйдә
3) Исмәгыйль кызы – Мохтар бай хәләле –
4) һиҗри мең ике йөз җитмеш сигезенче елда,
5) милади мең сигез йөз алтмыш беренче [ел]
6) декабренең егерме беренче көнендә
7) алтмыш алты яшендә бу
8) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
9) күчте. [Аллаһ] аны, ата-анасын,
10) бөтен мөэмин ирләрне һәм хатын-кызларны рәхим кылсын.
11) Һиҗри 1278 һәм милади 1861 [еллар]».

Уң ягы: «Зөбәйдә Исмәгыйль кызы – Мохтар бай җәмәгате – 66 яшендә 1861 елда вафат».

Сул ягы: «Ләззәтләрне бетерүчене [үлемне] еш искә төшерегез. Вафат булганчы ук үлегез. Үлем вәгазьче буларак җиткән».

Арткы ягы:
1) «Вәгазьләр.
2) Васыятем будыр, әй, акыллы ирем,
3) юмартлык белән миңа даими [рәвештә] дога кыл.
4) Балаларым, догада искә алыгыз,
5) сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз.
6) Шулай ук Коръән укып, бүләк итәсез,
7) Үлгәннән соң да файда китерә торган сәдака да бирәсез.
8) Безнең Коръән укырга телебез юк,
9) хәер-изгелек кылырга көчебез юк.
10) Ул якка, бу якка карап, дога көтәрбез,
11) хәер-изгелек шулай ук өмет итәрбез.
12) Чынлыкта, мәет ярдәм сорый торган батучы сыман,
13) дога көтә, әгәр дә тапса, ул дога аңа бу дөньядан һәм анда булган
14) барлык нәрсәләрдән дә хәерле нәрсә кебек булачак».

Таш үлчәмнәре: 129x43x22.

55. Бибихәдичә Мостафа Адәмев кызына куелган кабер ташы, 1869 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Мәрхүмә мәгъсүмә
2) Бибихәдичә бинте
3) Мостафа Адәмеф
4) фәүт итде
5) 8 йәшендә 1869 сәнә
6) 24 нче ийүлдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мәрхүмә, гөнаһсыз
2) Бибихәдичә бинте
3) Мостафа Адәмев
4) 8 яшендә 1869 елның
5) 24 июлендә
6) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 60x28x12.

56. Мөхәммәдшәриф Мөхәррәм улына куелган кабер ташы, 1890 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү
2) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт тарих
3) һиҗри 1307 сәнә шәүвәл...
4) руми 1890 сәнә май...
5) ндә Олуг Мәнңәрнең хаҗи
6) Мөхәммәдшәриф Мөхәррәм углы
7) 91 йәшдә даре фәнадан даре
8) бәкайә рихләт кылды гафәраллаһ».

Уң ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (калкытып язылган): «Әмүрру галәә бәәлийәәтин-нийәәм вәбкии галәйһәә... әл-мәкаам».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Бу кабер Мөхәммәдшәриф
2) Мөхәррәм углы Адәмеф
3) мәркәдедүр тайййбәллаһү сәраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр
2) җан иясе үлемне татыячак»..
3) Һиҗри 1307 елның ... шәүвәлендә,
4) милади 1890 елның ... маенда
5) Олы Мәңгәрдән хаҗи
6) Мөхәммәдшәриф Мөхәррәм улы
7) 91 яшьтә фани дөньядан мәңгелек
8) дөньяга күчте. Аллаһ кичерсен».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Череп беткән йоклап ятучылар янынnан барам һәм елыйм... урын».

Арткы ягы:
1) «Бу – Мөхәммәдшәриф
2) Мөхәррәм улы Адәмев
3) каберәдер. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Таш үлчәмнәре: 120(153)x44x22.

57. Мөхәммәдшакир Мөхәммәдшәриф улына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү
2) мән галәйһәә фәән руми 1891 сәнә
3) фибрал 6 сында һиҗри 1308
4) сәнә рәҗәб 9 нда Олуг Мәнңәр-
5) -нең ражүл салих Мөхәммәдшакир
6) Мөхәммәдшәриф хаҗи углы 70
7) йәшдә чәһаршәнбә көн
8) вафат улды тайййбәллаһ»[138].

Уң ягы (уеп язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Сул ягы (уеп язылган): «сәраһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ әәмиин»[139].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибү һәзәәл-мәркадил-гаалиий-
2) -ил-хәәҗҗи Мөхәммәдшакир бине әл-хәә-
3) -җҗи Мөхәммәдшәриф әл-Мәнңәри гафийә
4) ганһүл-Бәәрии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә]
2) булучы һәркем, һәрнәрсә фани. Милади 1891 елның
3) 6 февралендә, һиҗри 1308

[138] Дәвамы сул ягында.
[139] Башы алгы ягында.

4) елның 9 рәҗәбендә Олы Мәңгәр-
5) -дән изге кеше Мөхәммәдшакир
6) Мөхәммәдшәриф хаҗи улы 70
7) яшьтә чәршәмбе көн
8) вафат булды. Аллаһ [аның туфрагын] яхшы [җиңел] кылсын».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һич тә мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Аның туфрагын [Аллаһ яхшы [җиңел] кылсын] һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Бу олуг кабер иясе –
2) хаҗи Мөхәммәдшакир бине ха-
3) -җи Мөхәммәдшәриф Мәңгәри. Юктан бар итүче
4) [Аллаһ] аны кичерсен».

Таш үлчәмнәре: 110x39x23.

58. Бибифатыйма Мортаза кызына куелган кабер ташы, 1884 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) руми 1884 сәнә април
3) 25 ндә һиҗри 1301 сәнә
4) рәҗәб 24 ндә Олуг
5) Мәңгәрнең Мөхәммәдшакир
6) Мөхәммәдшәриф углының
7) зәүҗәсе Бибифатыйма Мортаза
8) кызы 62 йәшдә чәһаршәнбә»[140].

Сул ягы (калкытып язылган): «көн даре бәкайә рихләт кылды тайййибәллаһү сәраһәә»[141].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәә кабру Бибифатыйма бинте
2) Мортаза зәүҗәи Мөхәммәдшакир
3) бине Мөхәммәдшәриф әл-Мәнңәри».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади 1884 елның 25
3) апрелендә, һиҗри 1301 елның
4) 24 рәҗәбендә Олы
5) Мәңгәрнең Мөхәммәдшакир
6) Мөхәммәдшәриф улының
7) хатыны – Бибифатыйма Мортаза
8) кызы – 62 яшьтә чәршәмбе».

Сул ягы: «көн мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын».

Арткы ягы:
1) «Бу Бибифатыйма бинте
2) Мортаза, Мөхәммәдшакир бине
3) Мөхәммәдшәриф Мәңгәри хатыны – кабере».

Таш үлчәмнәре: 107x38x19.

59. Хәдичә мулла Хәсән кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) кад интәкаләт иләә дәәрил-бәкааъи
3) Хәдичә бинте мулла Хәсән
4) әл-Курсави 1323 сәнә
5) фии 29 рабигыйль-әүвәл
6) рахимәһәәллаһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Балаларым догада идеңез йад тәсаддыклә рухымы әйләңез шад кәтәбәһү Гариф».

Сул ягы (уеп язылган): «Васыйәтем будыр әй зәүҗ гакыйл кәрәм илә бәңа даим дога кыйл».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «1905 сәнәи миладиййә май 19 нда
2) Хәдичә мулла Хәсән
3) кызы мулла Һади
4) бине мулла Бикчәнтәй
5) әһлийәсе 38 йәшендә
6) даре бәкайә рихләт әйләде
7) рахимәһәәллаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Хәдичә бинте мулла Хәсән
3) Курсави 1323 елның
4) 29 рабигыль-әүвәлендә
5) мәңгелек дөньяга күчте.
6) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Балаларым, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз. Моны язды: Гариф».

[140] Дәвамы сул ягында.
[141] Башы алгы ягында.

Сул ягы: «Васыятем будыр, әй, акыллы ирем: юмартлык белән миңа даими [рәвештә] дога кыл».

Арткы ягы:
1) «Милади 1905 елның 19 маенда
2) Хәдичә мулла Хәсән
3) кызы – мулла Һади
4) бине мулла Бикчәнтәй
5) хатыны – 38 яшендә
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Аллаһ аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 83х32х11.

Әлеге кабер иясе чыгышы белән Курса авылыннан. Аның фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Хәдичә бинте Хәсән бине Хәмид бине Исмәгыйль бине Габдерәззак[142].

60. Мөхәммәдгалим Габдессаттар улына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт
3) Олуг Мәнгәрнең Мөхәммәдгалим
4) Габдессаттар углы
5) 1904 нче йылда 4 нче майда
6) 60 йәшендә даре фәнада-
7) -н даре бәкайә рихләт әйләде
8) рахмәтүллааһи рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт
3) Олуг Мәнгәрнең Мөхәммәдгалим
4) Габдессаттар углы
5) 1904 нче йылда 4 нче майда
6) 60 йәшендә даре фәнада-
7) -н даре бәкайә рихләт әйләде
8) рахмәтүллааһи рахмәтән вәәсигаһ».

Таш үлчәмнәре: 116х33х11.

61. Бибихәдичә Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә
3) Бибихәдичә Хәбибулла
4) кызы Мөхәммәдшакир Муса
5) углы Исхакыф әһлийәсе
6) 1911 сәнә миладиййә март 12 ндә
7) 1329 һиҗриййә рабигы әүвәл
8) 25 ндә 70 йәшдә мәдфүнә».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән әнтә тәсыыйру мислии»[143].

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[144].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Бибихәдичә Хәбибулла
4) кызы – Мөхәммәдшакир Муса
5) улы Исхаков хатыны –
6) милади 1911 елның 12 мартында,
7) һиҗри 1329 [елның] 25 рабигыль-
8) -әүвәлендә 70 яшьтә җирләнде».

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Таш үлчәмнәре: 101(118)х35х16.

62. Бибигарифә Хөсәен кызына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) мәрхүмә Бибигарифә
3) Хөсәйен кызы
4) һиҗриййә илә 1309 нчы йылда
5) миладиййә 1891 нче йылда
6) 16 нчы мартда Әхмәд
7) Мөхәммәдшакир углының
8) зәүҗәсе 25 йә-
9) -шендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Зүүрууль-кубүүра фә-иннәһәә түзәккиракүмүл-әәхыйраһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Ән-нәәсү нийәәмүн изәә мәтүү интәбәһүү».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Безем Коръән у-

[142] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 135.

[143] Башы сул ягында.

[144] Дәвамы уң ягында.

2) -кырга телемез йу-
3) -к тәсаддык һәм
4) кыйлурга пу-
5) -лымыз йук».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Мәрхүмә Бибигарифә
3) Хөсәен кызы –
4) Әхмәд Мөхәммәдшакир
5) улының хатыны –
6) һиҗри белән 1309 елда,
7) милади 1891 елның
8) 16 мартында 25 я-
9) -шендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар сезгә ахирәтне искә төшерә».

Сул ягы: «Кешеләр йоклыйлар, үлгәч уяналар».

Арткы ягы:
1) «Безнең Коръән у-
2) -кырга телебез ю-
3) -к, сәдака бирергә
4) дә кө-
5) -чебез юк».

Таш үлчәмнәре: 105(120)x31x14.

63. Садреддин Халид улы Исхаковка куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Садреддин
3) Халид углы
4) Исхакыф
5) 57 йәшендә
6) 1917 сәнә 26 нчы
7) ийүндә вафат
8) Аллаһ рәхмәт
9) кыйлсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәраллаһү зүнүүбәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллаһү мәркадәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Садреддин
3) Халид улы
4) Исхаков
5) 57 яшендә
6) 1917 елның 26
7) июнендә вафат.
8) Аллаһ рәхим
9) кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 92x32x11.

64. Өммегөлсем Лотфулла Әмирханов кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) 1905 нче йыл 15 нче
3) нуйәбрдә Өммегөлсүм
4) Әмирханыф Лотф-
5) -улла кызы 6 йәшендә
6) вафат ата-анасыйна
7) шәфәгатьче улгай
8) иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) 1905 елның 15
3) ноябрендә Өммегөлсем
4) Әмирханов Лотф-
5) -улла кызы 6 яшендә
6) вафат. Ата-анасына
7) шәфәгатьче булса
8) иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 58x28x7.

65. Бибисабира мулла Галәведдин кызына куелган кабер ташы фрагменты, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) 27 нче...
2) Бибисабира мулла
3) Галәэддин кызы
4) 70 йәшенд мәд-
5) -фүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) 27...
2) Бибисабира мулла
3) Галәведдин кызы
4) 70 яшенд[ә] җир-
5) -ләнде».

Таш үлчәмнәре: 55х27х9.

66. Фәһимә Әхмәд кызына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рабби һәб лии
2) вә әл-хикънии би-
3) -с-саалихиин
4) миладиййә илә 1923 нче сәнәдә
5) гыйнвар 21 ндә Фәһимә Әхмәд кызы
6) бер йәшендә мәдфүнә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбрah
2) би-хүкмилләәһи Тәгаалә
3) җәгаләллаһү кабрahү[145] раудатүн мин рийәә-
4) -дыйль-җәннәһ зүүрууль-кубүүра фә-иннәһәә түзәккиракүм-
5) -үл-әәхыйрah» .

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Раббым, миңа [белем-хикмәт] бир
2) һәм изгеләргә
3) тоташтыр.
4) Милади белән 1923 елның
5) 21 гыйнварында Фәһимә Әхмәд кызы
6) бер яшендә җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
3) Аллаһ аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер
4) бакча итсен. Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар сезгә ахирәтне
5) искә төшерә».

Таш үлчәмнәре: 60(66)х30х10.

67. Гайнеҗамал Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) тарих 1909 сәнә миладиййә
3) ийүн 7 сендә Гайнеҗамал
4) Фәтхулла кызы Хәсән
5) Зөбәйер углы Кушайыф
6) әһлийәсе 78 йәшдә мәдфүнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1909 елның
3) 7 июнендә Гайнеҗамал
4) Фәтхулла кызы – Хәсән
5) Зөбәер улы Кушаев
6) хатыны – 78 яшьтә җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 77х31х10.

68. Гафифә Фәтхулла кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) саахибәтү һәзиһил-кабри
3) мәрхүмә Гафифә
4) Фәтхулла кызы
5) Хәсән Сәйфулла
6) углыйның җәмәгате
7) 1920 нче йыл 4 нче
8) фивралда 67 йә-
9) -шендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлән кыйлыңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүмә Гафифә
4) Фәтхулла кызы –
5) Хәсән Сәйфулла
6) улының җәмәгате
7) 1920 елның 4
8) февралендә 67 я-
9) -шендә вафат».

[145] Хатын-кызга куелган таш булса да, ир-атка карата кулланыла торган кушымча белән язылган. Андый хаталар ташъязмаларда, сирәк булса да, очрый.

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 85х29х10.

69. Мөхәммәдзакир Мөхәммәдшакир Габделгази улының улына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү
2) нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт руми
3) 1895 сәнә май 17 дә һиҗри
4) 1313 сәнә Олуг Мәнңәрнең
5) Мөхәммәдзакир бине Мөхәммәдшакир бине
6) Габделгази 55 йәшдә
7) даре бәкайә рихләт кылды
8) таййибәллаahү сәраahү вә җәгаләлҗәннәтә мәсвәәһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер Мөхәммәдзакир бине Мөхәммәд-
2) -шакир мәркадедүр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр
2) җан иясе үлемне татыячак. Милади
3) 1895 елның 17 маенда, һиҗри
4) 1313 елда Олы Мәңгәрдән
5) Мөхәммәдзакир бине Мөхәммәдшакир бине
6) Габделгази 55 яшьтә
7) мәңгелек дөньяга күчте.
8) Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Арткы ягы:
1) «Бу – Мөхәммәдзакир бине Мөхәммәд-
2) -шакир каберәдер».

Таш үлчәмнәре: 130х36х18.

70. Мөхәммәдшакир Габделгази Габдулла улының улына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) руми 1895 сәнә ийүн
3) 11 дә һиҗри 1313 сәнә
4) Олуг Мәнңәрнең Мөхәммәд-
5) -шакир Габделгази
6) углы 87 йәшдә
7) даре бәкайә рихләт кылды
8) таййибәллаahү сәраahү вә җәгаләлҗәннәтә мәсвәәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер Мөхәммәдшакир бине
2) Габделгази бине Габдулла
3) мәркадедүр 87 йәшдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади 1895 елның 11
3) июнендә, һиҗри 1313 елда
4) Олы Мәңгәрдән Мөхәммәд-
5) -шакир Габделгази
6) улы 87 яшьтә
7) мәңгелек дөньяга күчте.
8) Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Бу –Мөхәммәдшакир бине
2) Габделгази бине Габдулла
3) каберәдер. 87 яшьтә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 119х36х13.

71. Бибисәрви Әмир кызына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәүвәраллаahү
2) мәркадәһәә
3) Бибисәрви
4) Әмир кызы
5) Мөхәммәдшакир
6) хәләле» .

Уң ягы (калкытып язылган): «1889 йылда агыст башында».

Сул ягы (калкытып язылган): «75 йәшендә».

Арткы ягы (калкытып язылган): «Рухыйна Фатиха амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ аның
2) каберен нурландырсын.
3) Бибисәрви
4) Әмир кызы –
5) Мөхәммәдшакир
6) хәләле» .

Уң ягы: «1889 елның август башында [вафат]».

Сул ягы: «75 яшендә [вафат]».

Арткы ягы: «Рухына «Фатиха» [сүрәсе укы], амин».

Таш үлчәмнәре: 107x27x17.

72. Бәлкыйс Хисамеддин кызына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Бәлкыйс
3) Хисамеддин кызы
4) һиҗрииййә 1316 нчы йылда
5) миладиййә 1908 нче йылда
6) 27 нче агусда
7) Нәҗибулла зәүҗәсе».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Арткы ягы (уеп язылган): «70 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Бәлкыйс
3) Хисамеддин кызы –
4) Нәҗибулла хатыны –
5) һиҗри 1316 елда,
6) милади 1908 елның
7) 27 августында [вафат яки җирләнде]» .

Уң ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Арткы ягы: «70 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 69x30x10.

73. Сәхибҗамал Хуҗаәхмәд кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назил улмыш
3) мөтәвәффа мәрхүмә Сә-
4) -хибҗамал Хуҗаәхмәд
5) кызы Хәбибулла
6) Гобәйдулла углы-
7) -ның зәүҗәсе 55 нче
8) йәшендә руми 1904 нче
9) йылд 15 нче нуйәбрдә 21
10) нче рамазан дүшәнбә көн» .

Уң ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр»[146].

Сул ягы (уеп язылган): «Бәне күр бәне күр дә гилүр йарагын сәндә күр»[147].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә
3) вафат булучы мәрхүмә Сә-
4) -хибҗамал Хуҗаәхмәд
5) кызы – Хәбибулла
6) Гобәйдулла улы-
7) -ның хатыны – 55 нче
8) яшендә милади 1904
9) елның 15 ноябрендә, 21
10) рамазанында дүшәмбе көн иңде».

Уң ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачу, мине күр».

Сул ягы: «Мине күр дә гүр өчен кирәк-ярагыңны күр».

Таш үлчәмнәре: 122x33x14.

[146] Дәвамы сул ягында.
[147] Башы уң ягында.

74. Бибигафифә Гобәйдулла хатынына куелган кабер ташы, XIX гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәүвәраллаahү Тәгаалә
2) мәркадәһүмәә Биби-
3) -гафифә Чубыл
4) абый Гобәйдулла
5) хәләле вафат 70».

Уң ягы (калкытып язылган): «Һәр кеше бу мәркадә кыйлса нәзар».

Сул ягы (калкытып язылган): «Сахибене бел догада йат идәр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh Тәгалә аларның икесенең дә
2) каберен нурландырсын. Биби-
3) -гафифә Чубыл
4) абый Гобәйдулла
5) хәләле 70 [яшендә] вафат».

Уң ягы: «Һәр кеше бу кабергә караса».

Сул ягы: «Иясен бел, догада искә алыр».

Таш үлчәмнәре: 70x29x16.

75. Зөләйха Сәйфеддин кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәh
2) Зөләйhа Сәйф-
3) -еддин кызы
4) 1333 сәнәи һиҗриййә
5) 1915 сәнәи миладиййә
6) 80 йәшендә
7) пәнҗешәнбә көн
8) дәфен кылынды».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Габделфәттах
2) җәмәгате
3) рамазанның
4) 2 нче көнендә
5) 2 нче ийүл-
6) -дә мәдфүн
7) гарикы рәхмәт улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Х өкем Аллаhта гына.
2) Зөләйха Сәйф-
3) -еддин кызы
4) һиҗри 1333 елда,
5) милади 1915 елда
6) 80 яшендә
7) пәнҗешәмбе көн
8) җирләнде».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Сул ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Арткы ягы:
1) «Габделфәттах
2) җәмәгате
3) рамазанның
4) 2 нче көнендә,
5) 2 июль-
6) -дә җирләнде.
7) Рәхмәткә күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 107(129)x31x13.

76. Габделфәттах Габделхәмид улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәh
2) Габделфәттах
3) Габделхәмид углы
4) 24 нче ийүлдә
5) 60 йәшендә
6) 1316 сәнәи һиҗриййә
7) 1899 сәнәи миладиййә
8) шинбә көн вафат».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада иде-
3) -ңез йад тәсадды-
4) -клә кыйлунгыз
5) рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта гына.
2) Габделфәттах
3) Габделхәмид улы

4) милади 1899 елның
5) 24 июлендә
6) һиҗри 1316 елда
7) 60 яшендә
8) шимбә көн вафат».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә
3) алыгыз, сәдака бирү
4) белән рухымны
5) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 111x35x11.

77. Мәгъсүмә Ибраһим кызына куелган кабер ташы, 1929 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Мәгъсүмә
3) Ибраһим кызы
4) 1929 сәнәи миладиййә
5) 28 нче майда».

Арткы ягы (уеп язылган): «Гыймран зәүҗәсе».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәгъсүмә
3) Ибраһим кызы
4) милади 1929 елның
5) 28 маенда [вафат яки җирләнде]» .

Арткы ягы: «Гыймран хатыны».

Таш үлчәмнәре: 63x31x9.

78. Бибиməхфүзә Фәхреддин Шәмседдин улының кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп һәм калкытып язылган[148]):
1) «Би-хүкмилләәһ бу
2) каберә назилә карйәи Олуг
3) Мәнңәр Бибиməхфүзә Фәхре-
4) -ддин Шәмседдин
5) углының кызы Хисмәт-
6) -улла бине Ибатулла әһлийәсе
7) кәрәм әйләб догада кыйлыңыз йад
8) тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы шад».

Уң ягы (уеп язылган)[149]:
1) «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр
2) иннәә лилләәһи вә иннәә
3) иләйһи рааҗигуун»[150].

Сул ягы (уеп язылган)[151]:
1) «Бәне күр дә килүр йарагын сәндә күр
2) иннәә лилләәһи вә иннәә
3) иләйһи рааҗигуун»[152].

Арткы ягы (уеп һәм калкытып язылган[153]):
1) «Руми 1897
2) нче йылда 15 нче фив-
3) -ралда 45 йыл
4) гомер сөрүб
5) дарел-фәнадин
6) дарел-бәкайә һиҗрәт әйләде
7) күрәрмен дөнйаны вәйран бары
8) бакый ирməс һичдә йук карары» .

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән. Бу
2) кабергә иңүче – Олы Мәңгәр
3) авылыннан Бибиməхфүзә Фәхре-
4) -ддин Шәмседдин
5) улының кызы – Хисмәт-
6) -улла бине Ибатулла хатыны.
7) Юмартлык кылып, догада искә алыгыз.
8) Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Уң ягы:
1) «Үтте дәвер, бетте күңел ачу, мине күр.
2) Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
3) Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы:
1) «Мине күр дә килер өчен кирәк-ярагын син дә күр.
2) Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта,
3) Аңа кайтачакбыз».

Арткы ягы:
1) «Милади 1897
2) елның 15 фев-

[148] Өченче, дүртенче һәм бишенче юллары калкытып, калганнары уеп язылган.

[149] Беренче юлы вертикаль, калганнары горизонталь рәвештә язылган.

[150] Беренче юлының дәвамы сул ягында.

[151] Беренче юлы вертикаль, калганнары горизонталь рәвештә язылган.

[152] Беренче юлының башы уң ягында.

[153] Өченче, дүртенче һәм бишенче юллары калкытып, калганнары уеп язылган.

3) -ралендә, 45 ел
4) гомер сөреп,
5) фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Күрәм дөньяны: барысы җимерек,
8) һич тә мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 61(86)x36x16.

79. Бибигазизә Әюб кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Бибигазизә Әйүб
3) кызы гыйнвар 24 ндә
4) 1914 сәнәи миладиййә
5) 65 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Габдулла зәүҗә-
2) -се».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бибигазизә Әюб
3) кызы милади 1914
4) елның 24 гыйнварында
5) 65 яшендә [вафат яки җирләнде]» .

Арткы ягы:
1) «Габдулла хаты-
2) -ны».

Таш үлчәмнәре: 64x32x8.

80. Габдулла Гыймран улына куелган кабер ташы, 1929 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Габдулла Гыймран
3) углы 75 йәшендә
4) 1929 сәнәи миладиййә
5) 28 нче майда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Габдулла Гыймран
3) улы 75 яшендә
4) милади 1929 елның
5) 28 маенда [вафат яки җирләнде]» .

Таш үлчәмнәре: 63x32x8.

81. Гыйләҗеддин Вәли улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ Тәгаләнең
2) рәхмәтенә васыйл
3) улса иде Бәрәнге
4) авылыйның Гыйләҗеддин
5) Вәли углы
6) рахимәһүмәәллаһү Тәгааләә
7) рахмәтән вәәсигаһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1921 нче йылда
3) 1 нче гыйнварда
4) 21 йәшендә
5) вафат булды
6) салдатдан
7) кайтышда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгаләнең
2) рәхмәтенә ирешсә
3) иде. Бәрәңге
4) авылыннан Гыйләҗеддин
5) Вәли улы.
6) Аллаһ Тәгалә аларның икесен дә киң рәхмәте
7) белән рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1921 елның
3) 1 гыйнварында
4) 21 яшендә
5) солдаттан
6) кайтканда
7) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 60x29x11.

82. Бибимаһруй Фәхреддин кызына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Бибимаһруй
3) Фәхреддин кызы
4) Хәбибулла Гыйззәтулла
5) углының хәлиләсе
6) миладиййә илә»[154] .

[154] Дәвамы арткы ягында.

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1919 нчы сәнә
2) 22 нче март
3) һиҗри 1337 сәнә
4) 21 җөмади ахир
5) 59 йәшендә
6) вафат рахимәһәллаһү Тәга[155]«[156].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Бибимаһруй
3) Фәхреддин кызы –
4) Хәбибулла Гыйззәтулла
5) улының сөеклесе –
6) милади белән».

Арткы ягы:
1) «1919 елның
2) 22 мартында,
3) һиҗри 1337 елның
4) 21 җөмадиәл-ахирендә
5) 59 яшендә
6) вафат. Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын.

Таш үлчәмнәре: 64х32х10.

83. Әхмәдулла Бикмөхәммәд улына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми илә 1891
3) сәнә гыйнвар 16 сында һиҗри 1308
4) сәнә җөмадиәл-ахир 17 сендә
5) Олуг Мәнңәрнең хаҗҗел-хәрәмәйен
6) Әхмәдулла Бикмөхәммәд углы
7) 82 йәшдә чәһаршәнбә көн
8) мәдфүн улды Хак Җәлл»[157].

Уң ягы (уеп язылган): Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (калкытып язылган): «вә Галәә мәркаден пөр нур әйләсүн амин»[158].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибү һәзәәл-кабри хәәҗүл-хәрамәйни
2) Әхмәдулла бине Бикмөхәммәд әл-Мәнгәри
3) гафийә ганһүл-Мәликүл-Бәәрии тәү фии
4) сәнәти 1308 фии йәүмил-әрбәгааъ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади белән 1891
3) елның 16 гыйнварында, һиҗри 1308
4) елның 17 җөмадиәл-ахирендә
5) Олы Мәңгәрдән хаҗи
6) Әхмәдулла Бикмөхәммәд улы
7) 82 яшьтә чәршәмбе көн
8) җирләнде. Бөек Хак».

Уң ягы: Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «һәм Олуг [Аллаһ] каберен нурга күмсен, амин».

Арткы ягы:
1) «Бу кабер иясе – хаҗи
2) Әхмәдулла бине Бикмөхәммәд Мәңгәри.
3) Патша, Юктан бар итүче [Аллаһ] аны кичерсен.
4) [Һиҗри] 1308 елда чәршәмбе көн [җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 112(133)х40х22.

84. Шаһиәхмәд мулла Мөхәммәди улына куелган кабер ташы, 1932 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) Шаһиәхмәд
3) мулла Мөхәммәди углы
4) 88 йәшендә вафат
5) 1932 сәнәи миладиййә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «5 нче априлдә вафат
2) кәрәм әйләб догада
3) идеңез йад тәсаддыклә
4) кыйлуңыз рухымы шад» .

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Шаһиәхмәд
3) мулла Мөхәммәди улы
4) 88 яшендә милади

[155] «Тәгалә» сүзе шул рәвешле кыскартылып язылган.
[156] Башы алгы ягында.
[157] Дәвамы сул ягында.
[158] Башы алгы ягында.

5) 1932 елда вафат».

Арткы ягы:
1) «5 апрельдә вафат.
2) Юмартлык кылып, догада
3) искә алыгыз. Сәдака бирү белән
4) рухымны шатландырыгыз» .

Таш үлчәмнәре: 68х30х10.

Әлеге кабер иясенең фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Шаһиәхмәд бине Мөхәммәди бине Сафкол бине Котый бине Килмәк[159]. Ул дин әһеле, мөдәррис кенә түгел, тарихчы да булган: 1978 елгы Казан арты төбәгендә крестьяннар хәрәкәте турында ике томлы хезмәт (кулъязма рәвешендә) язганлыгы билгеле[160]. Шаһиәхмәд хәзрәт 1871 елның 8 февралендә указ (указ номеры – №8753) алгач, өченче мәхәллә мәчетенә имам-хатыйб итеп билгеләнгән, тик 1923 елда муллалык вазыйфасыннан ваз кичәргә мәҗбүр булган.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 9 б. №80.

85. Мулла Хаммад мулла Мөхәммәди улына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүт
3) румиййә илән 1901 нче
4) йылда 9 нчы ийүлдә дүшәнбә
5) көн мулла Хаммад мулла Мөхәммәди
6) углы даре бәкайә рихләт
7) әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) һиҗриййә илән 1316 нчы
3) йылда рабигыль-ахирнең 5 нче
4) көнендә мулла Хаммад мулла Мөхәммәди
5) углы 70 йәшендә
6) вафат булды дүшәнбә көн
7) дәфен кыйлынды Аллаһ Тәгалә
8) гарикы рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
3) Милади белән 1901
4) елның 9 июлендә дүшәмбе
5) көн мулла Хаммад мулла Мөхәммәди
6) улы мәңгелек дөньяга
7) күчте».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Һиҗри белән 1316
3) ел рабигыль-ахиренең 5 нче
4) көнендә мулла Хаммад мулла Мөхәммәди
5) улы 70 яшендә
6) вафат булды, дүшәмбе көн
7) җирләнде. Аллаһ Тәгалә
8) рәхмәткә күмсен».

Таш үлчәмнәре: 60х33х11.

Әлеге кабер иясенең фәнгә билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә: Хаммад бине Мөхәммәди бине Сафкол бине Котый бине Килмәк[161].

Олы Мәңгәр саласына кагылышлы бик күп шәҗәрәләрне күренекле галим (аның үзенең дә тамырлары әлеге авыл белән бәйләнгән) М. Әхмәтҗанов туплап, өйрәнеп, китаплар рәвешендә җәмәгатьчелеккә тәкъдим итте[162]. Авыл зиратында җирләнгән байтак шәхесләрнең шәҗәрәләре шул хезмәтләрдә урын алган.

Олы Өшкәтә авылы зираты

1. Нурмөхәммәд Сабит улына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Нурмөхәммәд
3) Сабит углы
4) 1311 сәнәи һиҗриййә
5) 1893 сәнәи миладиййә
6) 24 нче ийүлдә
7) 60 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

[159] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 187.
[160] Әхмәтҗанов М. Олы Мәңгәр авылы тарихы / М. Әхмәтҗанов. – Казан: Идел-пресс, 2000. – Б. 7.
[161] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 187.
[162] Кара: Әхмәтҗанов М. Олы Мәңгәр авылы тарихы / М. Әхмәтҗанов. – Казан: Идел-пресс, 2000. – Б. 22–25; Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: I т. / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 185–231.

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәс

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Нурмөхәммәд
3) Сабит улы
4) һиҗри 1311 елда,
5) милади 1893 елның
6) 24 июлендә
7) 60 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 84x28x8.

2. Хәсбиулла Гыйззәтулла улына куелган кабер ташы, XX гасырның 20 нче еллары.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабердә...
3) Хәсбийулла
4) Гыйззәтулла углы
5) вафат булды
6) 192... йылда
7) 20 нче аугыст
8) 53 йәшендә
9) Аллаһ рәхмәт
10) кылсын
11) Хәсбиулла
12) Гыйззәтулла
13) [углы]»[163].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабердә...
3) Хәсбиулла
4) Гыйззәтулла улы
5) 192... елның
6) 20 августында
7) 53 яшендә
8) вафат булды.
9) Аллаһ рәхим
10) кылсын.
11) Хәсбиулла
12) Гыйззәтулла
13) [углы]».

Таш үлчәмнәре: 103x32x13.

[163] Соңгы өч юлы латин графикасында язылган.

3. Зөбәйдә Габдерәшид кызына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә
3) Зөбәйдә Габдерәшид
4) кызы Насыйбулла Гобәйдулла
5) углының әһлийәсе 1893
6) сәнәи миладиййә 1 нче мартда
7) 80 йәшдә мәдфүнә
8) нәүвәраллаһү кабраһәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Зөбәйдә Габдерәшид
4) кызы – Насыйбулла Гобәйдулла
5) улының хатыны – милади
6) 1893 елның 1 мартында
7) 80 яшьтә җирләнде.
8) Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 103x33x14.

4. Мөәзин Мөхәммәдвафа Мөэмин улына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Мөәзин
2) Мөхәммәдвафа
3) Мөэмин углы
4) 1893 сәнә април 23 ндә
5) 87 йәшендә вафат
6) Аллаһ урынын
7) җәннәт бакчасы
8) кыйлсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мөәзин
2) Мөхәммәдвафа
3) Мөэмин улы
4) 1893 елның 23 апрелендә
5) 87 яшендә вафат.
6) Аллаһ урынын
7) җәннәт бакчасы
8) итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 93x30x11.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 9 б. №81.

5. Баһаеддин Хөснеддин улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу кабер
2) ийәсе
3) Хөснеддин углы
4) Баһаеддин ва-
5) -фат буды
6) 1918 йылда фир-
7) -пралның 18 нчешендә
8) 37 йәшен-
9) -ндә А рәхмә-
10) -т әйләсен
11) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Бу кабер
2) иясе
3) Хөснеддин улы
4) Баһаеддин
5) 1918 елның
6) 18 февралендә
7) 37 яшен-
8) -дә вафат бу[л]ды.
9) А[ллаһ] рәхим
10) кылсын,
11) амин».

Таш үлчәмнәре: 93х29х11.

6. Бибимәстүрә Габделхаликъ кызына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу рауза
3) ийәсе мәрхүмә
4) Бибимәстүрә
5) Габделхаликъ кызы
6) Хөсәйен әһлийәсе
7) -1913 сәнә март 8 дә
8) 69 йәшендә
9) вафат».

Уң ягы ягы (уеп язылган): «Галәмәтдин морадым бер догадыр».
Сул ягы (уеп язылган): «Бу көн бәңа икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу бакча
3) иясе мәрхүмә
4) Бибимәстүрә
5) Габделхаликъ кызы –
6) Хөсәен хатыны –
7) -1913 елның 8 мартында
8) 69 яшендә
9) вафат».

Уң ягы ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Сул ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 105х30х10.

Ташчишмә авылы зираты

1. Нигъмәтҗан Әхмәҗҗан улына куелган кабер ташы, 1930 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу
2) кабер сахибе
3) Нигъмәтҗан
4) Әхмәҗҗан
5) углы рахимәһ-
6) -үллааһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 193[164] нче йылда
3) 25 нче мартда
4) 65 йәшдә
5) дәфен кылынд».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Бу
2) кабер иясе
3) Нигъмәтҗан
4) Әхмәҗҗан
5) улы. Аллаһ аны
6) рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 193[0] елның
3) 25 мартында
4) 65 яшьтә
5) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 49х26х7.

2. Габдрахман Муса улына куелган кабер ташы, 1921 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу
2) кабер сахибе
3) Габдеррахман
4) Муса
5) углы рахимәһ-

[164] Ташта «193» дип язылса да, 1930 ел булырга тиеш, дип фаразлыйбыз.

6) -үллаah».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1921 нче йыл
3) 20 нче агуст
4) 57 йәшендә
5) дәфен кылынды
6) Тәгааләә[165]».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Бу
2) кабер иясе
3) Габдрахман
4) Муса
5) улы. Аллаһ Тәгалә аны
6) рәхим кылсын».
Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1921 елның
3) 20 августында
4) 57 яшендә
5) җирләнде.
6) Тәгалә».
Таш үлчәмнәре: 49(58)x26x7.

3. Мәфтуха Хәйбулла кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Мәфтуха
3) Хәйбулла
4) кызы 1920
5) нче йылда 65 йәшдә
6) дәфен кылынды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәү-
3) -т».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәфтуха
3) Хәйбулла
4) кызы 1920
5) елда 65 яшьтә
6) җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Һәр җан иясе
2) үлемне
3) татыячак».

Таш үлчәмнәре: 54x27x7.

[165] Бу «Тәгааләә» сүзе – алгы як текстның дәвамы.

4. Габделвaһһаб Габделҗәлил улына куелган кабер ташы, 1877 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) ошбу каберә назил
3) Габделвaһһаб Габд-
4) -елҗәлил углы
5) 1877 сәнәдә вафат
6) Аллаһ рәхмәт итсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабергә иңүче
3) Габделвaһһаб Габд-
4) -елҗәлил улы
5) 1877 елда вафат.
6) Аллаһ рәхим кылсын».
Таш үлчәмнәре: 69(81)x31x10.
Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 10 б. №82.

5. Зөбәйдә Мөхәммәдәмин улына куелган кабер ташы, 1886 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу кабер-
2) -станда дәфен кылынды
3) Фазлулла җәмә-
4) -гате Зөбәйдә Мөхәммәд-
5) -әмин кызы 72
6) йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Үхърус лидүнйәәкә кәъәннәкә тәгыыйшү әбәдәә».
Сул ягы (уеп язылган): «Вә игъмәл лиәәхыйратикә кәъәннәкә тәмүүтү гадәә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1886 нче йылда
3) 2 нче априлдә
4) Аллаһ Тәгалә каберен
5) җәннәт багчаларындан бер
6) багча кылса иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Бу зиратта
2) Фазлулла җәмә-
3) -гате – Зөбәйдә Мөхәммәд-
4) -әмин кызы –
5) җирләнде,
6) 72 яшендә вафат».

Уң ягы: «Бу дөнья өчен, мәңге яшәячәксең кебек тырыш».

Сул ягы: «Ахирәт өчен, иртәгә үләячәксең кебек гамәл кыл».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1886 елның
3) 2 апрелендә [вафат].
4) Аллаһ Тәгалә каберен
5) җәннәт бакчаларыннан бер
6) бакча итсә иде».

Таш үлчәмнәре: 78(97)x30x12.

6. Мәргубә Ибраһим кызына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң
3) зәәъикатүл-мәүүт
4) Аллаһ Тәгаләнең
5) рәхмәтенә васыйлә
6) улса иде
7) Ибраһим җәмә-
8) -гате Мәргубә
9) Ибраһим кызы».

Уң ягы (уеп язылган): «Әл-мәүтү бәәбүн вә күллүн-нәәси дәәхыйлүһ».
Сул ягы (уеп язылган): «Зикруль-кабри йүкаррибүкүм минәл-җәннәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә илә
2) 1902 нче йыл
3) беренче синтәбрдә
4) 85 йәшендә
5) дәфен кылынды
6) рахимәһәллааһү
7) Тәгаалә рахмәтән
8) вәәсигаһ әәмиин
9) йәә Рабб».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе
3) үлемне татыячак».
4) Аллаһ Тәгаләнең
5) рәхмәтенә
6) ирешсә иде.
7) Ибраһим җәмә-
8) -гате – Мәргубә
9) Ибраһим кызы».

Уң ягы: «Үлем – ишек, һәркем аннан керәчәк».
Сул ягы: «Каберне искә төшерү сезгә җәннәтне якынайта».

Арткы ягы:
1) «Милади белән
2) 1902 елның
3) беренче сентябрендә
4) 85 яшендә
5) җирләнде.
6) Аллаһ Тәгалә аны
7) киң рәхмәте белән
8) рәхим кылсын, амин,
9) йа, Раббы».

Таш үлчәмнәре: 97(107)x31x12.

7. Мөхәммәди Габдессаттар улына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иске Тазлар
2) Мөхәммәди Габдессаттар
3) углы 80 йәшендә
4) вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Иске Тазлардан
2) Мөхәммәди Габдессаттар
3) улы 80 яшендә
4) вафат».

Таш үлчәмнәре: 41x32x12.

8. Гобәйдулла Һибатулла улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ руми
2) 1907 сәнә агуст
3) 3 ндә һиҗри 1325 сәнә
4) рәҗәб 7 дә Гобәйдулла
5) Һибатулла углы 56
6) йәшдә даре бәкайә»[166].

Сул ягы (уеп язылган): «Рихләт кылды тайййибәллааһү сәраах әәмиин»[167].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта. Милади

[166] Дәвамы сул ягында.
[167] Башы алгы ягында.

2) 1907 елның 3
3) августында, һиҗри 1325 елның
4) 7 рәҗәбендә Гобәйдулла
5) Һибатулла улы 56
6) яшьтә мәңгелек дөньяга».

Сул ягы: «Күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын, амин ».

Таш үлчәмнәре: 95х35х13.

9. Гайшә Габделвәли кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Гайшә Габделвәли
3) кызы Гобәйдулла
4) җәмәгате миладиййә
5) 1915 нҗе йыл 5 нҗе
6) февралда 60
7) йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Һиҗриййә илә 1333 нҗе йыл 4 нҗе рабигы ахирдә».

3) искә төшерә».

Таш үлчәмнәре: 104х31х12.

9. Сәгъди Нәҗмеддин улына куелган кабер ташы, 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бәрәскә авылының
2) Сәгъди бине Нәҗме-
3) -ддин 1882 нче сәнә
4) 12 нче мартда
5) 35 йәшендә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бәрәскә авылыннан
2) Сәгъди бине Нәҗме-
3) -ддин 1882 елның
4) 12 мартында
5) 35 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 109х39х13.

10. Нәҗмеддин Мостафа улына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бәрәскә авы-
2) -лының Нәҗмеддин
3) бине Мостафа 1889 нче сәнә
4) 9 априлдә
5) 65 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бәрәскә авы-
2) -лыннан Нәҗмеддин
3) бине Мостафа 1889 елның
4) 9 апрелендә
5) 65 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 108х30/39х12.

11. Әсхабҗамал Нигъмәтулла кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) 1906 нчы йыл 10
3) нчы майда чәһаршәнбә
4) көн Түбән Бәрәскә
5) авылыйның Нәҗмеддин
6) Мостафа углыйның
7) җәмәгате Әсхабҗамал
8) Нигъмәтулла кызыйның 80
9) йәшендә гакыйбәт
10) баде әҗәл шәмгы рухыны
11) набуд әйләб җәвад
12) рахмәтуллага васыйл
13) кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) 1906 елның 10
3) маенда чәршәмбе
4) көн Түбән Бәрәскә
5) авылыннан Нәҗмеддин
6) Мостафа улының
7) җәмәгате – Әсхабҗамал
8) Нигъмәтулла кызы – 80
9) яшендә, ахырдан
10) әҗәл җиле рухын
11) бетереп, юмарт
12) Аллаһ рәхмәтенә
13) иреште».

Таш үлчәмнәре: 112х36х11.

12. Хубҗамал Шәмседдин кызына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Хубҗамал
2) Шәмседдин
3) кызы Мөхәммәд-
4) -шәриф җәмәгате».

Уң ягы (уеп язылган): «1315 сәнә h 2 ндә зилхиҗҗә».

Сул ягы (уеп язылган): «1898 сәнәи румиййә 19 нда март».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хубҗамал
2) Шәмседдин
3) кызы – Мөхәммәд-
4) -шәриф җәмәгате».

Уң ягы: «Һ[ижри] 1315 елның 2 зөлхиҗҗәсендә [вафат яки җирләнде]».

Сул ягы: «Милади 1898 елның 19 мартында [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 72х24/29х23.

13. Хөснежамал Ибраһим кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) әл-мәрхүүмәтү Хөснежамал
3) Ибраһим кызы 74 йәшдә
4) 1907 нче сәнә гыйнвар 27 сендә
5) дөнйадин ахирәт күчде
6) рәхмәте Аллаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Рәхим кылынган Хөснежамал
3) Ибраһим кызы 74 яшьтә
4) 1907 елның 27 гыйнварында
5) дөньядан ахирәткә күчте.
6) Аллаһ рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 67х35х15.

14. Мөхәммәдзариф Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Мөхәммәдзариф Ибраһим углы
4) 1906 нчы йылда гыйнвар
5) 3 нче көнендә 55 йәшендә
6) вафат Аллаһ рәхмәт әйләсүн
7) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәнга икән йарун сәнгадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Мөхәммәдзариф Ибраһим улы
4) 1906 ел гыйнварының
5) 3 нче көнендә 55 яшендә
6) вафат. Аллаһ рәхим кылсын,
7) амин».

Уң ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 77х33х11.

15. Маһинур Шогаеб кызына куелган кабер ташы, 1935 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллаһ Мүхәммәдүр-расүүлүллаһ
2) мәрхүмә бу
3) кабер ийәсе
4) Маһинур Шогайыб
5) кызы туды
6) 1904 вафат
7) булды 1935 йылда
8) дикәбрнең 5 ндә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Бу кабер
3) иясе мәрхүмә
4) Маһинур Шогаеб
5) кызы 1904
6) [елда] туды, 1935
7) елның 5 декабрендә
8) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 82х31х10.

16. Хөббениса Габделмәннаф кызына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибәтү һәзиһил-кабри мәрхүмә
3) Хөббенниса Габделмәннаф кызы
4) Хәйрулла Хисамеддин
5) углыйның әһлийәсе 1908 сәнә
6) миладиййә үктәбр 1 ндә
7) 45 йәшендә мәдфүнә».

Уң ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад дога берлә кыйлынгыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Рахимәһәәллааһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Хөббениса Габделмәннаф кызы –
4) Хәйрулла Хисамеддин
5) улының хатыны – милади 1908
6) елның 1 октябрендә
7) 45 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал, дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 98(118)х35х12.

17. Бәлхия Мәрхәба кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Бәлхийә Мәрхәба
3) кызы Хисам-
4) -еддин җәмәгате
5) 1324 сәнәи һиҗриййә
6) 1905 сәнәи миладиййә»[203].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Ийүннең 4 ндә
2) 80 йәшендә вафат
3) ихване мөслимин-
4) -дән дога рәҗа
5) идәмез»[204].

[203] Дәвамы арткы ягында.
[204] Башы алгы ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бәлхия Мәрхәба
3) кызы – Хисам-
4) -еддин җәмәгате –
5) һиҗри 1324 елда,
6) милади 1905 елның».

Арткы ягы:
1) «4 июнендә
2) 80 яшендә вафат.
3) Мөселман кардәшләр-
4) -дән дога өмет
5) итәбез».

Таш үлчәмнәре: 72(84)х30х11.

18. Мөхибҗамал Нигъмәтулла кызына куелган кабер ташы, 1825–1826 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һүвәл-хәййүл-ләзии ләә йәмүүтү әбәдәә
2) Казан шәһәре вилайәте эчендә
3) Өлә Казаклары нам карйәсендә
4) тәвәлләдә бер җәван нур сәййидә
5) йөзе бәдер ай Мөхибҗамал мөсәмма
6) ки Нигъмәтулланың фәрзәндәсе ул
7) ирүб ун түрт йәшинә ул дилара
8) Хак әмере ирде рухы йирдән итде
9) варыб Фирдәвес әгъла ула мәәва
10) килеб буңа зийәрәт идән ихван
11) кыйлалар рухына фатиха ихсан
12) тарихе һиҗрәт 1241 сәнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул Аллаһ – Тере, беркайчан да Үлмәүче.
2) Казан шәһәре вилаятенең
3) Өлә Казаклары дигән авылында
4) туган бер яшь, нурлы кыз,
5) йөзе тулган ай Мөхибҗамал исемле
6) ки, Нигъмәтулланың баласы ул.
7) Ундүрт яшенә җиткәч, аңа тынычландыручы
8) Хак әмере килде, рухы җирдән китте.
9) Урыны булыр Олуг Фирдәвес җәннәтләрендә,
10) [әгәр] монда килеп, зиярәт иткән кардәшләр
11) рухына дога-изгелек кылсалар.
12) Һиҗри 1241 елда [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 98х27х13.

19. Фатыйма Үтәгән кызына куелган кабер ташы, 1801 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Румиййә илә меңдә сигез йөз
2) беренче йыл Бакый хәләле Фатыйма Үтәгән кызы 25
3) йәшендә дарел-фәнадан дарел-бәкайә интикаль итде
4) нәүвәраллаahү Тәгаалә мәркадәhәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади белән мең дә сигез йөз
2) беренче елда Бакый хәләле – Фатыйма Үтәгән кызы – 25
3) яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.
4) Аллаh Тәгалә аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 78х40х13.

20. Ибраһим Габделкәрим улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) мәрхүм Ибраһим
3) Габделкәрим углы
4) 1327 сәнәи һиҗриййә
5) 1909 сәнәи миладиййә
6) 88 йәшендә
7) 3 нче ийүлдә
8) гарикы рәхмәт
9) улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Ибраһим
3) Габделкәрим улы
4) һиҗри 1327 елда,
5) милади 1909 елның
6) 3 июлендә
7) 88 яшендә [вафат яки җирләнде].
8) Рәхмәткә
9) күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 98х32х9.

21. Габделкәрим Габделгазиз улына куелган кабер ташы, 1875 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер ийәсе мөтәвәффа мәрхүм
3) Габделкәрим Габделгазиз
4) углы 75 йәшендә
5) 1875 нче йылда
6) 21 нче нуйәбрдә
7) кабере мөнәүвәр улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Дога берлә кыйлыңыз рухымы шад
2) кәтәбәhәә
3) мулла Сәлах».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем хәлеңне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделкәрим Габделгазиз
4) улы, 75 яшендә
5) 1875 елның
6) 21 ноябрендә вафат.
7) Кабере нурлы булсын, амин».

Уң ягы:
1) «Дога белән рухымны шатландырыгыз”.
2) Моны язды:
3) мулла Сәлах».

Сул ягы: «Каберемне күреп, хәлеңне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 105х37х12.

22. Хәбибулла Габделгазиз улына куелган кабер ташы, 1888 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) әл-мәрхүм Хәбибулла Габделгазиз углы
3) 1888 нче сәнә 15 нче ийүндә
4) 77 йәшендә дөнйадин үтде
5) Аллаһ Тәгалә рәхмәт кылсун
6) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Мәрхүм Хәбибулла Габделгазиз улы
3) 1888 елның 15 июнендә
4) 77 яшендә дөньядан үтте.
5) Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын,
6) амин».

Таш үлчәмнәре: 72х28х9.

23. Айбикәч Җәгъфәр кызына куелган кабер ташы, 1539 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-хәйүл-ләзии ләә йәмүүтү вә күллү хәййин сә-йәмүүт
2) кааләллаahү Тәбәәракә вә Тәгааләә
3) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһ[205]
4) тарих тукуз йөз кырык алты да
5) мөбарәк рабигыль-әүвәл айында ир дикем Гали
6) гыйалы Җәгъфәр кыз Ай Бикәҗ даре фәнадин даре бәкага нәүвәраллаah».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Сул ягы (уеп язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караарии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул Аллаһ – Тере, Үлмәүче һәм һәр җан иясе үләчәк.
2) Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
3) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать [Раббыңның] йөзе генә калачак».
4) Тугыз йөз кырык алтынчы [елның]
5) мөбарәк рабигыль-әүвәл аенда Гали
6) хатыны – Җәгъфәр кыз[ы] Айбикәч фани дөньядан мәңгелек дөньяга [күчте]. Аллаһ [каберен] нурландырсын».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: барысы җимерелгән, һаман мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 100х38х15.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 10 б. №87.

24. Ураздәүләткә куелган кабер ташы, 1543–1544 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләллаahү Тәбәәракә вә Тәгааләә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү
3) Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам
4) тарих тукуз йөз иллик-
5) -дә Бу...с гыйалы Үраздәүләт
6) даре фәнадин даре бәкага рихләт кыйлды».

Уң ягы (калкытып язылган): «Каалән-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә мәзрагатүл-әәхыйраһ».

Сул ягы (калкытып язылган): «Каалән-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә җиифәтүн вә таалибүһәә киләәб».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:
2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның
3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак.
4) Тугыз йөз илленче
5) [елда] Бу...с хатыны Ураздәүләт
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья – ахирәт басуы»«.

Сул ягы: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) әйтте: «Дөнья – үләксә, аны этләр генә тели»«.

Таш үлчәмнәре: 120х39х18.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 10 б. №88.

Бу зиратта 1947 елда археологлар тарафыннан XVI гасырга караган 7 кабер ташын теркәп калдырган булганнар, әмма соңрак аларның дүртесен инде таба алмаганнар[206]. Күргәнебезчә, югалган ташларның берсе безнең тарафтан табылды һәм өйрәнелде. Шулай итеп, хәзерге көндә биредә XVI гасырга караган 4 эпиграфик истәлек сакланган.

Түбән Көек авылы зираты

1. Мөхәммәдколый бине Корбангали улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт
3) бу каберә назил Түбән
4) Көйек карйәсинең

[205] Бу аять язылып бетмәгән.

[206] Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С. 96.

5) Мөхәммәд[колый бине Корбангали][207]
6) 1920 сәнә гыйнвар»[208].

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн миңа икән иртән сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «13 ндә 51 йәшендә
2) дарел-фәнадан дар-
3) -ел-бәкайә рихләт итде»[209].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак.
3) Бу кабергә иңүче Түбән
4) Көек авылыннан
5) Мөхәммәд[колый бине Корбангали]
6) 1920 елда гыйнварның».

Уң ягы: «Бу көн миңа икән, иртән сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Арткы ягы:
1) «13 ндә 51 яшендә
2) фани дөньядан мәңгелек
3) дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 76(94)х29х10.

2. Сибгатулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер назил мөтәвә[210]
3) мәрхүм Сибгатулла
4) Гобәйдулла углы вафат
5) 917 йылда 2 фиврал
6) илле биш йәшдә
7) кабере мөнәүвәрә улсун
8) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йазгучы...».

Сул ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлыгыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Бу кабергә иңүче, вафат булучы
3) мәрхүм Сибгатулла
4) Гобәйдулла улы
5) [1]917 елның 2 февралендә
6) илле биш яшьтә вафат.
7) Кабере нурлы булсын,
8) амин».

Уң ягы: «Язучы...».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 76х41х13.

3. Билгесез кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) ...
3) ...
4) углы 1920 сәнәи миладиййә
5) дикәбр 9 пәнҗешәнбә көн
6) 1339 сәнәи һиҗриййә 75 йәшдә
7) вафат Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Әй гафил алданма бу дөнйага».

Сул ягы (уеп язылган): «Гакыйбәт бер көн китәрсең бу гокбага».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) ...
3) ...
4) улы милади 1920 елның
5) 9 декабрендә пәнҗешәмбе көн,
6) һиҗри 1339 елда 75 яшьтә
7) вафат. Аллаһ рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әй, ваемсыз, алданма бу дөньяга».

Сул ягы: «Ахырдан беркөн китәрсең бу ахирәткә».

Таш үлчәмнәре: 93х32х13.

[207] Язулары өстеннән кара буяу белән йөртелеп чыкканга күрә, исеме һәм атасының исеме язылган урыннары начар күренә.
[208] Дәвамы арткы ягында.
[209] Башы алгы ягында.
[210] Бу сүз язылып бетмичә калган, «мөтәвәффа» дип язылырга тиеш булган, мөгаен.

4. Гафифә Ибраһим кызына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибәсе
3) Түбән Кийек авылыйның
4) мәрхүмә Гафифә
5) Ибраһим кызы Го-
6) -бәйдулла җәмәгате
7) мәдфүнә 1923 нче
8) йылда
9) 11 нче ийүлдә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «58 нче
2) йәшендә
3) Аллаһ Тәгалә-
4) -нең рәхмәтендә
5) булсын
6) амин карендә-
7) -шләр догадан
8) ташламагыз».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) Түбән Көек авылыннан
4) мәрхүмә Гафифә
5) Ибраһим кызы – Го-
6) -бәйдулла җәмәгате –
7) 1923
8) елның
9) 11 июлендә җирләнде».

Арткы ягы:
1) «58 нче
2) яшендә [җирләнде].
3) Аллаһ Тәгалә-
4) -нең рәхмәтендә
5) булсын,
6) амин. Карендә-
7) -шләр, догадан
8) ташламагыз».

Таш үлчәмнәре: 88х30х14.

5. Галимулла Галиәсгар улына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер сахибе
3) мәрхүм Галимулла
4) Галиәсгар углы
5) вафат улды 1919
6) нчы йылда дикәбрнең
7) 11 ндә 19 йәшендә
8) Аллаһның рәхмәтендә
9) булсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе
3) мәрхүм Галимулла
4) Галиәсгар улы
5) 1919
6) елның 11
7) декабрендә 19 яшендә вафат булды.
8) Аллаһның рәхмәтендә
9) булсын».

Таш үлчәмнәре: 89х33х14.

6. Габделҗаббар Габделлатыйф улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Габделҗаббар Габделлатыйф
4) углы 1912 нче йылда
5) 25 нче дикәбрдә 85
6) йәшендә 1330 сәнәи һиҗриййә илә
7) дарел-фәнадан дарел-бәкайә
8) рихләт кыйлды рахимәллааһү
9) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән әнтә тәсыйру мислии»[211].

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[212].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Габделҗаббар Габделлатыйф
4) улы 1912 елның
5) 25 декабрендә 85
6) яшендә, һиҗри белән 1330 елда
7) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ киң рәхмәте белән
9) рәхим кылсын, амин».

[211] Башы сул ягында.
[212] Дәвамы уң ягында.

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Таш үлчәмнәре: 105х35х12.

7. Сәфәргали Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) бу кабер иясе мәрхүм
3) Сәфәргали Ибраһим углы
4) 1909 нчы сәнәи миладиййә
5) април 12 сендә
6) 72 йәшдә вафат
7) Аллаһ рәхмәт кылсун
8) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлугыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күрүб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Сәфәргали Ибраһим улы
4) милади 1909 елның
5) 12 апрелендә
6) 72 яшьтә вафат.
7) Аллаһ рәхим кылсын,
8) амин».

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 94х31х14.

8. Галиәкбәр Бәйрәмгали улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) Галиәкбәр Бәйрәмгали углы
3) дарел-фәнадан күчте
4) 1328 сәнәи һиҗриййәдә
5) 1910 нчы сәнәи миладиййә
6) 17 гыйнвар
7) 48 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Галиәкбәр Бәйрәмгали улы
3) һиҗри 1328 елда,
4) милади 1910 елның
5) 17 гыйнварында
6) 48 яшендә
7) фани дөньядан күчте».

Таш үлчәмнәре: 65х37х17.

9.Корбангали Әлмөхәммәд улына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Корбангали Әлмөхәммәд углы
4) 1902 нче сәнәи миладиййә
5) үктәбр 6 нчы йәүмендә
6) 70 йәшендә дарел-бәка-
7) -йә рихләт кыйлды Аллаһ
8) рәхмәт кыйлсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәнгә икән йарун сәнгәдер».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән мора-дым бер догадур кәтәбәһә мөәзине Үртәм Лотфулла».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Корбангали Әлмөхәммәд улы
4) милади 1902 ел
5) октябренең 6 нчы көнендә
6) 70 яшендә мәңгелек дөнья-
7) -га күчте. Аллаһ
8) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәтән морадым бер догадыр. Моны язды: Үртәм [Казак Үртәме авылы] мөәзине Лотфулла».

Таш үлчәмнәре: 93х31х11.

10. Бибигафифә Хөсәен кызына куелган кабер ташы, 1867 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә илээһә илләәллаah Мүхәммәдүр-
расүүлүллаah
2) руми 1867 сәнә фибрал
3) 16 нда һиҗри 1282 сәнә
4) маһе шәүвәлдә Түбән Кийекнең
5) Бибигафифә Хөсәйен кызы
Габделҗаббар
6) Габделлатыйф углы Тукмакыф
7) зәүҗәсе 29 йәшдә
8) даре бәкайә рихләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «Таййибәллаahү сәраahәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә әәмиин».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Милади 1867 елның 16
3) февралендә, һиҗри 1282 елның
4) шәүвәл аенда Түбән Көектән
5) Бибигафифә Хөсәен кызы –
Габделҗаббар
6) Габделлатыйф улы Тукмаков
7) хатыны – 29 яшьтә
8) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен, амин».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 120х36х13.

11. Мулла Габделлатыйф мулла Хәмид улына куелган кабер ташы, 1873 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаahү Тәгааләә күллү нәфсиң
2) зәәъикатүл-мәүүт руми 1873
3) сәнә ийүл 11 ндә һиҗри 1290 сәнә
4) җөмадиәл-әүвәл 28 ндә Түбән
5) Кийекнең сахибел-хәйрат
6) мулла Габделлатыйф мулла Хәмид
7) углы 73 йәшдә йәкшәнбә
8) көн даре бәкайә рихләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәндә икән йарин сәңадур».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллаahү ләһүмәә вә ли-вәәлидәйһүмәә вә ли-мән йәзүүру кабраһүмәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак. Милади 1873
3) елның 11 июлендә, һиҗри 1290 елның
4) 28 җөмадиәл-әүвәлендә Түбән
5) Көектән изгелекләр иясе
6) мулла Габделлатыйф мулла Хәмид
7) улы 73 яшьтә якшәмбе
8) мәңгелек дөньяга күчте».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Аллаһ аларның икесен дә, ата-аналарын да һәм каберләрен зиярәт кылучыларны да гафу итсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 116х36х22.

Әлеге кабер иясенең 1861 елда үз акчасына авылда ике манаралы мәчет салдыруы мәгълүм[213].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 10 б. №89.

12. Хәбибҗамал Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1848 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-мәрхүүмәтүл-мүкәррамәтү Габд-
2) -еллатыйф хәләле Хәбибҗамал
3) Хәбибулла кызы дарел-фәнадин да-
4) -рел-бәкайә рихләт әйләде 48–
5) –18[214] нче йылда тәсдыйк әйләб
6) күр кәмал кадыйр Аллаһ әхәд тәкъд-
7) -ир әйләде үлүмне барча кальга ә-
8) -үвәл самәд без идек нәселе сагыйда-
9) -н бу рәми өстендә ула хәйран
10) ...имде калдык вә а-
11) -дашты бәнүм каберим зийәрәт идә-

[213] Нигъмәтҗанов Г. Түбән Көек мәчете / Г. Нигъмәтҗанов // Әтнә Таңы. – 1996. – 20 гыйнвар (№5).
[214] 1848 саны шул рәвешле ике юлга бүленгән.

12) -н ихван кылалар рухына фатиха-
13) ихсан».

Уң ягы (калкытып язылган): «Табмады һич ничә дайә ошбу үлемгә дәва ничә шаһ галим пәнаһ калды гажиз бинәва...».

Сул ягы (калкытып язылган): «Бәне кыйл мәгъфирәт Раббы йәздан би-хәккый гаршин әгъзамин нуури куръәән...».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Кааләл-хәййүл-ләзии ләә йәмүүт
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт күллү
3) мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәжһү Раббикә зү-
4) -л-җәләәли вәл-икраам каал-
5) -ән-нәбии галәйһис-сәләәм йәә ибнү әәдәәмин
6) әнтүм әл-йәүмә фиил-гусуури вә гадән
7) фиил-кубүүри вә бәгъдә гадин фиин-нүшүүр
8) вә әммәә иләәл-хүүри вәл-кусуури
9) вә ләммәә иләәл-вәйли вәл-кубүүр вә мәә-
10) -л-хәйәәтүд-дүнйәә илләә мәтәәгу-
11) -ль-гуруур кийәве Һибатулладан».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Рәхим кылынган, хөрмәтле Габд-
2) -еллатыйф хәләле – Хәбибҗамал
3) Хәбибулла кызы – 1848 елда
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
5) күчте. Дөреслеген танып,
6) күр: камил, көчле Аллаһ тәкъд-
7) -ир кылды үлемне. Барча кальга ә-
8) -үвәл мәңге бетмәс без идек нәселе авышучыда-
9) -н бу ату өстендә хәйран була
10) ...инде калдык һәм а-
11) -дашты[215]. Минем каберемне зиярәт иткә-
12) -н кардәш, рухына «Фатиха» сүрәсе укыйлар, изгелек
13) кылалар».

Уң ягы: «Һичкем бу үлемгә дәва тапмады, күпме шаһ, галим, сыену урыны тапмыйча, гажиз, ярдәмчесез калды...».

Сул ягы: «Мине гафу ит, Раббым Аллаһ, бөек гареш, Коръән нурының хакы белән».

Арткы ягы:
1) «Тере, Үлмәүче [Аллаһ] әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак. Анда [җир йөзендә] булучы
3) һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның Олуглык
4) һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак». Пәйгамбәр
5) (аңа сәлам булсын) әйтте: «Әй, адәм баласы,
6) сез бүген патша сарайларында, иртәгә
7) каберләрдә булырсыз, аннан соң яңадан терелерсез.
8) Кайберәүләр хур кызларына һәм патша сарайларына,
9) кайберләрегез үкенечкә һәм һәлакәткә таба китәр. Дөнья
10) тормышы алданудан башка нәрсә
11) түгел. Кияве Һибатулладан».

Таш үлчәмнәре: 145x33x12.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 10 б. №90.

13. Хәлимҗан Вәлид кызына куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һүвәл-халләәкуль-бәәкыый
2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә
3) Хәлимҗан[216] Вәлид кызы
4) Ибраһим Исмәгыйль углы-
5) -ның әһлийәсе 1889 нчы
6) йылда 25 нче гыйнварда
7) вафат Аллаһ рәхмәтендә
8) улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәнгә икән, йарин сәнгәдер».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән мурадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Ул [Аллаһ] – Бар итүче, Мәңге.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Хәлимҗан Вәлид кызы –
4) Ибраһим Исмәгыйль улы-
5) -ның хатыны –1889
6) елның 25 гыйнварында
7) вафат. Аллаһ рәхмәтендә
8) булсын, амин».

Уң ягы: «Бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

[215] Бу җөмләне аңлый алмадык.

[216] Ташта хатын-кыз исеме шул рәвешле язылган.

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 100х31х13.

14. Корбангали Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1896 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) румиййә илә 1896 сәнә май
3) 7 ндә Түбән Кийекнең
4) Корбангали Ибраһим
5) углы дүшәнбә көн
6) 51 йәшдә даре бәкайә»[217].

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары».

Сул ягы (уеп язылган): «Рихләт итде Аллаһ Тәгалә гарикы рәхмәт итсүн амин»[218].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади беләп 1896 елның 7
3) маенда Түбән Көектән
4) Корбангали Ибраһим
5) улы дүшәмбе көн
6) 51 яшьтә мәңгелек дөньяга».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары, бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күчте. Аллаһ Тәгалә рәхмәткә күмсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 95х35х19.

15. Мулла Габделгазыйм мулла Габделгафур улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әс-сәләәмү галәйкүм
2) йәә әһләл-кубүүр мәрхүм
3) мулла Габделгазыйм
4) мулла Габделгафур углы
5) 1899 сәнәи миладиййә
6) синтәбр 30 нда
7) 79 йәшенд вафат
8) Аллаһ рәхмәтендә улсун.

Уң ягы (уеп язылган): «Таки рузи идә Аллаһ оҗмахы»[219].

Сул ягы (уеп язылган): «Даимән кыйлгыл гыйбадәт әй әхый»[220].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Сезгә сәлам булсын,
2) әй, кабер әһелләре! Мәрхүм
3) мулла Габделгазыйм
4) мулла Габделгафур улы
5) милади 1899 елның
6) 30 сентябрендә
7) 79 яшендә вафат.
8) Аллаһ рәхмәтендә булсын».

Уң ягы: «Аллаһ оҗмах бирсен өчен».

Сул ягы: «Даими гыйбадәт кыл, әй, минем кардәшем».

Таш үлчәмнәре: 114х31х12.

Әлеге кабер иясе, 1884 елның 12 мартында указ (указ номеры – №1604) алып, муллалык вазыйфасын башкарган.

16. Хөснеҗиһан мулла Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу каберә назилә мәрхүмә
2) Хөснеҗиһан мулла
3) Хәбибулла кызы мулла
4) Габделгазыйм әһлийәсе
5) вафат 1904 нче 19 нчы
6) үктәбрдә 80 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабергә иңүче мәрхүмә
2) Хөснеҗиһан мулла
3) Хәбибулла кызы – мулла
4) Габделгазыйм хатыны –
5) 1904 елның 19
6) октябрендә 80 яшендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 74х35х10.

[217] Дәвамы сул ягында.
[218] Башы алгы ягында.
[219] Дәвамы сул ягында.
[220] Башы уң ягында.

17. Шәйхелислам мулла Фәйзеләкъдәс улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) мәхдүм Шәйхелислам
4) мулла Фәйзеләкъдәс
5) углы 1911 сәнәи миладиййә
6) март 15 ндә 1329
7) һиҗриййә 19 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Ән-нәдәәмәтү лаа түфиидү бәгъдәл-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) мәхдүм Шәйхелислам
4) мулла Фәйзеләкъдәс
5) улы милади 1911 елның
6) 15 мартында, һиҗри
7) 1329 [елда] 19 яшендә вафат».

Уң ягы: «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Таш үлчәмнәре: 82х33х13.

Түбән Шашы авылы зираты

1. Мөәзин Мөхәммәдшәриф Мөхәммәдсадыйк улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Мөхәммәдшәриф
3) [Мөхәммәдс]адыйк
4) углы 91 йәшендә
5) 10 нчы априлдә вафат
6) 1334 сәнәи һиҗриййә
7) 1916 сәнәи миладиййә
8) 20 йыл мөәзин булган
9) Аллаһ кабул кыйлсун».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада иде-
3) -ңез йад
4) тәсаддыклә кыйлы-
5) -ңыз рухымы
6) шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мөхәммәдшәриф
3) [Мөхәммәдс]адыйк
4) улы 91 яшендә
5) һиҗри 1334 елда,
6) милади 1916 елның
7) 10 апрелендә вафат.
8) 20 ел мөәзин булган,
9) Аллаһ кабул итсен».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә
3) алыгыз.
4) Сәдака бирү белән
5) рухымны
6) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 117х33х10.

2. Садреддин Нигъмәтулла улына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Түбән Шашы авылы
2) Садреддин Нигъмәтулла
3) углы 1919 нчы йылда
4) 9 нчы дикәбр 53 йәшенд
5) даре бәкайә рихләт
6) әйләде тугры адәм
7) иде рахимәһүллааһүл-Мәннәән».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗриййә илә 1318 нче сәнә
2) рабигыль-әүвәл 25 нче көне
3) җан тәслим әйләде
4) углы Низамеддин
5) бина кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Түбән Шашы авылыннан
2) Садреддин Нигъмәтулла
3) улы 1919 елның
4) 9 декабрендә 53 яшендә

5) мәңгелек дөньяга
6) күчте. Тугры адәм
7) иде. Нигъмәт бирүче Аллаһ аны рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән 1318 ел
2) рабигыль-әүвәленең 25 нче көнендә
3) җан тәслим кылды.
4) Улы Низамеддин
5) куйды».

Таш үлчәмнәре: 79(93)х32х9.

3. Сираҗеддин Нәҗмеддин улына куелган кабер ташы, 1926 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «...
2) Сираҗеддин
3) Нәҗмеддин углы
4) 67 йәшендә
5) җөмадиәл-хир-
6) -нең[221] 27 сендә
7) дүшәнбә көн
8) мәдфүн».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1344 сәнәи һиҗриййә
2) 1926 (?) сәнәи миладиййә
3) 27 нче дикәбрдә
4) кәрәм әйләб дога-
5) -да идеңез йад
6) тәсаддыклә кыйлу-
7) -ңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «...
2) Сираҗеддин
3) Нәҗмеддин улы
4) 67 яшендә
5) җөмадиәл-ахир-
6) -нең 27 сендә
7) дүшәмбе көн
8) җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри 1344 елда,
2) милади 1926(?) елның
3) 27 декабрендә [җирләнде].
4) Юмартлык кылып,
5) догада искә алыгыз.
6) Сәдака бирү белән
7) рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 90х31х9.

4. Бибизарифә Габдерәхим кызына куелган кабер ташы, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Инил-хүкмү илләә лилләәһ
2) Бибизарифә Габд-
3) -еррәхим кызы
4) йәшендә
5) Сираҗеддин
6) зәүҗәсе
7) 13 сәнәи[222] һиҗриййә».

Уң ягы (уеп язылган): Фә-кәъәннәмәә зәәрании фии хәйәәтии»[223].

Сул ягы (уеп язылган): «Ли-мән зәәрании бәгъдә мәмәәтии»[224].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада иде-
3) -ңез йад тәсадды-
4) -клә кыйлуңыз
5) рухымы
6) шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта гына.
2) Бибизарифә Габд-
3) -ерәхим кызы –
4) Сираҗеддин
5) хатыны –
6) яшендә
7) һиҗри 13 елда [вафат]».

Уң ягы: «Шул мине исән чагымда зиярәт кылган кебек булыр».

Сул ягы: «Кем мине үлгәннән соң зиярәт кылса».

[221] «Җөмадиәл-ахирнең».

[222] Биредә кайчан һәм ничә яшендә вафат булуы күрсәтелмәгән. Таш, әле иясе вафат булганчы ук, әзерләнгән һәм, ул үлгәч, шул калдырылган урынга ничә яшендә һәм кайсы елда үлүе дә язылырга тиеш булган, ләкин ниндидер сәбәпләр аркасында бу эш башкарылмыйча калган, күрәсең.

[223] Башы сул ягында.

[224] Дәвамы уң ягында.

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә
3) алыгыз. Сәдака
4) бирү белән
5) рухымны
6) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 107(113)х36х12.

5. Галиәсгар Габделкәрим улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Галиәсгар
3) Габделкәрим углы
4) һиҗриййә илә 1328 нче йылда
5) миладиййә 1910 нчы йылда
6) 4 агусда
7) 80 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Безем Коръән у-
2) -кырга пылымыз йук».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Галиәсгар
3) Габделкәрим улы
4) һиҗри белән 1328 елда,
5) милади 1910 елның
6) 4 августында
7) 80 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Арткы ягы:
1) «Безнең Коръән у-
2) -кырга көчебез юк».

Таш үлчәмнәре: 108х31х11.

6. Нигъмәтулла Зәбир улына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Нигъмәтулла
3) Зәбир углы мөхәррәм 4 нд
4) миладиййә 1902 нче йылда
5) беренче априлд
6) 84 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Нигъмәтулла
3) Зәбир улы 4 мөхәррәмдә,
4) милади 1902 елның
5) беренче апрелендә
6) 84 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 80х32х11.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Нигъмәтулла бине Зәбир бине Нәзир бине Ирмәк бине Ярмәк бине Ибраһим[225].

7. Шәрәфҗамал Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Шәрәфелҗама-
3) -л Хәбибулла кызы
4) миладиййә 1909 нче йылда
5) 10 нчы нуйәбрдә
6) 90 йәшендә».

[225] Әхмәтҗанов М.И. Татар археографиясе. Милли-мәдәни мирас хәзинәләре системасына сәхифәләр. – Казан, 2011. – Б. 190.

Уң ягы (уеп язылган): «Беләсез бу каберә киләчәк вакытыңыз йакыйн».

Сул ягы (уеп язылган): «Йә әхый гафил улма сакыйн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Шәрәфҗама-
3) -л Хәбибулла кызы
4) милади 1909 елның
5) 10 ноябрендә
6) 90 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Беләсез: бу кабергә киләчәк вакытыгыз якын».

Сул ягы: «Әй, кардәшем, гафил булма, сак бул».

Таш үлчәмнәре: 82 (96)х31х11.

8. Хисамеддин Гаделша улына куелган кабер ташы, 1898 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу кабер
2) би-хүкми Хода мәд-
3) -фүн Хисаэддин[226]
4) Гаделша углы
5) 1898 нче йылда
6) миладиййә илә
7) 24 нче дикәбрдә
8) 64 йәшендә».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әд-дәәру дәәру нәгыыймин ин гамилтә биһәә»[227].

Сул ягы (калкытып язылган): «Йүрдааль-иләәһә вә ин хааләфтә фән-нәәр»[228].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хода хөкеме белән.
2) Бу кабер Хисамеддин
3) Гаделша улыныкы,
4) милади белән
5) 1898 елның
6) 24 декабрендә
7) 64 яшендә
8) җирләнде».

Уң ягы: «Әгәр [Раббың риза булырлык] гамәлләр кылсаң, барачак урының җәннәт йорты булыр».

Сул ягы: «Раббың риза булырлык. Әгәр каршы килсәң, урының ут булыр».

Таш үлчәмнәре: 110(116)х31х14.

9. Латыйфа Хисамеддин кызына куелган кабер ташы, 1896 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Латыйфа
3) Хисамеддин кызы
4) һиҗриййә 1314 нче йылда
5) миладиййә 1896 нчы йылда
6) 13 майда Мөхәммәдшәриф
7) мөәзин җәмәгате 63 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу көн бәндә икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Латыйфа
3) Хисамеддин кызы –
4) Мөхәммәдшәриф мөәзин җәмәгате –
5) һиҗри 1314 елда,
6) милади 1896 елның
7) 13 маенда 63 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр».

Таш үлчәмнәре: 86х31х13.

10. Мулла Мөхәммәдшәриф мулла Хәмид улына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-имәәмүл-гаадилү

[226] Бу исем Хисамеддин булырга тиеш, «м» хәрефе төшеп калган, ахыры.
[227] Дәвамы сул ягында.
[228] Башы уң ягында.

2) мүтәвәффәә вә мәрхүүмүн
3) мулла Мөхәммәдшәриф
4) бине мулла Хәмид әш-Ша-
5) -шыви дәфен кыйлынды
6) 1908 нче сәнәдә
7) 27 нче майда
8) сиһшәнбә көн
9) 59 йәшендә».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әл-мәүтү бәәбүн вә күллүн-нәәси дәәхыйлүһ»[229].

Сул ягы (калкытып язылган): «Фә-ләйтә шәгърийә бәгъдәл-мәүти мәәд-дәәр»[230].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мин һиҗрати расүүл-
2) -үллаahи салләәллаahү
3) Тәгааләә галәйһи вә сәлләм
4) 1326 нчы йылда
5) 10 нчы җөмадиәл-әүвәл
6) мулла Мөхәммәдшәриф
7) мулла Хәмид углы
8) мәдфүн 59 йә-
9) -шендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Гадел имам,
2) вафат булучы, рәхим кылынган
3) мулла Мөхәммәдшәриф
4) бине мулла Хәмид Ша-
5) -шыви
6) 1908 елның
7) 27 маенда
8) сишәмбе көн
9) 59 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Үлем – ишек, һәр кеше аннан керәчәк».

Сул ягы: «Үлгәннән соң нинди урын әзерләнгәндер».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ илчесе (аны Аллаһ
2) Тәгалә олыласын һәм сәламләсен)
3) һиҗрәтеннән [Мәккәдән Мәдинәгә күченүеннән саналган ел исәбе белән]
4) 1326 елның
5) 10 җөмадиәл-әүвәлендә
6) мулла Мөхәммәдшәриф
7) мулла Хәмид улы
8) 59 яшендә
9) җирләнде».

Таш үлчәмнәре: 110x32x12.

Әлеге кабер иясе, 1875 елның 14 октябрендә мулла булып эшләр өчен указ (указ номеры – №7522) алганнан соң, авылга имам-хатыйб итеп билгеләнгән.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №91.

11. Билгесез хатын-кызга куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «...
2) Бибиб...
3) кызы...
4) хәләле...
5) Х...
6) ...
7) 1899 нчы сәнәдә».

Таш үлчәмнәре: 51x25x6.

12. Нигъмәтулла Рәхмәтулла улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[231]:
1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгааләә
2) мәдфүн Нигъмәтулла
3) Рәхмәтулла углы
4) 77 нче йәшендә 1894 нче
5) сәнәдә рахимәһүллаahү рахмәтән
6) вәәсигат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.
2) Нигъмәтулла
3) Рәхмәтулла улы
4) 77 нче яшендә 1894
5) елда җирләнде. Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән
6) рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 48x34x7.

[229] Дәвамы сул ягында.
[230] Башы уң ягында.
[231] Өске ягында ай рәсеме уелган.

Чембулат авылы зираты

1. Бибимәликәбану Төхфәтулла кызына куелган кабер ташы, 1862 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһил-кәбиирил-
мүтәгааль
2) руми 1862 сәнә ийүл 3 ндә
3) һиҗри 1280 сәнә сәфәрел-хәйер-
4) -нең әүвәлендә Ченбулатның
5) Бибимәликәбану Төхфәтулла
6) кызы хаҗҗел-хәрәмәйен Таҗ-
7) -еддин Сәйфеддин углының
8) хәләле 38 йәшдә» .

Сул ягы (уеп язылган): «Даре фәнадин даре бәкайә рихләт кылды тайиибәллаахү сәраахәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Һәзәә кабру Бибимәликәбану
2) бинте Төхфәтулла зәүҗәи хаҗҗел-
хәрәмәйен
3) Таҗеддин бине Сәйфеддин әл-
Ченбулати».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Бөек, Югарыда булучы Аллаһта.
2) Милади 1862 елның 3 июлендә,
3) һиҗри 1280 ел сәфәре –
4) -нең әүвәлендә Чембулаттан
5) Бибимәликәбану Төхфәтулла
6) кызы – хаҗи Таҗ-
7) -еддин Сәйфеддин улының
8) хәләле – 38 яшьтә».

Сул ягы: «Фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын һәм урынын җәннәт итсен».

Арткы ягы:
1) «Бу – Бибимәликәбану
2) бинте Төхфәтулла, хаҗи Таҗеддин
3) бине Сәйфеддин Чембулати хатыны, кабере».

Таш үлчәмнәре: 120(141)х36х16.

2. Фазлыйәхмәд Рәхмәтулла улына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Мөтәвәффа Фазлыйәхмәд
2) Рәхмәтулла углы
3) 1894 нче йылда
4) априлдә 56 йәшендә
5) дарел-фәнадан рихләт әйләде
6) рахмәтүллааһи галәйһүмәә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (калкытып язылган): «Калиилү гумринәә фи дәәри дүнйәә вә мәрҗигунәә илә бәйтит-түрааб».

Сул ягы (калкытып язылган): «Мән йәржүү минәд-дүнйәә вәфәәъән кә-мән йәржүү шәраабән мин сәрааб».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Вафат булучы Фазлыйәхмәд
2) Рәхмәтулла улы
3) 1894 елның
4) апрелендә 56 яшендә
5) фани дөньядан күчте.
6) Аларның икесенә дә Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Уң ягы: «Безнең гомеребезнең аз өлеше генә дөньяда һәм кайтачак җиребез туфрак йорты».

Сул ягы: «Кем дөньядан тугрылык көтсә, шул рәшәдән эчемлек көткән сыман булыр».

Таш үлчәмнәре: 73х31х12.

3. Габделлатыйф Мөхәммәдсиддыйк улы Шәриповка куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаахүммәҗгаль
2) кабра һәзәәл-мәййити
3) мин рийәәдыйль-җәннәһ
4) Габделлатыйф
5) Мөхәммәдсиддыйк
6) углы Шәрипуф
7) дәфен кылынды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә
2) илә 1922 нче
3) сәнәдә 17 нче
4) априлдә 69
5) йәшендә даре
6) бәкайә рихләт
7) әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһым, бу мәет
2) каберен җәннәт
3) бакчаларыннан ит.
4) Габделлатыйф
5) Мөхәммәдсиддыйк
6) улы Шәрипов
7) җирләнде».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) белән 1922
3) елның 17
4) апрелендә 69
5) яшендә мәңгелек
6) дөньяга
7) күчте».

Таш үлчәмнәре: 87x30x8.

4. Салих Шиһабеддин мулла улына куелган кабер ташы, 1870 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1870 нче сәнәдә
2) дикәбрнең 26
3) вафат булды
4) морза Салих бине мулла
5) Шиһабеддин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһның рәхмәтенә
2) гарикъ улсун
3) шәфәгатьнең
4) рузый кыйлсун
5) 5 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1870 елның
2) 26 декабрендә
3) морза Салих бине мулла
4) Шиһабеддин
5) вафат булды».

Арткы ягы:
1) «Аллаһның рәхмәтенә
2) күмелсен,
3) шәфәгатен
4) насыйп итсен.
5) 5 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 68x42x8.

5. Габдрахман Шиһабеддин мулла улына куелган кабер ташы, 1871 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1871 нче елда мартның 14
2) морза Габдеррахман
3) мулла Шиһабеддин
4) углы вафат улды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) Аллаһ шәфәгатьнең
3) рузый кыйлсун
4) рәхмәтенә гарикъ улсун
5) йәш йарымда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1871 елның 14 мартында
2) морза Габдрахман
3) мулла Шиһабеддин
4) улы вафат булды».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Аллаһ шәфәгатен
3) насыйп итсен,
4) рәхмәтенә күмсен.
5) Яшь ярымда [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 44x44x6.

6. Мулла Шиһабеддин Габделгафур улына куелган кабер ташы, 1887 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә иллээллааһ Мүхәммәдүр-
расүүлүллааһ салләәллааһү галәйһи вә сәлләм
2) әл-гаалимүл-фәәдыйлү мулла
3) Шиһабеддин ибне Габде-
4) -лгафур Ченбулат илинең һижриййә
5) илә 1305 нче сәнәд рабигъ сәни
6) руми 1887 нче йылд 29».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән өмидем бер догадыр бу кө бәңга икән йарин сәңгадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Нче нуйәбрдә даре фәнадан рихләт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе, Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен.
2) Галим, лаеклы зат мулла
3) Шиһабеддин ибне Габде-
4) -лгафур (Чембулат иленнән) һижри
5) белән 1305 елның рабигыль-ахирендә,
6) милади 1887 елның 29».

Уң ягы: «Галәмәттән өметем бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә синадыр».

Сул ягы: «Ноябрендә фани дөньядан күчте»

Таш үлчәмнәре: 86x31x10.

Әлеге кабер иясе, 1865 елның 8 февралендә указ алгач, авылда мулла вазыйфасын башкарган.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №92.

7. Бибихәдичә дамелла Шиһабеддин кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) дәфен кыйлынды Бибихәдиҗә
3) дамелла Шиһабеддин
4) хәзрәт кызы румиййә илә
5) 1904 нче сәнә 15 нче май
6) 29 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Күрәрмен дөнйаны вәйран бары».

Сул ягы (уеп язылган): «Һәмишә бакый ирмәс йук карары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бибихәдичә
3) дамелла Шиһабеддин
4) хәзрәт кызы милади белән
5) 1904 елның 15 маенда
6) 29 яшендә җирләнде».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары».

Сул ягы: «Һаман мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 71(94)x31x12.

8. Шәмседдин Сәедбофһан улына куелган кабер ташы, 1871 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1871 нче
2) сәнәдә
3) абрилнең
4) 27 көндә Шәмс-
5) -еддин Сәйедбофһан
6) углы 65 йәшендә
7) вафат булды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһның
2) рәхмәтенә
3) гарикъ у-
4) -лсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1871
2) ел
3) апреленең
4) 27 көнендә Шәмс-
5) -един Сәедбофһан
6) улы 65 яшендә
7) вафат булды».

Арткы ягы:
1) «Аллаһның
2) рәхмәтенә
3) күмел-
4) -сен».

Таш үлчәмнәре: 52x51x6.

9. Идрис Бикчәнтәй улына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1907 нче йылда
2) 1325 нче сәнә
3) шәүвәлнең 16 нда

4) җомга көн Идр-
5) -ис Бикчәнтәй
6) углы 81 йәшендә
7) дарел-фәнадан дарел-бәкайә
8) рихләт әйләде Аллаһ
9) рәхмәт әйләсүн
10) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1907 елда,
2) [һиҗри] 1325 елның
3) 16 шәүвәлендә
4) җомга көн Идр-
5) -ис Бикчәнтәй
6) улы 81 яшендә
7) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ
9) рәхим кылсын,
10) амин».

Таш үлчәмнәре: 110x35x11.

10. Бибимаһирә Бикмөхәммәд кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) 1907 нче йылда румиййә
4) илә 28 нче агустда
5) Хәбибулла җәмәгате Бибимаһирә
6) Бикмөхәммәд кызы 48
7) йәшендә даре фәнадан
8) рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Һәр нә дәклү чук йәшәрсә бер кеше».

Сул ягы (уеп язылган): «Гакыйбәт үлмәк дорыр аның эше».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Милади белән 1907
4) елның 28 августында
5) Хәбибулла җәмәгате – Бибимаһирә
6) Бикмөхәммәд кызы – 48
7) яшендә фани дөньядан
8) күчте».

Уң ягы: «Ни тиклем озак яшәсә бер кеше».

Сул ягы: «Ахырдан үлү булыр аның эше».

Таш үлчәмнәре: 101x32x11.

11. Хәлилулла Хәмид улына куелган кабер ташы, 1902 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) румиййә илән 1902
3) нче йыл 6 нчы гыйнварда
4) 80 йәшендә Хәлилулла Хәмид
5) углы даре фәнадан
6) даре бәкайә рихләт әйлә-
7) -де кабере мөнәүвәр улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Һәр кеше бу мәркадә кыйлса нәзар».

Сул ягы (уеп язылган): «Сахибине бел догада йад идәр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Милади белән 1902
3) елның 6 гыйнварында
4) 80 яшендә Хәлилулла Хәмид
5) улы фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күч-
7) -те. Кабере нурлы булсын».

Уң ягы: «Һәр кеше бу урынга караса».

Сул ягы: «Иясен белеп, догада искә алыр».

Таш үлчәмнәре: 95x32x11.

12. Габделкадыйр Габделмөэмин улына куелган кабер ташы, 1899 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) дәфен кыйлынды Габделка-
3) -дыйр Габделмөэмин углы
4) миладиййә илән 1899 нчы
5) йыл 18 нче дикәбрдә
6) 64 йәшендә нәүвә-
7) -раллаһү кабраһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Васыйәтем будур әүлядләримә».

Сул ягы (уеп язылган): «Дәхи ихванларыйм дамадларыйма».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мисраг
2) газиз гомеренгезнең кадерен беләсез
3) бу мәнзил йарагын анда кыйласыз
4) безә Коръән укурга монда тел йук
5) тәсаддык һәм вирүргә кулда пыл йук
6) уйан бу йан бакуб дога көтәмез
7) хәйер ихсан дәхи өмид итәмез».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Габделка-
3) -дыйр Габделмөэмин улы
4) милади белән 1899
5) елның 18 декабрендә
6) 64 яшендә җирләнде. Аллаһ
7) аның каберен нурландырсын».

Уң ягы: «Васыятем будыр балаларыма».

Сул ягы: «Шулай ук кардәшләрем, кияүләремә».

Арткы ягы:
1) «Шигырь:
2) Газиз гомерегезнең кадерен беләсез,
3) Бу урын кирәк-ярагын анда әзерлисез.
4) Безгә Коръән укырга монда тел юк,
5) Сәдака бирергә дә кулда көч юк.
6) Ул якка, бу якка карап, дога көтәбез,
7) Хәер-изгелек шулай ук өмет итәбез».

Таш үлчәмнәре: 95x31x10.

13. Гайнекамал Әхтәм кызына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Һәзәә мәркадүл-мәрхүүмәти
2) Гайнекамал Әхтәм
3) кызы 1897 нче
4) йылда фибралда
5) дарел-фәнадан рихләт әйләде».

Уң ягы (калкытып язылган): «Ләү кәәнә-тид-дүнйәә түдүүмү ли-вәәхидин лә-кәәнә расүүлүллааһи фии[һәә] мүхълидәә».

Сул ягы (калкытып язылган): «Йәә вәә-кыйфән фии кабрии мүтәфәккиран би-әмрии күнтү мислүкә әмсин фә-тәсыыйру гадән мислии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу мәрхүм
2) Гайнекамал Әхтәм
3) кызы кабере, 1897
4) елның февралендә
5) фани дөньядан күчте».

Уң ягы: «Әгәр дә дөнья берәр зат өчен дәвам итсә, Аллаһның илчесе [Мөхәммәд пәйгамбәр] анда мәңге булыр иде».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 68(80)x31x12.

14. Бибифатыйма Сәгъдәнша кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Бибифатыйма Сәгъдән-
3) -шаһ кызы
4) Сәмигулла
5) зәүҗәсе».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «10 нчы ийүнд
2) 1909 сәнәи миладиййә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бибифатыйма Сәгъдән-
3) -ша кызы –
4) Сәмигулла
5) хатыны».

Арткы ягы:
1) «Милади 1909 елның
2) 10 июнендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 54(67)x26x7.

15. Таҗеддин Сәйфеддин улына куелган кабер ташы, 1897 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгааләә күллү мән
2) галәйһәә фәән руми 1897 сәнә
3) гыйнвар 21 ндә һиҗри
4) 1314 сәнә рамазан әүвәл көнендә

5) Ченбулатның хаҗҗел-хәрәмәйен
6) Тажеддин Сәйфеддин
7) углы...».

Уң ягы (уеп язылган): «Мән таләбә гыйбратән фәл-мәкаабиратү тәкфиих».

Сул ягы (уеп язылган): «Көн даре бәкайә рихләт кыйлды Аллаһ рәхмәт әйләсүн».

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Һәзәә мәркадүл-хәәҗҗи Таҗ-
2) -еддин бине Сәйфеддин
3) әл-Ченбулати мәәтә 1897 сәнәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: Анда [җир йөзендә] булучы
2) һәркем, һәрнәрсә фани. Милади 1897 елның
3) 21 гыйнварында, һиҗри
4) 1314 ел рамазанының әүвәлге көнендә
5) Чембулаттан хажи
6) Тажеддин Сәйфеддин
7) улы...».

Уң ягы: «Кем гыйбрәт сораса, аңа зират җиткән.».

Сул ягы: «Көн мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Бу хажи Таж-
2) -еддин бине Сәйфеддин
3) Чембулати кабере, 1897 елда вафат».

Таш үлчәмнәре: 97x33x18.

16. Маһимарзыя мулла Шиһабеддин кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) би-хүкмилләәһи Газзә вә Җәлл дарел-
фәнадин
3) дарел-бәкайә рихләт әйләде Маһимарзыйа
4) мулла Шиһабеддин хәзрәт кызы
5) Чуаш иле мулла Габдеррахман
6) хәзрәт әһлийәсе румиййә
7) иләп 1904 нче сәнә 25 йәшендә
8) 12 нче ийүлдә мәдфүнә рахимәллааһү Тәгааләә
9) иләйһәә».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадур бу көн бәңа икән йарын сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Олуг һәм Бөек Аллаһ хөкеме белән. Маһимарзыя
3) мулла Шиһабеддин хәзрәт кызы –
4) Чуаш иленнән мулла Габдрахман
5) хәзрәт хатыны – фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте, милади
7) белән 1904 елның 12 июлендә
8) 25 яшендә җирләнде. Аллаһ аны рәхим
9) кылсын».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миндә икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 108(117)x31x14.

17. Гайшәбикә мулла Хәсән кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллааһү ли-мән зәәрании
2) бу каберә назилә мөтәвәффәт мәрхүмә
3) имраәте салиха Гайшә-
4) -бикә мулла Хәсән кызы Ченбыт мулла
5) Шиһабеддин хәзрәт әһлийәсе
6) 1904 нче сәнә 9 нчы дикәбр
7) 66 йәшендә кабере мөнәүвәр улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән бикабрии мүтәфәккиран фии әмрии».

Сул ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗрииййә иләп
2) 1321 нче йылда
3) 14 нче шәүвәлдә
4) дәфен иделде
5) Аллаһ рәхмәт итсүн
6) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабергә вафат булучы мәрхүмә,
3) изге хатын Гайшә-
4) -бикә мулла Хәсән кызы – Чембулаттан мулла
5) Шиһабеддин хәзрәт хатыны –
6) 1904 елның 9 декабрендә
7) 66 яшендә иңде. Кабере нурлы булсын».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче».

Сул ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән
2) 1321 елның
3) 14 шәүвәлендә
4) җирләнде.
5) Аллаһ рәхим кылсын,
6) амин».

Таш үлчәмнәре: 91(100)x31x12.

18. Сәмигулла Галиулла улына куелган кабер ташы, 1923 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Сәмигулла Галий-
3) -улла углы 65
4) йәшендә агусда
5) 21 сендә вафат».

Арткы ягы (уеп язылган): «1923 сәнәи миладиййә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Сәмигулла Гали-
3) -улла улы 65
4) яшендә августның
5) 21 ндә вафат».

Арткы ягы: «Милади 1923 елда [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 57x31x8.

19. Габделгалләм Гайнеддин улына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Габделгалләм
3) Гайнеддин
4) углы 72 йәшендә
5) дарел-фәнадан
6) дарел-бәкага
7) рихләт кыйлды
8) рахимәһүллааһү
9) рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухымы шад амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1925 сәнә
2) 10 нчы майда
3) 15 шәүвәл
4) йәкшәнбә көн
5) дәфен кыйлынды
6) Аллаһ рәхмәт
7) кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Габделгалләм
3) Гайнеддин
4) улы 72 яшендә
5) фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга
7) күчте.
8) Аллаһ аны киң рәхмәте
9) белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Арткы ягы:
1) «1925 елның
2) 10 маенда,
3) 15 шәүвәлендә
4) якшәмбе көн
5) җирләнде.

6) Аллаһ рәхим
7) кылсын».

Таш үлчәмнәре: 85х29х8.

20. Һади Заһидулла улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Һади Заһид-
4) -улла углы
5) 1911 нче йылның
6) февралендә 80 йә-
7) -шендә вафат рахимәһ-
8) -үллаһү рахмәтән
9) вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлыңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе
3) Һади Заһид-
4) -улла улы
5) 1911 елның
6) февралендә 80 я-
7) -шендә вафат. Аллаһ аны
8) киң рәхмәте белән
9) рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Каберемне күреп, әҗәлне искә ал».

Таш үлчәмнәре: 78х23х11.

21. Маһиҗамал Хәбибулла кызына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Даре фәнадан даре бәкайә
2) рихләт әйләде Габид-
3) -улла җәмәгате Маһиҗамал
4) Хәбибулла кызы 1908 нҗе
5) йыл румиййә илә 23 нҗе
6) априлдә 57 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Һәр нә дәклү чук йәшәрсә бер кеше».

Сул ягы (уеп язылган): «Гакыйбәт үлмәк дорыр аның эше».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Габидулла җәмәгате – Маһиҗамал
2) Хәбибулла кызы – милади белән
3) 1908 елның 23
4) апрелендә 57 яшендә».
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте».

Уң ягы: «Ни тиклем озак яшәсә бер кеше».

Сул ягы: «Ахырдан үлү булыр аның эше».

Таш үлчәмнәре: 75(84)х31х10.

22. Бибизөһрә Әхмәдулла кызына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Бибизөһрә
3) Әхмәдулла кызы
4) Габделхәким Гыйззәтулла
5) әһлийәсе 1916 йыл
6) 29 нчы април һиҗрииййә
7) илә 1334
8) рәҗәб 12 дә 70».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәшдә рахимәһәәллаһү рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Бибизөһрә
3) Әхмәдулла кызы –
4) Габделхәким Гыйззәтулла [улының]
5) хатыны – 1916 елның
6) 29 апрелендә, һиҗри
7) белән 1334 [елның]
8) 12 рәҗәбендә 70».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «[70] яшьтә [вафат яки җирләнде]. Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 83(98)x29x10.

23. Габделлатыйф Мөхәммәдсадыйк улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Габделлатыйф Мөхәммәдсадыйк
4) углы 1917 нче миладиййә
5) 15 нче март 65 йәшендә
6) дарел-бәкайә рихләт
7) кыйлды Аллаһ рәхмәт
8) әйләсүн амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән бикабрии мүтәфәккиран фии әмрии».

Сул ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Габделлатыйф Мөхәммәдсадыйк
4) улы милади 1917 [елның]
5) 15 мартында 65 яшендә
6) мәңгелек дөньяга
7) күчте. Аллаһ рәхим
8) кылсын, амин».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче».

Сул ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Таш үлчәмнәре: 111(120)x30x12.

24. Йосыфҗан Габидулла улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) румиййә илә 1910 нчы
3) йыл 26 нчы синтәбр-
4) -дә Йосыфҗан Габид-
5) -улла углы 21
6) йәшендә йәкшәнбә
7) көн ошбу у-
8) -рында мәдфүндер».

Уң ягы (уеп язылган): «Ләһү мәләкүн йәнәәдии күллә йәүүм».

Сул ягы (уеп язылган): «Лидүү лил-мәүти вәбнүү лил-харарб».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Милади белән 1910
3) елның 26 сентябрен-
4) -дә Йосыфҗан Габид-
5) -улла улы 21
6) яшендә якшәмбе
7) көн бу у-
8) -рында җирләнгәндер».

Уң ягы: «Көн саен фәрештә аңа [кешегә] әйтә».

Сул ягы: «Туыгыз – барыбер үләчәксез, биналар төзегез – барыбер җимереләчәк».

Таш үлчәмнәре: 92(110)x30x11.

25. Хәнифә Мөхәммәтҗан кызына куелган кабер ташы[232], 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Хәнифә Мөхә-
4) -ммәтҗан кызы
5) 1918 нче йылда 17
6) нче февралда 25
7) йәшендә вафат улды
8) Аллаһ рәхмәтендә булсын
9) амин
10) күреб каберем әҗәлн
11) әйләгел йад».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Дога берлә кыйлынгыз рухым шад».

[232] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер, шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә, игътибарга лаек.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм[ә]
3) Хәнифә Мөхә-
4) -ммәтҗан кызы
5) 1918 елның 17
6) февралендә 25
7) яшендә вафат булды.
8) Аллаһ рәхмәтендә булсын,
9) амин.
10) Каберемне күреп, әҗәлне
11) искә ал».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Дога белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 85x26x11.

26. Әхмәдша Һади улына куелган кабер ташы[233], 1931 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мәрхүм
3) Әхмәдшаһ
4) Һади углы
5) 1931/1931 нче йыл гыйнвар
6) 18/18 ндә 75/75 йәшендә
7) рамазан 1 ндә вафат
8) Аллаһ рәхмәтендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Булсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Әхмәдша
4) Һади улы
5) 1931 елның 18
6) гыйнварында, 1 рамазанында
7) 75 яшендә вафат.
8) Аллаһ рәхмәтендә».

Уң ягы: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Булсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 77x24x11.

27. Хәсбиулла Хәмидулла улына куелган кабер ташы, 1928 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһә илләәллааһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
2) мәрхүм Хәсбийулла
3) Хәмидулла
4) углы 1928
5) йылда 15 ийүлдә
6) 63 йәшендә
7) рахимәһүллааһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Күллү мән галәйһәә фәән».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун
2) амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Мәрхүм Хәсбиулла
3) Хәмидулла
4) улы 1928
5) елның 15 июлендә
6) 63 яшендә [вафат яки җирләнде]
7) Аллаһ аны рәхим кылсын».

Уң ягы: «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани».

Сул ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз,
2) амин».

Таш үлчәмнәре: 78(84)x27x9.

[233] Бу таш түгел, агач тактага уеп эшләнгән билге. Барыбер, шул ук кабер ташы функциясен үтәгәнгә күрә, игътибарга лаек.

Шәкәнәч авылы зираты

1. Мулла Исхак Динмөхәммәд улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) 1329 сәнә зилкагдәнең
3) 8 ндә руми 1911 сәнә үктәбр
4) 15 ндә мулла Исхак бине
5) Динмөхәммәд күп сәнәләр
6) имамел-мөслимин улуб
7) 92 йәшендә даре
8) бәкайә рихләт кылды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әраад-дүнйәә хараабән би-игътибәәрии
2) фәләә йәбка мүдәмән бил-караар
3) күрәрмен дөньяны вәйран бары
4) һәмишә бакый ирмәс юк карары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) 1329 елның 8
3) зөлкагдәсендә, милади 1911 елның 15
4) октябрендә мулла Исхак бине
5) Динмөхәммәд, күп еллар
6) мөселманнар имамы булып,
7) 92 яшендә мәңгелек
8) дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Күрәм дөньяны: җимерек бары,
2) бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары.
3) Күрәм дөньяны: җимерек бары,
4) бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 111x32x11.

Әлеге кабер иясе, официаль рәвештә мулла итеп билгеләнмәсә дә, 1905 елда төзелгән мәчеттә имам-хатыйб вазыйфасын башкарган. аның улы Габдуллажан да атасының изге эшен дәвам иткән.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №93.

2. Бибилатыйфа Мөхәммәдрәхим кызына һәм Хәбибрахман Җиһанша улына куелган кабер ташы, 1931 һәм 1933 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Бибилатыйфа Мөхәммәд-
3) -рәхим кызы
4) Җиһанша зәүҗә-
5) -се 57 йәшендә
6) 1931 сәнәи миладиййә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) Хәбибрахман
3) Җиһаншаһ углы
4) 1933 сәнәи миладиййә
5) 20 йәшендә
6) беренче шәгъбан
7) вафат булды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бибилатыйфа Мөхәммәд-
3) -рәхим кызы –
4) Җиһанша хаты-
5) -ны – 57 яшендә
6) милади 1931 елда [вафат]».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Хәбибрахман
3) Җиһанша улы
4) милади 1933 елның
5) беренче шәгъбанында
6) 20 яшендә
7) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 73x27x9.

3. Исхак Йосыф улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Исхак
3) Йосыф углы
4) 60 йәшендә
5) 1920 сәнәи миладиййә
6) 10 нчы ийүлендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Исхак
3) Йосыф улы
4) 60 яшендә
5) милади 1920 елның
6) 10 июлендә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 68х27х7.

4. Хәербаян Гыйльман кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[234]:
1) «Хәйербайан
2) Гыйльман кызы
3) Аллаһ рәхмәт кыйлсун
4) Хәербәйан
5) Гыйльман кызы
6) т. 1866 VIII
7) ү. 1910 йылда».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһәә».

Сул ягы (уеп язылган): «Гафәраллааһү зүнүүбәһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хәербаян
2) Гыйльман кызы.
3) Аллаһ рәхим кылсын.
4) Хәербаян
5) Гыйльман кызы,
6) 1866 [елның] августында туган,
7) 1910 елда вафат».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен».

Таш үлчәмнәре: 66х31х11.

5. Вәлид Шәфигулла улына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Вәлид
3) Шәфигулла углы
4) 1332 сәнәи һиҗриййә
5) миладиййә 1914 нче сәнә
6) 25 нче априлдә».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Сул ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) мәрхүм Вәлид
3) Шәфигулла улы
4) һиҗри 1332 елда,
5) милади 1914 елның
6) 25 апрелендә [вафат яки җирләнде]».

Уң ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Сул ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 65х28х11.

6. Гайнулла Гомәр улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Гайнулла Гомәр
3) углы 57 йәшендә
4) 1922 сәнәи миладиййә
5) 5 нче фибралда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада идеңез
3) йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Гайнулла Гомәр
3) улы 57 яшендә
4) милади 1922 елның
5) 5 февралендә [вафат яки җирләнде]».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә

[234] Ахыргы 4 юлы латин графикасында язылган.

3) алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 56х29х7.

7. Заһидә Хәсән кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Заһидә
3) Хәсән кызы
4) һиҗрииййә 133[235] 72 йәшендә
5) миладиййә 1914
6) нче йылда 17 нче майд
7) вафат булды».

Уң ягы (уеп язылган): «Дога кыйлсан савабы безгә булсун»[236].

Сул ягы (уеп язылган): «Анын әҗере сезгә дә насыйб улсун»[237].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) мәрхүм Заһидә
3) Хәсән кызы
4) һиҗри 133[2 елда] 72 яшендә,
5) милади 1914
6) елның 17 маенда
7) вафат булды».

Уң ягы: «Дога кылсаң, савабы безгә булсын».

Сул ягы: «Анын әҗере сезгә дә насыйп булсын».

Таш үлчәмнәре: 69х28х11.

8. Галиәсгар Хәмидулла улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назил Галиәсгар
3) Хәмидулла углы
4) 65 йәшендә
5) 1909 нчы йылда
6) 20 нче гыйнвада вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлынгыз рухымы шат».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада улынгыз йат».

Арткы ягы (уеп язылган): «65 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Бу кабергә иңүче Галиәсгар
3) Хәмидулла улы
4) 65 яшендә
5) 1909 елның
6) 20 гыйнварында вафат».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Арткы ягы: «65 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 62х32х12.

9. Сәгъдеддин Бәйрәмгали улына һәм Шәмсежиһан Садыйк кызына куелган кабер ташы, 1920 һәм 1921 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Сәгъдеддин Бәйрәм-
3) -гали углы беренче гыйнв-
4) -арда 62 йәшендә
5) 1920 сәнәи миладиййә
6) кәрәм әйләб дога-
7) -да идеңез йад».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Шәмсежиһан
3) Садыйк кызы
4) Сәгъдеддин зәүҗәсе
5) 1921 сәнәи миладиййә
6) 58 йәшендә 15 нче ү-
7) -ктәбрдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Сәгъдеддин Бәйрәм-

[235] Датасы язылып бетмәгән, һиҗри 1332 ел булырга тиеш.
[236] Дәвамы сул ягында.
[237] Башы уң ягында.

3) -гали улы милади 1920
4) елның беренче гыйнварында
5) 62 яшендә [вафат яки җирләнде].
6) Юмартлык кылып, дога-
7) -да искә алыгыз».

Арткы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Шәмсеҗиһан
3) Садыйк кызы –
4) Сәгъдеддин хатыны –
5) милади 1921 елның
6) 15 октябрендә
7) 58 яшендә [вафат яки җирләнде]».

Таш үлчәмнәре: 80х33х8.

10. Мөэзин Габделкәбир Габделвәли улына куелган кабер ташы, 1878 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Ошбу кабер-
2) -станда дәфен
3) кылынды Габд-
4) -елкәбир Габд-
5) -елвәли углы
6) рахимәһүллаһү Тәгаалә».

Уң ягы (уеп язылган): «Мөэзинел-мөслимин»[238].

Сул ягы (уеп язылган): «Күнгәр карйәсендә»[239].

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Миладиййә
2) илә 1878 нче
3) йылда 30 нчы
4) синтәбрдә
5) 52 йәшендә
6) вафат улды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер-
2) -станда
3) Габд-
4) -елкәбир Габд-
5) -елвәли улы җирләнде.
6) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Уң ягы: «Мөселманнар мөэзине».
Сул ягы: «Күңгәр авылында».

Арткы ягы:
1) «Милади
2) белән 1878
3) елның 30
4) сентябрендә
5) 52 яшендә
6) вафат булды».

Таш үлчәмнәре: 70х32х11.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №94.

Югары Бәрәскә авылы зираты

1. Мөхәммәҗан Әшрәф(?) улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Мөхәммәҗан Әшрәф(?)
4) 1909 нчы сәнәдә 29 нчы
5) мартда 75 йәшендә
6) вафат Аллаһ рәхмәт кылгай
7) иде амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән әнтә тәсыыйру мислии»[240].

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[241].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Мөхәммәҗан Әшрәф(?) [улы]
4) 1909 елның 29
5) мартында 75 яшендә
6) вафат. Аллаһ рәхим кылса
7) иде, амин».

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Таш үлчәмнәре: 89(107)х34х14.

[238] Башы сул ягында.
[239] Дәвамы уң ягында.
[240] Башы сул ягында.
[241] Дәвамы уң ягында.

2. Бибигазизә Мөхәммәдшәриф кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Рахимәллаһү ли-мән зәәрании
2) саахибәтү һәзәл-кабри мәрхүмә Биби-
3) -газизә Мөхәммәдшәриф кызы
4) Мөхәммәдгали Габделкәрим углыйның
5) әһлийәсе 1909 нчы йылда
6) ийүн 29 нда 58
7) йәшендә мәдфүнә нәүвәр-
8) -аллаһү кабраһәә әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мине зиярәт кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә Биби-
3) -газизә Мөхәммәдшәриф кызы –
4) Мөхәммәдгали Габделкәрим улының
5) хатыны – 1909 елның
6) 29 июнендә 58
7) яшендә җирләнде. Аллаһ
8) аның каберен нурландырсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 96(108)х36х9.

3. Мөхәммәдгали Габделкәрим улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) бу каберә назил мәрхүм
3) Мөхәммәдгали Габделкәрим
4) углы 1892 нче йылда
5) синтәбр 15 ндә
6) 45 йәшендә вафат
7) Аллаһ рәхмәт кыйлсун
8) амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Изәә тәхәйһәртүм фил-үмүүри фә-стәгыыйнүү мин әһлил-кубүүр».

Сул ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәнга икән йарин сәнгадыр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүм
3) Мөхәммәдгали Габделкәрим
4) улы 1892 елның
5) 15 сентябрендә
6) 45 яшендә вафат.
7) Аллаһ рәхим кылсын,
8) амин».

Уң ягы: «Әгәр [бу] эшләрдә аптырашта калсагыз, кабер әһелләреннән сорагыз».

Сул ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 88х32х11.

4. Хөршидбану Камаледдин кызына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигуун
2) мәзлумә Хөршидбану
3) Камаледдин кызы
4) 31 йәшендә 1892 сәнә
5) април 6 нда вафат
6) Аллаһ рәхмәт
7) кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз.
2) Җәберләнгән Хөршидбану
3) Камаледдин кызы
4) 31 яшендә 1892 елның
5) 6 апрелендә вафат.
6) Аллаһ рәхим
7) кылсын».

Таш үлчәмнәре: 67х32х10.

5. Хәйрулла Халид улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Хәйрулла Халид
4) углы 1909 нчы йылда
5) 14 нче аугусда 80
6) йәшендә вафат итде
7) рахимәллаһү рахмәтән вәәсигаһ
8) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Хәйрулла Халид
4) улы 1909 елның
5) 14 августында 80
6) яшендә вафат булды.
7) Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын,
8) амин».

Таш үлчәмнәре: 94х32х10.

6. Фәтхулла Гобәйдулла улына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) тарих румиййә илән 1892 нче сәнәдә
3) 23 нче ийүлдә мәрхүм Фәтхулла
4) Гобәйдулла углы 78 йәшендә
5) дарел-фәнадин дарел-бәкайә рихләт
6) әйләде Аллаһ гарикы рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Галәмәтдән морадым бер догадыр бу көн бәңа икән йарин сәңадыр».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлмне татыячак.
2) Милади белән 1892 елның
3) 23 июлендә мәрхүм Фәтхулла
4) Гобәйдулла улы 78 яшендә
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһ рәхмәткә күмсен».

Уң ягы: «Галәмәттән морадым бер догадыр, бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 96х35х17.

7. Мулла Габдерәхимгә һәм мулла Баһаеддин мулла Габдерәхим улына куелган кабер ташы, [1845] һәм 1889 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе мулла Баһаэддин
3) бине мулла Габдеррәхим әл-мәшһүр ахун
4) румиййә 1889 нчы сәнә
5) 82 йәшендә хитабе иржигыый Хакдин
6) ирешүб май 2 нче көн дәфен иделде
7) рахимәһүллааһү Тәгаалә».

Уң ягы (уеп язылган): «Бу тарафда йырак дәгел имам вә мөдәррис Габдеррәхим... йыл 80 йәшендә 18 нче фибрал мәдфүн».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем аллаһта.
2) Бу кабер иясе мулла Баһаеддин
3) бине мулла Габдерәхим (мәшһүр ахун)
4) милади 1889 елда
5) 82 яшендә, Хактан [Аллаһтан]: «Кайт», – дигән чакыру
6) ирешеп, майның 2 нче көнендә җирләнде.
7) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Уң ягы: «Бу тарафта ерак түгел имам һәм мөдәррис Габдерәхим... [1846] елның 18 февралендә 80 яшендә җирләнде».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 100х31х11.

Әлеге аталы-уллы имамнарның фәнгә билеле булган шәҗәрәләре түбәндәгечә: Баһаеддин бине Габдерәхим бине Бикчәнтәй бине Ибраһим. Габдерәхим Бәрәскә авылында мәдрәсә тотып, озак еллар анда укыткан, халык арасында «Апый мелла» дип йөртелгән. Ш. Мәржәнинең газиз атасы Баһаеддин хәзрәт аның шәкерте булып санала[242]. Габдерәхим хәзрәтнең атасы Бикчәнтәй чыгышы белән Олы Саба, кайбер сүзләргә караганда, (хәзреге Арча районы) Буклавыч (Акчишмә) авылыннан булган. Ш. Мәржәнинең бабасы Сөбхан хәзрәт – мулла Бикчәнтәйнең шәкерте[243].

[242] Мәржәни Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 301.
[243] Шунда ук. – Б. 244–245.

Баһаеддин Габдерәхим улы (кушаматы «Ахун») 1840 елда Бәрәскәдә имам-хатыйб булып билгеләнгән, тик аның вакытында атасы һәм бабасы чорында дан тоткан мәдрәсә тәмам беткән[244].

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №95.

8. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) ...сендә 60 йәшдә
2) вафат итде рахимәһ-
3) -үллаһү Тәгаалә».

Уң ягы (уеп язылган): «[Әй гафил алд]анма бу дөнйага».

Сул ягы (уеп язылган): «[Гакыйбәт бер көн к]итәрсең ул гокбага».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) ...сендә 60 яшьтә
2) вафат булды. Аллаһ Тәгалә
3) аны рәхим кылсын».

Уң ягы: «[Әй, ваемсыз, алд]анма бу дөньяга».

Сул ягы: «[Ахырдан бер көн к]итәрсең ул ахирәткә».

Таш үлчәмнәре: 51x36x14.

9. Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) үктәбрдә хитабе иржигыый Хакдин
2) ирешүб
...».

Уң ягы (уеп язылган): «[Тәсаддыклә] кыйлуңыз рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) октябрьдә Хактан [Аллаһтан]: «Кайт», – дигән чакыруы
2) ирешеп,
...».

Уң ягы: «[Сәдака бирү белән] рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 21x19x10.

10. Маһруйҗамал Исмәгыйль мулла кызына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Маһруйҗамал Исмәгыйль
4) мулла кызы Мөхәммәдбоһан
5) әһлийәсе 1913 сәнәи миладиййә
6) ийүн 16 нда 1332 сәнәи һиҗриййә
7) рәҗәб 24 нче 27 йәшендә
8) вафат рахимәллаһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Йиде башлу аждаһадур бу җиһан бу әҗәл һич кемсәйә вирмәс әман».

Сул ягы (уеп язылган): «Үтте дәүран кичде сәйран бәне күр бәне күр дә гүр йарагың кыйла күр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Маһруйҗамал Исмәгыйль
4) мулла кызы – Мөхәммәдбоһан
5) хатыны – милади 1913 елның
6) 16 июнендә, һиҗри 1332 елның
7) 24 рәҗәбендә 27 яшендә
8) вафат. Аллаһ киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Җиде башлы аждаһадыр бу җиһан, бу әҗәл һич кемсәгә бирмәс иминлек ».

Сул ягы: «Үтте дәвер, бетте күңел ачу, мине күр, мине күр дә гүр өчен кирәк-ярагыңны күр».

Таш үлчәмнәре: 112(130)x31x10.

[244] Шунда ук. – Б. 323.

11. Гобәйдулла Гыйззәтулла улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Гобәйдулла
2) бине Гыйззәтулла
3) вафат
4) 1912 сәнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Гобәйдулла
2) бине Гыйззәтулла
3) 1912 елда
4) вафат».

Таш үлчәмнәре: 78х48х16.

12. Бибиәсма Әхмәдулла кызына куелган кабер ташы, 1892 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) тарих румиййә иләn 1892 нче
3) сәнәдә 10 нчы априлдә Бибиәсма бинте Әхмәд-
4) -улла Гобәйдулла Гыйззәтулла углының
5) әһлийәсе 52 йәшендә дарел-фәнадан
6) дарел-бәкайә рихләт әйләде
7) Аллаһ гарикы рәхмәт әйләсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) милади белән 1892
3) елның 10 апрелендә Бибиәсма бинте Әхмәд-
4) -улла – Гобәйдулла Гыйззәтулла улының
5) хатыны – 52 яшендә фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Аллаһ рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 90х35х17.

13. Бибифатиха Габделхаликъ кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Бибифатиха
3) Габделхаликъ кызы
4) Фәхреддин җәмәгате
5) миладиййә 1905 нче йылда
6) 20 нче ийүндә
7) 28 йәшендә вафат
8) гарикы рәхмәт улсун».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә идеңез рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Нәүвәраллаahү кабраһәә
2) вә җәгаләл-җәннәтә мәсв-
3) -әәһәә вә мәъвәәһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Бибифатиха
3) Габделхаликъ кызы –
4) Фәхреддин җәмәгате –
5) милади 1905 елның
6) 20 июнендә
7) 28 яшендә вафат.
8) Рәхмәткә күмелсен».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ аның каберен нурландырсын
2) һәм урынын җәннәт
3) итсен».

Таш үлчәмнәре: 97х31х12.

14. Гыйззәтуллага куелган кабер ташы, 1869 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) бу каберә назил Гыйззәтулла
3) ... углы 62 йәшендә
4) 1869 нчы йыл 5 нче
5) үктәбрдә кабере мөнәүвәр
6) улсун амин».

Уң ягы (уеп язылган): «Зүүрууль-кубүүра фә-иннәһәә түзәккируль-мәүүт».

Сул ягы (уеп язылган): «Мән әксәру зәкәраль-кабра вәҗәдә раудатән мин рийәәдыйльҗәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Бу кабергә Гыйззәтулла
3) ... улы 62 яшендә
4) 1869 елның 5
5) октябрендә иңде. Кабере нурлы
6) булсын, амин».

Уң ягы: «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар үлемне искә төшерә».

Сул ягы: «Кем каберне еш искә алса, шул җәннәт бакчаларыннан бер бакчага юлыгыр».

Таш үлчәмнәре: 89х34х15.

15. Бибилатыйфа Мөхәммәдрәхим кызына куелган кабер ташы, 1893 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүмә Бибилатыйфа
3) Мөхәммәдрәхим кызы
4) Хисамеддин хатуны
5) 2 нче үктәбрдә
6) миладиййә 1893 нче
7) йылда 40 йәшендә
8) вафат Аллаһ гарикы
9) рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә идеңез рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүмә Бибилатыйфа
3) Мөхәммәдрәхим кызы –
4) Хисамеддин хатыны –
5) милади 1893 елның
6) 2 октябрендә
7) 40 яшендә
8) вафат. Аллаһ рәхмәткә
9) күмсен».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 97х32х11.

16. Бибимәфтуха Исмәгыйль кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибимәфтуха Исмәгыйль
4) кызы Галимҗан Шәрифҗан
5) углының әһлийәсе вафат
6) 1910 нчы сәнә синтәбр 9 нда
7) 20 нче рамазан шәрифдә
8) 67 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад дога берлә кыйлунгыз рухымны шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ рәхмәт кыйлгай иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә иңүче мәрхүмә
3) Бибимәфтуха Исмәгыйль
4) кызы – Галимҗан Шәрифҗан
5) улының хатыны –
6) 1910 елның 9 сентябрендә,
7) 20 рамазан-шәрифендә
8) 67 яшендә вафат».

Уң ягы: «Күреб каберем әҗәлне әйләгел йад дога берлә кыйлунгыз рухымны шад».

Сул ягы: «Аллаһ рәхмәт кыйлгай иде амин».

Таш үлчәмнәре: 97х30х12.

17. Хәсәнҗан Габделвахид улына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) Хәсәнҗан Габделвахид

4) углы 1916 нчы йыл м.
5) фибрал 8 ндә һиҗрииҙә
6) 1334 сәнә рабигыль-ахир
7) 17 ндә 68 йәшендә вафат
8) нәүвәраллаһү кабраһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әмсин күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии»[245].

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии»[246].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) Хәсәнҗан Габделвахид
4) улы милади 1916 елның
5) 8 февралендә, һиҗри
6) 1334 елның 17
7) рабигыль-ахирендә 68 яшендә вафат.
8) Аллаһ аның каберен нурландырсын, амин».

Уң ягы: «Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерләүче».

Таш үлчәмнәре: 102x34x14.

18. Бибинәфисә Исмәгыйль кызына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Бибинәфисә Исмәгыйль кызы
4) Хәсәнҗан Габделвахид
5) углыйның әһлийәсе вафат
6) 1917 сәнә май 21 ндә
7) 65 йәшдә рахимәһәәллааһ»[247].

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл».

Сул ягы (уеп язылган)[248]:
1) «Ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдәл-әҗәл
2) рахмәтән вәәсигаһ
3) әәмиин»[249].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе мәрхүмә
3) Бибинәфисә Исмәгыйль кызы –
4) Хәсәнҗан Габделвахид
5) улының хатыны –
6) 1917 елның 21 маенда
7) 65 яшьтә вафат. Аллаһ аны рәхим кылсын».

Уң ягы: «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит».

Сул ягы:
1) «Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми.
2) Киң рәхмәте белән [Аллаһ рәхим кылсын],
3) амин»[250].

Таш үлчәмнәре: 93x34x14.

19. Ибраһим Йосыф улына куелган кабер ташы, 1784 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим мәбдәә әсмәәил-хүснәәл-кадиим
2) вә кааләллааһү Тәгаалә күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа
3) вәҗһү Раббикә зүүл-җәләәли вәл-икраам вә каалә-
4) -н-нәбии салләәллааһү галәйһи вә сәлләм иннә әүлийәәүллааһи
5) лә йәмүүтүүнә бәл йүнкалүүнә мин дәәрин илә дәәр лә хәүлә вә лә
6) куввәтә илләә билләәһил-галиййил-газыыйм фә-һәзә мәркад-
7) -үш-шәйхый Ибраһим бине Йосыф Бәрәскәи әнәәраллааһү
8) мәдъҗәгаһү вә гафәра ли-мән зәәра илә йәүмил-кыйәмәһ тарих
9) меңдә йөздә туксан сигезенче йыл шәүвәл
10) айының шинбә көнендә даре фәнадин даре бәкайә нәкыль
11) итде рахимәллааһү галәйһи рахмәтән вәәсигаһ».

Уң һәм сул якларындагы язулары бөтенләй диярлек сөртелеп беткән.

[245] Башы сул ягында.
[246] Дәвамы уң ягында.
[247] Дәвамы сул ягының ахыргы ике юлында.
[248] Беренче юлы вертикаль, калган юллары диагональ рәвештә язылган.
[249] Ахыргы ике юлының башы алгы ягында.
[250] Башы уң ягында.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән. Аллаһның күркәм исемнәреннән әүвәлгесе – «әл-Кадим» (Мәңге).

2) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать Раббыңның

3) Олуглык һәм хөрмәткә ия булган йөзе генә калачак. Пәйгамбәр

4) (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) әйтте: «Чынлыкта, Аллаһның якын кешеләре

5) үлмиләр, бәлки бер йорттан икенче йортка күчәләр. Олуг һәм Бөек

6) Аллаһтан башка көч һәм куәт иясе юк. Бу – шәех

7) Ибраһим бине Йосыф Бәрәскәви кабере. Аллаһ аның урынын

8) нурландырсын һәм Кыямәткә хәтле каберен зиярәт иткән кешеләрне гафу итсен.

9) Мең дә йөз дә туксан сигезенче елның шәүвәл

10) аенда шимбә көн фани дөньядан мәңгелек дөньяга

11) күчте. Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 90x71x33.

Әлеге эпиграфик истәлек текстының укылышын заманында эпиграфист галим Һ.В. Йосыпов тәкъдим иткән иде[251], тик ул һиҗри 1198 елны хаталы рәвештә милади 1785 ел белән билгеләгән, шулай ук гарәп җөмләләрен дөрес тәрҗемә итмәгән.

Биредә җирләнгән зат – атаклы сәүдәгәр Ибраһим бине Йосыф бине Әснай бине Исәнкол бине Борнагол – Әби патшадан рөхсәт алып, үз хисабына 1769 елда Түбән Бәрәскә авылында ике катлы, зур, мәһабәт таш мәчет салдырган. Ш. Мәрҗани аны түбәндәгечә искә алган: «Ибраһим мәшһүр сәүдәгәрләрдән санала, зур байлык иясе һәм ярдәмчел кеше була, күп яхшылыклар кыла, күпсанлы мәчетләр, мәдрәсәләр салдыра һәм башка изгелекләр дә эшләп калдыра... Бәрәскәдә Ибраһим бине Йосыфның таштан төзеткән зур пулатлары, каберлегендә тимер ишекләр белән ясаткан таш стенасы, күп басулары, урман-җирләре һәм сулары булган»[252]. Мәрҗани хәзрәтләре, Ибраһим Борнаев һиҗри 1201 елның шәгъбан аенда вафат булган, дип ялгышкан[253].

Югарыда искә алынган кабер ташы кирпечтән эшләнгән төрбә (үлчәмнәре: 1670x1250) эченә урнаштырылган. Шунысын да искәртик: моннан башка авыл зиратында борынгы татар традициясе буенча корылган, кызыл кирпечтән эшләнгән тагын бер төрбә (үлчәмнәре: 1540x 1225) сакланган, әмма эчендә кабер ташы табылмады. Бәлки, ул туфрак астында калгандыр.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №96.

20. Габдерәфыйк хатынына куелган кабер ташы фрагменты, XIX гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

«...

1) даре бәкайә рихләт әйләде рахимә ләһәә вә ли-вәәлидәйһәә

2) йәә ихвәәнәнәә вән-зуруу иләә әхвәәлии ләә тәгурраннәкүм-

3) -үд-дүнйәә фәиннәд-дүнйәә фәәниййәтүн вәл-әәхыйратү әәтиййәтүн

4) вә күллү әәтин кариб фәәтихәһ».

Уң ягы (калкытып язылган): «Дога мәрхәмәт...».

Арткы ягы (калкытып язылган):

«...

1) ... йиденче

2) ... Габдерәфыйк хаҗи никахында

3) зүүрууль-кубүүра фә-иннәһәә түзәккируль-мәүүт

4) әл-кабру әүвәлү мәнзили мин мәнәәзилил-әәхыйраһ

5) хайрун-нәәси мән ләм йәнсәл-кабр».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

«...

1) мәңгелек дөньяга күчте. [Аллаһ] аны һәм ата-анасын рәхим кылсын.

2) Әй, кардәшләрем, минем хәлләремә карагыз, дөньяга

3) алданмагыз, чынлыкта, дөнья фани, ахирәт киләчәк

4) һәм һәр киләчәк нәрсә якын. [Рухына] «Фатиха» [сүрәсе укы]».

Уң ягы: «Дога-мәрхәмәт...».

[251] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / Г.В. Юсупов. – М.-Л.: Изд-во Академии наук СССР, 1960. – Табл. 77.

[252] Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 386–387.

[253] Шунда ук. – Б. 386.

Арткы ягы:

«...

1) ... җиденче
2) ... Габдерәфыйк хаҗи никахында
3) Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар үлемне искә төшерә.
4) Кабер – ахирәтнең тора торган урыннарының иң беренчесе.
5) Кешеләрнең иң хәерлесе – каберне онытмаучы.

Таш үлчәмнәре: 47х45х21.

21. Мозаффар Мостафа улына куелган кабер ташы, 1887 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Мәркаде мәрхүм
2) Мозаффар бине
3) Мостафа вафат
4) 76 йәшендә
5) 1887 нче сәнәдә
6) мартның унберендә
7) рухыйна фатиха».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Мәрхүм
2) Мозаффар бине
3) Мостафа кабере,
4) 76 яшендә
5) 1887 елның
6) унберенче мартында вафат.
7) Рухына «Фатиха» сүрәсе укы».

Таш үлчәмнәре: 110х30х14.

22. Хәбибҗамал Мәхмүд кызына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Саллээллаahү Тәгаалә галәйh
2) Хәбибҗамал
3) Мәхмүд кызы
4) Мозаффар зәүҗәсе
5) 901 нче йылда 7 нче ийүл
6) 72 йәшендә дарел-бәкайә
7) рихләт кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Аллаh Тәгалә аны олыласын һәм сәламләсен.
2) Хәбибҗамал
3) Мәхмүд кызы –
4) Мозаффар хатыны –
5) [1]901 елның 7 июлендә
6) 72 яшендә мәңгелек дөньяга
7) күчте».

Сул ягы: «Дога-мәрхәмәт...».

Таш үлчәмнәре: 97(113)х35х13.

23. Гафифә Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1916 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) бу каберә назилә мәрхүмә
3) Гафифә Габденнасыйр кызы
4) мулла Фазылҗан
5) әһлийәсе 1916 җыл
6) синтәбр 5 ндә
7) 62 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Каалүү иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи раажигуун».

Сул ягы (уеп язылган): «Рахимәһәәллаahү рахмәтән вәәсигаh әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабергә мәрхүмә
3) Гафифә Габденнасыйр кызы –
4) мулла Фазылҗан
5) хатыны – 1916 елның
6) 5 сентябрендә
7) 62 яшендә иңде».

Уң ягы: «Әйттеләр: «Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа кайтачакбыз».

Сул ягы: «Аллаh аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 81х31х8.

24. Сабира Фазылҗан кызына куелган кабер ташы, 1904 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Лаа иләәһә илләәллаah Мүхәммәдүр-расүүлүллаah саллээллаahү галәйһи вә сәлләм
2) һәзәә кабру Сабира
3) бинте Фазылҗан түвәллүдән фии
4) карйәи Бәрәскә фии сәнәти 1875

5) 2 нче ийүл интәкалә
6) мин дәәрил-фәнәәи иләә»[254].

Уң һәм сул якларында чүлмәктәге гөл рәсеме төшерелгән.

Арткы ягы (калкытып язылган):
1) «Би-хүкми Тәгааләә
2) дәәрил-бәкааи фии
3) сәнәти 1904 нуйәбр 8 нче
4) Аллаһ Тәгалә гарикы рәхмәт
5) әйләсүн»[255].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) ««Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен).
2) Бу – Сабира
3) бинте Фазылҗан кабере,
4) Бәрәскә авылында 1875 елның
5) 2 июлендә туды,
6) фани дөньядан күчте».

Арткы ягы:
1) «[Аллаһ] Тәгалә хөкеме белән.
2) мәңгелек дөньяга
3) 1904 елның 8 ноябрендә [күчте].
4) Аллаһ Тәгалә рәхмәткә
5) күмсен».

Таш үлчәмнәре: 60х27х10.

25. Бибимаһитаб дамелла Мөхәммәдшакир кызына куелган кабер ташы, 1894 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) мәркаде мәрхүмә Бибимаһитаб
3) дамелла Мөхәммәдшакир хәзрәт
4) кызы мулла Исмәгыйль мулла
5) Фазылҗан углының зәүҗәсе
6) 1894 сәнәи румиййә 22 нче априлдә
7) 31 йәшендә даре бәкайә
8) рихләт әйләде рахимәһәәллааһү
9) Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Мәрхүмә Бибимаһитаб
3) дамелла Мөхәммәдшакир хәзрәт
4) кызы – мулла Исмәгыйль мулла
5) Фазылҗан улының хатыны – кабере,
6) милади 1894 елның 22 апрелендә
7) 31 яшендә мәңгелек дөньяга
8) күчте. Аллаһ Тәгалә аны киң
9) рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 106х37х12.

26. Мулла Фазылҗан мулла Габденнасыйр улына куелган кабер ташы, 1901 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) саахибү һәзәл-кабри мәрхүм
3) имам мулла Фазылҗан
4) мулла Габденнасыйр углы
5) 1901 нче сәнәи миладиййә 1 нче аугыстда
6) 1319 сәнәи һиҗриййәдә 85
7) йәшендә вафат рахимәллааһү Тәгааләә әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әл-мәүтү кәәъсүн күллү нәәсин шәәрибүһәә әл-кабру бәәбүн вә күллү нәәсин дәәхыйлүһәә».

Сул ягы (уеп язылган)[256]:
1) «Йәә әхыый күн нәәдимән каблә-әҗәл ән-нәдәәмәтү ләә түфиидү бәгъдә-әҗәл
2) кәтәбәһәә мөәзине
3) Үртәм Лотфулла».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Бу кабер иясе мәрхүм
3) имам мулла Фазылҗан
4) мулла Габденнасыйр улы
5) милади 1901 елның 1 августында,
6) һиҗри 1319 елда 85
7) яшендә вафат. Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын, амин».

Уң ягы: «Үлем – савыт, һәрбер кеше аннан эчәчәк, кабер – ишек һәм һәрбер кеше аннан керәчәк».

Сул ягы:
1) «Әй, кардәшем, әҗәл килгәнче гөнаһларыңнан тәүбә ит. Әҗәл килгәч, тәүбә файда бирми.
2) Моны язды: Үртәм
3) мөәзине Лотфулла».

Таш үлчәмнәре: 103х35х15.

[254] Дәвамы арткы ягында.
[255] Ахыргы 4 юлның башы алгы ягында.
[256] Беренче юлы вертикаль, калганнары горизонталь рәвештә язылган.

Әлеге кабер иясе 1843 елның 17 февралендә муллалыкка указ алган[257] һәм авылда озак еллар имам-хатыйб вазыйфасын башкарган.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 11 б. №97.

27. Шакиржан Габденнасыйр мулла улына куелган кабер ташы, 1887–1888 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәүвәраллаahү
2) мәркадәh
3) Шакиржан
4) бине мулла
5) Габденнасыйр
6) 65 йәшендә
7) тарих һиҗрииjә-
8) -нең 1305
9) нче сәнәдә».

Уң ягы (калкытып язылган): «Килеб каберем зийәрәт идән ихвандин»[258].

Сул ягы (калкытып язылган): «Сахибенә уласыз изгү дога илә мөгыйн»[259].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh аның
2) каберен нурландырсын.
3) Шакиржан
4) бине мулла
5) Габденнасыйр
6) 65 яшендә
7) һиҗри
8) 1305
9) елда [вафат]».

Уң ягы: «Каберемә килеп, зиярәт иткән кардәш».

Сул ягы: «Иясенә изге дога белән ярдәм итүче буласыз».

Таш үлчәмнәре: 138x25x13.

28. Бибифатыйма Халит кызына куелган кабер ташы, 1877 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Нәүвәраллаahү мәркадәh
2) мәрхүмә
3) Бибифатыйма
4) Халит кызы
5) Шакиржан мулла
6) хәләле 40
7) йәшендә».

Уң ягы (калкытып язылган): «95 нче сәнәдә 1877 нче йылда»[260].

Сул ягы (калкытып язылган): «Тарих һиҗрииjәнең ике йөз дә»[261].

Арткы ягында төрле бизәкләр төшерелгән.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh аның каберен нурландырсын.
2) мәрхүмә
3) Бибифатыйма
4) Халит кызы –
5) Шакиржан мулла
6) хәләле – 40
7) яшендә [вафат]».

Уң ягы: «95 нче елда, 1877 елда [вафат]».

Сул ягы: «Һиҗри ике йөз дә».

Таш үлчәмнәре: 155x25x13.

29. Хәмид Габид улына куелган кабер ташы, 1851 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-халләәкуль-бәәкыый
2) Йукары Бәрәскәнең
3) Хәмид Габид углы вафат
4) 80 йәшендә 51 нче йыл 11 май».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бар итүче, Мәңге булучы Аллаh.
2) Югары Бәрәскәдән
3) Хәмид Габид улы 80
4) яшендә [18]51 елның 11 маенда вафат».

Таш үлчәмнәре: 85x29x15.

[257] Татарстан Республикасы Милли архивы: 2 ф., 2 тасвир., 8 эш берәм.
[258] Дәвамы сул ягында.
[259] Башы уң ягында.
[260] Башы сул ягында.
[261] Дәвамы уң ягында.

30. Хәбибҗамал Биккенә кызына һәм Шаһгали Әхмәд улына куелган кабер ташы, XIX гасыр һәм 1851 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
«...
1) ... беңдә ике йөздә...
2) икенче йылда рабигыль-ахирнең бишенче
3) йәүмендә Биккенә кызы Хәбибҗамал Әхмәд
4) хәләле кырык биш йәшендә даре фәнадин
5) даре бәкайә интикаль итде нәүвәра мәркадәһәә».

Сул ягы (калкытып язылган):
4) кызы Вәлийулла хәләле 73 йә-
5) -шдә йәкшәнбә көн даре бәкайә рихләт
6) кыйлды рахимәһәәллаahү Тәгааләә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне
2) татыячак». Милади 1883 елның 15
3) июлендә Миһрикамал Корбангали
4) кызы – Вәлиулла хәләле – 73 я-
5) -шьтә якшәмбе көн мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 93(103)х32х16.

[323] Өске өлешендә бизәк уелган.

[324] Бу гыйбарә хаталы язылган.

24. Бибигарифә Мөхәммәдшакир кызына куелган кабер ташы, 1891 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә руми 1891 сәнә
2) март 16 нда Бибигарифә Мөхәммәдшакир
3) бине Гыйнәйәтулла зәүҗәсе 35
4) йәшендә даре бәкайә интикаль әйләде
5) Аллаһ Тәгалә гарикы рәхмәт кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән. Милади 1891 елның
2) 16 мартында Бибигарифә Мөхәммәдшакир
3) бине Гыйнәятулла хатыны – 35
4) яшендә мәңгелек дөньяга күчте.
5) Аллаһ Тәгалә рәхмәткә күмсен».

Таш үлчәмнәре: 78х31х13.

25. Бибимәймүнә Гобәйдулла Әбүбәкер улының кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмүллаәһи руух[325]
2) Йаңа Өҗемдә
3) Бибимәймүнә
4) дарел-бәкайә
5) рихләт кылды
6) Әхмәдулла Вәлийулла
7) углыйның зәүҗәсе
8) 1322 / 1905».

Уң ягы (уеп язылган): «Сәфәр айының 6 сында дишәнбкөн».

Сул ягы (уеп язылган): «1905 нче април 28 ндә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Ашыт
2) карйәсинең
3) Гобәйдулла Әбү-
4) -бәкер углыйның
5) кызы
6) 48 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Яңа Өҗемдә
3) Бибимәймүнә –
4) Әхмәдулла Вәлиулла
5) улының хатыны –
6) 1322 / 1905 [елда]
7) мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Уң ягы: «Сәфәр аеның 6 сында дүшәмбе көн [вафат]».

Сул ягы: «1905 елның 28 апрелендә [вафат]».

Арткы ягы:
1) «Ашыт
2) авылыннан
3) Гобәйдулла Әбү-
4) -бәкер улының
5) кызы
6) 48 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 83(91)х32х14.

26. Әхмәдулла Вәлиулла улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмүллаәһи руух[326]
2) ошбу Йаңа Өҗемдә
3) Әхмәдулла Вәлийулла
4) углы дарел-бәкайә
5) рихләт кылды
6) 59 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «1906 нчы майның 17 сенд».

Сул ягы (уеп язылган): «1324 рабигыль-ахир 8 ндә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу Яңа Өҗемдә
3) Әхмәдулла Вәлиулла
4) улы 59 яшендә
5) мәңгелек дөньяга
6) күчте».

Уң ягы: «1906 [елның] 17 маенда [вафат]».

[325] Бу гыйбарә хаталы язылган.

[326] Бу гыйбарә хаталы язылган.

Сул ягы: «[һиҗри] 1324 [елның] 8 рабигыль-ахирендә[вафат]».

Таш үлчәмнәре: 80(88)х32х13.

27. Габделкоддүс Хәбибулла улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмүллаahи руух[327]
2) Йаңа Өҗемд
3) Габделкоддүс
4) Хәбибулла углы
5) дарел-фәнадин
6) дарел-бәкайә рихләт
7) идәлде».

Уң ягы (уеп язылган): «27 сенд гыйнвар».

Сул ягы (уеп язылган): «58 йәшенд 1911 йылда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Яңа Өҗемдә
3) Габделкоддүс
4) Хәбибулла улы
5) фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга
7) күчте».

Уң ягы: «27 гыйнварда [вафат]».

Сул ягы: «58 яшендә 1911 елда [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 84х31х13.

28. Габделкадыйр Габделмәннаф улына куелган кабер ташы, 1917 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) Йаңа Өҗемнең
3) Габделкадыйр Габделмәннаф
4) углы һиҗрәт
5) кылды 1917 сәнә
6) май 17 72 йәшенд».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кабер
2) ташымны
3) укуб
4) дога рәхим
5) кылсаңыз
6) ла».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Яңа Өҗемнән
3) Габделкадыйр Габделмәннаф
4) улы
5) 1917 елның
6) 17 маенда 72 яшендә [ахирәткә] күчте».

Арткы ягы:
1) «Кабер
2) ташымны
3) укып,
4) дога
5) укысагыз
6) иде».

Таш үлчәмнәре: 100х30х10.

29. Бибиәшрәф Хәйбулла кызына куелган кабер ташы, 1907 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) Йаңа Өҗемнең
3) Габделкадыйр җәмәгате
4) Бибиәшрәф Хәйбулла
5) кызы даре
6) фәнадин даре
7) бәкайә рихлә-
8) -т кылды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мәрхүм
2) 85 йәшендә
3) һиҗрәт
4) 1325 йылда
5) милади
6) 1907 йылда
7) ошбу кабер
8) ийәсен
9) рәхмәт
10) кылгай иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Яңа Өҗемнән
3) Габделкадыйр җәмәгате –
4) Бибиәшрәф Хәйбулла

[327] Бу гыйбарә хаталы язылган.

5) кызы – фани
6) дөньядан мәңгелек
7) дөньяга
8) күчте».

Арткы ягы:
1) «Мәрхүм
2) 85 яшендә
3) һиҗри
4) 1325 елда,
5) милади
6) 1907 елда [вафат].
7) Бу кабер
8) иясен [Аллаһ]
9) рәхим
10) кылса иде».

Таш үлчәмнәре: 98х31х12.

30. Хөббениса Исмәгыйль кызына куелган кабер ташы, 1900 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[328]:
1) «Кааләллаһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) кятиб Касыйм мулла
4) Йаңа Өҗем авылыйның Габделгаффар
5) җәмәгате Хөббениса Исмәгыйль
6) кызы 1900 нче йылда нуйәбр
7) 5 нче көне 75 йәшендә
8) җан тәслим әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган)[329]:
1) «Хөббениса
2) Исмәгыйль кызы
3) бу гамьдән улмады азад
4) нәби мөрсәл вәли зөһад
5) каму ни әйләде бер бад
6) һәм әгъйан әгъйардан».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Язучы: Касыйм мулла.
4) Яңа Өҗем авылыннан Габделгаффар
5) җәмәгате – Хөббениса Исмәгыйль
6) кызы – 1900 ел ноябренең
7) 5 нче көнендә 75 яшендә
8) җан тәслим кылды».

Арткы ягы:
1) «Хөббениса
2) Исмәгыйль кызы.
3) Бу гамьнән булмады азат
4) пәйгамбәр, илче, изге, аскетлар.
5) барысын бер җил нишләтте –
6) аксөякләрне оятлардан».

Таш үлчәмнәре: 90(112)х31х11.

31. Габделгаффар Байморат Ишмөхәммәд улының улына куелган кабер ташы, 1895 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһ
2) Йаңа Өҗем авылыйның Габделгаффар
3) атасы Байморат Ишмөхәммәд углы
4) 1895 нче сәнә ийүн 12 нче көне
5) 82 йәшендә даре фәнадан
6) даре бәкайә рихләт әйләде
7) Аллаһ Тәгалә рәхмәт
8) кылсун».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) кә хөкме Аллаһ будыр ошбу фәнада
3) кә кимсә калмайа бакый фәнада
4) мокаррәб кәр мәлик кәр мөрсәл ула
5) бәка булмайа иллә ахир ула
6) Габдеззакир Габделҗәмил углы
7) хәражаты илән бина кылынды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ хөкеме белән.
2) Яңа Өҗем авылыннан Габделгаффар
3) (атасы – Байморат Ишмөхәммәд углы)
4) 1895 ел июненең 12 нче көнендә
5) 82 яшендә фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Аллаһ Тәгалә рәхим
8) кылсын».

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Аллаһ хөкеме будыр бу фани дөньяда:
3) кемсә калмый мәңгегә бу фани дөньяда;
4) әгәр якын кеше, патша, пәйгамбәр булса да,
5) мәңге булмый, ахыры була.
6) Габдеззакир Габделҗәмил улы
7) акчасына куелды».

Таш үлчәмнәре: 90х33х13.

[328] Беренче ике юлы ике түгәрәк эченә язылган.
[329] Беренче ике юлы ике түгәрәк эченә язылган.

32. Хубҗамал Гыйззәтулла кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) руми 1910 нчы
3) йылда гыйнвар
4) 31 ндә шинбә
5) көн 50 йә-
6) -шендә Күәмнең
7) Гыйззәтулла кызы
8) Хубҗамал
9) Шәрәфеддин
10) зәүҗәсе дал-фәна-
11) -дин дал-бәкайә[330]
12) рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә илләәллаah Мүхәммәдүр-расүүлүллаah».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаh рәхмәте гарикъ кыйлсын амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh хөкеме белән.
2) Милади 1910
3) елның 31
4) гыйнварында шимбә
5) көн 50 я-
6) -шендә Күәмнән
7) Гыйззәтулла кызы
8) Хубҗамал –
9) Шәрәфеддин
10) хатыны – фани дөнья-
11) -дан мәңгелек дөньяга
12) күчте».

Уң ягы: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе».

Сул ягы: «Аллаh рәхмәткә күмсен, амин».

Таш үлчәмнәре: 101х32х11.

33. Маһишәрәф Шәрәфеддин кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә
2) руми 1910 нчы
3) йылда май 23 ндә
4) Йанга Өҗем карйәсинең
5) Шәрәфеддин кызы
6) Маһишәрәф 15 йәшендә
7) дарел-фәнадин да-
8) -рел-бәкайә рихләт
9) әйләде Аллаh
10) рәхмәте гарикъ кыйлсын
11) ләә иләәһә илләәллаah Мүхәммәд-
12) -үр-расүүлүллаah».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh хөкеме белән.
2) Милади 1910
3) елның 23 маенда
4) Яңа Өҗем авылыннан
5) Шәрәфеддин кызы
6) Маһишәрәф 15 яшендә
7) фани дөньядан мәң-
8) -гелек дөньяга
9) күчте. Аллаh
10) рәхмәткә күмсен.
11) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд –
12) Аллаһның илчесе».

Таш үлчәмнәре: 98(106)х32х11.

34. Гөлсара Шиһабеддин кызына һәм Маһибәрур Габделкадыйр кызына куелган кабер ташы, 1912 һәм 1917 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1912 сәнә нуйәбр
2) 17 ндә Гөлсара Шиһаб-
3) -еддин кызы 5 йәшендә
4) дәфен иделде шәфәгате
5) насыйб улсун[331]».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер Маһибәрур
2) Габделкадыйр кызы Шиһаб-
3) -еддин зәүҗәсенең мәркаде
4) 1917 сәнә агуст 21 ндә
5) маһе рамазан 22 ндә 30
6) йәшендә мәдфүн улды
7) рахимәһәллаahү Тәгааләә».

[330] «Дарел-фәнадин дарел-бәкайә» сүзләре булырга тиеш, «р» хәрефе ялгыш төшеп калган.

[331] Ислам дине өйрәтүенчә, сабый вакытында вафат булган балалар Кыямәт көнендә ата-аналары өчен Аллаh каршында шәфәгать кылачаклар, әлеге догада шул нәрсә күздә тотыла

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1912 елның 17
2) ноябрендә Гөлсара Шиһаб-
3) -еддин кызы 5 яшендә
4) җирләнде. Шәфәгате
5) насыйп булсын».

Арткы ягы:
1) «Бу Маһибәрур
2) Габделкадыйр кызы – Шиһаб-
3) -еддин хатынының кабере,
4) 1917 елның 12 агустында,
5) 22 рамазанында 30
6) яшендә җирләнде.
7) Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 86x28x14.

35. Гыйльмелбаян Габдеззакир кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[332]:
1) «Кааләллаһү Тәгаләә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
3) Йаңа Өҗем авылыйның Габдезза-
4) -кир кызы Гыйльмелбайан 15 йәшендә
5) даре фәнадан даре бәкайә
6) рихләт әйләде 1910 нчы сәнә
7) майның 18 нче көне».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Гыйльмелбайан
2) кани күстәр берен әй җан
3) кани вармы әүханлардан
4) рәсүл рәхмәте Рахман
5) аныйда әйләтде бу дардан
6) хуш бәхил бул газиз атам әл-фирак
7) догада бул газизә анам әл-фирак».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Яңа Өҗем авылыннан Габдезза-
4) -кир кызы Гыйльмелбаян 15 яшендә
5) 1910 ел маеның 18 нче көнендә
6) фани дөньядан мәңгелек
7) дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Гыйльмелбаян.
2) Кайда, күрсәт берәрсен, әй, җан,
3) кайда, бармы мәңге калган кеше?
4) Рәсүл [Мөхәммәд пәйгамбәр], Рахман [Аллаһ] рәхмәте
5) аны да алып китте бу дөньядан.
6) Хуш, бәхил бул, газиз атам, [бу –] аерылу.
7) догада бул, газиз анам, [бу –] аерылу».

Таш үлчәмнәре: 90(108)x31x11.

36. Билгесез кабер ташы, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
«...
1) әйләгәй иде».

Арткы ягы (уеп язылган):
«...
1) Аллаһүммәжгальһәә фиил-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
«...
1) кылса иде».

Арткы ягы:
«...
1) Аллаһым, аңа җәннәт бир».

Таш үлчәмнәре: 23x32x13.

37. Шәрәфи Мөхәммәдшәриф улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Җуван Шәрәфи
2) Мөхәммәдшәриф углы 1920 нче сәнә
3) май 8 нче көне 65 йәшендә
4) даре фәнадан даре бәкайә
5) рихләт әйләде
6) рахмәтүллаһи рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Юан Шәрәфи
2) Мөхәммәдшәриф улы 1920 ел
3) маеның 8 нче көнендә 65 яшендә
4) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
5) күчте.
6) Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 82x32x9.

[332] Беренче ике юлы ике түгәрәк эченә язылган.

38. Мәрьям Хәйрулла кызына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ
2) Мәрйәм Хәйрулла
3) кызы 1911 сәнә
4) 11 нҗе ийүндә
5) 18 йәшендә
6) мәдфүнә
7) рахмәтүллааһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ.
2) Мәрьям Хәйрулла
3) кызы 1911 елның
4) 11 июнендә
5) 18 яшендә
6) җирләнде.
7) Аллаһның рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 60х25х7.

39. Гаҗбикамал Габделваһһаб кызына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаһ
2) Гаҗбикамал бинте Га-
3) -бделваһһаб 1339 сәнәи
4) һиҗрииййә маһе рабигыль-ә-
5) -үвәлдә 90 йәшендә
6) мәдфүнә рахмәтүллааһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кятиб мулла
2) Габделмәннаф».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ.
2) Гаҗбикамал бинте Га-
3) -бделваһһаб һиҗри
4) 1339 елның рабигыль-әүвәл
5) аенда 90 яшендә
6) җирләнде. Аллаһның рәхмәте булсын».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Арткы ягы:
1) «Язучы: мулла
2) Габделмәннаф».

Таш үлчәмнәре: 59х29х9.

Ташка язу остасы Габделмәннаф бине Мөхәммәдзакир бине Ибраһимның 1915 елның 5 июнендә указ (указ номеры – №2088) алганлыгы мәгълүм.

40. Хәйрулла Хәлилулла улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Йаңа Өҗем авылыйның Хәйрулла
3) Хәлилулла углы 1915 нче сәнә
4) фиврал 14 нче көне 57
5) йәшендә даре фәнадан
6) даре бәкайә рихләт әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Бу мәрхүмнең мөнәҗәте
2) әгәрчә хезмәтем кимдүр Ходайа
3) өмидем рәхмәтеңдин Хода йа
4) гүйә падиса сән кәрәм кыйл
5) гөнаһым гәрчә таг булса гадәм кыйл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Яңа Өҗем авылыннан Хәйрулла
3) Хәлилулла улы 1915 ел
4) февраленең 14 нче көнендә 57
5) яшендә фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Бу мәрхүмнең мөнәҗәте:
2) Гәрчә хезмәтем кимдер Ходага,
3) өметем рәхмәтеңнән, йә, Хода,
4) гүя падишаһ син, юмартлык ит,
5) гөнаһым гәрчә тау булса, юк ит».

Таш үлчәмнәре: 73х36х12.

41. Mаһисорур Әүхәди кызына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә руух
2) Иске Өҗем Әүхәди
3) кызы Mаһисорур
4) Йанга Өҗем Хәкимулла
5) Сәйфулла углыйның
6) зәүҗәсе 33 дә
7) дарел-фәнадин дар-
8) -ел-бәкайә рихләт әйләде
9) 1913 = май 19 нда».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә руух
2) 1913 нче 19 нчы майда
3) Mаһисорур Хәкимулла
4) зәүҗәсе 33 йәшендә
5) дарел-бәкайә рихләт
6) әйләде Аллаһның
7) рәхмәтендә улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Иске Өҗемнән Әүхәди
3) кызы Mаһисорур –
4) Яңа Өҗемнән Хәкимулла
5) Сәйфулла улының
6) хатыны – 33 тә
7) 1913 елның 19 маенда
8) фани дөньядан мәңгелек
9) дөньяга күчте».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1913 [елның] 19 маенда
3) Mаһисорур Хәкимулла
4) хатыны 33 яшендә
5) мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһның
7) рәхмәтендә булсын».

Таш үлчәмнәре: 93(114)х34х10.

42. Бибигафифә Вәлиулла кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгааләә руух
2) Йанга Өҗем Вәлийулла
3) кызы Бибигафифә
4) Сәйфулла Сәфәргали
5) углыйның зәүҗәсе дарел-бәка-
6) -йә интикаль әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «1914 нче 16 нчы дикәбрдә».

Сул ягы (уеп язылган): «64 дә дәфен кыйлынды Илләһии әәмиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Углы Хәкимулла
2) бина кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Яңа Өҗемнән Вәлиулла
3) кызы Бибигафифә –
4) Сәйфулла Сәфәргали
5) улының хатыны – мәңгелек дөнья-
6) -га күчте».

Уң ягы: «1914 [елның] 16 декабрендә [вафат]».

Сул ягы: «64 тә җирләнде. Илаһым, амин».

Арткы ягы:
1) «Улы Хәкимулла
2) куйды».

Таш үлчәмнәре: 79(90)х31х15.

43. Бибифатиха Баязид кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әгуузү биллләһи мин-
2) -әш-шәйтааниp-раҗиим бисм-
3) -илләәһир-рахмәәнир-рахиим
4) ләә иләәһә иллләәллаah Мүхәммәдүр-расүүл-
5) -үллаah ләә иләәһә иллләәллаah Аллаah
6) Йанга Өҗем карйәсинең
7) Солтангали Габденнасыйр
8) мәрхүм углыйның зәүҗәсе
9) Бибифатиха Байазид кызы дар-
10) -ел-фәнадин дарел-бәкайә
11) рихлү[333] әйләде 65 йәшендә
12) 1905 нче йыл».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Ләгънәт кылынган шәйтаннан

[333] «Рихләт» сүзе булырга тиеш, хаталы язылган.

2) Аллаһка сыенам. Шәфкатьле,
3) Рәхимле Аллаһ исеме белән.
4) Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның
5) илчесе. Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк. Аллаһ
6) Яңга Өҗем авылыннан
7) Солтангали Габденнасыйр
8) мәрхүм улының хатыны –
9) Бибифатиха Баязид кызы – 65
10) яшендә 1905 елда
11) фани дөньядан мәңгелек
12) дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 102(114)х31х12.

44. Хәмидулла Әхмәдулла улына куелган кабер ташы, 1883 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Румиййә 1883 сәнә
2) април 9 нда Хәмидулла
3) Әхмәдулла углы 52
4) йәшендә дәфен иделде
5) Аллаһ Тәгалә рәхмәт итсүн».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Милади 1883 елның
2) 9 апрелендә Хәмидулла
3) Әхмәдулла улы 52
4) яшендә җирләнде.
5) Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 70(77)х31х9.

45. Гыйбадулла Хәмидулла улына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[334]:
1) «Дарел-фәнадин дарел-бәка-
2) -йә рихләт әйләде
3) Гыйбадулла Хәмид-
4) -улла углы».

Арткы ягы (уеп язылган)[335]:
1) «1912 нче йылда
2) синтәбр 5 ндә
3) 45 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) ««Гыйбадулла Хәмид-
2) -улла углы
3) фани дөньядан мәңгелек дөнья-
4) -га күчте».

Арткы ягы:
1) «1912 елның
2) 5 сентябрендә
3) 45 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 57х30х9.

46. Бибигафифә Мөхәммәдшәриф кызына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү руух[336]
2) Йаңа Өҗем авылының
3) Бибигафифә
4) Мөхәммәдшәриф
5) кызы Мөхәммәдшакир
6) зәүҗәсе дарe-
7) -л-фәнадин дарел-бәкайә ри-
8) -хләт кылды».

Уң ягы (уеп язылган): «1906 нчы йылда 70 йәшендә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем [Аллаһта].
2) Яңа Өҗем авылыннан
3) Бибигафифә
4) Мөхәммәдшәриф
5) кызы – Мөхәммәдшакир
6) хатыны – фани
7) дөньядан мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Уң ягы: «1906 елда 70 яшендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 90х32х14.

47. Шәрифҗан Камаледдин улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллааһү Тәгаалә
2) күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт

[334] Өске өлешендә ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.
[335] Аскы өлешендә бертөрле бизәк төшерелгән.
[336] Хаталы язылган.

3) Шәрифҗан Камаледдин
4) углы 1909 нчы йылда 20 нче
5) гыйнвар йәкшәнбә көн 11
6) йәшендә җан тәслим кыйлды
7) ата-анасына шәфәгатьче
8) кылсун амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте:
2) «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
3) Шәрифҗан Камаледдин
4) улы 1909 елның 20
5) гыйнварында якшәмбе көн 11
6) яшендә җан тәслим кылды.
7) [Аллаһ аны] ата-анасына шәфәгатьче
8) кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 90х31х9.

48. Бибигалимәбикә Камаледдин Мөхәммәдзакир улының кызына куелган кабер ташы, 1903 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Йаңа Өҗем авылыйның Камаледдин
3) Мөхәммәдзакир углының кызы
4) Галимәбикә дарел-фәнадан дар-
5) -ел-бәкайә рихләт итде 19
6) йәшендә рахмәтүллааһи рахмәтән вәәсигаһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Буны йазмакдан морадым догадыр бу көн бәнга йарин сәнгадыр
2) Бибигалимәбикә
3) Оры авылыйның Сәлахеддин
4) Әүхәди углыйның җәмәгате
5) 1903 нче сәнә 4 нче фибралда вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Яңа Өҗем авылыннан Камаледдин
3) Мөхәммәдзакир улының кызы
4) Галимәбикә 19 яшендә фани
5) дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллаһның киң рәхмәте булсын».

Арткы ягы:
1) «Моны язудан морадым догадыр, бу көн миңа, иртәгә сиңадыр.
2) Бибигалимәбикә
3) Оры авылыннан Сәлахеддин
4) Әүхәди улының җәмәгате
5) 1903 елның 4 февралендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 95х31х10.

Әлеге кабер иясенең ире Сәлахеддин бине Әүхәди бине Мәхмүд бине Габдрахман бине Кәлим бине Субай бине Бикбулат бине Килмәмәт бине Морзагилдә бине Мәмәт[337], 1920 елның 1 гыйнварында вафат булып, Арча районы Түбән Оры авылы зиратында җирләнгән. Без аның кабер ташын шунда таптык[338].

49. Таибә Камаледдин кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) 1905 нче йылда 5 нче
3) фибралда даре фәнадан
4) даре бәкайә рихләт әйләде
5) Таибә Камаледдин кызы
6) [25 йәшендә вафат]».

Уң ягы (уеп язылган)[339]:
1) «Душисәр тупраг җисеме
2) белүрсез үлисез рәсеме
3) ...
4) ...».

Сул ягы (уеп язылган)[340]:
1) «Дүнүб тайибә дөнйадан
2) эчүб васләт шәрабындан
3) нисар итде җайын Хакга
4) теләб дидарын...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) 1905 елның 5
3) февралендә .... Камаледдин
4) кызы фани дөньядан
5) мәңгелек дөньяга күчте
6) [25 яшендә вафат]».

Уң ягы:
1) «Душисәр туфрак җисеме

[337] Салихов Р.Р. Служилая Ура: рождение татарского капитализма / Р.Р. Салихов. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015. – С. 226–247.
[338] Гайнетдинов А.М. Арча районы эпиграфик истәлекләре / А.М. Гайнетдинов. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2016. – Б. 239.
[339] Диагональ буенча язылган.
[340] Диагональ буенча язылган.

2) белерсез, үлесез рәсеме
3) ...
4) ...».

Сул ягы:
1) «Матур дөньядан китеп,
2) эчеп кавышу шәрабеннән,
3) таратты урынын Хакка,
4) йөзен [күргән] теләп».

Таш үлчәмнәре: 83х35х11.

50. Камаледдин Габдеззакир улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Кааләллаһү Тәгааләә күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) би-исмиһи Тәгааләә
3) Йаңа Өҗем авылыйның Камаледдин
4) Габдеззакир углы һиҗриййә иләи
5) 1328 нче сәнә 22 нче шәгъбан йәкшәнбә көн
6) румиййә иләи 1910 нчы сәнә аугыст 15 ндә
7) 56 йәшендә вафат итде
8) Хода гарикы рәхмәт әйләгәй иде
9) ачык йөзле татлы сүзле адәм иде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Камаледдин.
2) әҗәл каблады саг восул
3) күрәдер ике күзең йул
4) сиңа сәндән йакындыр ул
5) кә тумышдыр бәйлә һәмзад
6) кә хөкме Аллаһ будыр ошбу фәнада
7) кә кимсә калмайа бакый фәнада».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне татыячак».
2) Аның [Аллаһ Тәгаләнең] исеме белән.
3) Яңа Өҗем авылыннан Камаледдин
4) Габдеззакир улы һиҗри белән
5) 1328 елның 22 шәгъбанында, якшәмбе көн,
6) милади белән 1910 елның 15 августында
7) 56 яшендә вафат булды.
8) Хода рәхмәткә күмсә иде.
9) Ачык йөзле, татлы сүзле адәм иде».

Арткы ягы:
1) «Камаледдин.
2) Әҗәл каплады исән-сау ирешүне,
3) күрәдер ике күзең юл,
4) сиңа синнән якындыр ул,
5) тугандыр кә шулай ризыкташ.
6) Аллаһ хөкеме будыр бу фани дөньяда:
7) кемсә калмый бу фани дөньяда».

Таш үлчәмнәре: 60х34х16.

51. Габделмәннаф Камаледдин улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) мәрхүм Габделмәннаф
3) Камаледдин углы
4) 1329 сәнәи һиҗриййә
5) 1911 сәнәи миладиййә
6) 22 нче ийүндә
7) 15 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Тәсаддыклә кыйлуңыз рухымы шад».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догада идеңез йад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Мәрхүм Габделмәннаф
3) Камаледдин улы
4) һиҗри 1329 елда,
5) милади 1911 елның
6) 22 июнендә
7) 15 яшендә вафат».

Уң ягы: «Сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, догада искә алыгыз».

Таш үлчәмнәре: 103х36х11.

52. Габдулла Камаледдин Закир улының улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[341]:
1) «Аллаһ
2) һәзәә мәркадүл-мәрхүүми
3) Габдулла бине Камал-
4) -еддин бине Закир бине Габд-
5) -елгалим дарел-фәнадан

[341] Беренче юлы түгәрәксыман бизәкле рәсем эченә язылган.

6) әл-бәкайә рихләт әйләде
7) җәгаләллаahү мәркадә
8) раудатән мин рийәәдыйль-җәннәh».

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән фии кабрии мүтәфәккиран би-әмрии күнтү мислүкә әмсин фә-тәсыыйру гадән мислии».

Сул ягы (уеп язылган): «Ләү кәәнәтид-дүнйәә түдүүмү ли-вәәхидин лә-кәәнә расүүлүллаahи фии[hәә] мүхълидәә».

Арткы ягы (уеп язылган)[342]:
1) «Мөхәммәд
2) миладиййә 1913 нҗ
3) йылда 15 нче үктәбрдә
4) hиҗриййә илә 1332 нҗе
5) йылда 29 нҗы мөхәррәмдә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh.
2) Бу – мәрхүм
3) Габдулла бине Камал-
4) -еддин бине Закир бине Габд-
5) -елгалим кабере, фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте.
7) Аллаh каберен җәннәт
8) бакчаларыннан бер бакча итсен».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Әгәр дә дөнья берәр зат өчен дәвам итсә, Аллаhның илчесе [Мөхәммәд пәйгамбәр] анда мәңге булыр иде».

Арткы ягы:
1) «Мөхәммәд.
2) Милади 1913
3) елның 15 октябрендә,
4) hиҗри белән 1332
5) елның 29 мөхәррәмендә [вафат]».

Таш үлчәмнәре: 73х32х11.

53. Сибгатулла Нигъмәтулла улына куелган кабер ташы, 1913 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) Йаңа Өҗем авылыйның
3) Сибгатулла бине Нигъмәтулла
4) 67 йәшендә даре фәна-
5) -дан даре бәкайә рихләт әйләде
6) 1913 нче сәнә ийүн 7 нче көне».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаhта.
2) Яңа Өҗем авылыннан
3) Сибгатулла бине Нигъмәтулла
4) 67 яшендә 1913 ел
5) июненең 7 нче көнендә фани дөнья-
6) -дан мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 116х31х13.

54. Габделгазизгә куелган кабер ташы, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Аллаh
2) hәзиhи түрбәтүл-мәр-
3) -хүүмил-мәгъфүүрил-мү-
4) хътәәҗи иләә Раббиh»[343].

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-Гафүүри
2) Габделгазиз әфәнде
3) рухына фатиха»[344].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаh.
2) Бу – рәхим
3) кылынган, гафу ителгән,
4) Раббысына мохтаҗ».

Алгы ягы:
1) «Гафу итүче [Раббысына мохтаҗ]
2) Габделгазиз әфәнде [төрбәсе].
3) Рухына «Фатиха» сүрәсе укы.

Таш үлчәмнәре: 89х31х10.

55. Шәмсежамал Мөхәммәҗән кызына куелган кабер ташы, 1919 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү шәйъин
2) hәәликүн илләә вәҗhәh
3) Шәмсежамал

[342] Беренче юлы түгәрәксыман бизәкле рәсем эченә язылган.

[343] Дәвамы арткы ягында.

[344] Башы алгы ягында.

4) Мөхәммәджан кызы
5) 1919 сәнә 3 нче фибрал
6) вафат рахмәтүллаahи
7) галәйһәә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аның [Аллаһның] Йөзеннән башка
2) һәрбер нәрсә һәлак булучы.
3) Шәмсежамал
4) Мөхәммәджан кызы
5) 1919 елның 3 февралендә
6) вафат. Аңа Аллаһның
7) рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 44х28х12.

56. Нигъмәтҗан Мөхәммәджан улына куелган кабер ташы, 1925 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү шәйъин
2) һәәликүн илләә вәҗһәһ
3) Нигъмәтҗан Мөхәммәд-
4) -жан углы1925 сәнә
5) 2 нче майда 80
6) [йәшендә вафат]».

Арткы ягы (уеп язылган)[345]:
1) «Җәгаләллаahү кабраһү рау-
2) -датән мин рийәәдыйль-жәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аның [Аллаһның] Йөзеннән башка
2) һәрбер нәрсә һәлак булучы.
3) Нигъмәтҗан Мөхәммәд-
4) -жан улы1925 елның
5) 2 маенда 80
6) [яшендә вафат]».

Арткы ягы:
1) «Аллаһ аның каберен жәннәт
2) бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 66х30х9.

57. Мөхәммәдвафа Мөхәммәдгариф улына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) Йаңа Өҗем авылыйның
3) Мөхәммәдвафа Мөхәммәдгариф
4) углы 1905 нче сәнә
5) ийүл 20 сендә 40
6) йәшендә даре фәнадан
7) даре бәкайә күчде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Яңа Өҗем авылыннан
3) Мөхәммәдвафа Мөхәммәдгариф
4) улы 1905 елның
5) 20 июлендә 40
6) яшендә фани дөньядан
7) мәңгелек дөньяга күчте».

Таш үлчәмнәре: 43х27х10.

58. Әшрәфниса Гарифҗан Мөхәммәдвәли улының хатынына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт
2) Йаңа Өҗем авылыйның Гарифҗан
3) Мөхәммәдвәли углыйның хәләле Әшрәф-
4) -енниса даре фәнадан даре
5) бәкайә рихләт әйләде рахмәтүллаahи
6) рахмәтән вәәсигаһ 190[346] нче йылда».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр жан иясе үлемне татыячак.
2) Яңа Өҗем авылыннан Гарифҗан
3) Мөхәммәдвәли улының хәләле Әшрәф-
4) -ниса 190 елда фани дөньядан
5) мәңгелек дөньяга күчте Аллаһның
6) киң рәхмәте булсын».

Таш үлчәмнәре: 101(116)х31х13.

59. Гарифҗан мулла Мөхәммәдвәли улына куелган кабер ташы, 1872 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү нәфсиң зәәъикатүл-мәүүт

[345] Диагональ буенча язылган.

[346] Биредә кайчан вафат булуы күрсәтелмәгән. Таш, әле иясе вафат булганчы ук, әзерләнгән һәм, ул үлгәч, шул буш калдырылган урынга кайсы елда үлүе дә язылырга тиеш булган, ләкин ниндидер сәбәпләр аркасында бу эш башкарылмыйча калган, күрәсең.

2) Йаңа Өҗем авылыйның Гарифҗан
3) мулла Мөхәммәдвәли углы даре фәнадан
4) даре бәкайә рихләт әйләде
5) 1872 нче йылда май 6 нчы
6) көне 40 йәшендә Хода гарикы
7) рәхмәт әйләб җәннәт әһелендән
8) әйләгәй иде амин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.
2) Яңа Өҗем авылыннан Гарифҗан
3) мулла Мөхәммәдвәли улы
4) 1872 ел маеның 6 нчы
5) көнендә 40 яшендә фани дөньядан
6) мәңгелек дөньяга күчте. Хода, рәхмәткә
7) күмеп, җәннәт әһеленнән
8) итсә иде, амин».

Таш үлчәмнәре: 86x31x10.

60. Бибифатыйма Сафиулла кызына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Йаңа Өҗем кар-
4) -йәсинең
5) Бибифатыйма Са-
6) -фийулла кызы
7) мәдфүн 1915
8) йыл беренчә
9) фивралда Алла
10) рәхмәт әйлә-
11) -сүн».

Уң ягы (уеп язылган): «-ның җәүҗәсе 62 йәшендә»[347].

Сул ягы (уеп язылган): «Габделҗаббар Габдессәлам углы-»[348].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Бу кабер иясе
3) Яңа Өҗем авы-
4) -лыннан
5) Бибифатыйма Са-
6) -фиулла кызы
7) 1915
8) елның беренче
9) февралендә җирләнде. Алла
10) рәхим кыл-
11) -сын».

Уң ягы: «-ның хатыны, 62 яшендә [вафат]».

Сул ягы: «Габделҗаббар Габдессәлам улы-».

Таш үлчәмнәре: 92x32x10.

61. Габделҗаббар Габдессәлам улына куелган кабер ташы, 1882 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаалә
2) руми 1882
3) нче сәнә маһе шәри-
4) -фнең 19 нда
5) Өҗем авылының
6) Габделҗаббар Габд-
7) -ессәлам углы
8) даре фәнадан даре
9) бәкайә рихләт кыйлды
10) 65 йәшендә».

Уң ягы (уеп язылган): «Кәәтибүл-хурууфи Габдулла Габделҗаббар углы».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аллаһ Тәгалә хөкеме белән.
2) Милади 1882
3) елның 19
4) рамазанында
5) Өҗем авылыннан
6) Габделҗаббар Габд-
7) -ессәлам улы
8) 65 яшендә
9) фани дөньядан мәңгелек
10) дөньяга күчте».

Уң ягы: «Хәрефләрне язучы: Габдулла Габделҗаббар улы».

Таш үлчәмнәре: 84x30x9.

62. Разия Гыйнәятулла кызына куелган кабер ташы, 1933 ел.

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйһәә фәән
2) Разийа бинте
3) Гыйнәйәтулла».

[347] Башы сул ягында.
[348] Дәвамы уң ягында.

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «1933 сәнә
2) 16 нчы ийүл
3) 17 йәшендә
4) даре җәфадан
5) күчде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани.
2) Разия бинте
3) Гыйнәятулла».

Арткы ягы:
1) «1933 елның
2) 16 июлендә
3) 17 яшендә
4) җәфа йортыннан
5) күчте».

Таш үлчәмнәре: 99x31x11.

63. Фазыйлә Җамаледдин кызына куелган кабер ташы, 1929 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган)[349]:
1) «Фазыйлә
2) Җамаледдин
3) кызы 1929
4) нчы йылда гыйнвар
5) 16 нче көне 14
6) көнлек бала
7) җан тәслим кылды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Фазыйлә
2) Җамаледдин
3) кызы 1929
4) ел гыйнварының
5) 16 нчы көнендә 14
6) көнлек бала [вакытта]
7) җан тәслим кылды».

Таш үлчәмнәре: 42(52)x26x8.

64. Галиулла Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1929 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Галийулла
2) Исмәгыйль углы
3) 1929 нҗы йылда ийүн[350]
4) фиврал 8 ндә 63
5) йәшендә вафат
6) тугры адәм иде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Галиулла
2) Исмәгыйль улы
3) 1929 елның
4) 8 февралендә 63
5) яшендә вафат.
6) Тугры адәм иде».

Таш үлчәмнәре: 93x31x11.

Яңа Шашы авылы зираты

1. Мулла Габделвәли мулла Сәмигулла улына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Мулла Габделвәли
2) бине мулла Сәмигулла әл-Кенәри
3) дамелла Сибгатулла хәзрәтдә
4) гыйлем тәхсыйль кыйлуб Йаңа Шашы
5) карйәсендә 42 сәнә биля тәхәллеф
6) имамәтчилек кыйлуб ахирәткә
7) интикаль әйләде рахмәтүллаahи
8) рахмәтән вәәсигah әәмиин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) тарих hиҗриййә илән 1327 дә
3) пәнҗешәнбә көн 27 нче шәүвәл
4) миладиййә илән 1909 нчы сәнә
5) үктәбр 29 нда 72 йәшендә
6) даре фәнадан даре бәкайә
7) рихләт әйләде».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мулла Габделвәли
2) бине мулла Сәмигулла Кенәри,
3) дамелла Сибгатулла хәзрәттә
4) гыйлем алып, Яңа Шашы
5) авылында 42 ел бер дә калдырмыйча
6) имамлык итеп, ахирәткә
7) күчте. Аңа Аллаһның киң
8) рәхмәте булсын, амин».

[349] Ай һәм йолдыз рәсеме төшерелгән.

[350] Бу сүз ялгыш язылган, күрәсең.

Арткы ягы:
1) «Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Һиҗри белән 1327 [елның]
3) 27 шәүвәлендә пәнҗешәмбе көн,
4) милади белән 1909 елның
5) 29 октябрендә 72 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте».

Таш үлчәмнәре: 103х35х11.

Әлеге кабер иясе, 1879 елның 18 июнендә указ (указ номеры – №4911) алып, вафатына хәтле Яңа Шашы авылында мулла вазыйфасын башкарган.

Төсле ябыштырмадагы фотосын кара: 12 б. №106.

2. Әүхәди Әхсәни улына куелган кабер ташы, 1911 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү шәйъин һәәликүн илләә вәҗһәһ
2) Әүхәди Әхсәни
3) углы тарих миладиййә
4) илә 1911 нҗе сәнә 15 нҗе
5) аугыстда һиҗриййә илә
6) 1329 нҗы сәнә 4 нҗе
7) рамазанда 60 йәшендә
8) даре бәкайә рихләт кылды
9) рахимәһүллаahү Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Кабернең хәлене сагышлайасыз безә Коръән укыб багышлайасыз».

Сул ягы (уеп язылган): «Кәрәм әйләб догалә идеңез йад тәсаддыклә идеңез рухымы шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аның [Аллаһның] Йөзеннән башка һәрбер нәрсә һәлак булучы.
2) Әүхәди Әхсәни
3) улы милади
4) белән 1911 елның 15
5) августында, һиҗри белән
6) 1329 елның 4
7) рамазанында 60 яшендә
8) мәңгелек дөньяга күчте.
9) Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Кабернең хәленә сагышланыгыз, безгә Коръән укып багышлагыз».

Сул ягы: «Юмартлык кылып, дога белән искә алыгыз, сәдака бирү белән рухымны шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 125х36х15.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Әүхәди бине Әхсәни бине Салих бине Сәгыйдь бине Биккол бине Ипкә бине Биктә.

3. Бибигайшә Сиражеддин Ишморат улының кызына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Йәә зәәл-җәләәли вәл-икраам
2) Бибигайшә Сираҗ-
3) -еддин Ишморат
4) углыйның кызы Әүхәди
5) Әхсәни углыйның
6) хәлиләсе миладиййә 1914 нҗе
7) сәнә 27 нҗе үктәбрдә һиҗриййә
8) 1332 нҗе сәнә 21 нҗе зилхиҗҗә
9) 56 йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Мазарстанларә гяһ гяһ киләсез кә бездән гыйбрәт алубән кидәсез».

Сул ягы (уеп язылган): «Рәхмәтеңлә кич гөнаһын әй Хода кыйл шәфәгать йә Мөхәммәд Мостафа».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Йә, Олуглык һәм хөрмәт иясе [булган Аллаһ].
2) Бибигайшә Сираҗ-
3) -еддин Ишморат
4) улының кызы – Әүхәди
5) Әхсәни улының
6) сөеклесе – милади 1914
7) елның 27 октябрендә, һиҗри
8) 1332 елның 21 зөлхиҗҗәсендә
9) 56 яшендә вафат».

Уң ягы: «Зиратларга вакыт-вакыт киләсез, бездән гыйбрәт алып китәсез».

Сул ягы: «Рәхмәтең белән кичер гөнаһын, әй, Хода; шәфәгать кыл, йә, Мөхәммәд Мостафа».

Таш үлчәмнәре: 115х36х17.

4. Мөкәррәмә Хәкимҗан кызына куелган кабер ташы, 1924 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «1924 сәнә нуйәбр
2) 25 нче көне 2 йәшендә
3) Мөкәррәмә Хәкимҗан кызы
4) тәслиме рух әйләде
5) шәфәгатьче булсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «1924 ел ноябренең
2) 25 нче көнендә 2 яшендә
3) Мөкәррәмә Хәкимҗан кызы
4) рух [җан] тәслим кылды.
5) Шәфәгатьче булсын».

Таш үлчәмнәре: 63х25х8.

5. Габделлатыйф Нәзир улына куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-кабру гыйбрah
2) саахибүл-мәркади Габделлатыйф
3) бине Нәзир һиҗри 1239 сәнә
4) 21 нче җөмадиәл-әүвәлдә
5) йәкшәнбә көн 71 йәшендә
6) даре фәнадан даре бәкайә
7) рихләт әйләде».

Уң ягы (уеп язылган): «Әй туганлар әй йакынлар безләре искә алыб»[351].

Сул ягы (уеп язылган): «Рухымы шад итсәңез лә каберемә бер тезләнеб»[352].

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Милади
2) 1920 сәнә 30 нчы
3) гыйнварда вафат
4) рахимәһүллаahү рахмәтән
5) вәәсигah».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер – гыйбрәт.
2) Кабер иясе Габделлатыйф
3) бине Нәзир һиҗри 1239 елның
4) 21 җөмадиәл-әүвәлендә
5) якшәмбе көн 71 яшендә
6) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
7) күчте».

Уң ягы: «Әй, туганнар, әй, якыннар, безне искә алып».

Сул ягы: «Рухымны шатландырсагыз ла, каберемә бер тезләнеп».

Алгы ягы:
1) «Милади
2) 1920 елның 30
3) гыйнварында вафат.
4) Аллаh аны киң рәхмәте белән
5) рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 107(125)х30х10.

6. Фәйзрахман Хәкимҗан улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Фәйзрахман
2) Хәкимҗан углы
3) 1915 нче сәнә май 24 нче
4) көне даре фәнадан
5) даре бәкайә рихләт
6) әйләде 6 айлык».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗрииййә 1333 нҗе сәнә
2) рәҗәб 23 нҗе көне вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Фәйзрахман
2) Хәкимҗан улы
3) 1915 ел маеның 24 нче
4) көнендә фани дөньядан
5) мәңгелек дөньяга
6) күчте, 6 айлык [иде]».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри 1333 ел
2) рәҗәбенең 23 нче көнендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 85х30х9.

[351] Дәвамы сул ягында.
[352] Башы уң ягында.

7. Хәдичәбикә Хәкимҗан кызына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Хәдичәбикә
2) Хәкимҗан кызы
3) 1918 нче сәнә ийүл 19 нчы
4) көне ике йәш йарымда
5) җан тәслим әйләде».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗрииййә илә
2) 1336 нчы сәнә 22 нче
3) шәүвәлдә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хәдичәбикә
2) Хәкимҗан кызы
3) 1918 ел июленең 19 нчы
4) көнендә ике яшь ярымда
5) җан тәслим кылды».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән
2) 1336 елның 22
3) шәүвәлендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 72x26x8.

8. Гыйльмебаян Габделгалим кызына куелган кабер ташы, 1912 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәh
2) тарих миладиййә илә 1912 нче
3) ийүл 16 нчы көне 57 йәшендә
4) Гыйльмебайан Габделгалим кызы
5) даре фәнадан даре бәкайә
6) рихләт әйләде Аллah Тәгалә
7) рәхмәт әйләб җәннәт илә мөшәррәф
8) әйләгәй иде амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Һиҗрииййә илә 1330 нчы сәнә
2) 15 нче шәгъбан дүшәнбә
3) көн җан тәслим әйләде
4) Габделлатыйф Нәзируф
5) җәмәгате Гыйльмебайан».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллahта.
2) Милади белән 1912 [ел]
3) июленең 16 нчы көнендә 57 яшендә
4) Гыйльмебаян Габделгалим кызы
5) фани дөньядан мәңгелек дөньяга
6) күчте. Аллah Тәгалә,
7) рәхим кылып, җәннәт белән
8) хөрмәтләсә иде амин».

Арткы ягы:
1) «Һиҗри белән 1330 елның
2) 15 шәгъбанында дүшәмбе
3) көн җан тәслим кылды.
4) Габделлатыйф Нәзиров
5) җәмәгате Гыйльмебаян».

Таш үлчәмнәре: 108(120)x33x13.

9. Бибимәфтуха Габделгаффар кызына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү мән галәйhәә фәән
2) руми 1910 сәнә фибрал
3) 15 ндә Габделгаффар
4) кызы Бибимәфтуха
5) Иске Өҗемнең Мөхәммәди
6) җәмәгате 75 йәшендә
7) дарел-бәкайә рихләт
8) кыйлды».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Кәрәм әйләб
2) догада идегез йад
3) тәсаддыклә кыйлыңыз рухымы
4) шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Анда [җир йөзендә] булучы hәркем, hәрнәрсә фани.
2) Милади 1910 елның 15
3) февралендә Габделгаффар
4) кызы Бибимәфтуха –
5) Иске Өҗемнән Мөхәммәди
6) җәмәгате – 75 яшендә
7) мәңгелек дөньяга
8) күчте».

Арткы ягы:
1) «Юмартлык кылып,
2) догада искә алыгыз.
3) Сәдака бирү белән рухымны
4) шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 90x33x11.

10. Галәведдин Хисамеддин улына куелган кабер ташы, 1914 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Галәәддин Хисам-
4) -еддин углы 58
5) йәшендә 1914 нче
6) 8 нче фибралда вафат
7) булды 9 нчы фибралда
8) дәфен кыйлынды
9) Аллаһ рәхмәтенә гарикъ улсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер иясе
3) Галәведдин Хисам-
4) -еддин улы 58
5) яшендә 1914 [елның]
6) 8 февралендә вафат
7) булды, 9 февралендә
8) җирләнде.
9) Аллаһ рәхмәтенә күмелсен».

Таш үлчәмнәре: 91x31x11.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Галәведдин бине Хисамеддин бине Хәсән бине Сәгыйдь бине Биккол бине Ипкә бине Биктә.

11. Мөхәммәдша Габделгаффар улына куелган кабер ташы, 1922 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Мөхәммәд-
2) -шаһ
3) Габделгаффар
4) углы вафаты
5) 1922 нче җыл
6) ийүн 10 нында
7) 81 йәшендә».

Арткы ягы (уеп язылган): «Ләә иләәһә илләәллааһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мөхәммәд-
2) -ша
3) Габделгаффар
4) улы, вафаты
5) 1922 елның
6) 10 июнендә
7) 81 яшендә».

Арткы ягы: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк».

Таш үлчәмнәре: 69(81)x27x9.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Мөхәммәдша бине Габделгаффар бине Салих бине Сәгыйдь бине Биккол бине Ипкә бине Биктә.

12. Мәхубҗамал Мөхәммәдсиддыйк кызына һәм Шаһиәхмәд Сабит улына куелган кабер ташы, 1888 һәм 1905 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер сахибәсе
3) Мәхубҗамал Мөхәммәдсиддыйк
4) кызы Шаһиәхмәд
5) Сабит углының зәүҗәсе
6) 1888 нче йылда
7) 21 нче гыйнварда
8) 50 йәшендә вафат
9) улды рахмәтүллааһи Тәгаалә
10) рахмәтән вәәсигаһ әәмиин».

Уң ягы (уеп язылган): «Әл-кабру раудатүн мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Әл-кабру әүвәлү мәнзилин мин мәнәәзилил-әәхыйраһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү би-әмрилләәһ
2) бу кабер сахибе
3) Шаһиәхмәд Сабит
4) углыңдур
5) 1905 нче йылда
6) 25 нче гыйнварда
7) 68 йәшендә вафат
8) улды рахмәтүллааһи
9) Тәгаалә рахмәтән вәәсигаһ
10) әәмиин».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер иясе
3) Мәхубҗамал Мөхәммәдсиддыйк
4) кызы – Шаһиәхмәд
5) Сабит улының хатыны –
6) 1888 елның

7) 21 гыйнварында
8) 50 яшендә вафат
9) булды. Аңа Аллаһ Тәгаләнең
10) киң рәхмәте булсын, амин».

Уң ягы: «Кабер – җәннәт бакчаларыннан бер бакча».

Сул ягы: «Кабер – ахирәт йортларының иң әүвәлгесе».

Арткы ягы:
1) «Хөкем Аллаһ әмере белән.
2) Бу кабер иясе –
3) Шаһиәхмәд Сабит
4) улы.
5) 1905 елның
6) 25 гыйнварында
7) 68 яшендә вафат
8) булды. Аңа Аллаһ
9) Тәгаләнең киң рәхмәте булсын,
10) амин».

Таш үлчәмнәре: 104x33x10.

13. Галиәсгар Габдессәлам улына куелган кабер ташы, 1906 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Күллү шәйьин һәәликүн илләә вәҗһәһ
2) Галиәсгар Габд-
3) -ессәлам углы
4) миладиййә илә 1906 нҗ
5) йыл 25 нҗе мартда
6) һиҗриййә илә 1324 нҗе сәнә
7) 16 нҗы сәфәрдә 75
8) йәшендә вафат».

Уң ягы (уеп язылган): «Әд-дүнйәә сәәгатүн фәҗгальһәә таагаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Илаһи мәгъфирәт кыйл Раббы йәздан би-хәккый гаршин әгъзамин нуури куръәән».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Аның [Аллаһның] йөзеннән башка һәрбер нәрсә һәлак булучы.
2) Галиәсгар Габд-
3) -ессәлам улы
4) милади белән 1906
5) елның 25 мартында,
6) һиҗри белән 1324 елның
7) 16 сәфәрендә 75
8) яшендә вафат».

Уң ягы: «Дөнья бер сәгатьлек, аны [Аллаһка] итагать белән үткәр».

Сул ягы: «Илаһым, гафу ит, Раббым Аллаһ, бөек гареш, Коръән нурының хакы белән».

Таш үлчәмнәре: 98(105)x29x10.

14. Хәдичәбикә Бәйрәмгали кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ руми 1905 сәнә
2) март 5 дә һиҗри 1323 сәнә
3) Хәдичәбикә Бәйрәмгали
4) кызы Хәйреддин Зәйнулла
5) углы зәүҗәсе 23
6) йәшдә даре бәкайә рихләт»[353].

Сул ягы (уеп язылган): «Кылды тайййибәллаһү сәраһәә әәмиин»[354].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта. Милади 1905 елның
2) 5 мартында, һиҗри 1323 елда
3) Хәдичәбикә Бәйрәмгали
4) кызы – Хәйреддин Зәйнулла
5) улының хатыны – 23
6) яшьтә мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «Күчте. Аллаһ аның туфрагын яхшы [җиңел] кылсын, амин».

Таш үлчәмнәре: 85x31x13.

15. Бибизөһрә Корбангали кызына куелган кабер ташы, 1909 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Би-хүкмилләәһи Тәгаләә
2) саахибәтү һәзәәл-кабри мәрхүүмәтү
3) Бибизөһрә Корбангали
4) кызы Бәйрәмгали Нәзир
5) углыйның әһлийәсе
6) 1909 нчы сәнәи миладиййә 19
7) гыйнварда 56 йәшдә
8) мәдфүнә нәүвәраллаһү кабраһәә әәмиин».

[353] Дәвамы сул ягында.
[354] Башы алгы ягында.

Уң ягы (уеп язылган): «Йәә әхыый күн нәәдимән каблəл-әҗəл ән-нәдәәмәтү лəə түфиидү бәгъдəл-әҗəл».

